
# КАЗАН УТЛАРЫ

1
ЯНВАРЬ
1982



М. Рәхимов.　　　　ХӨСӘЕН ЯМАШЕВ.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

1

ЯНВАРЬ
1982

## *Бу санда*

СССР ТӨЗЕЛҮГӘ 60 ЕЛ

**И. ЮЗЕЕВ.** Ленин дәшә безгә. Шигырь . . . 3
**А. РАСИХ.** Ямашев. Роман . . . . . . . . . 4
**Н. АРСЛАНОВ.** Дүрт атым. Шигырьләр . . . . 83
**А. ХӘСӘНОВ.** Авыр миссия. Хикәя . . . . . . 90
**Г. ЛАТЫЙП.** Тормыш һәм гаделлек. Шигырьләр . 100

ДУСЛАР ЖЫРЫ

**Р. САФИН.** Җирем моңы. Шигырьләр . . . . . 105

ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

**Ә. ГАФФАР.** Сиксән беренче ел икмәге . . . . 108

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Укучылар белән тынычланмаска! Анкетага җаваплар . . . . . . . . . . . 118
**М. ХӘСӘНОВ.** Әйдә халыкка хезмәткә!.. . . . 127
**Х. ХӘЙРИ.** Яңа дулкын . . . . . . . . . . 138

Х. ЯМАШЕВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

**Х. ХӘСӘНОВ.** Сүнмәс учак . . . . . . . . . 142

ИСТӘЛЕКЛӘР

**М. МУЛЛАНУРОВ.** Һәйкәл янында уйланулар . . 147

Г. ЛАТЫЙПКА — 70 ЯШЬ

**Ш. ӘХМӘДУЛЛИН.** Юлың уң булсын, шагыйрь! . 153

ТӨРЛЕСЕННӘН

**Ә. ЕНИКИ.** Очрашу һәм аерылышу . . . . . . 158

СӘНГАТЬ

**Ф. ИЛЬСКАЯ.** Истәлекләрем . . . . . . . . . 166
**В. ГОРШКОВ.** Сабантуйлардан — дөнья сәхнәсенә 177
**Д. ГЫЙМРАНОВА.** Каргаймас нкат . . . . . . . 183

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Тауларда‌гы кайтаваз** . . . . . . . . . . . . 187

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 190

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

**Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ** *(баш редактор урынбасары)*, **РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** *(җаваплы секретарь)*, **СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ**

---

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

---

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63; сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 1/X-1981 ел. Басарга кул куелды 17/XII-1981 ел. ПФ 09063. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65044 экз. Заказ Д-355. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1982 ел.

# СССРның төзелүенә 60 ел

Илдар Юзеев

## Ленин дәшә безгә

Киләчәккә ашыгып барган чакта
Каләмдәшләр туктап уйга калган...
«Тукай варислары бармы?» диеп,
Ленин дәшә безгә узганнардан.

Кеше күңеленә керәлдекме,
Җырларыбыз, дөрес, күккә ашкан...
Турылык һәм Чынлык бармы җырда? —
Ленин сорый бүген алгы сафтан.

Киләчәккә барыр җырлар бармы,
Бик күп матур җырлар көйләсәк тә? —
Борчылулар, сөенечләр белән
Ленин дәшәр безгә Киләчәктән.

Тукайлы да, Җәлилле дә халык
Каһарманлык таләп итә бездән...
Узган, Бүген һәм Киләчәк бергә
Ленин булып җавап көтә бездән!

Атилла Расих

# ЯМАШЕВ

РОМАН

*(Өченче китап)*

## I

Уникенче январь көнне төнге унберне сукканда Хөсәеннәрнең квартира ишеген шакыдылар. Хөсәен йокыга талган иде инде. Хатынының дәшүенә ул сискәнеп уянды, шундук лампа кабызып, киемнәренә үрелде. Хөсәен шомланып калган Хәдичәгә, тыныч бул, дигәнне аңлатып керфек сирпеде дә, пиджаген иңенә салып, йокы бүлмәсеннән чыгып китте.

Бераздан ул үзе белән Галимҗан Сәйфетдиновны ияртеп керде.

— Төнге вояж өчен гафу үтенәм,— диде Галимҗан алгы бүлмәдән узмыйча гына. Тәгаен ул Хәдичәгә әйтә иде.— Мин беразга гына Хөсәенне алып китәргә тиеш.

— Нәрсә булды инде тагын, ходаем,— диде Хәдичә, ризасызлык белдереп. Ул яткан урыныннан торырга итенде.

— Борчылырга һич урын юк, Хәдичәкәй. Ят син, озакламый кайтырмын.

— Кая барасың соң, ераккамы? Һич булмаса шунысын әйт.

— Кайткач, кайткач. Тик син борчылма гына.

Ул шулай диде дә, йөткеренгәләп, пиджагенең кайтарылып калган якасын рәтли-рәтли, Галимҗан янына, күрше бүлмәгә чыгып китте.

Хөсәеннәр яшәгән агач өйдән чыккач алар биек таудан аска төштеләр дә, чатлыкта тукталып, тәмәке кабыздылар. Хөсәен папиросын комсызланып бер суырганнан соң:

— Я, хәбәр ит,— диде.

— Хәбәр шуннан гыйбарәт,— диде Галимҗан, — «Әткәй» безнең ярдәмгә мохтаҗ. Без хәзер үк Ефим Панкратьевич белән очрашырга тиеш. Бүген кичкырын гына миңа әйттеләр. Синең дә булуыңны үтенгән ул.

Галимҗан тәфсилләп хәл-әхвәлне аңлата башлады. Сүз — Ефим Панкратьевич Табейкинның улы Василийны төрмәдән коткару турында барды. Хөсәенгә күп нәрсә билгеле иде инде. Шушы көннәрдә очрашып, бу турыда бер сөйләшү кирәклеге дә, әлеге очрашу вакытын да Галим-

җан анықларга тиешлеге дә мәгълүм иде. Алафузов заводы эшчеләренең башлыгы «Әткәй» кушаматлы Ефим аганың ике улы да — Василий һәм Иван — этиләре юлыннан китте, үзләрен революция эшенә багышладылар. Табейкинның олы улы Василий хәзерге вакытта Томский шәһәрендәге төрмәдә утыра иде. Ул аннан революционерлар ярдәме белән кача. Ләкин бу эш, никадәр нык әзерләнсә дә, уңышлы булып чыкмый. Василий тагы кулга эләгә һәм аңа котылу өчен бердәнбер юл — үзенең кем икәнлеген яшерү кала. Ул үзен бүтән кеше итеп таныта, барлык җәза-кыйнауларга түзә. Ниһаять, аның чынлап та Табейкин булуын җасуслар[1] аркылы белеп, Василийның кемлеген суд каршында исбат итү өчен, егетне Казанга алып кайталар. Төрмәгә эти-әнисен дә китертәләр. Кызганычка каршы, берни дә белмәгән ата-ана, Василий белән күрешергә ташланалар, шаһитлар каршында Василийның бөтен планнары җимерелә. Әлбәттә, бераздан хәлне Ефим аңлап ала, ләкин эш инде узган була. Шулай да карт революционер югалып калмый, җаен табып, улына төрмәдән котылу мөмкинлеген әйтеп өлгерә. Хәзер, Галимҗанның сөйләвенә караганда, егетне төрмәдән качыру өчен практик эшкә күчү вакыты җиткән иде. Бу бик ашыгыч башкарылырга тиеш, чөнки Василийны, бүген булмаса иртәгә, яңадан конвой астында Томский төрмәсенә алып китәчәкләр икән.

Әйе, алда ифрат хәтәр эш тора иде. Хөсәен уйга калды. Ничегрәк уйлый икән «Әткәй», ничегрәк башкарылырга тиеш икән бу? Юкса адым саен шпион, адым саен сатлык җан. Бишенче елларда күкрәк киереп, революция өчен җан атып йөргән кайбер бушбугазлар хәзер пачкалары белән дошман лагерена күчтеләр. Өметсезлек, төшенкелек кара сөрем булып күзләрен томалады бериш интеллигентның. Ә фиргавеннәр сизгерлекләрен күпкә арттырдылар, җасусларның берсе өстенә икенчесен доносчы итеп, ялларга керештеләр. Аларның күзләренә хәзер, кем әйтмешли, салам да бүрәнә булып күренә. Әйе, шундый бер вакытта бу эш җиңел булмаячак. Хәер, өметсез шайтан, ди.

— Мин «Әткәй»нең планын күз алдына китерәм шикелле,— диде Хөсәен, әмма Галимҗан аны ишетмәде. Ачы искән җилдән сакланып, ул йөзен пальто якасы белән каплап бара иде. Башын чайкады.

— Мин «Әткәй»нең планы турында,— диде Хөсәен, тавышын көчәйтә төшеп.

— Баргач белербез инде,— диде Галимҗан,— син тын гына бар. Үпкәләреңне сакла, агайне.

Соңгы вакытларда Хөсәеннең үпкә чире үзен көннән-көн ныграк сиздерә башлаган иде. Уфага барып кымыз эчеп кайтулар ярдәм иткән кебек булса да, чир әрсезләнеп, Хөсәенне торган саен ныграк кысрыклый иде. Хөсәен үзенең авыру икәнлеген Хәдичәдән һәм дусларыннан никадәр оста яшерергә тырышмасын, бу торган саен сизелә бара, уйламаганда-көтмәгәндә фаш итела иде.

— Пустяки,— диде Хөсәен,— син күбрәк минә үзең турында уйла. Синең улың бар.

— Ә нәрсә мин,— диде Галимҗан,— мин җен кебек таза, әз генә авырсам, тотам да туган ягыма кымызга китәм. Чир-сырхауларны казакъның кымызы сыпырып кына төшерә.

Хөсәен дәшмәде. Аның уйлары тагы Табейкинга әйләнеп кайтты.

Тиздән алар Табейкинның Кәҗә бистәсендәге тәбәнәк кенә агач өенә барып җиттеләр. Тәрәзәләр томаланган, капкачлары ябылган иде инде. Галимҗанның алдан сөйләшенгән сигнал буенча шакуына күп тә үтмәде, кечкенә капка ачылып китте. Күләгә кебек тавышсыз-тынсыз гына ишегалдына уздылар. Ике бүлмәле бу тәбәнәк өйнең урамга

[1] Җасус — шымчы, шпион.

караган ягында бушлык, тынлык хөкем сөрә, эчке ягында исә тәмәке исе таралган, өстәл тирәсендә кешеләр күренә иде.

Түргә утырган Табейкин, Хөсәеннәр килеп керү белән аягүрә басты, якты чырай күрсәтеп, кунакларга урын тәкъдим итте. Күрәсең, биредә тәмәке тарту һич тыелмый иде. Хөсәен дә, чишенеп утыргач, папирос кабызды. Биредәге кешеләрнең күбесе таныш иде. Охранка тарафыннан Казан комитеты берничә тапкыр туздырылгач, подпольега киткән группа членнарын ул шулай явка урыннарында очраштыргалый иде. Билгеле, Табейкин белән хәзер элеккегедәй еш күрешеп булмый, бик сирәк, анда да әле бик кыска вакыт арасында гына очрашырга, бер-ике авыз сүз белән чикләнергә туры килә. Хөсәеннең Ефимны узган елның языннан бирле күргәне юк иде инде. Карт күзгә күренеп үзгәргән, зур киң сакалы ап-ак булган, хәтта кашларына кадәр бәсләнгән, ә яңаклары эчкә батып кергән. Бетергән «Әткәй»не бала кайгысы, дип уйлады Хөсәен.

Хөсәеннәр урнашкач, сүзне Ефим үзе башлады.

— Без киңәшкәннән соң, Хөсәен Минһаҗетдинович, шундый бер фикергә килдек... — Ул, тукталып, Хөсәенгә төбәлде.

— Сезгә Гассан эшнең нидән торганын аңлаткандыр инде?

— Аңлатты, дәвам итегез.

— Менә шул,— диде карт көрсенеп.— Минем Василийны ничек тә булса төрмәдән коткарырга иде бит. Ул Иске бистә төрмәсендә. Теге... Әҗем мәчетеннән ерак түгел. Аңлыйсыздыр... татар арасында. Сезнең анда бәйләнешләр нык булса кирәк.

— Әйе, бар,— диде Хөсәен.

Ефимның йөзенә канәгатьләнү яктылыгы иңде.

— Менә, менә. Безнең бер вариант менә шул мөмкинлектән файдалануга корылган. Әлбәттә, сез үзегез бу эштә катнашалмассыз, мәгәр сезнең кешеләр белән бәйләнешкә керүегез кирәк.

— Барын да аңлыйм. Шул вариантыгыз белән таныштырыгыз,— диде Хөсәен.

Хөсәен Хәдичә янына төнге бердә генә кайтып ятты. Башта йокы алмый азаплады аны. Табейкинның кичерешләрен үзе белән алып кайткан иде ул. Хәзер менә шул уйлар утында яна. Гомерен азатлык өчен, эшче халыкның азатлыгы өчен биргән кеше нинди язмышка тарган бит! Бер караганда, ул үз куллары белән улын дошманына саткан булып чыга түгелме? Хаиннәр! Нинди рәхимсез ысуллар кулланалар! Хәер, мондый хәлләрне ишетмәде, күрмәде мени Хөсәен? Мең, мең ләгънәт сезгә халыкны утлы зынҗырлар белән богауда тотучылар! Килер бер көн, килер, валлаһи, сездән үч алынып!

Ничек булса да Василийны төрмәдән йолып алырга кирәк. Хөсәен элемтә җепләрен иртәгә үк бәйли башлаячак. Элемтә дигәннән, ышанып эш тапшырырлык кемнәр калды соң әле? Хөсәен берәм-берәм иске дусларын, ышанычлы танышларын күз алдыннан кичерә башлады. Никадәр кеше кулга алынган! Алар сөргендә яки төрмәләрдә иза чигә. Садыйк Кавказда, Фәрхетдин Төмән якларында — Ялуторовскида. Инде килеп тагы кем? Хөсәен барлык таныш-белешләрен күз алдыннан кичерде. Һәм әле дә Крестовников заводында эшләүче, кайчандыр прокламацияләр басышкан Гыйльфанны хәтерләде. Эшне шуннан башларга кирәк дигән карарга килде. Ниһаять, ул, беренче прокламацияләр басуга бәйләнешле вакыйгаларны хәтерләп, хәзер казакъ арасында хәлфә булып ятучы Җәгъфәрне дә исенә төшерде. Ул теге чакта ук шурләп дошманга бер сатылган иде, ә хәзер инде бөтенләй провокаторга әверелгәндер, дип уйлап куйды. Тиздән аны мамыктай йомшак, төпсез караңгы йокы үз кочагына алды.

## 2

Иртәгесен, әле Хәдичә уянмас борын ук, Хөсәен ашык-пошык кенде дә «барабыз» яллап Иске бистәгә юл тотты. Вакытлы барып житте — Гыйльфан сменага китмәгән иде әле, тәрәзә чиертүдән үк кем килгәнлеген аңлап, урамга чыкты һәм сорау белән Ямашевка карады.

— Әйт әле,— диде Хөсәен,— мондагы төрмәдә берәр надзиратель белән бәйләнешкә керү мөмкинлеге бармы? «Эткэй»гә генә түгел, партиягә кирәкле хезмәтне күрсәтә алабызмы, юкмы?

Гыйльфан озак кына баш ватты.

— Авыр, авыр,— диде, ниһаять.— Тик...

— Нәрсә тик?

— Шулай да бәләкәй генә җеп очы бар кебек.

— Бу бик ашыгыч һәм үтә җитди задание.

— Бара-бара сөйләшербез. Юкса мин эшкә соңга калам. Хәзер мин өйгә кереп төшлеккә дигән ризыгымны гына алып чыгыйм да...

Алар Крестовниковның сабын кайнату заводына таба китеп бардылар.

— Мин белгән кеше Яңа бистәдә тора,— диде Гыйльфан.— Аның өе Зариф хәзрәт капкасыннан ике генә йорт аша.

— Зариф хәзрәт? Безнең Фатих Әмирханнар торган өйме?

— Әйе. Ишетүемчә, бер надзиратель Фатих Әмирханнарга бик якын кеше. Дөрес булса, ул безнең агайнегә, төрмәдә эшләвеннән файдаланып, ярдәм куллары да сузгалый, имеш.

— Димәк, мин бу эшкә Фатих Әмирханны тартырга тиеш булам?

— Аңардан безне шул надзиратель белән таныштыру гына соралачак!

— Юк, Гыйльфан, башка берәр ысул табарга кирәк,— диде Хөсәен кырт кисеп.

— Син тиктомалга ашыгып баш тартма, Хөсәен. Бәлки барып чыгар. Син бит үзең дә ул язучы Гассарны бик якын күрә, дисең. Бәлки әлеге надзиратель дә безнең эшкә хәерхаһ кешедер.

— Мин белмим,— диде Хөсәен, ә эченнән генә: «Һәрхәлдә мин бу турыда ишеткән булыр идем», дип уйлап куйды.— Ә мена Фатих Әмирханны кылыч астына куясым килми.

— Ул тамчы да куркыныч астында калмас.

Хөсәен Гыйльфанның хәйләкәр елмайган күзләренә карап җилкәләрен сикертеп куйды.

— Ай-һай ла!?

— Фатих Әмирханнан әлеге надзиратель турында сорашыйк, берни дә югалтмабыз. Аның өчен борчылма.

Алар тәрәзәләреннән пар бөркелгән, гөрелтеле, шыксыз зур кызыл кирпеч бинаны уздылар да заводның контроль капкасында аерылыштылар.

«Димәк, эш ансат кына хәл ителмәячәк» — дип уйланды Хөсәен. Ул хәзер чияләнгән төенне чишәргә тиеш иде. Болай да фиргавеннәр күзәтүе астында яшәгән әдипне хәвефле эшкә тартыргамы, юкмы? Ә барып чыкмаса? Зур әдип, аяксыз калган Фатих, шушындый абайсызрак килеп чыккан эш аркасында һәлакәткә очраса?.. Хөсәен ашыкмыйча гына урам буйлап алга китте. Үзе туып үскән, хәзер инде башка кешеләр яшәгән мезонинлы бер катлы өй ягына, балалык чорының якты хатирәләрен саклаган йортка каерылып-каерылып карады. Ләкин алай артык хис-тойгыларга бирелер чак түгел шул. Хәзер үк ниндидер карарга килергә кирәк. Әйе, әйе, озакка сузмыйча, хәзер үк. Ул Галимҗан Сәйфетдинов белән Бакыр бабай бакчасында очрашты, кичә үк шулай сөйләшенгән иде. Галимҗан да әлегә берниндн бәйләнеш булдыра алмаган

Эскәмияләре кар мендәрләре белән түшәлгән, тын аулак бакчада шактый вакыт сөйләшеп-киңәшеп йөргәннән соң, Фатих Әмирхан аша тегеләр надзиратель белән танышуны бердәнбер кулай юл дип таптылар. Хөсәен шундук Яңа бистәгә китте. Пелатән урамы чатында трамвайдан төште, юлын җәяүләп дәвам иттерде.

Тиздән ул Иске бистә белән Яңа бистә арасындагы каберлекне читләтеп узды да Татар бистәсенең тәбәнәк агач өйләр тезелеп киткән урамына барып керде.

Фатих өйдә иде. Әле генә иртәнге чәен эчеп, үзенең бүлмәсендә кырынып утырган чагы. Бу — татарда шәкертләр хәрәкәтенең танылган җитәкчесе, үзе дә шәкерт чагында ук кулдан «Әльислах» исемле журнал чыгарган кеше, ә инде җиденче елдан алып шул ук исемдәге басма журналның фактик редакторы. Татар язучылары арасында прогрессив карашларны иң эзлекле рәвештә алып баручысыдыр, мөгаен. Ул мең тугыз йөз алтынчы елны зур бәхетсезлеккә дучар булды, паралич аны аяктан калдырды. Бу фаҗига турында Хөсәен Уфада чакта ишеткән иде. Ул чакны Фатихны кызганып аның йөрәге генә түгел, бөтен җаны сыкранды. Яшеренеп кенә Казанга кайтуларының берсендә ул Фатихны күрергә ашыкты. Җылы сүзләр табып, үзенчә аны юатырга теләде. Чөнки бу фаҗига шәкертләр юлбашчысына гади бер тән гариплеге генә китермәгән, аны рухи яктан да изгән булырга тиеш иде. Печән базары әһелләре, кадимчеләр, карагруһчылар аның бу фаҗигасенә шатланып бетә алмадылар. Аның бәхетсезлеген алланың каһәре аркасында, Фатихның җәдит булганлыгына ходаның җәзасы дип карыйлар, һәм һәр җирдә шул турыда коткы тараталар, тантана итәләр, гайбәт чәйниләр иде. Хөсәен боларның барысын да белгәнгә күрә, ул чакта Фатихны бөтенләй бетерешкән, канатлары салынган бер хәлдә күрермен дип бик борчылып уйланган иде. Әмма Ямашевның чиксез шатлыгына каршы, Фатихта ул әз генә дә төшенкелек сизмәде. Фатих шактый ябыккан, олыгая төшкән булуына карамастан, рухи яктан әз генә дә үзгәрмәгән иде. Ул элеккечә шат, якты чырайлы, нәкъ элеккечә — чак кына иронияле. Ул вакытны Фатих әле яңа гына үзенә резин көпчәкле җиңел арба-кресло алдырткан иде. Ул сау аякларын алыштырырга тиешле резин кыршау тоткан тәгәрмәчле арбага әле яңа гына күнегеп килә иде. Фатих, кулларын кызу хәрәкәтләндереп, арбасында бер алга барды, бер чигенде, уңга борылды, сулга борылды һәм моның уңышлы барып чыгуына балаларча куанган да сыман иде.

Ә инде җиденче ел азагында бөтенләйгә Казанга әйләнеп кайткач, Хөсәен Фатихны еш күрде, һәм күргән саен кайчандыр елдам, төз гәүдәле Фатихның, хәзер инде арбага ябышып яшәвенә, урамга чыкканда Хәкимҗан абзасы этеп йөртүенә һич кенә дә күнегә алмады. Ләкин Фатих, ни әйтсәң дә, элекке Фатих иде.

Хөсәен бу юлы да, ничектер авырсыныбрак, ишек чаршавыннан Фатихның бик тырышып сакал кыруын бераз вакыт дәшмичә генә күзәтеп торды. Керергә рөхсәт сораганчы ук Фатих аны көзгесеннән күреп өлгерде һәм, күзләрен кыса төшеп, аңа таба борылды:

— Һа, Хөсәен әфәнде! Нәрсә ятим бала кебек ишек төбендә генә торасың, уз. Мин үземне кызлар күзенә күренерлек бер хәлгә китерәм дә синең өчен гел илтифат,— диде.

— Кырын, кырын,— диде Хөсәен.— Исәнлек-саулыкмы?

— Ал да гөл. Син әле укыдыңмы, безнең Вафаны ахун вә имам Мәмлиевләр «Әльислах»та шәхесебезгә тиде, безне хурлады, дип судка биргәннәр?

Хөсәеннең ачудан күзләре елтырап китте.

— Шулай дигәннәрме? Булыр, булыр, алардан барысын да көтәргә була.

— Менә шулай, агайне, «Эльислах» безне тиешсезгә тәхкыйрь иткән дип, судка чын-чынлап гариза язганнар.

Фатих, бритвасын ияк кырыйларыннан бер уздырды да, көтелмәгән житезлек белән борып, арбасын ишеккә таба юнәлтте.

«Ничек сүз башларга?» дип баш ватты Хөсәен. Ул һаман әле әйтеләсе сүзнең очын таба алмыйча азаплана иде.

Ләкин бу эш көтелгәннән күп ансат хәл ителде. Фатих Әмирхан юынып, сөртенеп бүлмәгә килеп керүгә, үзе Хөсәенгә мөрәҗәгать итте.

— Син, әлбәттә, әфәндем, без гарипнең хәлен белер өчен генә килмәгәнсеңдер. Сине нинди дә булса фәукылгадә[1] йомыш йөгерткәндер. Әйт йомышыңны, сөхбәтләшик, аннан мине өстәлем көтә.

Фатих пенснесын киеп алды, пыялаларын ялтыратты. Хөсәеннең әйтеләчәк сүзен көтә башлады.

— Синең, Фатих дус, Әҗем төрмәсендә надзиратель булып эшләүче берәр ышанычлы танышың юкмы?

Фатихның йөзеннән сәерсенү шәүләсе узды.

— Төрмә надзирателе һәм ышанычлы кеше! Надзиратель, минемчә, бары власть әһелләренә генә турылыклы була ала.

— Димәк, юк?— диде Хөсәен шактый кискен итеп.

Фатих, һаман сынагандай, Хөсәенгә карап тора иде.

— Нигә кирәк булды ул сиңа?

— Анысын соңыннан әйтермен. Шактый катлаулы бер йомыш кушарлык ышанычлы төрмә хадиме[2] кирәк.

Фатихның йөзе җитди бер төс алды. Әлегәчә булган ирония тоны юкка чыкты.

— Бар андый кеше,— диде ул.— Курыкмыйча таянырга мөмкин булган кеше бар. Ул эшне көнем өчен дип түгел, денем өчен дип башкаручылардан. Ләкин булдыра алырмы ул сезнең үтенечне. Сизенүемчә, зур эш башкарырга җыенасыз. Төрмәдән качу икән, ай-һай, мин белгән егет андый рискка ук бара алырмы икән...

— Үзе белән сөйләшергә кирәк, бәлки булдыра алыр.

— Яхшы,— диде Фатих,— мин сезне беренче мөмкинлек чыгу белән таныштырырмын.

— Вакыт бик чикле, әфәндем.

— Ярый. Мин бүген үк аңа кеше җибәрермен.

— Менә хәзер үк мөмкин түгелме?

Фатих, калын иреннәрен җәеп, елмаеп куйды.

— Кара син аны, ә?

Ул шундук әлдертеп алгы бүлмәгә чыгып китте. Бүлмәне китап шкафлары, язу өстәле һәм берничә утыргыч кына бизи. Стенада Шиһаб Мәрҗани һәм Лев Толстой портретлары эленгән. Хөсәен шуларны күзәткән арада Әмирхан әйләнеп тә керде.

— Әз генә сабыр итсәң...— диде ул.— Бәлки әле хәзер үк килеп җитәр.

Фатих, кулларына күтәрелеп, арбасыннан өстәл янындагы креслосына күчеп утырды.

— Үзеңнең кәеф-шәрифләрең ничек соң?— дип сорады.

— Әйбәт,— диде Хөсәен,— ярый. Менә университетка керергә җыенам.

— Бәхетле кеше,— дип куйды Фатих. Ләкин тагы сынап карап куйды. Бу караштә: «Бик әйбәт күренми шул хәлләрең, җанкисәгем», дигән сыман фикер чагыла иде.— Безнең Габдуллаҗанның эшләре шәптән түгел бит. Үпкәсендә аның да...

---

[1] Фәукылгадә — гадәттән тыш

[2] Хадим — хезмәтче

— Тукайны бит әле бизгәк чире дә җәфалый.

— Тормыш шариәтләре,— диде Фатих күңелсезләнеп,— ул бичараның кайчан булса да кешечә яшәгәне, ял иткәне, дәваланганы булдымы соң!

— Әйтмә дә инде.

Хөсәен Оренбургта Тимерша Соловьев чыгара торган журналның Тукайга өзлексез мәсхәрә яудыруы турында искә төшереп алды.

— Мин сезнең арадагы кайбер кешеләрнең вак эгоистлыгына хәйран калам,— дип нәтиҗә ясады.— Мәйдандашын батыру исәбенә үзенең персонасын расларга омтылалар алар.

— Анысы бар,— диде Фатих көрсенеп,— ул безнең культура түбәнлегеннән киләдер ахры.

Кинәт Фатих игътибарын ишеккә юнәлтте, алгы яктан хатын-кыз тавышы ишетелде. Ул надзирательнең бүген ял көне булганлыгын һәм аны үзе белән алып ук килгәнлеген әйтте.

— Керсен,— диде Фатих.

Бүлмәгә, жандармныкына охшаш бөтеркә мыеклы, түгәрәк битле, таза ир уртасы кеше килеп керде. Ул керү белән, сәлам биреп, татарча ике куллап күреште, шикләнеп Хөсәенгә карап куйды, сорау белән Фатихка текәлде.

— Башта танышыгыз бу әфәнде белән,— диде Фатих, Хөсәенгә ымлап,— бу мәшһүр Хөсәен Ямашев үзе була.

Надзиратель көлеп җибәрде.

— Ишетеп белә идем, нәкъ безнең төрмә зар-интизар булып сагынган кеше икән.— Ул яңадан ике куллап Хөсәен белән күреште.— Мостафа булабыз,— дип куйды.

— Мостафа, минә минем бик якын дустым Хөсәеннең сиңа зур бер үтенече бар. Син аның үтенечен минем үтенеч дип тә кабул ит. Аңлашылдымы? — диде Фатих.— Әйдә, әнә Хөсәен янына утыр да, сөйләшегез. Ә минем эшем бар, мин күрше бүлмәдә булырмын.

Фатих арбасында бүлмәдән чыгып та китте. Хөсәен аны туктатмакчы иде дә, ләкин яңадан кире уйлады. Фатих артыннан ишек ябылгач, ул ничек сүз башларга белмәгәндәй, бермәл тынып торды. Ниһаять:

— Әҗем төрмәсендә Василий Табейкин атлы кеше утыра. Сез шуны беләсезме? — дип сорады.

— Аны өченче көн кичкырын, этап белән, көчле конвой астында озаттылар бит.

Хөсәен агарына төште:

— Чынлапмы?

— Коръән тотып ант итә алам, ышанмасагыз. Минем дежур чакны озатылды ул...

## 3

Эш теләгәнчә генә барып чыкмый. Моны, инде авыр реакция елларында үзен аерата нык сиздерә торган кагыйдәне, Хөсәен электән ук үзләштергән иде. Хикмәт шунда ки, уңышсызлыклар күңелне төшерергә, сайлаган юлыннан кешене ваз кичтерергә тиеш түгел. Монысын да Хөсәен әйбәт үзләштергән иде.

Василий вакыйгасы ачыкланды, Мостафа Хөсәенгә дөресен әйткән икән. Әлбәттә, эшнең болай бетү ихтималын тәҗрибәле карт большевик Табейкин алдан ук күргән, һәм улының Казанда ятуыннан файдаланып, аңа качуның бүтән вариантларын да җиткергән. Хәзер инде Томский подпольщиклары белән бәйләнешкә кереп, өметне өзмичә, түземле рәвештә көтәргә генә кала. Бу кадәресен Ефим үзе башкарырга тиеш иде.

Бу көннәрдә Хөсәеннең башка эшләре дә хәттин ашкан иде. Унынчы елны Казан большевикларына, кем әйтмешли, җиде кат җир астына төшеп эш йөртергә генә калды. Революцион эш алып баруның үзенчәлекләрен яхшы белүче тәҗрибәле кешеләрнең күбесе сөргеннәргә куылды, яки чит илләргә китәргә мәҗбүр булды. Вилонов авырып, Ленинның киңәше буенча, дәваланырга Швейцариягә китте, Дамперов сигезенче елны ук Казанда медицина факультетын тәмамласа да имтихан бирергә рөхсәт ала алмады, Казанда эшкә урнаша алмыйча, Болгариягә китәргә мәҗбүр булды, Гассар шулай ук Казаннан китте, Догадов та Казанда юк. Казан студентларының сөекле юлбашчысы Андрей Кулеша Тобол якларында сөргендә, Лозовский тугызынчы елдан бирле Женевада, Садыйк Сәгыев Баку якларында исемен яшереп йөри, Саммер Иван Адамович, Хөсәенгә «Урал»ны чыгарырга ярдәм күрсәткән большевик, төрмәдә. Яшь революционер Тихомирнов Архангельск якларына сөрелде. Тагы бик күп җитәкче кадрлар, революцион эшчеләр Казаннан куылган, яки үзләре киткәннәр. Хәзер ышанычлы дуслар бәрәмтекләп кенә санарлык калган иде. Эзләрне бутау өчен явка урыннарын бик еш алыштырырга туры килде. Чөнки адым саен хаин, җасус, охранка кешесе. Менә шундый авыр шартларда эшли иде Хөсәеннәр.

Хөсәен һәм аның иптәшләре үзәк белән һәм үзара элемтәне хәзер Николай Лотов, Абрам Комлев, Владимир Адоратский, Михаил Жаков, Евгений Зариницын һәм аның хатыны «Смоленский-Шмилев сәүдә йортында» кассир булып эшләүче Юлия Михайловналар аша тоталар иде.

Хөсәен җиденче елның азакларында гына, үзенең газетасын терелтүдән өмет өзеп, Казанга кайтып егылды. Ул Урал якларын, андагы завод-фабрикалы татар эшчесе күп тупланган шәһәрләрне аз таптамады. Ләкин газетага терәкләнеп калырлык бер генә урын да таба алмады. Хәер, Чиләбедә эш мантый язган иде. Булачак газетага нашир да, редактор да, җирлек тә табылган иде. Хәтта Хөсәен татар күп яшәгән шәһәрләрдәге элекке агентлар белән бәйләнешкә кергән, яңаларын эзләргә керешкән иде. Тик Оренбург жандармериясенең рәхимсез кулы бөтен нәрсәне җимереп ташлады, нинди генә оста корылган хәйләләрне дә охранка алдан сизенеп, юлны кисә торды. Ниһаять, Хөсәен большевистик рухтагы легаль газетаның татар телендә хәзер чыга алуына тәмам өметен өзде һәм Казанга кайтып егылды. Әйе, чын мәгънәсендә егылды. Чөнки үпкәсендәге чир дә, йөрәк авыртулары да бергә кушылып аның тәмам хәлен алган иде.

Ул бер айга якын өйдән чыкмый дәваланып ятарга мәҗбүр булды. Ләкин якын дуслар аны ярдәмсез калдырмадылар. Акча юнәтеп, дәваланырга Кавказга җибәрделәр. Ул анда бераз хәл алгач, Баку аша Уфага кайтты. Уфада кымыз эчеп ятты. Хәзер исә ул шул дәвалануларның игелеген күреп, үзен тәмам таза-сәламәт кеше исәпләп, яңадан эшкә, һәр даим күңеле өндәп, чакырып торган революцион хезмәткә чумды. Ул эш хәзер чиксез катлаулы иде, эшчеләр белән уздырыла торган түгәрәкләрдә даими эшчәнлек алып бару өчен чамадан тыш күп көч куярга кирәк. Өстәвенә аңа алдынгы татар интеллигенциясе белән дә эш алып бару вазифасы йөкләтелде. Хәер, бу өлкәдә аның бик ышанычлы ярдәмчеләре, утны-суны бергә кичкән, сыналган көрәштәшләре Галимҗан Сәйфетдинов, Гафур Коләхметовлар бар иде. Алар бергәләп уйлаштылар да бу эшне әдәбият түгәрәге оештырудан башладылар. Ләкин бу кайчандыр Габитовлар өендә башлап җибәргән түгәрәк түгел иде инде. Моның максаты — большевистик пропаганда алып баруны иҗат интеллигенциясе арасында җайга салудан гыйбарәт. Бу түгәрәк ныклы большевистик рухта булырга тиеш иде. Аның утырышларын конспиратив шартларда гына алып барырга карар кылынды.

Ләкин Хөсәен үзе сайлаган мөхиттә никадәр генә кайнамасын, суга ташланган балыктай, никадәр генә шул мөхиттә йөзү рәхәтен кичермә-

сен, аның күңеле тыныч түгел иде. Ул кулга алынудан яки эзәрлекләнүдән дә курыкмый. Аңа авыруы да әле ул кадәр җиңелмәслек булып тоелмый. Аны борчыган нәрсә — өендәге хәл. Ир белән хатын арасындагы фикер каршылыгы соңгы өч елда көннән-көн көчәя, үсә торды. Хәдичә күзгә күренеп ераклаша бара һәм Хөсәен бу фаҗигане берничек тә туктата алмаудан гаҗиз иде. Гомумән, эчке кичерешләрен сөйләргә бик өнәми торган Хөсәен, үзе яраткан якын, кадерле кешесенең хәзер үзеннән читкә тайпылырга теләвен, һәрбер форсаттан файдаланып, фикер каршылыгын сиздерергә тырышуын үтә авыр, эчтән сызып кичерде. Кем нинди киңәш бирә ала соң мондый чакта? Ничек Хәдичәне элекке хәленә кайтарырга, ничек итеп аны үз юлың белән җитәкләп алып китәргә һәм иң зур бәхет дигән нәрсәнең шул икәнлеген аңлатырга?

Бу көннәрдә, ничектер вакыт табып, Хөсәен Габдулла Тукай янына барып килергә булды. Тукайны энеседәй якын күрә Хөсәен, аның һәр шигырен тәэсирләнеп укый һәм эчтән генә, безнең халык та, ниһаять, шундый олы шагыйрь тудырды бит, дип шатлана иде. Тукай белән Хөсәеннең иркенләп сөйләшеп утырмаганына байтак вакытлар узды инде. Әйтәсе сүзләр, хәбәрләр һәм фикерләр шактый күп җыелган иде. Хәзер Тукай «Болгар» номерыннан күчеп аерым фатирга урнашкан, ул исә Хөсәенгә шактый якын кешеләр, Вахит мөәзиннәр өендә — Яңа бистәдә.

Хөсәен үзенең теләгән бары февраль урталарында гына гамәлгә ашыра алды. Чарлактагы тар гына бүлмәдә яши икән Тукай. Хөсәенне күргәч, ул балаларча шатланды. Ләкин Тукай хәзер кайчандыр Уральскида яшәгән Тукай түгел иде инде. Йөзгә чандырлык чыккан, күзләр эчкә бата төшкән. Шагыйрьнең дулкынланып җилкәсенә төшеп торган коңгырт чәчләре аңа ничектер бөтенләй ят бер кыяфәт бирә. Кочаклашып күрештеләр. Шагыйрьнең балаларныкы кебек ябык, какча гәүдәсен Хөсәен үз кочагында сеңеп беткәндәй тойды. Туганнар арасында гына була ала торган кардәшлек җепләре бәйләгәндәй иде аларны.

— Сине эзләп килдем, Габдулла,— диде Хөсәен,— синең хәлләреңне белергә.

— Хәлләр минем бер дигән, Хөсәен әфәнде. Менә сез килеп кергәч, бөтен бүлмәм һәм күңелем нурланып киткән кебек булды. Күргәнегезчә, мин яңа фатирда. Рамазанов җәнапларының «Болгар» номерыннан качтым, туйдым печән базарының кырыктартмачы Хафизларыннан, Көфер почмагыннан. Рәхмәт изге кешеләргә, әйбәт киңәш бирделәр. Биредә ичмаса җаным тыныч.

Стена буендагы шкафта тәртипсез урнаштырылган китаплар, кульязмалар, тәрәзә алдындагы язу өстәлендәге кәгазь өемнәрен күреп, Хөсәен шагыйрьнең бик илһамланып эшләгәнлеген аңлады. Габдулла исә, идәнгә чүгәләгән килеш, чыбыктан үрелгән капкачлы кәрзиннән нидер эзли һәм таба алмавына гасабилана иде.

— Мине кичерегез,— диде ул аягүрә басып,— мин бер хат кисәген эзли идем. Вакытында аны игътибар белән укый алмадым, чөнки ул хат мине беренче юлларыннан ук тирән хәсрәткә дучар итте.

— Нинди хат иде соң ул кадәр?— диде Хөсәен сәерсенә төшеп.— Хәсрәт дәрьяларын күргән кешене тетрәтерлек булгач, ул инде гадәттән тыш бер хат булгандыр.

— Менә ул хат,— дип, ябык сөякчел бармаклары арасындагы кәгазь кисәген өскәрәк күтәрде Тукай.— Ул шундый хат, мин аны хәзер дә укырга куркам.

Хөсәен кызыксынуын яшерә алмады. Дөресен генә әйткәндә, бу гади бер кызыксыну гына да түгел иде, Хөсәеннең ничек тә булса даһи дустын юатасы килә, аның авыр минутларын җиңеләйтәсе килә иде. Габдулла Хөсәеннең теләгән аңлады.

— Бу хат турында без Фатих белән икәү генә беләбез. Чөнки ул миңа бәйләнешле булса да Фатихка адресланган,— дип куйды Габдулла.

Хөсәен сүзнең дәвамын көтте.

— Мин бу турыда кешегә сөйләргә бик яратмыйм, Хөсәен әфәнде. Ләкин сезне мин шулкадәр хөрмәт итәм, бу серне сездән яшерү — дуслыкка хыянәт кебек тоела.— Тукай, гадәтенчә, башын кыйшайта төшеп, Хөсәенгә карап алды.— Сезгә Зәйтүнә турында бер сөйләгән идем булса кирәк?

— Теге Чистай кызымы? Күргәнем дә бар иде шикелле аны, хәтерем ялгышмаса. Беләм...

Хөсәен Габдулланың бер Чистай кызына гашыйк булу вакыйгасын белә иде. Тукай үзенең мәгъшукасына багышлап шигырьләр язды. Казаннан өенә кайтып киткән кызны күрү өчен Чистайга барып килергә омтылып карый. Тик моңа батырлыгы житми, табигатендәге хатын-кыздан оялу гадәте комачаулый. Шулай итеп ул эчке кичерешләр белән янып, хыялында бер генә минутка да Зәйтүнәсеннән аерылмыйча яши. Ниһаять, ул түзми, сердәше һәм дусты Фатих Әмирханга шул кызны өзелеп сөюен әйтә. Фатих исә, шагыйрьнең рөхсәте белән, Зәйтүнәгә Тукай исеменнән тәкъдим хаты җибәрә.

— Я, нинди җавап яза соң кызый?— диде Хөсәен.

— Үзе язмый. Аның өчен башкалар яза, якын кардәшләре.

— Ничек инде?!— диде Хөсәен аптырый төшеп.— Син аңа язасың, башка кешеләр сиңа җавап бирә.

— Ул үзе Чистайдан Курсага укырга киткән. Анда аның туганнары яши икән.

— Барыбер, аңламыйм. Ничек инде бер кеше өчен икенче кеше җавап хаты язарга хаклы. Бигрәк тә бу мәсьәләдә.

— Соң бит тәкъдим хатын язучы да мин түгел. Минем исемнән Фатих язды.

Хөсәен, тулысы белән булмаса да, җаваптан канәгатьләнгән кебек иде.

— Я, нәрсә язалар соң аларның карендәшләре?

— Хатны укып тормыйм... кайбер өзекләрен генә...

Тукай хат юллары өстеннән күзләрен йөртә башлады. Аның зур кара-коңгырт күзләре, артык дулкынланганын сиздереп, уттай яна башладылар.

— Менә нәрсә,— диде, ничектер әрнүле бер тавыш белән.— «Габдулла Тукаев әфәнденең Зәйтүнәгә булган тәкъдимен нигезсез дип табабыз. Ул үзе хәзергә Чистайда түгел, читтә — туганнарында Курса карьясендә укуда. Без аның белән хәбәрләшеп аңлашканнан соң шуны язабыз: аның күңелендә шагыйрь Габдулла Тукаев түгел хәзергә, ә бөтенләй башка нәрсәләр».

Габдулла артык укып тормыйча, хатны кәрзингә ташлады.

— Димәк, ул мине яратмый. Ә бит Казанда чакта бөтенләй башка иде. Аның күзләре мине күрү белән нурланып китә иде. Исемдә: бервакыт шәрык кичәсендә ул конфеттине беренче булып миңа сипте. Шигырь укыган чагымда күзләрен миннән алмады. Я хода, шулай да була микәнни? Шундый икейөзле микәнни хатын-кыз нәүгысы?

— Синә болай борчылырга һич урын юк, Габдулла,— диде Хөсәен.

— Ничек юк, ничек юк. Мин бит шушы кәгазь кисәге белән үлемгә дучар ителдем.

— Син, Габдулла, кайчак чын мәгънәсендә кечкенә балалар кебек хөкем итәсең.

— Я, әйтегез алайса, Хөсәен әфәнде, мин сезне акыллы, иң якты рухлы кунакларымнан саныйм, я, әйтегез, нишләргә миңа?

— Валлаһи, синең урынында булсам, бүген үк, менә хәзер үк ат яллатыр идем дә Курсага китәр идем. Күрер идем синең башыңны әйләндергән кызыйны, үзе белән утырып бер сөйләшер идем.

— Сөйләшер идең? Үзе белән? — дип сорады Габдулла. Ул таркау бер елмаю белән, кулларын җәеп җибәрде.— Юк, мин аны булдыра алмыйм.

— Әмма сиңа шушы хат аркасында газап чигәргә бернинди нигез юк. Бәлки болар барсы да дошманлык аркасында язылгандыр. Бәлки әти-әнисе бик иске фикерле кешедер. Син бит хыялга бай, шулай була алмыймени? Бәлки бу бер көнчелек аркасында язылган уйдырмадыр...

— Нинди көнчелек була ала,— диде Габдулла аптырый төшеп,— хатта бик ачык итеп «без Зәйтүнә белән хәбәрләшеп торабыз», диелгән.

— Юк, юк,— диде Хөсәен катгый рәвештә,— мин синең урынында булсам, бу хатны укып чыгар идем дә шундук онытыр идем. Я китәр идем Зәйтүнәне күрергә. Ә син хискә бирелеп шашынасың.

Хөсәен теләсә нинди темага сөйләшүне көткән иде бүген, тик мондый әңгәмәне генә күз алдына китермәгән иде. Ләкин шагыйрьнең авыр кичерешләренә битараф карау да кешесезлек булыр иде.

— Фатих Әмирхан ни әйтә соң бу хат турында?— дип сорады Хөсәен.

— Нәрсә әйтсен. Ул көлә, төкер барысына да, ди.

— Гомумән дөрес әйтә. Синең мәхәббәт-фәлән дип вакланырга, таркалырга хакың юк. Син — шагыйрь.

— Сезнең өчен, социалист дустым, бары революция генә кирәк, башкасы пустяк. Ә мин шагыйрь, миңа шигырь язу гына кирәк булып чыгамы? Мәхәббәт, хисләр турында да шундый өлге белән эш итәсезме? Бәлки мине бары мәхәббәт кенә шагыйрь иткәндер дә. Мәхәббәт һәм нәфрәт.

Хөсәен Габдулланың ачуы килгәндә, тыела алмыйча, теләсә кемгә теләсә нәрсә әйтә алу ихтималын яхшы белә иде. Шуңа күрә ул шагыйрьгә үпкәләмәде, аның әйткәннәрен тыныч кына, мыек астыннан елмайган килеш тыңлады. Габдулла тынычлана төшкәч:

— Яхшы алайса, мин сиңа бу мәсьәләдә дөреслекне белү өчен үзем ярдәм итәрмен,— диде.

Тукайның әле генә тынычлык иңә башлаган йөзенә шөбһәләнү билгесе чыкты.

— Алла хакы өчен кирәкми. Мин инде ничек булса да үз фаҗигамны үзем генә йотып сеңдерермен.

Габдулла белән бу турыда артык сөйләшеп торуның мәгънәсе юк иде. Хөсәен сүзне икенче темага күчерергә ашыкты.

— Яхшы,— диде,— мин риза, сиңа ярдәм итим әле дип, кыл да тибрәтмәм. Тик шулай да кысыр хәсрәтләр белән юкка газапланасың. Менә нәрсә, Габдулла, мин әдәбият түгәрәге оештырып йөрим бит әле. Дөресрәге ул бар, яши инде, тик аның әгъзалары азрак. Аны колачлырак иттереп оештыруда мин синең ярдәмеңә мохтаҗ.

— Баш өсте. Мин ярдәмгә әзер. Әле менә «Шәрык клубы»нда халык әдәбияты турында лекция сөйләргә исәбем бар, шул ук лекцияне мин сезнең әдәби түгәрәктә дә сөйли алам.

Габдулла, хәйләкәр генә көлемсерәп, Хөсәенгә карап куйды. Шагыйрь, әлбәттә, Хөсәеннең түгәрәге асылда бөтенләй әдәби түгәрәк түгеллеген, политик эш максаты белән оештырылганын яхшы төшенә иде. Хәзер исә, баягы сөйләшүнең үчен алырга теләгәндәй, Хөсәенне юри нрештерә иде Тукай. Хөсәен моны тиз аңлады.

— Бик мәслихәт, нәкъ менә шундый ярдәмеңне теләгән дә идем мин, Габдуллаҗан,— диде.

— Беләм мин сезнең хәйлә и шәргыя капчыгы икәнлегегезне, Хөсәен әфәнде. Сез нәрсә, минем шул түгәрәк утырышларына йөрүемне һәм көннәрдән бер көнне, аяк-кул богауда килеш, Казаннан Себер якларына каторгага сөрелүемне телисезмени? Белеп торыгыз, әфәндем, мин болай да күзәтү астында яшәүче, ышанычсызлар таифәсеннән.

Хөсәен Габдулланың юрамалый усаллануын сизә иде. Шуңа күрә шагыйрьнең сүзләрен елмаю аша уздырды. Ә инде бераз үткен теллеләнгәннән соң, Габдулла җитди рәвештә: «Мин ул түгәрәккә йөриячәкмен, мотлакан йөриячәкмен,— диде,— тик лектор сыйфатында түгел, ә гади тыңлаучы сыйфатында».

— Менә шул кирәк иде дә миңа,— диде Хөсәен,— мин сиңа үз вакыты белән аның кайда һәм кайчан булачагын белдерермен. Тик шулай да әйтми кала алмыйм, Габдулла, бу очрашуда син мине үз чыгырыңнан ычкынган бер халәттә каршы алдың, дустым. Белүемчә, шактый тыныч та була ала идең.

Габдулла уңайсызлана төшеп елмайды һәм җитдиләнеп:

— Белсәгез иде минем алҗуларымны, Хөсәен әфәнде,— диде.— Мин әле генә сезгә йөрәгемне өзгәләгән әлеге хат турында әйттем. Ләкин мине мондый хатлар гына борчып тормый. Казанга килеп төшү белән мин тирә-юнемдәге шома, тәти, бик укымышлы егетләрне күреп, үземне наданлыкта калган бер мескен дип уйлаган идем. Инде тора-бара ул шома егетләрнең күбесе шапырынчык, коры куыклардан торганын белдем. Инде матбугатта шигырьләрем үзләренә юл салырга өлгермәделәр, тирә-ягымны дошман чолгый башлады. Эттән күп дошманым. Аларның һау-һауларына каршы торып, юлыңнан тайпылмый бару өчен ифрат күп көч кирәк. Сөмсерем коелуы бары шуннан гына.

Әйе, Хөсәен Тукайның бик ачы телле булуын, турыдан бәреп әйтә торган гадәтен белә иде. Ләкин аның әдәбият турындагы һәр сүзе гадел, әйтелергә һәм «мыекка чорналырга» тиешле сүз иде. Мәгәр кайберәүләр моны күтәрми, Тукайның дошманына әверелеп, теләсә нинди юллар белән аны кимсетергә керешә. Бу кешеләр арасында, кызганычка каршы, шактый талантлы шәхесләр дә юк түгел.

Тукай сүзен дәвам иттерде.

— Сезнең алда, Хөсәен әфәнде, барлык ясалмалыкларны читкә атып, бөтен булганымны күрсәтәсем килә минем. Сез мине аңларсыз дип ышанам. Бу миңа үзе бер рәхәтлек, ләззәт бирә.

Хөсәен көлеп җибәрде.

— Рәхмәт андый ышанычың өчен. Мин дә сиңа шундый ук ышаныч күрсәтергә тырышырмын.

— Ә үзегезнең хәлләр ничегрәк соң? Сезгә тагы да авыррак шартларда көрәш алып барырга туры килә бит!

— Бик күп иптәшләр юк ителде, сөрелде, Габдулла. Күреп торасың бит, заманында революционер булуны бер модага санаган буш куыклар синең тирә-юнеңнән дошман лагерена качтылар яисә бөтенләй постылар. Менә шундый шартлар, дустым.

Габдулла кашларын җыерып бераз уйланды да кинәт яктырып, көтмәгәндә:

— Мин сезнең әдәбият түгәрәгенә бик теләп йөриячәкмен,— дип куйды.— Уральскидәге инкыйлапчы чакларым искә төшмәсме. Рус әйтмешли: тряхнем стариной.

— Мин башка сүз көтмәгән дә идем синнән, Габдулла.

— Аңлаштык. Алдым-бирдем ясадык,— диде Тукай көлә-көлә.

— Мин бер көн Фатих Әмирханны күреп сөйләштем, шунда ул синең бер кызыклы хат алуың турында әйтте...— диде Хөсәен кинәт сүзне икенчегә борып.

— Нинди мәктүп икән ул? Шаять, кызлар хаты түгелдер, анысын мин сезгә күрсәттем.

— Юк, бу егетләр хаты. Кызыксынуымның сәбәбе шул: син андый егетләрдән ераграк булсаң иде.
— Сез Җәгъфәр әфәнде хаты турында әйтәсез — аңлыйм. Нигә шундый көчле нәфрәт сездә аңа карата?
— Чөнки мин аны беләм.
— Бәлки мин аны сездән яхшырак беләмдер?
— Син аны сөйләве буенча гына беләсең, ә мин гамәле буенча.
Тукайның коңгырт-кара күзләре усаллык белән бер көйрәп алдылар, ул шактый зәһәрләнеп:
— Сезнең партиягез адәм баласының күңеленә вәсвәсә салу өчен оешмагандыр бит... Кеше кешегә ышанырга тиеш. Сез дә кешенең асылы әйбәт, тумыштан беркем дә җасус яки хаин булып тумый, дисез.
— Әйе, ләкин аның тәрбиясе, тирә-як даирәсендәге шартлары аңа билгеле бер мөһер суга, аны калыплый һәм фәрештәдәй саф булып туган сабыйдан, үсә төшкәч, кеше үтерүче канэчкечләр килеп чыга кайчак!
— Җәгъфәр шул рәвешкә кереп калыпланган кеше дияргә минем бөтенләй телем бармый,— диде Тукай.— Сез әгәр шулай дип икърар итәсез икән, биш рәкәгать намаз укып антлар эчсәгез дә мин ышанмаячакмын. Ул Уральскида юкка чыкканнан соң миңа бу көнгәчә миңа бер генә хат та язмады. Хәлбуки, шушы вакыт эчендә күп авырлыклар кичергән һәм үз юлын табу турында күп уйлаган. Әгәр сез аның кайнар күз яшьләре белән сугарылган хатын укысагыз бәлки калбегез йомшара төшәр иде.
Хөсәен ачы елмаеп:
— Һәм бик озак уйланганнан соң, ул баеннан бәдәл алып хаҗга китәргә булган. Шулаймы?,— диде.
Тукай дәшмәде. Хөсәен һөҗүмне дәвам иттерде.
— Әгәр син, Габдулла туган, революцияләрнең тарихын ныклап өйрәнсәң, күрерсең, моңарчы булган гадәләт өчен көрәшләрне әнә шул Җәгъфәр ишеләр һәлакәткә китергәннәр. Менә ни өчен без аларга карата артык сак, менә ни өчен без андыйларны яратмыйбыз. Син мине беләсең, дускаем, мин кеше кавемен ихлас күңелдән сөючән бәндә. Мәгәр шулай булуыма карамастан, дөресрәге, шуңа күрә мин аумакайлар һәм битараф булып кыйланучыларга һәрвакыт шикләнеп карыйм. Хәер, мөмкин булса, бир әле миңа шуның хатын.
Тукай өстәл астындагы кәрзингә иелде һәм тиз арада Җәгъфәрнең хатын табып, аны Хөсәенгә сузды.
— Рәхим итегез. Сездән яшерен берни дә юк, Хөсәен әфәнде.

## 4

Җәгъфәр үзенең хатында Габдуллага түбәндәгеләрне язган иде.
«Хөрмәтле вә инсаниятле Габдулла әфәнде!
Сезнең гүзәл һәм тирән мәгънәле шигырьләрегезне «Вакыт», «Әльислах», «Йолдыз», «Яшен» вә башка матбугат сәхифәләрендә укып барсам да, хәтта сезнең Казаныбызда «Болгар» номерларында яшәвегезне белсәм дә, моңа кадәр сезгә мәктүп күндерергә базмадым. Сезне борчыйсым, сезнең кадерле минутларыгызны үземнең уй-тойгыларым белән бүлдерәсем килмәде.
Хәзер исә артык түзәрлек тәкатем калмады, кулыма каләм алдым. Һәм, шашынып, үземнең кайгы-кичерешләремне сезгә хат аша бәян кылырга керештем. Вакытыгызны юкка исраф кылсам, гафу итегез.
Мин моннан өч ел элек, сездән аерылгач, Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсен бетереп чыккан бер егетнең киңәше буенча, ач үлемнән котылу

өчен, казакъ арасына мөгаллим сыйфатында киттем. Кустанай далаларында Убаган елгасы буендагы бер бай казакъ, мәрхәмәт кулын сузып, мине үзенең оныкларын укытырга алды. Укытасың, берак дин сабагын гына, диде. Шулай итеп мин яңадан кайчандыр үзем ташлап киткән мәдрәсә елларын искә төшерергә, һәфтиякне кулга алырга мәҗбүр булдым. Хәерле булсын, дидем, бу — минем мәсләгемә каршы килү килүен, тик хуҗаның сүзенә риза булмый ярамый. Шулай да күңел түрендә, үзем теләгән эшләрне башкара алырмын әле, дигән өмет чаткысы көйри иде. Мин үзебезнең халык арасында җәмгыятькә файдалы эш майтарудан ваз кичкәнмен икән, бәлки монда ак патша изүен, ыруг талашларын, коллык һәм наданлык кичергән кардәш казакъ халкына булдыра алганча файдалы хезмәт күрсәтермен дигән өмет белән яши башладым. Өметем: балаларга дини схоластиканы гына түгел, дөньяви фәннәрне дә укытып, аларның күзләрен ачарга булышу иде. Адәм баласы һәр төрле шартларда да үзенә рухи тигезлек халәте таба икән. Мин «мулдәкә»легемнең беренче елларында, ниһаять, тормышта үземнең урынымны таптым, шул юлдан гомер буе атларга кирәк булыр, дип уйладым. Тиз арада казакъ телен үзләштереп алдым. Рус, татар, казакъ телләрен белүем, бик тырышып балалар укытуым баем алдында да абруемны күтәрде, хәтта чак кына аның кияве булмый калдым. Тик бер тәсадеф[1] кына мине коткарды. Бай кызының үпкә чиреннән вакытсыз үлеп китүе мине баемның кияве булудан азат итте. Хәер, мин ул вакытларда моңа кайгырдым да. Байның ирдән калган кызы чыннан да чибәр, иркә бер зат иде. Хәтеремдә, соңгы таянычым да җимерелде, дип бик кайгырдым. Мәгәр миңа димләгән кызы үлгәч тә бай мине ташламады. Тормышка ашмаса да мине хакыйкый кияведәй үз итте. Җәйләүдән-җәйләүгә йөреп, кымыз эчеп, кәеф-сафа коруны гына белгән җүнсез улларыннан мине якынрак күрде. Тора-бара мин, баемның иң якын киңәшчесе сыйфатында, аның белән ыруг талашларына катнаша башладым. Казакъ куылган җирләрне кайтару өчен, ыругның патша чиннарына йөрүче ышанычлысы булып киттем. Бай мине бер генә житди бәрелештән, яки мөһим мәсьәлә хәл кылына торган җыеннан калдырмас булды. Ул миннән берни дә кызганмады. Мулдәкә, ыругымнан теләсә нинди яшь толны хатынлыкка ал, бездә гомергә кал, синең белән каннар да берексен, мал кирәк икән, канча теләсәң, шулкадәр елкы бирәм, куй бирәм, мөгезле эре терлек бирәм, дия башлады. Ул бик бай иде. Биш йөз баштан артык иде аның җылкысы гына да. Хәлбуки байның юмартлыгы улларында миңа карата сүнмәс бер нәфрәт уятты. Алар мине кан дошманы итеп күрә башладылар. Һәр мөмкинлектән файдаланып, мине халык каршында пычратырга тырыштылар. Байга төрле гайбәтләр җиткереп тордылар. Әмма бай ифрат акыллы кеше булып чыкты. Ул, коткыга бирелмәстән, мине бер вакытта да үз канаты астыннан чыгармады. Тик шулай да ул да аңлый иде, күрәсең. Картайган, көче бетеп бара, бер көнне мотлакан балалары кулына калачагын аңлый иде. Чираттагы бер әләктән соң ул мине үзенең ак тирмәсенә чакыртты. Чырагым,— диде,— мин барысын да күреп торам гүй. Улларым сине җаман күрәде, минем яклавым булмаса, алар сине шундук өзгәләп ташларга торалар. Алар мин үлгәч синә мирас калудан куркалар. Алар ахмак, алар синдәй кешенең безнең көннәрдә бик кирәк икәнлеген белмиләр. Син булмасаң, узган талашларда дошман ыругларын ялгызым җиңеп чыга алыр идеммени?! Алар шуны аңламыйлар. Ачудан күзләрен кан басып киткән, алар синә «чашка бас» нугай дип кенә карыйлар. Мин боларның барысын да күреп торам гүй. Казакъ яхшылыкка каршы начарлык кылмайды. Син яхшылык кылдың, инде мин дә синә бер яхшылык күрсәтәен. Яшем алтмышка житте,

---

[1] Тәсадеф — очрак.

кулларымнан көч китеп бара ятыр, тик моңарчы дөнья мәшәкате артыннан куып, ахирәт эшләренә кулым җитмәде. Хаҗ кылып киту иде минем исәбем бу дөньядан. Инде күрәм, бу мөмкин эш булмастыр кебек. Шуңа күрә сиңа бәдәл [1] биреп, уз урыныма хаҗга сине җибәрмәкче булам. Бу сине вакытлыча булса да улларымның явыз эшләреннән коткарыр, алар да, бәлки, син киткәч, акылларына килеп, нәфрәт исереклегеннән айнырлар. Менә минем шундый теләгем бар, шәт син моңа риза булырсың, диде. Мин аңа рәхмәтләр укыдым, яхшы, утагасы, сезнең сүзегез минем өчен атамның сүзедәй якын, дидем. Тик шулай да уйга калдым. Әгәр мин байның бәдәлен алып, хаҗ сәфәрләренә чыгып китсәм, нәрсә көтә мине алда? Бу минем карашларыма, мәсләгемә туры килерме соң? Мине хыялымнан тагы да читкәрәк алып китмәсме бу эш? Мине әнә шундый уйлар, сораулар бимазалый башлады. Ахыр чиктә хаҗ сәфәре булган хәлдә, мин үземә таянычны, кеше өчен кирәкле таянычны кайдан табармын дип баш вата башладым. Мин узган юлымны бәйнә-бәйнә күздән кичереп чыктым. Анык белдем, мин инкыйлап юлын сайлый алмыйм. Бу минем кулымнан килми. Ни өчен? Чөнки мин аның кешелекне гадәләткә илтүенә ышана алмыйм. Кеше һаман үзенең алла биргән сыйфатлары белән теләсә нинди социаль тәртипләрдә дә кеше булып калачак. Мин милләтчеләр белән дә бер сафта була алмыйм. Чөнки, кайчандыр, бишенче елны ук, мин аларның пароходта уздырылган корылтайларында булып, мондый эшнең барып чыкмасына ышандым. Мин, ниһаять, рус мәдәниятенә йөз тотып, халыкны агарту мөмкинлегенә дә ышана алмадым. Чөнки Европалашу ул диннән, шәригать законнарыннан йөз чөеру. Шунда мин диннең милли яшәеш өчен нинди зур терәк икәнлеген аңладым. Мин күптән хәтердән чыккан әйберләрне искә төшерә башладым. Диннең изгелекләрен өйрәнгән саен тирәнгәрәк керәсем килде, ниһаять, әллә чыннан да баемның тәкъдимен кабул итеп ислам диненең ватаны булган җирләргә барып, динислам өлкәсендәге мәгълүматымны киңәйтимме, бәлки бу миңа урталыкта яшәүдән котылу өчен бер мөмкинлек тудырыр дип уйлана башладым. Тик миңа тагы ниндидер олы затның акыллы киңәше кирәк булды. Бу теләк бераздан көйрәп торган күмер кисәгеннән ут ялкынына әйләнде. Мин сездән дә лаек кеше таба алмадым.

Хөрмәтле Габдулла әфәнде, мин сезнең бәхетсезлеккә очраган һәрбер кешегә кул сузарга әзер торуыгызны беләм, шуңа күрә хатымны җавапсыз калдырмассыз дип уйлыйм.

1910 сәнә, февраль. Җәгъфәр».

## 5

Хөсәен, артыннан килгән «койрык»тан котылу өчен генә, трамвайдан төшеп, Проломныйга, халык арасына кереп киткән иде. Ул бүген ничектер башта ук абайлап өлгермәде, соңгарыбрак искәрде. Иртәнге якта Казан комитеты каршындагы округ группасы җитәкчесе Лотов Николай Николаевичта булды ул. Аңардан кирәкле яшерен адреслар алып, Яңа Горшечный урамыннан шәһәрнең үзәгенә таба юл тотты. Бары, бер-ике чат узгач кына, Лотовка кергәндә үк күзәтеп калган кешене абайлады. Әйе, Лотов бик нык сак астында яши иде. Аңа кергәнчыккан һәрбер кеше күзәтү астына эләгә. Хөсәен аннан котылу өчен, артык озак уйламастан, узып барган трамвайга сикереп менде, халык арасына чумды. Тик теге кеше дә трамвайга ябышырга өлгерде. Бәхеткә каршы, пассажир күплеге генә аңа алга узарга, Хөсәенгә якынла-

[1] Бәдәл — үз урынына кеше яллап хаҗга җибәрү

шырга ирек бирмәде, ул халыкны этеп-төртеп болай таба килә башлауга, Хөсәен алгы ишектән төшеп калырга да өлгерде. Болакка таба борылып, тиздән Мокрый урамындагы яшерен типографиягә якынлашты. Кичекмәстән андагы иптәшләрне кисәтергә кирәк, охранка яшерен типографиянең эзенә төшкән, әле хәзергә аның кайдалыгы гына мәгълүм түгел. Тәгаен аның тиздән беленүе мөмкин. Моны хәбәр итеп өлгерергә кирәк иде. Бу хәл Лотов белән сөйләшкәннән соң ачыкланды. Партия директивасы шундый, нинди генә юллар белән булса да, типографияне саклап калырга кирәк. Хөсәен камытлар, дугалар, сбруя һәм шуның ише кирәк-яраклар сатыла торган бәләкәй генә, дегет исе аңкып торган агач кибеткә бик эшлекле кыяфәттә кереп китте. Кибеттә кеше заты юк иде. Аңа сары мыеклы яшь кенә рус егете кибет аша складка керү ишеген ачты. Бераздан ул склад подвалындагы ярым караңгы типографиядә иде инде.

Карт печатник, әле күптән түгел генә сөргеннән кайткан Тимофей Логинов, хәвефле яңалыкны алдан ук сизенгәндәй, Хөсәенне шомланып каршы алды.

— Эш хөрти,— диде Хөсәен, картның буялып беткән кулын кысып,— күченергә кушалар.

— Тагымы?

— Тагы, һәм бу юлы шактый еракка.

— Бәлки Царево-Кокшайскигадыр? Анда минем бәйләнешләр әйбәт.

— Юк,— диде Хөсәен.— Нижний Новгородка.

Карт йөзен чытты. Хөсәен, болай да аңлашыла бит дигәндәй, авыз чите белән генә көлемсерәп куйды.

— Аңлыйм,— диде Тимофей.

— Менә нинди карар чыгарылды: басылырга тиешле материалны өлгертү белән, басу станогын сүтеп әрҗәләргә тутырырга. Бу эштә иптәшләр ярдәмгә килер. Шрифт һәм станокны шулай салырга кирәк ки, аны Устьега алып барганда да, пароходта да нәрсә икәнлеген белмәслек булсын.

Хөсәен, эшләрен төгәлләп, өенә кайтып кергәндә сәгать кичке тугызны суга иде. Хәдичә әчке бүлмәдә дәрес хәзерләп утыра. Аңа комачауларга ярамый. Ул Расинцев мәктәбендә теш табиблыгына укый. Әле Хөсәеннең кайтып кергәнен сизмәде дә булса кирәк. Хөсәен кухня якка кереп, аннан олы якка бер чынаяк чәй белән катлама алып чыкты да, китапларын ачып, өстәл янына урнашты. Хөсәеннең күптән хыялланган максатына ирешү көннәренә ерак түгел иде инде. Прошение бирелгән, Хөсәен бернигә дә карамастан, университетка керергә тиеш. Бу аның хыялы, бик күптәнге хыялы. Төшләренә кереп алҗыта, һәрбер буш минутын үзенә тарта торган хыял.

Хөсәен тарих сәхифәләренә кереп чумгач кына, күрше бүлмәдән Хәдичәнең тавышы ишетелде.

— Хөсәен, син кайткансың икән ич, ник дәшмичә торасың? Әнә кухня өстәлендә тастымалга төрелгән мискидә аш, ит-бәрәңге бар. Теләсәң, кичәге кишер бөккәне, катлама бар. Алып аша.

— Ярый, бераздан. Мин укыйм әле,— диде Хөсәен. Кайтып керүен сизмәмешкә салышкан Хәдичәгә ачуы килеп китте.

Аларның аралары киеренке иде хәзер. Өйдә ир белән хатын арасында ачыктан-ачык кискен бәрелешләр булмаса да, алар бер-берсеннән көннән-көн ераклаша баралар. Һәм моны икесе дә сизгән хәлдә, яңадан элеккечә якын, иңгә-иң торып яшәү өчен берни дә нәтиҗәле чара күрә алмыйлар иде.

Хәдичәнең теш врачлыгына укый башлавы да асылда Хөсәеннең изге эшендә бер ярдәм күрсәтү теләге белән туган гамәл түгел, киресен-

чә, аннан мөстәкыйль булу, ул тапканга карап яшәмәү өчен иде. Бу исә шулай ук Хөсәенгә авыр тоелды. Әлбәттә, ул бер тапкыр да сүз кузгатмады, хатынының укырга омтылуына ихлас күңелдән куану гына белдерде. Ләкин шулай да...

6

Яз Казанга артык ашыгып килде. Март ае кереп, үзенең бураннарын дулатырга өлгермәде, күк йөзен яңгыр болытлары сарып алды, вак яңгыр сибәләргә кереште. Тротуарларда кар эреде, Арча кыры калкулыкларыннан гадәттә апрель азакларында гына була торган гөрләвекләр ага башлады. Шәһәр халкының хәллерәкләренә бу яз калошны бик иртә кидертте, фәкыйрь-фөкара исә, күпчелеге татар агай-эне, киез итекләргә такта күтәртмәләр бәйләргә мәҗбүр булды. Идел бозы күгелҗем-яшькелтләнеп күперде, өстенә туш чыкты. 26 мартта инде Югары Ослан турысыннан боз кузгалды. Ә инде җиденче апрельдә бөтен Иделне иңләп, котырынып ташу ташый, боз ага башлады. Бозлар китеп, елга өсте арчылу белән, Стахеевлар «Кавказ һәм миркурий» акционер җәмгыяте пароходларын елгага төшерергә ашыктылар. Күрер күзгә су өсте чистарган кебек булса да бозлар елгада астыртын гына ага, шуңа күрә көймәләргә утырып йөрү шактый хәвефле иде бу көннәрдә.

Пассажир азлыгыннан файдаланып, табыш арттыру өчен теләсә нинди йөкне төяргә әзер торган пароход хуҗаларының комсызлыгыннан файдаланып, Казан комитетының яшерен типографиясен, мөмкин кадәр тизрәк, Нижнийга озатырга карар кылынды. Бу эшне башкаруга Лотов, Зарницын, Комлев һәм Хөсәен Ямашевлар җаваплы иде. Лотов Хөсәенгә соңгы очрашуда Нижний Новгород белән бәйләнешкә керүен хәбәр итте, тик печать станогын пристаньгә алып төшү мәсьәләсе генә әлегә хәл ителмәгән. Бик ышанычлы ломовой кирәк, машинаны Устьега, әлбәттә, төн караңгысында алып барырга туры киләчәк.

— Әле кайда соң ул печать станогы? — дип сорады Хөсәен.

— Хәзергә без аны шул ук Мокрыйда гына яшерә алдык.

Хөсәеннең хәтеренә кылт итеп Шәрифулла абзый төште. Хөсәеннәргә җаны-тәне белән булышып йөргән, революциягә ярдәм күрсәтәм дип, бишенче елны төпчек улыннан язган Шәрифулла абзый. Исән микән әле ул? Казанга кайтканнан бирле Хөсәеннең аларга барганы юк иде. Хөсәен Лотовка үзенең уй-ниятен әйтеп бирде: «Әгәр барысы да без теләгәнчә барып чыкса, бабай безгә һичшиксез ярдәм итәр»,— диде.

— Әмма бу эшнең бик ашыгыч икәнлеген онытма,— диде Лотов,— үзең күреп торасың, жандармерия артыбыздан үкчәгә басып йөри. Алар бүген булмаса иртәгә типография җиһазын яшерелгән җиреннән табып алачак.

Хөсәен Гыйльфанны эзли китте. Хөсәеннең үзенә Шәрифуллага бару ярамас иде. Чөнки аны белүче шпиклар аз түгел. Ә Гыйльфанны ул тирәдә күргән кеше юк, ул Крестовников заводы һәм Яңа бистә тирәсендә күбрәк чуала.

Гыйльфан сменадан кайту белән елга аръягына китте. Хөсәен түгәрәк йөзле, ничектер моңлы карый торган яшькелт зәңгәр күзле дусты артыннан ук диярлек барды. Ләкин ул Шәрифуллалар өенә барып житәр-житмәс, бишенче ел революциясе көннәрендә яшерен очрашу урыны булган чәйханәгә кереп калды. Гыйльфан озак көттермәде. Хөсәен, таш чәйнектән агызып бер чынаяк кайнар чәй эчәргә өлгермәде, ул Хөсәен янына әйләнеп тә кайтты.

Гыйльфан Хөсәенгә карамыйча гына:

— Өендә ул,— дип пышылдады.
— Керергә ярыймы соң, мин биргән язуны укыдымы?
— Бик озак маташты. Кем соң бу, дигән була, мин бит андый кешене белмим дә, дигән була.
— Менә жен,— дип сукранып куйды Хөсәен,— беренче сорт конспиратор яки коты алынган бер мескен.
Гыйльфан чәй китертте. Аны ашыкмыйча гына чынаягына койды, шикәр тешләп, чәен тәмләп бер йотты, шуннан соң гына мәченекедәй хәйләкәр күзләрен Хөсәенгә текәде.
— Бер дә куркак, мескен түгел, бабай — шәп конспиратор. Соңыннан ул минем дөресен әйтүемә ышанды.
— Соң миңа анда керергә ярыймы, нәрсә сузасың.
— Ярый, ярый, Хөсәен, тик ул кадәр кычкырып сөйләшмә. Тик шулай да сак бул. «Койрык» тагылмасын. Бабай теге бишенче елгы хәлләрне охранка онытмый, ди, бик нык күзәтәләр, ди.
— Яхшы, мин киттем алайса, хәзергә сау бул, рәхмәт,— дип, Хөсәен урыныннан кузгалды.
Биш минут узмады, ул инде Шәрифулланың җиргә иңә башлаган агач түбәле өе янында иде. Тузып чери башлаган агач капкадан кергәндә аны бер мизгелгә хатирәләр, бишенче елның давыллы истәлекләре күмеп китте. Бу кунакчыл өйдә ничә тапкырлар җыелышып, алдагы көрәш һәм җиңү рухы белән канатланып, дәртләнеп утырмадылар алар. Барысы узды, инде тауга менеп җиттек дигәндә генә бозлы сукмак буенча тагы түбәнгә, караңгыга шуып төшеп киткәндәй булды ул чак. Тагы барысын да яңа баштан кузгату, тагы тырмашып өскә үрмәләү. Хәер, бусы ул вакыттагы үрмәләү түгел инде. Бу юлы сыналган кешеләр, тауның үзе кадәр зур тәҗрибә туплаган кешеләр. Хөсәеннең күңелен бер мизгелдә сызып үткән уйлар шулар иде. Ул алдан ук ачып куелган ишектән керде. Нәкъ теге вакыттагыча — сәкеле алгы як бүлмә, хуҗа да нәкъ элекке киемнәреннән: җиңсез комзол, түбәтәй. Тик аның хәзер инде яңаклары тагы да суырыла төшкән, сакал-мыегына куе булып бәс кунган. Күрәсең, ул да Хөсәенне элекке кыяфәтендә күрергә җыенгандыр. Ләкин каршында — эшче агай-эне кия торган постау пиджак, чалбар, кун итек кигән, башына ямшәйгән картуз чәпәгән Хөсәенне күргәч, ул бермәл ни әйтергә дә белми өнсез торды.
— Мин бу, мин, Шәрифулла абзый. Алайса таныш булыйк — Хөсәен атлы кеше булам мин.
— Күрәм, күрәм... Тик менә бик өшәнеп киткән син. Хөсәен, әллә чирләп йөрисеңме?
— Чирләргә вакыт юк әле, Шәрифулла абзый. Мөһим эшләр тора алда.
Хөсәен, карт белән исәнләшеп, сәке читенә утырды. Ул арада судан Шәрифулланың хатыны Маһитап та кайтып керде. Карчык бу елларда аерата бетерешкән иде. Ул Хөсәенне бөтенләй танымады да, аны рус кешесе дип уйлап «здрасти» дип исәнләште. Ирләр тавышланып көлә башлагач кына ул, күзләрен кыса төшеп, яңадан Хөсәенгә текәлде. Ниһаять, таныды.
— Сөбханалла, үзебезнең Хөсәен түгелме соң? Катыр киткән ул дип сөйләнәләр тагы!
— Әйе, әйе, анысы да хак сүз, сине, Хөсәен, жиденче ел азагында ук сөргенгә куганнар дигән сүз булды.
— Мин инде җиденче ел азагында Казанда идем. Оренбурда газета чыгаруымны син яхшы хәтерлисеңдер. Гафур миңа сезнең өйдә җыелышып ул газетаны укыганлыкларын язган иде.
Карт карчыгына кул гына селтәде.
— Майтап берни дә белми ул, без инде андый эшләрне үзебез генә башкардык.

Хөсәен, якты чырай күрсәтеп, Мәһитапның кулын кысты.

— Ничек соң кәефләр, исәнлек-саулыкмы, Мәһитап апа?

— Үзебезне үзебез йөртә алганга шатланып, аллага шөкер дип торабыз инде, Хөсәен, юкса карт та, мин дә кайчак, әҗәлебезне көтеп, кәефенлекләр барлый башлыйбыз.

Карт тагы кулын өметсез селкеп куйды. .

— Юкны сөйли ул. Булмаганны. Каян килеп әҗәл көтсен ди синең арыслandaй Шәрифуллаң. Юкны сөйли, ышанма аңа, Хөсәен. Барысы да әйбәт, давай әйтер сүзеңне башла. Ә син, карчык, безне түр якка озат та әйбәтләп чәй әзерлә, самаварыңны куй. Әнә, Хөсәен тамак кибеп китте әле, дип тора.

— Әле генә чәйдән торыш,— диде Хөсәен елмаеп. Ул картның көр күңеллегенә шатланып, эчтән һаман көлемсерәгән хәлдә, Шәрифуллага ияреп, түр якка чыкты. Кайчандыр алар менә шушы түр якта, идәндә ашъяулык җәеп, чәй алдында сыйнфый көрәш әлифбасын өйрәнәләр иде. Ә хәзер монда да үзгәреш күренә, бүлмә уртасында киндер ашъяулык ябылган бәләкәй кенә өстәл, аның тирәсендә артсыз утыргычлар тора.

Алар кара-каршы утырыштылар да сүзгә керештеләр.

Икенче көнне сәгать төнге унберне сукканда, Мокрый урамындагы ике катлы чалшайган агач өйнең капкасыннан иске комод салынган арбалы ат күренде. Ат тотканы, мескен бүрекле татар абзые һәм аның янында эшләпә кигән накидкалы кеше утыра иде.

Төнге караңгылыкта алар артык күзгә чалынмадылар. Тиздән Казан елгасы аша салынган күпердән узып, Устьега юнәлделәр. Бу кешеләрнең эшләпәлесе — Хөсәен, ә дилбегә тотканы исә Шәрифулла абзый иде. Ниһаять, ат аларны Устье юлына алып чыкты. Йомры таш җәелгән бу юл бөтен саныңны дырылдата. Хәтта яңак итләрең калтырата иде. Мәгәр Хөсәен комод эченә яшерелгән машина турында күбрәк борчылды. Ярый ла, бу комодның юка такталары чыдаса... Шәрифулла үзе дә Хөсәеннең борчылып баруын тойды ахрысы, атны юл читенә, таш җәелмәгән урынга алып чыкты.

Биткә җепшек Идел сулышы орына. Тәрәзәләрдән күренгән һәр ут юлчыларны хәвефләндерә, сагайта. Әйтерсең лә; шул тәрәзәләр аша барын да күреп торалар. Әйтерсең лә, алар бу комод эчендә нинди әйбер алып барылганын һәм озакламый ул яңа урында дәһшәт салачагын беләләр. Хөсәен ирексездән тирә-юнен, сунарчыдан сакланган җәнлектәй, күзәтә барды. Тамак кипшенә, күзләр ялкынсынгандай авырта иде. Менә алар кызыл кирпечтән салынган Петрушкин төрмәсен узып, бераз барганнан соң буш кырга килеп чыктылар. Шылт иткән тавыш, бер генә хәрәкәт булсынчы! Бары Идел өстендәге пароход утлары гына җемелди. Әллә нигә бер гудок авазы ишетелә.

— Исән-сау барып җиттек булса кирәк,— диде Хөсәен маңгай тирен сөртеп.

— Ашыкма, әле шактый җир үтәсе бар,— диде Шәрифулла.

Дебаркадер янында үзенең җылы сулышы белән бөтен тирә-юнне җанландырып Нижний Новгородка китәргә тиешле пароход тора иде.

Атлылар дебаркадер янына килеп җитүгә, аларга дүрт кеше якынлашты.

— Кая, барин, бу комодны кертәсеме? — диде аларның берсе. Егетләрнең барысы да таныш иде. Ләкин алар бүген крушник киемнәреннән.

— Бәясеннән тормам, алып керегез,— диде Хөсәен. Егетләр йөкне дәррәү тотынып, арадагы иң калку, пәһлеван гәүдәленең аркасына салдылар. Егет, аякларын шактый аерып атлый-атлый, иптәшләренең

озатуы астында пароходка таба басма буйлап төшеп китте. Арттарак калган егеттән Хөсәен шыпырт кына сорады:

— Калган әйберләр килеп җиттеме?

— Алар күптән трюмда, без сезне килеп җитә алырлармы дип, бөтенләй хафага калган идек инде...

«Ярый, барсы да без теләгәнчә, уңышлы барып чыкты булса кирәк», дип, җиңел сулап куйды Хөсәен.

Май башында полиция Лотовның эзенә төшеп, аны кулга алды. Ләкин Казан большевикларының типографиясе эштән туктамады. Бу вакыт типография Нижнийда үзенең хәтәр хезмәтенә керешкән иде инде.

V

Офыкка кадәр җәйрәп яткан, өстәлдәй тигез, ямь-яшел далада нәрле атка атланган бер яшь кеше бара. Ул ерактан килә ахры, аның аты шабыр күбеккә баткан, җайдак чаптар атын хәзер атлатып кына бара. Бу бай казакъка «мүлдәкә» булып ялланган Җәгъфәр иде. Әле байның рөхсәте белән Кустанай шәһәреннән җәйләүгә кайтышы иде аның. Ара ерак түгел, бары алтмыш биш-җитмеш чакрымнар гына исәпләнә. Җәгъфәр кичә китте, бүген инде кайтып та килә.

Ул, әле дала буйлап ат өстендә барганда, үзенең хәзерге рәхәт минутларына куана. Ямьсез уйларны үзеннән куарга тырыша, букчасындагы Казан газетлары турында уйлый, алда аларны укып яту минутларының ләззәте белән рухлана. Ә тирә-юньдә дала яз тантанасын кичерә. Тургайлар өзлексез чөр-чөр сайрап озаталар аны. Тирә-юне камышлыклар белән капланган якты күлләр очрый. Анда бихисап үрдәк-каз, торналар. Әйе, язын кыргый даладан да гүзәлрәк җир тагын бар микән! Җәгъфәр татлы уйларыннан аерылып, табигатьнең язгы уяну түен, андагы җан ияләренең тантанасын тамаша кыла иде.

Казакъ бае ишле нәсел-ыруы белән моннан унбиш көннәр элек кенә җәйләүгә килеп урнашкан иде. Монда аның җирләре, монда ул хаким, монда аның сүзе генә закон. Ләкин ул, бәхеткә каршы, Җәгъфәрне яратты һәм аны үз канаты астына алды. Җәгъфәр дә үз эшенең кадерен белеп, байга мөмкин кадәр яхшылык эшләргә тырыша.

Бай яңа җәйләүгә күчеп килгәч, Җәгъфәр үзен бөтенләй башка дөньяга эләккәндәй хис итте. Иркен дала һавасы, шифалы май кымызы, болар барсы тәнгә генә түгел, җанга да рәхәт тынычлык бирделәр. Тик шулай да күңелне, ургылыпискән җилдәй, авыр ямансулык туфаннары күмеп китәли иде. Алда — хаҗ сәфәренә бару мәсьәләсе тора. Бу — вакытлыча гына булса да, кимсетелү газапларыннан котылып тору, әлбәттә. Тик ерак юлда кешене ниләр генә сагаламый. Бәлки бу хаҗ кылам дип, бай саваплы булсын дип йөрү Җәгъфәрне бөтенләй туган иленнән аерыр. Әгәр шулай икән, кирәкми аңа хаҗлары, сәяхәтләре. Хәер, ни күрде соң әле ул туган илендә! Әйе, Җәгъфәр аек акыл белән, никадәр генә хәл-әхвәлен бәяләргә тырышмасын, май аеның далага китергән гүзәллекләренә дә карамастан, аның күңеле әллә кайларга, ерак-еракларга ашкына бу тормыштан, ялгыз, сердәшсез, иптәшсез, тынчу тормыштан котылу җаен карый. Әле бу яңа урынга күчеп киләсе көннәрдә генә ул Габдулла Тукаевтан кыска гына хат кисәге алды. Тукай турында ул башкача уйламаган да иде. Шагыйрь, аның фикеренчә, иң кешелекле бер зат иде. Җәгъфәр кулына хатны алгач та бу фикернең рас булуына тагы бер тапкыр ышанды. Тукай үзенең хатында Җәгъфәргә мәгърифәт өлкәсендә уңышлар теләгән. Хаҗга бару мәсьәләсендә ул кистереп ни әйтергә дә белмәвен, хаҗ сәфәре — дөнья күрү, сәяхәт җәһәтеннән шактый күңелле нәрсә булса да, ахыр чиктә

билгеле бер дини максат аркасында эшләнгәнгә күрә, бу эш Җәгъфәрнең шәхси эше, намус эше икәнлеген белдергән. Димәк, дип уйлады Җәгъфәр, мин Тукай әфәнде карашынча, үз ихтыярым белән хәл итәргә хаклы бу мәсьәләне.

Сыек зәңгәр күк йөзе аяз. Кояш инде төшлектән шактый түбәнәйгән. Ләкин шулай да көн ифрат җылы, бөтен дала үзенә бер төрле кош сайраулары белән тулган. Тар сукмактан барган атның бәкәленә язгы сары чәчәкләр тиеп китә. Бөтен тирә-яктан борынга хуш ис сирпелә. Ул ис, татлы шәраптәй, кешене җиңелчә исертә һәм күңелгә гамьсезлек ләззәте бирә иде.

Бераздан еракта җәйләү дә күренде. Әнә, тирмәләр арасыннан күзгә нык ташланып, Туктыбайның зур ак киез өе калыккан, аның белән янәшә байбичәнең шундый ук ак киездән корылган тирмәсе, аннан ары бай улларының киез өйләре һәм тукал өе тезелеп киткән, иң ары—капкара киез өйләр төркеме. Болары — фәкыйрь ерак кардәшләренең, ялчыларның, көтүчеләрнең тирмәсе. Әнә шулар арасында Җәгъфәрнең дә бәләкәй генә тирмәсе бар. Бәхеткә каршы, аның үзенә генә билгеләнгән тирмәсе бар. Җәгъфәр озакламый, тирмәсенә кереп көрпәгә сузылып ятачак һәм Кустанайдан алып кайткан Казан газеталарын укый башлаячак.

— На, на, малкай, на ак койрыгым, ак ялым!

Ләкин Җәгъфәр тиз генә максатына ирешә алмады. Җәйләүгә якынлашкан саен, аның зиһенен чуалтып, нинди дер ямьсез тавышлар ишетелә башлады.

Җәгъфәр җәйләүгә җиткәч җиргә төште, атын тезгененнән тотып тавыш килгән якка таба китте. Барлык җәйләү халкы җыелган иде бирегә. Уртадагы баганага нинди дер таза бер ир кешене кулларын күтәртеп бәйләгәннәр, ярым ялангач шул ирне чыбыркы белән кыйныйлар. Суккан саен, бәйләнгән кешенең ялангач аркасында канлы юллар сузылып кала. Ул, суккан саен, җан ачысы белән үкерә иде. Җәгъфәр мондый вәхшилектән тетрәнеп артка чигенде, атын алып китәргә килгән көтүчедән: «Бу ни бу, ни өчен?» — дип сорады.

— Байның туктысын урлап суйган гуй,— диде теге. Я, хода, бер бүлтерек сарык өчен шундый җәзамы?

— Әле моның белән генә бетмәс, ни булганын менә күрерсең,— диде көтүче. Ул, артык бер сүз дә дәшмәстән, гадәттәгедән дә ныграк бөкрәйгән мескен бер кыяфәттә, чапанны ияртеп алып китте. Хуҗа үзе биредә юк иде. Ул, күрәсең, хөкем чыгарган да, киткән. Күзәтеп торуны улларына тапшырган.

Угры көтүче бераздан бөтенләй тынып калды, ә инде аркасында берничә тапкыр каеш чыбыркы чажлаганнан соң, кинәт аның әлегәчә текә торган башы җилкәсенә салынып төште. Кайсыдыр «булды» дип кычкырды. Угрыны, бауларын чишеп, җиргә сузып салдылар, аякларына тубыктан югары кыл аркан бәйләделәр. Җәгъфәр хәйран калып, өнен җуйган хәлдә, якындагы тирмә керәгәсенә сыенды. Кемнәрдер көтүдән яңа тотылган, әле бер тапкыр да җигелмәгән кыргый кара айгырны җитәкләп китерделәр, аның муенына корык элмәге салганнар, икенче бер ялчы атның өске иренен боргычлап тоткан. Ат пошкыра, тибешергә итә. Ләкин аңа ирек бирмиләр, күзләрен кан баскан кешеләр кабаланып, җирдә яткан карак көтүченең аягындагы бауны атның койрыгына бәйләп маташалар. Атны шулай дала иркенлегенә җибәрергә исәпләре.

Җәгъфәр түзмәде, атылып чыкты да:

— Үлә бит, теткәләнә кеше, нишлисез сез! — дип кычкырды.

Байның олы улы Балтабай, явыз мыгырданып, нидер әйтеп куйды. Җәгъфәр аның сүзләреннән «тыгылма, синең эшең түгел», дигән мәгънә генә аңлады. Ул күргәннәренә ышанмыйча, башын чайкый-чайкый

сөрлеккәләп, үзенең тирмәсенә таба китте. Киез өйгә кереп, мангаен кирәгәгә төртеп бик озак ятканнан соң торып әле генә Кустанай каласыннан алып кайткан газеталар төргәген кулына алды. Тагы ятты. Юк, юк, хәзер аны көтелгән рәхәт кичерешләр били алмый иде инде. Ул укыганнарын озак кына вакыт зиһененә сеңдерә алмыйча ятты. Ниһаять, баш авыртуы әкренләп беткәндәй булды. Җәгъфәрнең тетрәнгән күңеле дә язылса башлады, газета хәбәрләре ачыкланганнан-ачыклана, аңлашылганнан-аңлашыла бардылар. Анда бик-бик сагындырган туган як хәбәрләре язылган иде. Кадерле, ләкин Җәгъфәрне гомергә тибәргән якның хәбәрләре. Менә ул Тукай язган безнең нурлы, моңлы Казан. Карасана, Шәрык клубында лото уйныйлар имеш. Бу көннәрдә Алафузов заводыннан 900 эшче чыгарылачак дигән хәбәр бар. Нишләрләр инде ул мескеннәр. Җәгъфәр шушы урында тукталып кайчандыр үзе эшләгән Алафузов заводының цехларын күз алдыннан кичерде. Ләкин ул анда беркем белән дә якыннан дуслаша алмаган иде, яратмадылар аны, сатлык җан дип аңардан шикләнделәр...

Җәгъфәр газетадан «Бүген якшәмбе 17 гыйнварда... музыка кичәсе була... урын бәһалары утырырга 40 тиен, керергә 53 тиен» дигән юлларны укыды. Күңеле тәкатьсез булып тыпырчынып куйды. Я, хода, шунда булсаң иде. Һич югында бер генә минут...

Газетада «Шәрык клубын»дагы бер кичәнең ярты килере Догадов исемле кешегә Прага конференциясенә бару өчен бирелә, дип хәбәр иткән иде. Кем ул Догадов? Тәгаен берәр революционердыр. Тәгаен бу эшне Хөсәен Ямашев оештыргандыр.

Җәгъфәр газетаны тоткан килеш тирмә гөмбәзендәге төнлеккә карап ятты. Ул күз алдына Хөсәенне китерергә тырышты. Күралмый иде аны Хөсәен. Син мәслоксез дип хурлый иде. Белмим, белмим, дип мыгырданды Җәгъфәр, күрәсең мине ходай шундый итеп яраткандыр инде...

Җәгъфәр быел Казанда җиденче апрельдә үк боз китүен белеп хәйран калды. Уночение апрель номерында Тукайның «Миграж» исемле шигыре басылып чыккан. Укып карыйк, ниләр яза икән минем бердәнбер киңәшчем? Шигырьне укып чыккач, Җәгъфәр: «Шагыйрьнең күңел төшенке,— дигән фикергә килде,— күрәсең авыр кичерешләре бардыр».

Газетаның бер номерында: «Якын арада Габдулла әфәнде Тукаев халык әдәбияты турында лекция укыячак», дип хәбәр ителгән иде. Җәгъфәрнең күңелендә сагыну ялкыны яңа көч белән дөрләп кабынды. Хәзер менә шул «Шәрык клубы»нда булсаң иде, Габдулланың лекциясен тыңласаң иде. Я, хода, Җәгъфәргә андый бәхетләр насыйп түгел шул.

Әйе, болар барысы да коры хыял гына. Туган якларына бөтенләйгә, бөтенләйгә юл киселгән. Чөнки аны хаин, сатлык җан дип исәплиләр иде анда. Әлбәттә, әгәр аларның хокуклары булса, Җәгъфәрне бәлки җан гына түгел, тән газабына да тартырга күп сорамаслар иде ул кешеләр. Менә шуның аркасында ул биредә «мүлдәкә» булып казакъ далаларында качып ята. Тик монда яту, ай-һай, Җәгъфәр уйлаганча, Җәгъфәр хыялланганча чын яшәү микән?

Җәгъфәрнең тирә-юне газеталар белән тулган. Ул әле генә укылганын читкә ташлап, башта укыганын кулына алды. Ирексездән, аның күзләренә: «Быел хаҗда ике йөз илле мең кеше булган» дигән сүзләр чагылды. Ул мәкаләне игътибарын җигә төшеп укырга керешә. Икенче бер санда Төркиядә арнауд фетнәләренең көннән-көн куәтләнүе турында һәм Җавид исемле төрек патшасының гаскәрләре албанияләләрнең берничә авылын җимерү турында укыды. Җәгъфәр хаҗ сәфәренә Төркиянең башкаласы Истамбул аша барачагын күз алдына китерергә тырышты. Бу аның газеталардагы Истамбул хәбәрләре белән кызык-

сынуын арттырды. Газеталарда исә Истамбул вакыйгаларына шактый күп урын бирелгән иде.

Җәгъфәр яткан урыныннан торды. Түгәрәк тирмәдә, читлектәге җәнлек кебек, йөренә башлады. «Китәм мин бу җәһәннәм базыннан, китәм мин бу ләгънәтләнгән илдән, һич югында башка илне күреп кайту өчен, бераз иркен һава сулау өчен». Ул бүген үк, җаен туры китереп, Туктыбайга үзенең ризалыгын әйтергә булды.

## 8

Казан уртасыннан аккан Болак елгасы Кабан күле белән кушылган турыда Балык базарыннан Евангелистлар урамына алып чыга торган киң агач күпер бар. Балык базарыннан килгәндә, күпер аша узып уң яктагы икенче йортта алдынгы татар яшьләренең сөеп йөри торган урыны — «Шәрык клубы» дигән бина тора. Бина таштан салынган, ике катлы, күрер күзгә алай Проломный яки Грузинский урамнарындагы таш пулатлар кебек күз явын алмый. Ләкин шулай да ул бинаны алдынгы татар шәкерте дә, приказчигы да ярата. Һәр көнне диярлек бу өйнең кечкенә генә залында нинди дә булса кичә уздырыла. Концертлар куела, лекцияләр ясала, төрле кызыклы уеннар я булмаса танцы кичәләре була. Яшьләр өчен бу урын чын мәгънәсендә мәгърифәт чишмәсе. Кәфер почмагы әһелләре өчен исә бу урын иң, иң пычрак урын, хәтта фәхешханәләрдән дә пычраграктыр, чөнки монда «ахыр заман фетнәләре», «деннән язган тар балаклар оясы».

Габдулла Тукаев, чынын әйткәндә, менә шушы арада гына халык әдәбиятына багышланган лекция укырга җыенмаган да иде. Ничектер ул, «Болгар» номерының бер бүлмәсендә тереклек иткән «Йолдыз» газетасы идарәсендә «шундый лекция укыйсы иде», дип ычкындырды. Күрәсең, бу фикер редакция әһелләренә ошап калгандыр, алар, күп уйлап тормастан, газетага игъланнамә дә бастырып чыгардылар. Инде чигенерлек урын калмаган иде. Тукай, барлык эшен ташлап, лекциягә әзерләнергә кереште. Хәер, бу лекциянең һәрбер «кирпече» аның башында күптән, бик күптән әзер иде инде. Ул юкка гына «җыр капчыгы» дигән кушамат та йөретми иде ич. Татарның җырын да, такмагын да, әкият-табышмакларын да күп белә иде Габдулла. Бәләкәй чагыннан ук, бер өйдән икенче өйгә сөрелеп йөрүче үксез, ятим чагыннан ук мондый нәрсәләргә хирыс булды. Бәлки ул үзенең ачы язмышын җыр, хыял җимеше булган әкият белән җиңеләйтергә теләүдәндер. Ни булса булган, әмма хәзер һәр мәҗлестә, шәкертләр арасындамы, башка урындамы, аннан да күбрәк җыр, такмак, әкият белгән башка берәү дә юк иде. Әйе, сөйләячәк лекциясенә аның материалы тулып, ташып тора иде. Хәзер исә шуларны тәртипкә китереп, бер җепкә тезеп язасы гына бар. Габдулла бу эшне бер кичтә башкарып чыкты. Әле беренче тәҗрибә булуына карамастан, бу хезмәт аңарда зур канәгатьләнү тудырды.

«Болгар» номерында үзенең тар, караңгы, ләкин үз эшләре якында гына яшәгән бүлмәсенә аның әйләнеп кайтканына бер атна вакыт узган иде инде. Яңа бистә аңа ошамады. Кайчандыр бик кечкенә чагындагыча кунакчыл, үзен иркәләп тора торган йомшак куллы Газизә, Мөхәммәтвәли Яңа бистәсе түгел иде бу. Наданлык баткагына кереп чумган гайбәтчеләр, эшсез, дини хорафатчылар басып киткән бистәне, һаман берүк кул эшеннән алҗып, уйлау сәләтләрен югалткан вак һөнәрчеләр, кендек әбиләре, сөннәтче бабайлар, яучы карчыклар, имче-багучылар, мулла-мәзиннәр Габдулланы болай да туйдырган иде инде. Аны җилкәсенә кадәр төшеп торган озын чәче дә туйдырды. Күнегелмәгән. Габдулла аны да кыскарттырды.

Әле бүген, кунаклар булмавыннан файдаланып, Габдулла узган төндә язганнарын берелеп укырга кереште. Ул, гадәтенчә, караватына тезләрен кочаклаган килеш утырды да, язуларын алдына куеп, тирбә-лә-тирбәлә укыды. Хәтере бик әйбәт иде. Лекцияне ике тапкыр карап чыгу җитте аңа. Ул хәзер язганнарын һич сөртенми-нитми яттан сөйләп чыга ала иде. Эш шулай артык тиз арада төгәлләнде. Хәлбуки алай ук тиз бетмәсә дә ярар иде. Чөнки эч поша. Габдулла, шундый халәттән качарга теләгәндәй, тиз генә караватыннан сикереп төште дә тәрәзәгә таба китте.

Печән базары шаулап-гөрләп яши бирә. Халыкның күпчелеге татарлардан тора. Кешеләр өзлексез хәрәкәттә. Берсе сата, икенчесе ала. Кибет прилавкалары артында түбәтәйле, казакиле юан сәүдәгәрләр. Муеннарына бау белән «кибетләрен» аскан, канәфер, дарчин, борыч, янсә каптырма, сәдәф, төймә сатып йөрүче тавышчан, елдам кырык-тартмачылар. Барысы да, тамаклары ертылганчы кычкырып, үз товарларын мактый. Алача ыштан, беләүләнгән түбәтәй я мескен бүрек кигән алъяпкычлы, чабаталы авыл агайлары, илтер бүрекле, иске җөббәле, читек-кәвешле шәкертләр, чалмалы яки кызыл фәсе ерактан ук күзгә ташланган яшел чапанлы пишкадәмнәр, тагы әллә кемнәр, әллә нинди җан ияләре; хуҗасыз этләр, карак мәчеләр, иреннәрен салындырып мәрткә киткән ябык, җигүле атлар... Барысы да баш әйләндергеч хәрәкәттә, күз карашыңны бер ноктага теркәү һич мөмкин түгел.

Тукай бу тамашаны, «кырмыска оясын», көлемсерәп байтак вакыт карап торды. Шулай ял итте, күңелен ачкандай булды. Кемдер ишек шакыды. Гадәттә үз кеше булганда шакып керү гадәте юк иде. Җил-ләнеп килеп керәләр дә сүзгә керешәләр, хәтта, күп очракта исәнләшеп тору гадәте дә онытыла. Ә ишек һәрвакыт, һәркемгә ачык, ул беркайчан да бикләнми. Әле генә ишек шакучы чит кеше булырга, яки бик нәзакатьле таныш булырга тиеш дип уйлады Габдулла. Ишектән керүче Хөсәен иде.

— Әйдүк, әйдүк, Хөсәен әфәнде,— диде Габдулла. Хөсәен исә аның йомшак буынлы кайнар кулын кысты да: — Син Габдулла дус, тәҗрибәле конспираторлардан бер дә ким түгел икән,— диде.

— Нигә алай дисез?

— Чөнки атна саен фатир алыштырасың.

Хөсәен Габдулланың чәче китәрелгән булуына игътибар итте. Чәчен алдыргач, шагыйрь бөтенләй яшүсмерләр кыяфәтенә кергән иде.

— Бу минем яшерен фатирым түгел, бу бик күпләргә мәгълүм — Тукайның фәкыйрь хөҗрәсе. Рәхим итегез, утырыгыз, Хөсәен әфәнде. Мин сезне күрүемә шатлыктан гаҗиз. Сезне күрү миңа һәрвакыт ниндидер илаһи бер көч-куәт бирә.

— Менә нәрсә, Габдулла дус, минем озаклап утырырга вакытым юк. Бары бер нәрсәне генә исеңә төшерергә кердем мин. Хәтереңдә булса, син безнең әдәбият түгәрәгендә катнашырга ризалык биргән идең.

Тукайның ябык йөзенә елмаю билгесе чыкты.

— Мин ул вәгъдәмне бик яхшы хәтерлим, Хөсәен әфәнде.

— Хәтерләсәң бик әйбәт. Эшкә керешү вакыты җитте. Бүген утырыш. Син бүген анда була аласыңдыр бит?

Тукайның йөзенә бераз аптырау билгесе чыкты.

— Сез, күрәсең, Хөсәен әфәнде, бүген «Шәрык клубы»нда минем лекциям булачагын оныткансыз.

— Юк, юк, әз генә дә онытмадым, мин үзем дә анда булачакмын. Безнең утырыш нәкъ сезнең лекция тәмамлангач була. Мин бары башка кешеләргә ияреп китә күрмәгез дип кенә кисәтергә кердем.

— Ничәләрдә башлана инде ул әдәбият кичәсе?

— Төнге уникедән дә калмас, дип уйлыйм. Сезнең лекция тугызда бит. Ул уникенче яртыларда тәмам булыр шәт.

— Мин ул урынны ничек табармын соң?

— Сезне анда дустыгыз Габдулла Кариев алып барачак.

Габдулла, хәйран калып, күзләрен зур итеп ачып торды. Ирексездән аның хәтеренә Уральский чоры килеп төште. Карый анда революцион китаплар сатып бер «янгач», икенче мондый эш белән шөгыльләнмәскә ант иткән иде. Кара син аны, тагы батырчылык иткән диген.

— Ярый, мин риза, баш өсте,— диде Тукай, Карый турындагы уйларын фаш итмәстән.

Хөсәен, Тукайга карап дустанә бер елмайды да, кул хәрәкәте белән генә шагыйрьне сәламләп чыгып китте.

«Шәрык клубы»нда халык күп иде. Ни өчендер, Тукай лекция тыңларга халык җыелмас дип борчылган иде. Аның басылып чыккан һәрбер шигырен укучы яратып кабул итә, аларның күбесе әдәбият мәйданының бер гүзәл вакыйгасы буларак кабул ителә. Хәтта алай гына да түгел әле, күп шигырен ятлап баручыларны белә Тукай. Лекциягә килгән халыкның күбесе яшьләр. Залда хатын-кыз да байтак иде.

Тукай килеп кергәч, зал аша җиңелчә пышылдау узды. Тукайны абайлаучылар күршеләренә шундук хәбәр салдылар. Шагыйрь, күз кырые белән генә тирә-юнен күзәтә-күзәтә, сәхнәгә таба узды. Танышларына баш иде, арткы рәтләрнең берсендә утыручы Хөсәен дә күзенә чалынды.

Шулай сөйләшенгән иде инде: Тукай халык җыелгач кына клубка киләчәк һәм туп-туры сәхнәгә узып лекциясенә керешәчәк. Шулай итте дә — житез адымнар белән сәхнәгә менде, урталыкка басып туктalып калды. Халык гөрләп кул чабарга тотынды. Гадәттә, Тукай үзләшкән урында бер дә каушамый иде. Бүген исә ничектер югалып калды. Ниһаять, баштагы чуалчыклык таралды, болытлы күк аяза башлагандай, зиһенгә яктылык, ачыклык шәүләсе инде. Габдулла рампага якыная төште:

— Хөрмәтле ханымнар һәм әфәнделәр!

Лекция башланып китте. Беренче мизгелдәге каушау бөтенләй бетте диярлек. Шагыйрь, әйтерсең лә гомере буена шул темага лекция сөйләгән, су эчкәндәй җиңел ага иде һәр сүзе. Ул башта язган текстын сөйләгәндә үк үзгәртә торды, нотыгын тагы да матуррак мисаллар белән бизи барды. Бу чыгыш татар халкының фольклорына багышланган чын мәгънәсендә тирән бер тикшеренү икәнен залда утыручылар гына түгел, шагыйрь үзе дә эчтән тоя һәм мондый уңышка үзе дә сабыйларча куана иде кебек. Бер сәгатькә якын дәвам иткән лекция сизелмәде дә. Шуның белән сүзем тәмам дип, Тукай җиңелчә баш игәч, бер кавым тынлыктан соң халык тагы зал тутырып кул чапты. Сораулар бирү башланды.

Габдулла клубтан чыкканда ишек төбендә аны көтәләр иде инде. Кариев адашының кулын җибәрмичә бик каты кысып торды. Күрәсең, шик-шөбһәләрен дә оныткан иде ул.

— Афәрин, Габдуллаҗан, син үзеңнең лекциячң белән публиканың халкыбызга булган мәхәббәтен тагы да арттырдың. Әйткәннәрең бик дөрес, халык ул — даһи ул!

— Рәхмәт, дускаем. Мине нигә көтеп торуыңны аңлыйм, киттек. Тик, артык соңга калсак, безне номерга кертерләрме соң?

— Хафаланма, мин Мөбарәк абзый белән сөйләштем; җайладым, ул ничәдә кайтсак та арт ишекне ачарга булды.

— Алайса бик әйбәт, киттек.

Урамга чыгу белән аларның йөзенә дымсу, әмма җылы апрель сулышы орынды. Кабан күле өсте тынып калган, Казан исә шулай ук йокыга талган. Бары сирәк-мирәк кенә исерекләр һәм околоточныйлар күз-

гә чалына, кайдадыр үзләре күренмәгән каравылчыларның шакылдавык тавышлары һәм эт өргәне генә тынлыкны боза иде.

Габдулла Кариев үзенең театры, артистлары, планнары турында сөйләп барды. Соңгы вакытларда адашлар сирәк күрешә иделәр. Шуңа күрә Тукай өчен Карыйның һәр җөмләсе кызыклы тоелды. Ул дустының татар халкына театр бүләк итүе белән ихластан горурлана һәм хәзер элекке шадра Миңлебайны — хәзерге профессиональ артист Габдулла Кариевны тагы да ныграк хөрмәт итә иде. Шагыйрь әле генә үзе укыган лекция тәэсиреннән айнып бетмәсә дә, барлык игътибарын туплап, язгы җепшек һаваның авыру үпкәсен кытыклавыннан ара-тирә ютәлләп, сүзгә кушылмыйча гына тыңлап барды. Балык базарын узып, Тукай белмәгән аулаграк бер урамга борылгач, Карый тукталып калды.

— Җиттек,— диде шыпырт кына,— миңә шушы капкадан керәсе...

9

Иделдә бозлар агып бетү белән Казанда рәхимсез тузанлы корылык башланды. Май башларында ук Идел суы кимегән, Казан елгасы саеккан, кечкенә инешләр кипкән, кырларда уҗымнар күтәрелә алмый саргая башлаган иде. Халык арасында эч китү, хәтта ваба чире очраклары күренә башлады, авылларда исә мал-туар арасында түләмә таралды. Ахыр заман, башка берни түгел, ахыр заман кәсафәтләре бу, дигән хәбәр халык арасында көчәйгәннән көчәя барды. Җитмәсә тагы койрыклы йолдыз җиргә якынлаша икән, дигән хәвефле хәбәр таралды. Инде дә шул йолдызның койрык очы гына җиргә тиеп китсә дә, җир шартлап ярылачак икән, җиһанны һәлакәт басачак, дип бөтен Казан, бөтен Печән базары, Иске һәм Яңа бистә шаулады.

Әлбәттә, Хөсәен һәм Хәдичә кебекләр мондый сүзгә уйдырма дип кенә карадылар. Ләкин шулай да җәйнең фаҗигале башлануын беркая да куеп булмый иде. Базар бәяләре кискен рәвештә күтәрелеп китте. Икмәкнең кадагы өч ярым тиенгә, ит егерме тиенгә менде. Килере бик аз булган түбән катлау халкына сизелерлек дәрәҗәдә авыр чор башланды. Моны Хөсәеннәр дә бик яхшы тойдылар. Алар хәзер ашау-эчүдә булсын, кием-салымда булсын, аерата сакчыллык күрсәтә башладылар. Кыйммәтчелекнең газабын, төп расход тотучы буларак, Хәдичә авыр кичерде. Ир белән хатын арасында бу темага еш кына сүз булгалый иде. Хәдичә чын мәгънәсендә үзен хәзер бәхетсез бер кеше дип исәпли. Жандармерия кылычы астында сагаеп яшәүгә тагын җитмәүчелек тә өстәлде. Һәм болар барысы да аны Хөсәеннән ераклаштырганнан ераклаштыра барды. Җитмәсә тагы... Әйе, җитмәсә нинди дә чытлык гимназисткалар, курсисткалар ачу китерә. Алар Хөсәеннең башын әйләндерү өчен аның тирәсендә буталалар. Араларында Суфия дигәне, Гафур Коләхметовның сеңелесе дә бар, тәгаен Хөсәенгә гашыйк булган, каникулда Петербурдан кайтып төшкән вакытларында Хөсәенне очраттымы, күзләре үк елтырап, нурланып китә. Әйе, анысы Хәдичә өчен исбат ителгән нәрсә. Хикмәт бары шунда, ул кызыйга Хөсәен ничегрәк карый? Укуын тәмамлап кайту белән Хөсәен аңа китмәсме? Һич булмаса бер бәби дә табып бирә алмады бит ул Хөсәенгә.

Соңгы елда Чистайда еш булгалый Хәдичә. Ләкин әтиләренең дә хәлләре әллә ни авыз күтәреп мактанырлык түгел. Сәүдәләр начар, халык ачлыктан интегә, кызыл малга ул кадәр исе китми. Күп булмаса да Хәдичә аннан ит-казылыгын да, башка төр күчтәнәчен дә алып кайткалый — акмаса да тама энисеннән. Тик элеккечә түгел инде, бер киселгән икмәкне, кем әйтмешли, кире ябыштырып булмый бит.

Июньнең бишендә Хәдичә, чемоданын күтәреп, пароходта Чистайдан кайтып төште. Телеграмм сугуына карамастан, Хөсәен аны каршы алырга килмәгән иде. Пароходтан дебаркадерга керү белән Хәдичәне бөтенләй таныш булмаган рус егете каршылады. Йөгереп килеп Хәдичәнең кулыннан чемоданын тартып алды. Курка калган ханымны тынычландырырга тырышып, Хөсәеннең Казаннан ашыгыч эш белән Чабаксар ягына китүен хәбәр итте.

— Сезне мин кем дип белим соң? — диде Хәдичә. Гимназист формасы кигән кара тутлы егет эре ак тешләрен балкытып:

— Мине Гриша дип белегез, Хөсәен Минһаҗетдиновичның ышанычлы кешесе. Әйдәгез, безне өстә извозчик көтә.

Хәдичәнең егеткә иярүдән башка чарасы юк иде. Кинәт алда нindидер гүләү, ят бер аваз, күк күкрәвен хәтерләткән тавыш ишетелде. Хәдичә, ап-аяз көнне ни арада болытлар куерып өлгергән, дип уйларга өлгермәде, кинәт Идел суы ишелеп һавага күтәрелә башлады. Якындагы дебаркадерның калай түбәсен өермә коточкыч бер көч белән күз ачып йомганчы куптарып яр өстенә очырды. Тирә-юньне тузан каплады. Хәзер алда берни дә күренми, берни дә аерырлык түгел иде. Хәдичә үзен нindидер дәһшәтле көч өстери башлавын тойды. Аңышып өлгермәде, һава дулкыны аны, күтәреп бер ара очырганнан соң, яңадан җиргә китереп ташлады. Хәдичәнең тезләре, янбашлары сыдырылган, күлмәк итәге аерылып төшкән иде. Ул, нишләргә белмәүдән, җирдәге таш багана кисәген кочаклап тоткан килеш, барлык көченә кычкырырга, ярдәмгә кешеләр чакырырга тотынды. Ләкин ул көнне Казанда давыл юлына эләккән һәркем Хәдичә хәлендә иде. Хатынга, әлбәттә, ярдәмгә килүче булмады. Хәдичәнең башыннан «Кайда соң теге егет?» дигән сорау яшендәй сызылып үтте. Ләкин берни дә күренми, берни ишетелми иде. Бары якындагы нindидер корылмаларның шатырдап ауганы, зур мичкәнең тәгәрәп тузанлы караңгылыкта югалуы гына Хәдичәнең аңында чагылып калды. Хәдичә таш баганага чытырдап тотынган килеш, тирә-юнендә кайнаган мәхшәрдән котылырга тырышты. Баш өстендә үк нидер шартлап сынды. Менә ул Хәдичәнең өстенә үк ава булса кирәк. Хәдичә күзләрен йомып, ташны кысып тоткан килеш, җиргә сеңердәй булып йөзтүбән ятты. Агачның үз өстенә төшү-төшмәвен тоймады, аңын җуйды.

Ул уянып, күзен ачканда давыл тынган иде, тирә-якта ауган алачыклар, түбәләре куптарылып ташланган, җимерелгән тәбәнәк өйләр, тамырларыннан ук куптарылып читкә ташланган агачлар. Бөтен җир көмештәй ак эре балыклар белән тулган иде. Хәдичә Устьедәге баржа причалларында балык әрдәнәләренең бик күп булуын белә. Күрәсең, давыл шул әрдәнәләрне туздырган. Һавада кипкән балык исе аңкый.

Хәрабәләр арасында үле тынлык хөкем сөрә иде хәзер. Ичмаса бер генә кеше күренсәче! Хәдичә, зур авырлык белән торып, шәһәр ягына таба китте. Аңа шулай, ауган агачлар, җимерелгән корылмалар белән тулы урамнардан әле бик озак, тәмам хәлдән таеп егылганчы барырга туры килде. Инде Бишбалта бистәсен узып бушлыкка чыккач кына, ярдәмгә чыккан атлылар аны арбага утыртып алып киттеләр.

Иртәнге яктан ук Казанга килеп төшкән Хәдичә бары төштән соң гына өенә кайтып егылды. Хөсәен өйдә юк иде. Теге чемоданны алган студент та күренмәде. Өстәвенә Хәдичәнең өс-башы ертылып тузанга, туфракка буялган; куллары, бите, аяклары җәрәхәтләнеп беткән иде. Хәдичәнең битен чылатырлык та хәле калмаган. Караватына ауды да үксеп җыларга тотынды. Аныңча, хәзер бу кötелмәгән афәттә дә Хөсәен гаепле булып күренде. Әйе, ул, ул, барсына да ул гаепле. Әгәр иркен тормышлы, тук, бөтен гаилә кора алган булса, Хәдичә шулай азыктөлек өмет итеп, атасы өенә барып мескенләнер идемени?! Барсына да ул гаепле. Тапкан, ирек яулаучы Дон-Кихот. Тапкан, инкыйлап каһар-

маны булып дан казанырга теләүче. Я, хода, ничек кенә итәргә соң миңа, ничек кенә аны шул юлыннан, гомердә тормышка ашмый торган, бары төрмәгә илтеп тыга торган ахмак эшеннән айнытырга?!

Үзен тагы да бәхетсезрәк тойган Хәдичә, ярсып, рәнҗеп ятканнан соң, тәмам алҗып йокыга талды. Иртә белән ул кемнендер бүлмә ишеген ачып үз янына узуын тойды. «Хәдичә, син исәнме?» дигән таныш тавыш ишетелде. Бүлмәгә керүче Хөсәен иде. Башта хатынының иркенләп җылыйсы килде, ләкин ул тойгы күңелдә тернәкләнеп өлгермәде, каяндыр йөрәк астыннан, кичәге давылдай гүләп, нәфрәт хисе күтәрелә башлады. Хәдичә күзләрен зур итеп ачты да, әйтерсең лә бөтенләй йокламаган, аек бер тавыш белән:

— Нәрсә син, минем үлемемне теләгән идеңмени? Нигә мине ниндидер малайга ышандырып олактың? — диде.

Хатынының бу дәрәҗәгә җитеп шашынганын күргәне юк иде әле аның. Хөсәен бермәл югалып торды.

— Нәрсә сөйлисең син, Хәдичәкәй,— диде.— Мин бит эш белән. Ә сине каршы алырга тиешле кеше — минем дус егет, миңа университетка керергә булышкан егет. Ничек соң, давылга очрадыңмыни? Бер-бер җиреңне авырттырмадыңмы?

Ул Хәдичә янына утырып, аның чәчләреннән сыйпый башлады. Ләкин моңа карап Хәдичәнең Хөсәенгә карата ачуы әз генә дә басылмады. Ул Хөсәеннең кулын читкә этте һәм кискен генә стенага таба борылды.

Аңлашу мөмкин түгеллеген төшенгән Хөсәенгә бик күңелсез булып китте. Ул керосинкага чәйнек куеп керде. Ачыккан иде. Чәй кайнап чыкканчы дип китапларын өстәл өстенә җәеп салды, хатыны яткан якка ара-тирә караштыргалап укый башлады. Зур эшкә керешкән иде ул. Ул эш хәзер һичшиксез гамәлгә ашачак. Хөсәен университетка керәчәк, белем алырга, киләчәктә зур ачышлар ясарга — үзе өчен, бүтәннәр өчен. Әйе. Ә Хәдичә? Акылсыз хатын түгел бит ул, бер аңлар. Ике арадагы мөнәсәбәтне Хөсәен нинди генә авыр кичермәсен, кайчан да булса Хәдичә мине аңлар дигән өмет белән яши иде.

## 10

Казан каласыннан котырынып узган дәһшәтле давыл шәһәр урамнарын хәрабәләр, сынган агачлар, балчык-таш өемнәре белән тутырып китте. Газеталарда мондый җимергеч өермәнең Казанда беркайчан да булганы юк иде, дип яздылар. «Казан хәбәрләре» рубрикасында җимерелгән өйләрнең исәбе-хисабы юк, үлүчеләр бар, сигез меңнән артык агач кына давылда тамырыннан куптарылып ташланды, дип хәбәр ителде.

Гафурның сеңелесе Суфия Петербургтан җәйге каникулга унынчы июньдә кайтып төште. Давыл аерата көчле котырып үткән Казан урамнарында әле тәртип урнашып бетмәгән иде. Һәр җирдә ломовой извозчиклар, һәр җирдә бескозырка кигән солдатлар, яки шәһәр мещаннары кайнаша. Исән калганнар — яше-карты каралты-кура төзәтә, чүп чыгара, урам себерә — мәш килә иде. Суфияның мондый гарасатны әле күрү түгел ишеткәне дә юк иде. Чөнки Петербург белән Казан арасы, поездда кайтсаң, дүрт көнлек юл ул. Шуңа күрә хат-хәбәр Казаннан Петербургка тиз генә барып та җитми.

Суфияны каршы алырга Гафур үзе төште. Вокзалдан Пороховойга кайтышлый Суфия юл буенча диярлек давыл турында сорашты. Гафур исә Хәдичәнең дә давылга эләгеп, хәзер артык тетрәнүдән каефсезләнеп

өендә ятуын әйтте. Сүз Хөсәенгә кагылгач, Суфия никадәр сиздермәскә тырышса да, булдыра алмады. Кызыйның йөзе кызарып, күзләре нурланып китте. Һаман, һаман, Хөсәен белән саташа икән әле бу акылсыз кыз, дип уйлап куйды абыйсы. Ләкин Суфияга берни дә әйтмәде, янәсе сизмәде. Суфия исә бик җитди булырга тырышып, кара матур кашларын җыергалап төпченә бирде.

— Хәдичә апаның хәле артык серьезный түгелдер бит? Бәлки аңа медицина ярдәме кирәктер, абый?

Ул максатына ирешкән, Петербургта Бестужев курсларында укып врач булырга әзерләнә. Һәм хәзер, әлбәттә, ул үзен, медицина әһеле санап, һәр авыруга ярдәм итәргә әзер тора иде.

— Бераз яхшыра булса кирәк. Мин әле кичә генә Хөсәенне очраткан идем. Аның сөйләвенә караганда, Хәдичә, җәрәхәтләреннән дә бигрәк, ниндидер нервный тетрәнү аркасында авыруга сабышкан.

— Ничек соң ул шундый вакытта давыл уртасында калган?

Гафур белгәнен тәфсилләп сөйли башлады.

— Юк, Хәдичә апаның хәлен белмичә һич ярамый, абый,— диде Суфия.— Мин бүген булмаса иртәгә үк барам аларга.

«Синең Хәдичә апаңнан да бигрәк Хөсәенне күрәсең килә»,— дип уйлады Гафур, ләкин бу юлы да уйларын үз эчендә генә калдырды.

Гафур бик аз сүзле, кирәген генә сөйләшә торган кеше иде. Бу яктан ул әтисенә охшаган. Ә Суфия исә, киресенчә, әнисе кебек ачык, сөйләшергә яратучан, көләч һәм җиңел сөякле кыз. Ул юл буенча туктаусыз сорашты. Ахырда Петербургның соңгы хәбәрләрен сөйләргә керешә.

— Петербургтагы мөселманнар яңа салына башлаган мәчет белән саташалар хәзер,— диде.— Син беләсеңдер инде, Бохара әмире шул мәчетне салдыру өчен бик күп акча бүләк иткән. Инде җитмәгәнен халыктан иганә җыеп тулыландыралар.

— Газеталардан укыган идем, февральдә үк салырга керештеләр бит аны.

— Инде аның намаз укый торган залын эшләп яталар. Искиткеч гүзәл мәчет булырга тиеш. Әллә кайдан ук күренеп торачак манарасы.

— Нигә, аның күренеп торуы синең өчен шулкадәр мөһим мени?

— Мөһим шул.

Гафур көлемсерәп сеңелесенә карады. Өенә, Казанына кайтуга ифрат шат, бәхетле иде Суфия. Сеңелесенең шатлыгы Гафурның да күңелен күтәреп җибәрде.

— Мөһим, чөнки рус мещаннары арасында татарны кеше дип тә санамаучылар бар. Кайберләре хәтта капкаларына «Этләргә һәм тавышланып йөрүче татарларга керергә рөхсәт юк» дип язганнар. Мин үзем укыдым. Билләһи, абый. Менә шундыйларга юри үч итеп, мин татар мәчетенең манарасын бик биек, бөтен Петербург халкы күрерлек итәсем килә...

Гафур көлеп үк җибәрде.

— Син бик беркатлы, Суфия. Син әллә мещаннар арасында булган шовинистлар, байлар, чиновниклар арасында табылмас дип уйлыйсыңмы?

— Анысы да мөмкин. Имеш бер бай, шул мәчет манарасын каплатыр өчен, аның алдына ук әллә ничә катлы өй салдырачак икән, дип сөйлиләр.

— Мәчет манарасын күккә күтәреп кенә татарны бәхетле итеп булмас, сеңелем. Әнә шул тәхеттәге һәм аның тирәсендәге түрәләрне юк итсәк кенә ул бәхет булачак!

— Синең хәтәр сүзләреңне мин күптән ишетеп яшим инде, абый. Ләкин хәзер бишенче ел да, җиденче ел да түгел, кадерлем. Син сак бул

— Дәһшәтле караңгы реакция чоры кичерәбез. Сафлар хәзер бик сирәкләнде, Суфия. Минә шулай. Беребез дә иртәгә кремль төрмәсенә эләкмәм дип уйлый алмый.

Суфия күзләрен йомып, көрсенеп куйды.

— Петербурда да сезнең кебек революция дип янып-көеп йөрүчеләр аз түгел.

— Безнең татар егетләре арасындамы?

— Әйе, син, минемчә, аларның берсен беләсең. Һәрхәлдә белергә тиеш. Чөнки ул сине дә, Хөсәен абыйны да яхшы белә. Яратып сөйли.

— Үзе чибәрме?

— Ярыйсы.

— Үзе шатенмы?

— Нәкъ өстенә бастың.

— Үзе Мулланур атлымы?

Суфия көлеп җибәрде.

— Син аның шул икәнлеген әллә кайчан белдең инде. Сораштырып баш катырган була тагы.

Алар тиздән Пороховой бистәсен, Суфияне күптән сагындырган, таныш, якын, бер катлы өйгә кайтып җиттеләр. Суфия һәр почмагы, һәр бизәге бик кадерле тоелган якты өйгә килеп кергәч, үзен үтә дә бәхетле итеп тойды.

Бик мулдан булмаса да затлы башкала күчтәнәчләрен алып кайтырга да онытмаган иде кыз. Петербургтан кайтып төшкән курсистка үзе өчен махсус ягылган мунча кереп чыккач, гаилә бергә җыйналып, күңелле гөрләшкән хәлдә чәй эчте.

Суфия сүзендә торды. Икенче көнне үк, иртәнге чәен эчүгә, Хәдичәнең хәлен белешергә китте. Сагындырган урамнарны юл буенча карап барды. Ташаяк аша узганда аерата игътибарлы булды. Бу Казан ярминкәсенә аның бик татлы истәлекләре бәйләнгән иде. Шәһәрнең таш пулатлар тезелеп киткән үзәк урамнарында булып узган давыл эзе сизелми дә. Бу табигать шаяруы Казан байлары яшәгән төбәкне кызганган, күрәсең. Бары алачыкларда, җиргә иңә башлаган иске өйләрдә яшәүчеләрне генә туздырып, вәйран итеп киткән. Суфия Проломныйны буйлап узды, андагы ялтыр витриналарга, модный киемнәр эленгән магазиннар алдында тукталып торгалады. Мондагы күренешләр якын, үз булса да, Петербургта күз нәләшкән шәһәр манзарасы каршында ничектер артык гади, фәкыйрь сыман, Суфия умарта гөжләвен хәтерләткән, әле дә шактый зур балык базарын узып, сул якка борылды һәм тиздән Хөсәеннәр квартирына җитте.

Хәдичә ялгызы гына иде. Курсистканы күрү белән хуҗабикәнең йөзеннәнниндидер бер күләгә үткәндәй булды. Ләкин ул беренче тойгыга бирешмәде, ясалмарак килеп чыкса да, кунак кызга якты чырай күрсәтеп, аның белән исәнләште, түргә чакырды.

Суфияның яңалыкларын тыңлап, күчтәнәчләрен алгач:

— Рәхмәт килүеңә, Суфия,— диде. Үзенең давылга эләгү вакыйгасын сөйләп алды.— Хәзер барысы да үтте инде, шөкер,— диде.

— Ә чемоданыгыз табылдымы соң? — диде Суфия.

— Һи, чемодан! Чемодан гына түгел, аны күтәргән егет тә юк әле. Хөсәен Казанның барлык больницаларын айкап чыкты. Эзсез югалды, бичара.

— Бәлки чемоданны алып шылгандыр.

— Юк, юк, алай булуы мөмкин түгел. Хөсәен ул студент турында әйбәт фикердә, андый эшнең булуы һич тә мөмкин түгел, ди.

— Хөсәен абыйның хәлләре ничек соң? Авырмыймы?

Хәдичә җилкәләрен генә сикертеп куйды.

— Ничек әйтергә, ул университетка керергә хәзерләнә. Шуның белән саташа.

— Ә сәламәтлеге?

Хәдичә сәерсенүдән дә бигрәк, ничектер яратмыйчарак, Суфияга төксе бер караш ташлады.

— Сәламәтлеге? Менә Петербурдан укуыгызны тәмамлап доктор булып кайтыгыз да, Хөсәенне дәваларсыз.

Бусы артыграк иде, турыдан суктыру булып чыкты. Хәдичә бу сүзләре белән Суфияга, син минем өчен килмәгәнсең бирегә, син Хөсәенне күрергә килгәнсең, дигән фикерне аңлата иде.

Суфия җиңелчә кызарынды да шундук җавабын да бирде.

— Әлбәттә, Хәдичә апа, сезне дә, аны да врач булып чыккач дәваламый калмам. Чөнки мин Хөсәен абыйны Гафур абыемның иң якын дусты булганы өчен якын күрәм...

— Яратканыгызны беләм,— дип куйды Хәдичә, ничектер мәкерле бер тонда.

Суфия бер кузгалырга итенде, ләкин яңадан утырды. Әйтергә сүз тапмады, Хәдичәнең дәвам итүен көтте. Күрәсең, бу җитди сүзне башлау Хәдичә өчен җиңел түгел иде. Шулай да ул, эшне озакка сузмыйча, ятып калганчы — эчтән сызып, борчылып яшәгәнче — атып кал, дигән кагыйдә буенча, ел буена өелгән рәнҗүен Суфияга берьюлы актарып ташларга булды. Сүзен бик тыныч башлады. Хәтта ясалмалыгы сизелерлек тыныч иде аның тоны.

— Суфия, акыллым,— диде ул,— мин барысын да күреп, күрмәсәм дә сизеп торам, син Хөсәен абыеңны бик яратасың. Гафурның дусты булганы өчен генә түгел. Юк. Син аны просто яратасың. Кыз кеше булларак, кыз кеше егетен яраткан кебек.. Синең Хөсәенгә хатлар язып торуыңны да беләм. Алып укыганым юк, андый түбәнлеккә төшәргә ходай язмасын. Тик беләм — хатларыңда аңа карата бик җылы сүзләр язасың. Әйдә, ярата бир, минем эчке интим тормышыңа тыгылырга хакым юк. Ләкин мин сиңа менә нәрсә әйтергә телим. Минем бу сорауга туры җавап таләп итәргә хакым бар, чөнки мин аның никахлы хатыны. Ул сиңа ничек карый? Ул сиңа, әйткәнеңчә, бары сеңел итеп кенә карыймы, әллә инде...

Хәдичә, коңгырт күзләрен зур ачып, Суфияга текәлде.

Суфия, соң дәрәҗәдә дулкынланып, урыныннан сикереп торды. Аның йөзе кызарган, кара матур күзләре ут булып яна, куллары чак кына сизелерлек дерелди иде.

— Борчылмаска хакыгыз бар, Хәдичә апа,— диде ул кискен бер тавыш белән,— ул миңа нәкъ үзе әйткәнчә, бары сеңел итеп карый.

## 11

Июнь башларында ук корылык белән бергә Казанга төрле чирләр дә килде. Казанда Шәһәр идарәсе барлык медицина хезмәткәрләрен ваба белән көрәшкә мобилизацияләде. Күрәсең, шәһәр башлыклары көрәшне соңгарак калып башлаганнардыр, бер ай эчендә йөзләп кеше авырып, шуларның алтмышы үлеп тә китте. Әҗәл, сөякләрен шыгырдатып, үзенең чалгысы белән Казанда селтәнеп йөрергә тотынды. Үлемҗитемнең көннән-көн арта баруы халык арасында берсеннән-берсе куркынычлырак хәбәрләр тууга сәбәп булды. Әлбәттә, мондый чакта халык кичергән афәткә Хөсәеннәр катнашсыз кала алмады. Партия Комитеты вакытлыча яшерен эш йөртергә мәҗбүр ителсә дә, үзенең эшен бу өлкәдә дә булдыра алганча намус белән башкарырга кереште. Ул төп бурычны Земство һәм Управа аша йөретте. Максат шул: андагы түрәләр ныграк борчылсыннар. Мондый авыр вакытта халык ихтыяҗларын күбрәк кайгыртсыннар. Халык арасында куркынычлы авы-

руга каршы көрәшнең барышын дөрес аңлату бик әһәмиятле нәрсә иде. Моның өчен матбугат аша актив эш итү кирәк табылды.

Вабага каршы көрәштән Суфия да читтә кала алмады. Ул рәсми рәвештә мобилизацияләнмәсә дә, үз ирке белән, шәфкать туташы сыйфатында, холера баракларының берсендә эшләргә теләк белдерде.

Теге көнне, Хәдичә белән шактый тәэсирле аңлашу булганнан соң, ул яңадан аларга барырга батырчылык итмәде. Ләкин моңа карап Хөсәенне күрү теләге әз генә дә суынмады аңарда. Киресенчә, Хәдичә белән күзгә күз карап сөйләшкәннән соң, Хөсәен белән очрашуны ул кадәр гөнаһ эш дип санамый башлады. Аны ничек тә булса очратып, ягымлы тавышын ишетәсе, иркәләп, җылытып карый торган кара күзләрен күрәсе, нык кулын тотып торасы килә иде. Ул инде менә үсмер кыз яшенә кергәннән бирле хыялыннан Хөсәенне чыгарып ташлый алмый. Ул, өметләнеп, Хөсәеннең абыйсы янына килеп чыгуын көтте. Ләкин кайтканның беренче атналарында мондый куанычлы хәл насыйп булмады. Аннан Суфия эшли башлады. Әле егерме дүртенче июньдә генә ачылган Бишбалтадагы ваба барагында һәркөн иртәдән кичкә кадәр авырулар белән булышты.

Мәгәр һич көтмәгәндә очраштылар алар. Суфияның аптыравына каршы, Хөсәенне ул авырулар яткан барак алдында очратты. Салам эшләпәле, ак чесуча костюмлы, калку буйлы кешене тәрәзәдән күрү белән, атылып тышка чыкты. Күрәсең, Хөсәен Суфияның бирედә эшли башлавын белми иде әле. Аның да йөзенә чиксез аптырау билгеләре чыкты. Ул күзләрен йомгалап, Суфияга карап торды да көлеп җибәрде.

— Суфия! Мин бит сезне киткән, Петербур урамнарында йөридер хәзер дип фараз итәм. Ә сез холера барагыннан килеп чыктыгыз.

Суфия Хөсәеннең янына ук барды, аның шактый ябыккан йөзенә текәлде. Кызның бернигә дә карамастан, берни белән дә исәпләшмәстән, Хөсәеннең кочагына ташланасы килгән иде. Ләкин ниндидер көч аны тыелырга мәҗбүр итте, ул Хөсәеннең күзләренә, ничектер, көчсезлектән гаҗиз бер караш ташлап, Хөсәеннең үзенә таба сузылган кулын гына кысу белән чикләнде. Хөсәенне шул дәрәҗәдә үк көчле яратуын үзе дә белми иде әле Суфия. Ул бермәлгә югалып, өнсез калып торды.

— Шунда эшлисезме? — дип сорады Хөсәен, баракка таба ымлап.

— Әйе, эшлим, Хөсәен абый.

— Күптәнме?

— Менә бер атна инде, Хөсәен абый. Мин сездә булган идем. Бәлки Хәдичә апа әйткәндер.

— Әйе, әйтте.

Суфияның уй-фикерләре ныклы эзгә төшә башлады.

— Ә сез ничек монда килеп чыктыгыз соң?

— Мине барактагы дәвалау шартлары кызыксындыра, Суфия. Син, мөмкин булса, үзең турында да сөйлә, барак турында да сөйләп бир әле.

Алар әкерен генә атлап зур агач баракның артына, күләгәле якка чыктылар да андагы өянкеләр арасындагы артсыз эскәмиягә утырдылар.

Суфия барактагы эш турында сөйли башлады. Сорашмаса да зирәк кыз Хөсәеннең кемнәр кушуы буенча йөргәнен тиз аңлады. Ул бит Гафурның сеңелесе генә түгел, сердәше һәм мәсләктәше дә. Хәер, аңа эшкә катнашырга бер дә туры килмәде, абыйлары прокламация басканда урамда капка сагалау гына димәсәң... Ул барактагы хәлләр турында түкми-чәчми барысын да әйтте. Медикаментлар җитмәвен, тәҗрибәле врачларның аз булуын, тиешле азык-төлек китермәүләрен, аны да әле урлашуларын сөйләде.

Хөсәен төпченеп сорашты, фактларны күңеленә теркәп утырды. Сүз ваба чире турында беткәч, Хөсәен:

— Инде үзең турында сөйлә. Соңгы вакытларда ничек яшәдең? Синнән хатлар килми башлагач, мин хафага калган идем, Суфия,— диде.

Ул шундый мөлаем бер караш ташлады кызга, Суфия чын күңеленнән моның өчен Хөсәенгә эченнән рәхмәтләр укыды. Ул сөйгәненә тагы да якынрак елышты. Күзләре белән генә Хөсәенгә текәлеп: «Яратам, яратам, мин сине» дип кабатлады. Әйе, Хөсәен дә җансыз, хиссез түгел иде. Ул хәтта кызның күз карашы белән үзенә ниләр әйтергә теләвен дә аңлый иде. Дөресен генә әйткәндә, ул үзе дә Суфияны бик якын күрә иде. Аны ул хәзер үк кочагына алып, үбәргә, иркәләргә әзер. Кара тутлы, кара күзле, елдам, нәфис, нечкә билле матур кыз каршында нинди ир тыныч кала алсын! Ләкин андый эш мөмкинме соң? Хөсәен яшь, гүзәл кызга, үзенең иң якын, иң кадерле дустының иркә сеңелесенә яхшылык теләми мени? Ә яхшылык теләү ул нәрсә дигән сүз? Нишләргә тиеш була соң Хөсәен? Хөсәеннең алдагы авыр эшләре, һәркөнне хәвеф-хәтәр бусагасын атлап йөрүе, һәм, һич уйламаганда, көтмәгәндә зинданга эләгү, яки сөргенгә куылу ихтималы күңеленнән үтә. Үзенең гомер буена хыялланган югары мәктәптә уку мөмкинлеген тормышка ашыру алдында торганлыгын да исенә төшерә. Әйе, барыннан да бигрәк, Хөсәеннең сәламәтлеге тәмам какшаган бит. Докторлар йөрәгең зәгыйфь, саклан, диләр. Үпкәсендә дә бар. Инде шундый хәлендә ул гөл кебек янып торган сәламәт кызны бәхетсез итсенме?!

Бу сораулар, Суфия турына уйлаган саен, Хөсәеннең күңелен сызып узалар. Әле менә, күзгә-күз карашып янәшә утырганда, тагы да кискенрәк рәвештә алга килеп бастылар. «Җүләр кыз, җүләр, гүзәл кыз,— дип уйлады Хөсәен,— мин бит сиңа тиң түгел. Син үзеңә менә дигән, үзең кебек сау-сәламәт егет табарга, бәхетле яшәргә хаклы».

Хөсәен Суфияның үзенә гашыйк булуын моннан өч-дүрт ел элек, әле Оренбурда яшәгәндә үк сизгән иде. Казанга бер яшерен генә кайтып, Гафурларда куна калган иде ул. Алар өчәү генә — Гафур, Суфия, Хөсәен чәй эчеп утыралар. Шунда нинди дер бер көч Хөсәенне кызга карарга мәҗбүр итте. Суфия үзенең озын керфекле зур күзләре белән шундый караш ташлады ки, егетнең ирексездән кулындагы балкашыгы эскәтергә төшеп китте. Бу караштан Хөсәен: «Мин сине яратам, яратам, яратам», дигән сүзләрне укыды һәм шул тәэсирнең илаһи көченнән, дуамаллыгыннан тәмам югалып калды.

Хөсәен Оренбурда «Урал» газетасы чыгарганда Суфия аңа еш-еш хатлар язып торды. Хатларында ул беркайчан да үзенең мәхәббәтен изһар итмәде, ләкин хатларның һәр юлыннан ярату билгесе, кызның һаман өзми-куймый Хөсәен турында уйланулары бик-бик ачык чагыла иде.

Суфия, гимназияне уңышлы тәмамлап, Петербургка китте. Анда нинди генә чибәр, асыл егетләрне күрмәгәндер, очратмагандыр ул. Ләкин шулай да кыз Хөсәенгә булган үзенең кайнар, саф гыйшкын киметмәде. Әйе, Хөсәен бу турыда бик нык уйланырга мәҗбүр иде. Ул берничә тапкыр кызга бик ачык итеп язарга ымсынды. Күңеленнән бу хатның һәр сүзен, һәр җөмләсен язды, ләкин кулына каләм, кәгазь алып өстәл янына утыргач, үзенең мондый хаты белән кызның күңелен ничек җәрәхәтләячәге турында уйлап тукталып кала иде. Җавапсыз калган мәхәббәттән дә авыррак фаҗига буламы соң яшь кеше өчен! Шулай итеп Хөсәен язар хатын язмас булды. Ә язылган хатларында исә бөтенләй мәхәббәткә кагылмады. Бары үзенең тормышы турында һәм гомуми нәрсәләр турында яза торган булды.

Менә инде тагы Суфия белән очрашу. Икәүдән икәү генә калып очрашу. Эчке кичерешләреңне, яшерен хисләреңне ачыктан-ачык әйтергә мөмкин булган очрашу. Ләкин бу юлы да Хөсәеннең кызга турыдан-туры әйтергә көче җитмәде. Алар Петербург хәлләре, андагы тормыш, уку, татар яшьләре турында сөйләштеләр. Казан вакыйгаларына күч-

теләр. Хөсәен үзенең әле күптән түгел генә Чабаксар тирәсендәге авылларга барып кайтуын, андагы чуваш крестьяннарының ачлыктан интегеп яшәүләрен сөйләде. Ниһаять, сүз Казанны тетрәткән давылга килеп житте. Хөсәен, давыл буласы көнне Хәдичәне каршы алган студентның мәете жимерекләр астыннан әле өченче көн генә табылуын әйтте.

Бераздан саубуллаштылар. Суфия тизрәк баракка йөгерде, Хөсәен исә трамвайга ашыкты.



12

Суфияның Хөсәенгә карата булган мәхәббәте абыйсы Гафурны да авыр борчуга салды. Ул берничә тапкыр сеңелесе белән ачыктан-ачык сөйләшеп караган иде инде. Башта каты кагылмаска тырышты, соңыннан инде, кызып китеп, дорфарак сөйләшкән чаклары да булгалады. Әмма хисләрне, аерата яшь кешенең хисләрен, гади төшендерү юллары белән генә үзгәртеп буламы?! Хәер, бу кадәресен Гафур үзе дә аңлый иде. Көчсезлектән, сеңелесенә ниндидер йогынты ясый алмавыннан үзе дә гажиз иде. Хәлбуки Суфияны өзелеп сөйгән яшь, чибәр, хөр фикерле егетләр дә юк түгел иде бит. Араларында Агиев дигәне Суфия өчен жан ата. Ләкин Суфия һаман Хөсәен белән саташа.

Хөсәен белән Хәдичәнең арасы болай да киеренке икәнлеген белгән Гафур, бу вакытсыз мәхәббәт аркасында дустының тормышы бөтенләй тоташ фажигагә әйләнүеннән курка иде. Ниһаять, ул түзмәде, сеңелесе белән тагы бер тапкыр шул турыда ныклап сөйләшергә булды.

Суфия ул көнне эштән соң гына кайтты. Ул арыган, алжыган һәм төшенке күңелле иде. Аның суырылып калган кара тутлы йөзен күргәч, Гафур баштагы ниятләреннән шундук чигенде, ваба барагындагы хәлләр турында сораша башлады.

— Хәлләр безнең ифрат начар, абый,— диде Суфия чәен эчә-эчә,— шул дәрәжәдә начар, хәтта минем медицинага булган хөрмәтем дә кими башлады инде шуның аркасында.

— Нигә алай төшенкелеккә бирелергә, Суфия.

Суфия зур күзләрен абыйсына текәде. Чыннан да бу күзләрдә тирән хәсрәт кенә чагыла иде бүген.

— Кешеләр үләләр, ә без аларга ярдәм күрсәтә алмыйбыз. Медицина да авыруга ярдәм күрсәтә алмый икән, нигә кирәге бар соң аның?

— Бу эштә табиплык фәнен генә гаепләргә ашыкма син, Суфия.

— Анысы шулай,— дип куйды кыз,— синең сүзләреңдә дә дөреслек бар. Житми бит, абый, кирәкле дарулары юк, житми аның тиешле шартлары.

Суфия Гафур һич белми торган дарулар, ниндидер процедуралар турында кызып сөйли башлады.

— Димәк монда синең яраткан фәнең гаепле түгел, ә минә эш башында утыручы бюрократия гаепле. Дөрес нәтижәләр чыгара белергә кирәк, Суфия. Юкса син бет ачуын туннан ала башлагансың.

Шулай да Гафур ул көнне Суфия белән ныклап сөйләшергә булды. Соңгы тапкыр, диде үз-үзенә, бер кәлимә сүз әйтмәм мин аңа бүтән.

— Суфия, минә ни турыда сорашмакчы идем мин,— дип сүз башлады ул ашап-эчкәч.— Син теге көнне Хәдичә апаң янына баргач, ул борчылырлык, кирәкмәс сүзләр кузгатмадыңмы?

Суфия житдиләнеп китте.

— Мин кузгатмадым, Хәдичә апа үзе башлады.

— Нәрсә диде?

— Үзенең көнче күбәләк икәнлеген сиздерде — минә шул.

— Димәк, көнләшерлек сәбәпләр булган.

Алар өстәл янында икәүдән-икәү генә калганнар иде. Бераз вакыт тынлык булып торды.

— Суфия акыллым, син хәзер яшүсмер бала түгел,— дип башлады Гафур,— Хөсәен абыйларыңның тормышлары ифрат авыр хәзер. Материаль яктан гына түгел, үзара мөнәсәбәтләре дә... Син, җиңел акыллыгың белән, Хөсәен абыеңны һәлакәткә илтмәгәең...

— Абый, бу турыда очрашкан саен аңлашмый калмыйбыз. Тагы бер тапкыр үтенәм, минем яшерен хисләремә кагылма. Мин хәзер яшүсмер Суфия түгел. Бер елдан врач дигән абруйлы исемне алачак кеше.

— Мин синнән бик үтенәм,— диде Гафур.

Абыйсының бик аз сүзле кеше икәнлеген һәм шулай ук горур булуын Суфия яхшы белә иде. Инде дә ул шулай түбәнчелек белән сеңелесеннән үтенә икән, аңа нииндидер өметле сүз әйтми булмый.

— Мин сиңа бары шуны вәгъдә итә алам: Хөсәен абыйга минем аркада бернинди дә авырлык килмәячәк.

Гафур, ни әйтергә дә белмичә, гасабыйланып, күлмәк якасын ычкындырды, каты итеп әйтергә дип авызын ачты, тик сүз әйтергә өлгерә алмый калды, ишектә энеләре Габделмән күренде.

— Абый, сине сорыйлар.

Гафур коелып төште. Ул үзенең исәптә торганлыгын һәм бернинди сәбәп булмаса да һәр минут кулга алыну ихтималын яхшы аңлый иде. Ул, җәйге ялы башлану белән туган-үскән якларына юкка гына кайтып китмәде бит.

— Керсен, кем ул? — диде.

— Ул керми. Миңа Гафур абый кирәк иде, бер генә минутка чыксын әле, ди.

Гафур өстәлгә орыла-сугыла чыкты да караңгы коридорга таба китте. Ишек янында аны гади эшче киемендәге озын буйлы ир кеше көтә иде.

— Сезгә... ни йомыш? — диде Гафур коры гына.

— Гафур абый, исәнмесез.

Гафур игътибар беләнрәк карады, ләкин биредә караңгы иде, ул аның йөзен ачык күрә алмады. Әмма ничектер тавышы бик таныш иде бу кешенең.

— Тукта, тукта,— диде Гафур, кинәт хәтерләп,— сез Фәрхетдин түгелме соң?

— Нәкъ үзе, Гафур абый,— диде Фәрхетдин көлемсерәп.

— Я хода, әйләнеп кайттыңмы? Исән-саумы? — диде Гафур үзенә таба сузылган кулны каты иттереп кысып.

— Әйдә, әйдә, узыйк әле минә минем бүлмәгә.

— Кереп тормасам да ярар иде инде, Гафур абый.

— Сөйләмә булмаганны. Әйдә, әйдә.

— Туктагыз алайса, итекне салыйм.

— Салып та торма. Аяк асты коры.

Фәрхетдин аякларын ишек янында яткан чыпта кисәгенә сөртте дә Гафур белән бергәләп кечкенә бүлмәгә керде.

— Һаман шул килеш икән әле,— диде ул шкафтагы китапларны, бүлмә җиһазын күздән кичереп. Алар китаплар, кулъязмалар белән тулган өстәл тирәсенә утыргач, сүзгә керештеләр.

Фәрхетдин срогын тутырып, сөргеннән бөтенләйгә котылып, әле бүген иртәнге якта гына Казанга кайтып төшкән икән. Үзенең элекке танышларыннан берәүне дә өйдә очратмаган. Хөсәеннәр дә элекке өйләрендә яшәмиләр, Галимҗан Сәйфетдинов тә квартирадан-квартирага күчеп, эз чуалтып көн күрә икән, башка таныш-белешләр дә Казаннан киткән. Ярый әле, ходага шөкер, Гафур абыйсы иске фатирында булып чыкты.

— Ничек яшәдең соң анда? — дип сорады Гафур.

— Ничек яшәдем, Гафур абый, сөргендәге кешенең хәлен беләсең инде. Төрлесе булды. Ачлыгы да, кыйналуы да. Башта авыр эшләрдә изаладылар. Урман кистек. Аннан, бер елдан соң, тимерчелеккә эләктем, үз һөнәремә. Инде менә соңгы елны Ялуторовский дигән шәһәрдә эшләдем. Бик иза чиккән чаклар булса да, тимерчелек һөнәренә нык-лап өйрәндем, хәзер инде чүкеч сугып торучы гына түгел мин. Моңы-сыннан да зуррагы шул булды: рус телен үзләштердем, укырга-язарга өйрәттеләр. Менә дигән кешеләр арасында күп нәрсәне аңладым, укы-дым, күзләрем ачылды дип уйлыйм.

— Ишеткәнебезчә, Ялуторовскида безнең Учительскаяның иң сөек-ле кешеләреннән берсе — революционер, большевик Кулеша Андрей Степанович булырга тиеш. Ул сигезенче елны Мәскәүдә кулга алынып, шунда сөрелгән булган.

— Ул юк инде, Гафур абый...

— Ничек, юк инде?..

— Шулай... аны сволочь карагруһчылар урамда кыйнап үтергәннәр. Мин үзем күрмәдем, ләкин миңа бик белеп сөйләделәр — охранка ял-лап үтерткәндер дип уйладык без.

Гафур тетрәнүдән өнсез калды: шул Кулеша бит инде Учительская егетләренә марксизмның беренче әлифләрен танытты, шул бит инде мәктәптәге татар яшьләрен акны карадан аерырга өйрәтте.

— Бик авыр хәбәр әйттең син миңа, Фәрхетдин,— диде Гафур,— мин бит аны бик яхшы белә идем.

— Андрей Степанович Хөсәен абый турында да, сезнең турыда да сагынып сөйли иде. Егет кеше иде ул.

— Әйбәт итеп күмдегезме соң ичмаса?

— Булдыра алганның барысын эшләдек. Күмү процессиясе чын де-монстрациягә әйләнде. Кабер янында кайгы митингысы булды, ә поли-циянең митингны таратырга кодрәтеннән килмәде, нигә дисәң, Андрей Степановичның абруе зур иде. Аны белмәгән кеше бар иде микән.

— Кайчан булды бу хәл?

— Күптән түгел генә, шушы айның уңдүртендә.

Бераз тынлыктан соң Фәрхетдин:

— Ничек яшиләр соң безнең Хөсәен абыйлар? — дип куйды.

— Хәзергә исән-сау, адресын бирермен.

Ишектән Суфия күренде.

— Абый, өстәл әзер, кунакны зал якка чыгар.

Алар олы якка чыктылар, чәй эчәргә утырдылар.

— Аны әйт тә, моны әйт дигәндәй, Гафур абый, минем Гыйззәтул-ламның хәлләре ничек?

— Гыйззәтуллаң исән-сау. Әлмәттә безнең бер дус яши, әледән-әле шуннан хәбәр килеп тора. Улың асрамага алган кеше кулында, матур гына булып үсеп килә, дип яза.

— Ач-ялангач түгел икән алайса улым. Җәберләмиләр микән үзен?

— Тыныч бул, Фәрхетдин, әйтәм ич, әйбәт кенә үсеп килә улың, дип яза.

— Өч ел буена шуның өчен ут йотып яшәдем, Гафур абый. Әлмәткә хат язам — җавап юк. Күрәсең, укый-яза белүче юктыр инде ул гаилә-дә. Менә шул, Хөсәен абыйдан, сездән килгән хатлар белән юанып яшәргә туры килде.

— Борчылма, Әлмәт Казаннан ерак түгел.

— Казан губернасы ачлыктан интегә дигәч, ач-ялангач Гыйззәтул-лам күз алдыма килеп баса да нишләргә белми идем, Гафур абый. Мин иртәгә үк Әлмәткә юл тотам. Улымны бик күрәсем килә.

Сүз Казан хәбәрләренә күчте. Сәгать төнге уникене сукканда урыннарыннан кузгалдылар. Гафур үз бүлмәсенә кереп ятты, Фәрхетдин исә Суфия әзерләгән урынга, идәнгә урнашты.

## 13

— Карале, Хөсәен,— диде Галимжан,— безнең «Әти»нең эшләре шәптән түгел бит.

— Авыруы көчәйгәнме? — диде Хөсәен шомланып.

— Бөтенләй аяктан язды. Алафузов больницасында авыр хәлдә ята. Мин кичә барып килдем. Тик үзең беләсең, озаклап янында утыра алмадым.

Хөсәен әле сүз барган «Әти»— Табейкин Ефим Панкратьевичның улы белән килеп чыккан вакыйганы хәтерләде. Өлгермәделәр шул, өлгермәделәр. Аны теге вакыт Казаннан Пермь төрмәсенә озатканнар. Нәрсә көтә инде хәзер Василийны, иң киме — гомерлек каторга. Ничек итеп карт мондый фаҗиганы авыр кичермәсен?!

Хөсәен уйларын Галимжанга да әйтте.

— Бәлки ул гына аны аяктан екмас та иде,— диде Галимжан,— соңгы тапкыр төрмәдән үк бик бетерешеп, үпкә чире алып кайтты бит.

— Мин, әлбәттә, аның янында булырга тиеш,— диде Хөсәен катгый рәвештә.— Мин аны күреп сөйләшергә тиеш.

Ул Галимжан Сәйфетдиновтан Панкратьевичны ничек, кайчан күрү мөмкинлеге турында сорашты.

Алар шулай тыкрык чатында бераз сөйләшеп тордылар да тиздән аерылыштылар. Ләкин Хөсәеннең уйларына яңа юнәлеш бирү өчен бер минут вакыт җитте. Җаков белән булган гәпне дә, Хәдичәне дә, Суфияны һәм башка бик күп кешеләргә бәйле уйларын да онытты, бары Казан революционерлары арасында «Әти» дип хөрмәт белән аталып йөртелгән эшче, утыз биш ел гомерен революциягә биргән, сигез тапкыр патша төрмәсендә газап чиккән кеше турында гына уйлана башлады. «Булса да була бит батыр, чигенүнең ни икәнен дә белми торган кешеләр! Һәм нинди катлаудан чыга шулар. Гади эшче арасыннан. Аксөякләр кимсетеп, түбәнсетеп, кешегә дә санамыйча карый торган гади эшчеләр арасыннан. Менә кемнән үрнәк алырга кирәк. Эшче сыйныфының бәхетле булуы өчен утыз биш ел гомерен биргән «Әти». Хатыны да, уллары Василий, Ваня, Саша да аның рухында тәрбияләнгән. Революция — хак эш, җиңми калмас, илдә мондый кешеләр барында җиңми калмас,— дип уйлады Хөсәен. Ул хәзерге шартларның коточкыч авыр икәнлеген белә, ләкин алар вакытлы гына дип ышана иде Хөсәен,— бүген булмаса иртәгә көчле революцион хәрәкәт башланаячак. Әлегә хөкем сөргән серле тынлык — ул бары тик түл җыю, дөресрәге — дары, шартлагыч җыю чоры гына. Бер көн килер, бер көн килер дә, бу гаделсез тормышның астын өскә китерербез!» — Хөсәен шундый кайнар, дәртле уйлар белән булашып барды. Андый ышаныч аның кыйбласы гына түгел, авыр чакларда аның күңел юаткычы да иде. Авырлыклар, күңел җәрәхәтләре шул бөек ышаныч, иман аркасында Хөсәенне беркайчан да сытып, изеп юкка чыгара алмый, аның горур кешелек сыйфатларын әз генә дә киметми.

Хөсәен ул көнне Табейкин янына бара алмады. Ләкин икенче көнне иртәнге чәен эчү белән үк елга аръягына ашыкты. Иртәнге уннарда ул Ефим янында иде инде.

Карт аны якын күреп, елмаеп, каршы алды. Ефимның хәле чыннан да әйбәт түгел иде. Йөзе саргайган, сакал-мыегы тәртипсез чуалган, күзләре ялтырый, үзе авыр сулый иде. Хөсәен аның хәлсез кулын тотып

исәнләште, караватны янына артсыз урындыкка урнашты. Авыру кысан бүлмәдә ялгызы гына ята иде. Гадәттә мондый бүлмәләргә өметсез авыруларны салалар. Ирексездән, Хөсәен кайчандыр үзләрендә «жантимер»ләрдән качып яткан Заводскийны хәтерләде. Ул да шундый ук бер кыяфәттә ята иде бит. Ләкин ул әкренләп рәтләнде, аннан соң ничә ел яшәде, күрәште! Җиденче елны Хөсәен «Урал»ны чыгарудан тәмам өметен өзеп Казанга кайткач, аны тагы бер күргән иде. Алар якын дусларча сөйләштеләр. Щетинкин ресторанына кереп чәй эчтеләр. Әмма Заводскийга Казанда озакка калырга ярамый иде. Ленин чакыруы буенча Италиягә дәваланырга китте. Ә менә быел Швейцариядә Беренче май бәйрәме көнне, артык нык дулкынланудан егылып үлгән. Шулай да биш ел яшәде бит. Юкса нәкъ менә «Эти» кебек үк бөтенләй бетерешкән иде. Бәлки Ефим Панкратьевич та рәтләнеп китәр әле. Ә биш ел гомер Табейкин кебек революционерга ул бик күп эшләр майтарырга мөмкинлек бирә. Хөсәеннең күңеленнән Табейкин белән күрешкән арада шундый уйлар узды.

— Ярминкәдән кайтып җитәм булса кирәк, Хөсәен,— диде Ефим.

— Ашыкма, «Эти»,— диде Хөсәен.

— Чир ашыктыра бит, каһәр.

— Менә чарасына керербез, акча табып, сине Кырымга җибәрербез. Нигә, безнең бит андый тәҗрибә бар.

— Андый мөмкинлекләр хәзер юк инде, Хөсәен, хәзер безнең һәр адымыбыз күзәтү астында, бу авыр көннәрне син теге еллар белән чагыштырма. Аны үзең дә беләсең. Ә инде акчалата ярдәм оештырырык дисең икән, аны беләсеңме кемгә оештырырга кирәк? Догадовка, Сашага. Сиңа иптәшләр әйткәннәрдер инде: Прагада Бөтенроссия большевикларының конференциясе булачак. Шунда Казан делегаты булып Догадов барачак. Син аны хәтерлисеңдер бит. Хәзер ул Лонжюмода, Ленин мәктәбендә.

— Мин аны бишенче елдан ук беләм. Ул Либих заводында корыч коючы булып эшли иде. Без аны партиягә алдык. Мин аның белән Бакуда да очраштым.

— Менә шул Догадов Александр Иванович, безнең Казан егете, казанлылар исеменнән Прага конференциясенә барырга тиеш. Шундый карар кабул ителгән. Менә кемгә ярдәм итәргә кирәк.— Ефим, сакалын сыпырып, елмаеп куйды.— Ә мин, ярминкәдән кайтам дигәч тә, алай үләргә җыенмыйм әле,— диде ул еш-еш сулап.— Хәтәррәк хәлләрдән котылып аякка басканым бар.

— Мактанма, зинһар, Панкратьевич. Без кулдан килгәнне эшләми калмабыз. Син революция өчен кирәк.

— Анысы дөрес, Хөсәен, мин бөтен барлыгымны эшче сыйныфы өчен бирдем. Үзем өчен берни калдырмадым. Үземә берни дә кирәкми. Без теләгәннәр гамәлгә ашса, шул җиткән.

Ефим артык дулкынланып сөйли башлады. Аңа пышылдап сөйләшү дә артык авырга туры килә иде. Картның бит урталарына сырхау кызыллыгы йөгерде, күзләре тагы да ныграк ялтырый төште.

— Тынычлан, «Эти»,— диде Хөсәен аның өчен борчылып.— бераз тын гына утырыйк.

— Бер атна инде менә берниндиә дә яңалык хәбәр итмиләр миңа. Янәсе, борчыйсылары килми. Син үзең белгән яңалыкларны житкер әле, Хөсәен. Мин барысыннан да хәбәрдар булсам гына үземне тыныч тоям. Ул хәтта сәламәтлегем өчен дә файдалы булачак.

Хөсәен көлемсерәп куйды.

— Син, «Эти», һәрьяклап нигезләдең инде болай булгач.

— Бу — Догадов мәсьәләсен миңа кулга алынганчы ук Лотов әйткән иде. Улым Василий хәлләре аркасында хәзер тәмам читтә калдым.

— Нинди яңалык,— диде Хөсәен кулларын җәеп,— әйтерлек әллә ни юк. Охранка албасты кебек безне камаган, кымшанырга да ирек бирми.

— Анысың инде син арттырасың. Уйлабрак эшләсәк, тик ятмаска мөмкинлекләр бар әле.— Бераз паузадан соң карт сорап куйды:

— Безнең Миңнулла Вәлиевич кайда икән?

— Ул әле Мәләкәстә иде, белүемчә. Ә менә Сәгыевне Бакуда тагы кулга алганнар — провокатор саткан. Екатерининбургтан ук Садыйкка ияреп йөргән, сволочь. Әйе, әйтергә онытканмын, «Әти», син Фәрхетдин дигән егетне беләидеңме? Җиденче елны суды Казанда булды.

— Теге бишенче елны карагруһчылар кыйнаган егетме?

— Әйе, шул сөргеен срогын тутырып Ялуторовскидан кайткан бит. Күрдем, тәмам җитлеккән, менә дигән аңлы егет булып җитешкән.

— Анысы бик әйбәт булган,— дип куйды Ефим.— Тагы?

Кулеша турында әйтергәме, юкмы дип икеләнде Хөсәен. Әйтмәү дә җинаять иде аныңча. Табейкинның Кулешаны яхшы белгәнлеген, бик якын иткәнлеген ул хәтерли. Ләкин шулай да картны борчырга батырчылыгы җитмәде аның. Әнә Заводски да Беренче май көнне, урамнан узган демонстрацияне күреп, дулкынланудан кинәт үлеп киткән бит. Димәк, дулкынланырга ярамый авыру кешегә.

Ул бишенче елларда коммуна милициясе башлыгы булган Дамперовның Казанда медицина факультетын бетерсә дә, эшкә урнаша алмый йөрүен әйтте (үзе эчтән генә «Ә Хәдичә, ул да теш врачлыгына укый бит, ул эшкә урнаша алырмы соң?» — дип уйлап алды).

— Шушы араларда күргән идем үзен,— диде.— Чит илгә китми булмас ахры, ди. Болгариягә китү ихтималы бар. Ә Зарницын инде, беләсеңдер, узган елны ук этап белән Казанга кайтарылган иде. Хосуси дәресләр биреп көн итә. Хатыны — кибеттә кассир.

— Боларын беләм. Женяның эшсез йөргәнен беләм, дип әйтүем, ә менә аның чит илгә китәргә җыенуын беренче тапкыр ишетәм. Бәйләнеш ничек булыр, әгәр алар китсә? Юлия Михайловнаның кассада утыруы безнең өчен бик җайлы иде бит.

— Борчылма, чарасына керербез. Абрам Павлович минем белән бик нык бәйләнеш тота, без әйбәт эшлибез аның белән.

— Комлев шәп егет ул.

— Мальцев сөргендә, хатлары килеп тора.

— Анысын да беләм.

— Саммер Иван Адамович шулай ук сөргендә, хәтта Мальцев белән бергә — Вологдада.

— Анысын да беләм.

— Менә шул,— диде Хөсәен, авыр йөктән котылгандай,— калганы сиңа мәгълүм.

— Туктале,— дип Ефим чуалган кашларын җыерде.— Син теге Фәрхетдинне Ялуторовскийдан кайтты дидеңме?

Хөсәен, тиешсез сүз әйтеп җибәргәнлегенә борчылып, аскы иренен тешләде. Карт сүзен дәвам иттерде:

— Безнең Кулеша шунда бит. Аның турында берәр хәбәр алып кайтмаганмы егет?

— Кайткан,— диде Хөсәен, тәвәккәлләп,— ләкин бик күңелсез хәбәр. Картның йөзенә курку билгесе чыкты.

— Безнең Кулешаны карагруһчылар үтергән. Көпә-көндез, урамда аркасына пычак кадаганнар.

Ефим, өнсез калып, бер ноктага караган килеш беравык тын ятты.

— Менә бу хәбәрне яшьләргә — безнең сүзгә колак сала торган, күзләре ачыла башлаган яшьләргә житкерергә кирәк, Хөсәен. Аның үлеме дә безнең эшкә хезмәт итәргә тиеш.

— Шулай, «Эти», без әле кичә Жаков белән дә шул турыда сөйләшеп, шундый карарга килдек. Матбугаттан файдаланырга кирәк.

— Менә тагы нәрсә,— диде Табейкин. Ләкин ул сүзен төгәлли алмады, ишек ачылып китте дә җил-җил атлап керүче ачулы шәфкать туташы күренде.

— Сез бит, әфәнде, биш кенә минутка керәм, дигегез. Хәзер үк чыгып китүегезне үтенәм.

Каршы килүдә мәгънә юк иде. Хөсәен аягүрә басты, тизрәк савыгуын теләп, Ефимның кулын кысты.

— Менә сиңа бәләкәй генә күчтәнәч,— дип ул газетага төрелгән банкалы вареньены караватт янындагы тумбочкага куйды.

— Рәхмәт,— диде карт, карлыккан тавыш белән.

Ефимның, кайчандыр имәндәй таза булган Ефимның, хәзерге кыяфәтен күреп ул артык нык дулкынланган иде. Хөсәен шул ук көнне, акча булдыру максаты белән, якын дусларыннан Мөхетдин Корбангалиев һәм Гафур Коләхметов белән сөйләште. Алар өметне «Шәрык клубы»на бәйларга кирәклеген әйттеләр. «Шәрык клубы» башлыкларыннан кайчандыр Җәгъфәр гашыйк булып йөргән Рабига Габитова һәм Галиәсгар Камал, Солтан Рахманколыйлар белән сөйләшергә кирәк иде. Ике кичә уздырырга булдылар. Берсе аның Догадовка ярдәм итү өчен, икенчесе Ефим Панкратьевич файдасына.

Догадов өчен дип оештырылган концерт кичәсе тиз арада уздырылды, анда Солтан Рахманколый һәм башкалар җырлады. Акча да ярыйсы гына тупланды. Хөсәен ул акчаны Жаковка тапшырды.

Әмма икенче кичә булмый калды. Аны шактый зур концерт рәвешендә уздырырга җыенган арада, Табейкинның вафат булу хәбәре ишетелде.

## 14

Ефим Табейкин үлгәннән соң шулар мәгълүм булды: аны яңадан төрмәгә утырту өчен, охранкада материаллар хәзерләнеп беткән, ул нәкъ шушы көннәрдә кулга алынырга тиеш булган икән. Үлем генә карт революционерны инде тугызынчы тапкыр караңгы, юеш төрмәгә эләгүдән коткарып калган.

Хәер, патша сатрапларының, бер Табейкинны гына түгел, барлык мәгълүм революционерларны кулга алырга җыенуы беленде. «Урал» газетасын оештыручыларга булачак зур суд процессы, дәһшәт орып, көннән-көн якыная барды. Тикшерү — җавап алу, судка материал әзерләү дәвам итте. Хөсәенне, Галимҗанны, Тимершаны, Хәдичәне судка чакырып сораштылар, протоколлар яздылар.

Хөкемгә тартылучыларның берсе булган Тимерша Соловьевның әле Мәкәрҗәдә ресторанлы кунак өе, әле Казанда кинотеатр ачып акча туплавы һәм аннан файдалануы процессны кичектерүгә берникадәр ярдәм итсә дә, Хөсәен белән Галимҗан Сәйфетдинов өстендәге золмәт кылычы көннән-көн ныграк уйнады. Чөнки Хөсәеннең дә, Галимҗанның да «гөнаһлары» «Урал» газетасын чыгару белән генә чикләнми иде.

Рәхимсез репрессиянең яңа дулкыны якынлашкач, иптәшләре Хөсәенгә дәвалану сылтавы белән, Әстерхан аша Кавказ якларына китәргә, шомлы дулкын узганчы шунда торып торырга, ә Сәйфетдиновка туган шәһәре Троицкига китеп, шунда авыр чорны уздырырга киңәш иттеләр. Казан группасы большевиклары өчен татарлар арасында революцион эш алып баручылар аерата кадерле һәм аларны нинди генә юллар белән булса да саклап калырга кирәк иде. Хөсәенгә шул ук вакытта партия заданиеләры да бирделәр. Ул Әстерханда революционерлар

белән, хосусан, хәзер сөрген срогын уздыручы революционер Нариман Нариманов белән күрешергә һәм Бакуда, Садыйк кулга алыну аркасында югалган явкаларны яңадан булдырырга, большевиклар оешмасы белән бәйләнешкә керергә тиеш.

Галимҗан Сәйфетдиновка исә, туган шәһәренә кайтышлый, Екатеринбургка һәм Чиләбегә тукталырга, андагы иптәшләр белән бәйләнешкә керергә, аларның Казан большевистик группасы белән элемтәсен ныгытырга кушылды.

Идел саеккан, пароходлар тәртипсез йөри иде хәзер. Июль башында Хөсәен, Әстерхан пароходына утырып, Казаннан көньякка таба китте. Озатырга килгән Хәдичә аңа яулык болгап калды. Әйе, палубада торган Хөсәен күздән югалганчы яулыгын болгады ул, ләкин үзе дә сизде, бу аерылышу элеккеләре кебек, йөрәк өзгеч авыр түгел иде инде. Хәтта әле Хәдичә үзендә ниндидер бер җиңеллек сизде, күңел түрен борчып торган вазифадан котылу рәхәтен кичерде сыман.

Галимҗан Сәйфетдинов Казаннан туган шәһәренә поезд белән кузгалды. Аның байтактан инде әти-әнисен күргәне юк иде. Кәрәсе шәһәрләренә кереп, күрәсе кешеләрен күреп чыкканнан соң, ниһаять, ул Троицкига кайтып житте.

Комлы урамнары, Бабай таулары белән, җәйләрен кибеп бетәрлек саега торган Увелька һәм Уй елгалары белән гомергә истә калган шушы шәһәрдә узды аның балалык еллары. Увелька елгасы каланы икегә ярып уза, аның вокзал ягы — Амур, икенче ягы — Калаяк дип атала. Таш пулатлар, байларның пассажлары һәм тезелеп киткән таш кибетләре — Калаякта. Амур ягы исә, елга буйлап сузыла торгач, Яңавыл дип аталган бәләкәй бистәгә барып тоташа. Амур ягында яшәделәр Галимҗаннар. Әтисе кәвешче булды, ишле семьяга килере житенкерәми иде. Галимҗанга бик яшьли туган өй җылысын онытырга туры килде. Ләкин шул бәләкәй, дәртле шәһәрнең кешеләрен, әти-әнисен һаман сагынып яшәде ул. Әлбәттә, аның кем икәнлеген белеп, Галимҗанның язмышы өчен ут йотып яшәгән туганнарын ул мөмкин кадәр борчымаска тырышты. Үзенең төрмәдә булуын, сөргенгә озатылуын да яшерергә тырышты. Ләкин аның туган шәһәрендә дә шул ук патша сатраплары түрәлек итә иде. Алар озакка сузмадылар, әтисенә улының кем икәнлеген хәбәр иттеләр. Тыныч кына яшәгән ата-анага бу хәбәрне ишетү авыр иде. Динле кешеләр өчен тагы бер тетрәткеч хәбәр ишетелде. Галимҗанның марҗа кызына өйләнүен дә житкезделәр. Монысы да ата-ана өчен җиңел хәбәр булмады. Ләкин шулай да, картлар улларына бәддога укымадылар. Эчтән әрнеделәр, мәгәр Галимҗанга карата һаман шәфкатьле ата-ана булып калдылар, хәер-фатихада булдылар. Менә шундый хәлләрдән соң Галимҗанның туган якларына беренче тапкыр кайтуы иде әле.

Ул телеграмм сугып тормады. Троицкиның сөзәк тау өстендәге бәләкәй станциясендә поездан төшү белән ул, кеше-кара күзенә чагылмаскарак тырышып, извозчик яллады, шәһәр ягына ашыкты.

Шәһәр тау астында иде. Берара ачык дала буйлап барырга кирәк. Галимҗан Уй елгасы аръягыннан башланып киткән очсыз-кырыйсыз казакъ далаларының гүзәллеген исенә төшерде. Хәзер, чиллә кергәч, аның яме яз көнендәге кебек түгел шул дип уйланды. Хәер, «әби чәче»— кылганнары йөгергән киңлекләрнең үзенә бертөрле матурлыгы сакланган булырга тиеш әле. Кылганнарның киң далада «куян куып» уйнавы үзе ни тора!

Атны тыебрак таудан түбән төшә башладылар. Тау өстеннән Амурдагы өйләр һәм мәчет-чиркәүләр генә түгел, елга, елга аръягындагы Калаяк та, андагы ак таш пулатлар да ап-ачык булып күренә иде. Галимҗаннар төшкән шәпкә урамга килеп чыктылар. Урам — киң, ап-

ак ком белән түшәлгән. Җәйләрен биредә хәтәр өермәләр уйный, күз ачкысыз ком бураны була иде. Ләкин аның каравы тын көннәрдә, тымызык җәйге кичләрдә бу урам — малай-шалай өчен иң күңелле урын. Биредә лапта уйныйлар. Бөтен урам мәйданын шаулатып әллә кайларга туп очырталар, шау-гөр килеп туп артыннан чабалар, инде дә булмаса, чүрәкәй уйныйлар, яки шобай, я булмаса бакай уены белән шашалар. Чүрәкәйне Казан якларындагы кебек калак белән бәреп очырмыйлар, түгәрәк шома таяк кулланалар, инде шобай дигәннәре — бер карыш буйлы түгәрәк тимер кисәге, һич югында тырма теше. Бакай дигәннәрен Казан якларында да уйныйлар икән. Ишетелүенчә, шагыйрь Габдулла Тукай да, олы башын кече итеп, малайлар белән шул бакай уенында катнашкалый имеш. Әмма казанлылар бакайны русчалатып кузна дип йөртәләр.

Әйе, Галимҗан бала чакларындагы һәр мизгелне ачык хәтерли. Көз көне алар кәгазь очкыч, монах очыралар иде. Качак-качак уйнау дисеңме, шакшакала дисеңме — берсен дә уйнамый калмады Галимҗан. Яз житү белән, дала кочагына йомраннар ауларга чыга иде алар. Җәй башыннан ук Уй белән Увелька кушылган урынга балык тотарга йөриләр, су керәләр иде. Күңелле иде ул чак. Ләкин мондый ирекле тормыш Галимҗан өчен озакка бармады. Аны ишан мәдрәсәсенә бирделәр. Галимҗанның мәдрәсәдә укыйсы килмәде — китте ялгыз башын алып дөнья гизәргә. Ә менә бүген ул тагы балалык хатирәләрен уяткан туган каласы урамнарында извозчикта бара.

Галимҗанның туган шәһәре Россиянең казакъ белән алыш-биреш, сәүдә итә торган урыннарның берсе иде. Монда кассапчылар[1] бихисап күп, шәһәрнең Бабай тавы ягында кассапчы биналары тезелеп киткән. Мал сәүдәсе белән шөгыльләнүчеләр казакъ далаларыннан мал җыялар, меңәр баш сарык көтүләре, йөзләгән мөгезле эре терлек өзлексез шәһәр урамнарыннан узып кассап кураларына куыла. Анда аларны иткә әйләндереп, бозлы вагоннарда Россия шәһәрләренә озаталар. Ә Уй елгасы артында меновой двор, казакъ, татар аны «миңауный» дип атый. Монда сату-алу урыны, малга товар алыштыру, алдану һәм алдашу эшләре башкарыла. Базар көннәрендә анда мәхшәр, анда халык дәрьясы. Хәтта карусельләр корыла, кәмит күрсәтүчеләр, күз буяучылар, фокусчылар, канатта йөрүчеләр, шпага йотучылар, хәерчеләр, музыкантлар — барчасы шунда агыла. Әйе, шундый шәһәр ул Троицк. Ул үзенең миллионерлары һәм ишан хәзрәте, ахуны белән генә шөһрәтле түгел, анда алдынгы кешеләр дә тәрбияләнгән. Мәдрәсәдә Галимҗан Мәҗит Гафури белән бер вакытта укыды. Булачак шагыйрьне «аксак Мәҗит» дип йөртәләр иде. Ул бик фәкыйрь иде, бай шәкертләргә самавыр куеп, аш пешереп, үз көнен үзе күрде. Ә хәзер нинди хөрмәтле затка әйләнде! Соңгы вакытларда әдәбият галәменә шаулап килеп кергән, Тукайлар белән бәхәс куптара башлаган Галимҗанның әнисе дә бит Троицк кызы. Казанда дөньяви фәннәр укыта торган кызлар мәктәбе ачкан Фатиха Аитова Троицкида туып үсмәгәнмени! Менә шулайрак ул, аның туган каласы! Галимҗан, үзалдына һавалanып, елмаеп куйды. Аның хәзер үз каласы белән горурланасы, аның бары уңай якларын гына калкытып күрәсе килә иде.

Бу дәрәҗәдә үк үзен җылы каршы алырлар дип уйламаган иде Галимҗан. Аз сүзле әтисе дә хәтта Галимҗанны кочып аркасыннан сөйде, әнисе исә җылап үк җибәрде, улының муенына сарылды.

— Сезне күреп китү өчен, бераз ял да итеп булмасмы дип кайттым,— дип сүз башлады Галимҗан,— киленегездән бик күп сәлам, шулаи ук оныгыгыздан да сәлам,— дип өстәде.

---

[1] Кассапчы — мал суйдыручы.

Галимҗан үзенең ни өчен телеграммасыз, хәбәрсез килеп төшүен аңлатып тормады. Шулай да өйдәгеләргә үзенең кайтып керүен фаш итеп йөрмәскә, кунак кайтты дип мәҗлес җыймаска кирәклеген аңлатты. «Бераз тыныч кына яшисем килә, ыгы-зыгыдан мин болай да гарык»,— диде. Шәһәрдә бераз торганнан соң казакъка кымызга чыгарга җыенуын, әгәр теләсәләр инде, яшьләрне дә үзе белән ияртергә риза булуын әйтте.

Галимҗан кайтканның икенче көнендә үк, үзенә мәгълүм адреслар буенча, кирәкле кешеләрен эзләп тапты, алар белән бәйләнеш яңартты, алардан хәл-әхвәлне сорашып, шәһәр һәм аның тирәсендәге революцион эш турындагы яңалыкларны белде. Монда да реакция үзенең пычрак тырнакларын тырпайткан, революцион хәрәкәтне буып ташларга ашкына. Галимҗан, бик яшерен рәвештә, сыналган кешеләр белән әңгәмә уздырды, аларга үзәктәге яңалыкларны җиткерде. Икенче көнне ул хөр фикерле приказчиклар профсоюзында булды. Биредә эшчеләрдән битәр вак һөнәрчеләр күбрәк иде. Чөнки бөтен шәһәренә бер күн заводы, сыра заводы, паровой тегермән һәм ике кечкенә сабын производствосы гына бар. Бу вак һөнәрчеләр — кассапчылар һәм сәүдәгәрләр шәһәре иде.

Галимҗан бер атна әти-әнисендә кунак булганнан соң, энесен һәм кече сеңелесен ияртеп казакъ җәйләвенә китте. Уй елгасы буеннан вакытлыча торырга казакъ тирмәсе алды. Ризык — хуҗадан, көн дә ике чирек кымыз, ә чәй-шикәр — үзенеке.

## 15

Галимҗан үзенең туганнары белән казакъ җәйләвендә ятканда, мөмкинлектән файдаланып, күбрәк укырга тырышты. Аңа мондый вакыт иркенлеге беркайчан да тәтемәгән иде әле. Үзе белән марксистик әдәбиятны бер кочак алып килде. Энесе даладан кизәк җыя, сеңелесе аш пешерә, чәй кайната, ә Галимҗан, җиләс булсын өчен тирмә киезләрен күтәреп куя да, рәхәтләнеп тик китап укып ята. Хәер, алар иртә таңнан торып, төнбоеклы Уйның борылыш ясаган тын бер урынында балык та тоткаладылар. «Әҗәл тагарагында», кыргый үрдәкләрне куркытып, елганың әллә кайсы төбәкләренә барып чыккаладылар. Кичләрен черки, озынборыннан саклану өчен, пыскып янган учак янында «кем сукты», караңгы төшкәнче лото, яки акчасыз гына кәртле уйнадылар. Көннең озын вакыты, барысына да өлгерергә була. Галимҗан, гадәтенчә, бик тиз укый, шундук үзенең дәфтәренә бик кирәк урыннарын сызгалап та бара иде.

Ул үзе яки энесе атнага бер-ике тапкыр Троицкига чәй-шикәр алырга кайтып киләләр, итнең яңа суелганын, тәмлесен мул итеп ашыйлар, кымызны ашыкмыйча гына, каймак тәмнәре кергәнче, шапырып, озаклап җамаяклардан эчәләр. Галимҗанның да соңгы вакытларда үпкәсе начарлана башлаган иде. Заман чире, нихәл итәсең, дус-иш арасында бу чирне йоктырмаган кеше сирәк. Ләкин атна-ун көндә барысы рәтләнде, Галимҗанның йөзенә сәламәт алсулык йөгерде, мускулларының ныгуын ул үзе дә сизә башлады.

Аның янына шәһәрдән якын иптәшләре, фикердәшләре килгәләде. Алар караңгы төшкәч кенә,-кеше кара күзенә артык чалынмаска тырышып кына киләләр иде. Төнне Галимҗан белән тирмәдә сөйләшеп уздыралар. Сызылып таң ата башлау белән, утлап йөргән атларын тиз генә җигеп, шәһәргә юл алалар.

Соңгы тапкыр чәй-шикәргә дип шәһәргә кайтканда Галимҗан һич уйламаган-көтмәгән бер кеше белән очрашты. Ул Амурның комлы олы урамыннан бара иде. Алда ишан хәзрәтнең ике катлы өе, арырак —

мәчет. Ишан хәзрәт капкасы алдындагы ат бәйләү урыннары халык, мал-туар белән тулы. Ишанга һәр көнне мөритләре генә түгел, ерак казакъ далаларыннан фатиха алу өчен, өшкертү, дәва алып китү өчен һәммә кешеләр өзлексез килеп тора. Монда атлылар, дөя җигеп килүчеләр, болай гына, хәзрәткә сәдака итеп сарык, сыер, ат, дөя өше мал-туар тагып килүчеләр җәен дә, кышын да тукталмый. Сарыкларның бакырышуы, сыерлар мөгрәве, дөяләрнең төкеренүләре бередә үзенә бер базарны хәтерләтә. Элек тә шулай иде. Хәзер дә нәкъ элеккечә икән.

Галимҗан бу «базарны» читләтеп узып барганда, Яңавыл ягындагы чаттан чыбыктан үрелгән җиңел тарантаслы ат килеп чыкты. Түрдә юан карт казакъ утагасы кукраеп утыра, аның янында кәләпүшле, казакиле, мыеклы татар, ат башында исә, чиллә вакыты булуына карамастан, башына йөнтәс томак кигән казакъ егете. Галимҗан турына житкәч, атны туктаттылар. Җиргә төшеп, тузаннарын кага-кага, өс киемнәрен салып селки башладылар. Кара мыеклы татар, аякларын язу өчен ботларын угалый, хәтта биегән сыман итеп сикергәләп тә алды. Ничектер таныш иде бу кешенең йөзе. Галимҗан якынлашкан саен шуңа ныграк ышана барды.

— Гафу итәсез, әфәнде, мин сезне таныган кебек булам.

Җәгъфәр кара зур күзләрен ялт итеп Галимҗанга текәде. Йөзеннән башта куркыну, аннан аптырау билгеләре узды.

— Я хода,— дип куйды ул әкрен генә,— Галимҗан Сәйфетдинов бит сез. Сезне бирегә нинди җилләр ташлады?

— Бу минем туган шәһәрем. Менә сез ничек килеп чыктыгыз бирегә?

Казакъ бае, рус кыяфәтле Галимҗанга артык өнәмичә карап торды да:

— Мин тәһарәт сындырып чыгаем,— дип, ачык капкадан ишегалдына кереп китте.

Галимҗан Җәгъфәрнең йомшак кулын кысты, казакъ егете атны туарып маташкан арада алар сөйләшеп тордылар.

— Хәтерегездә булса, мин «Урал» идарәсенә үземнең казакъ арасына мөгаллим булып китәргә җыеңумны язган идем. Әмма мин бу эшне башкарырга өлгермәдем, сезнең газетаны ябып та куйганнар. Сез киттегез, ә мин казакъ арасында шулай каңгырап калдым. Тәмам казакълашып беттем, билләһи.

Җәгъфәр үзенең кайда яшәве, хезмәте турында сөйли башлады.

— Ә бирегә, ишан хәзрәт капкасы төбендә нигә тукталдыгыз соң әле?

— Менә, тәһарәтханәгә дип кереп киткән казакъ минем баем була инде,— диде Җәгъфәр.— Мин шуңа юлдаш буларак килдем. Юкса, ерак юл, карт кеше бит... Ә сез кайчаннан бирле бирегә?

Ул Галимҗанның әле ай башында гына кайтканлыгын белгәч, бик шатланды. Казан хәбәрләрен сораша башлады. Аны хәзер Казанның һәрбер яңалыгы кызыксындыра. Ул бары бер тапкыр гына, анда да бәхетле очрак аркасында Казан газеталары белән танышты. Галимҗан «мүлдәке»гә шактый сакланып, кайбер Казан хәбәрләрен әйтте. Ул Җәгъфәрне бишенче ел вакыйгаларыннан бирле белә иде, аны революционерлар арасында да күргәләде. Аумакай, принципсыз, куркак җан иде ул Галимҗан өчен.

Бераз сөйләшеп торганнан соң, алар аерылыштылар. Хәлбуки Җәгъфәр Галимҗанга дөресен әйтмәде. Ул казакъны озатып килүче сыйфатында гына түгел, хаҗ сәфәренә китәргә ишаннан үзенә фатиха алу өчен бирегә килгән иде.

Алар Туктыбай белән ишан хәзрәткә кереп, аның фатихасын алдылар. Кунак өендә кундылар. Солы ашатып атны ял иттерделәр. Аннан кире Убаган буена җәйләүгә кайтып киттеләр. Өч көннән соң Җәгъфәргә

Оренбургтан паспорт килде, ә биш көннән соң ул Самара аша Одессага таба поездда юл тотты.

Җәгъфәрнең Одесса кадәр дә гүзәл бер шәһәр күргәне юк иде әле. Шәһәрнең яшеллеккә күмелгән, шарлап торган фонтаннар белән бизәлгән урамнарын, диңгез буйларындагы паркларына карап йөрде. Искиткеч матур, җәннәт кебек урыннарга бай шәһәр иде бу. Хәтта Җәгъфәрнең күңелендә, әллә Төркиягә китмим микән дигән икеләнүле уй да туды. Ләкин бу тиз узды, чөнки диңгез арты аңа шатлык, бәхет, омтылышлы киләчәк вәгъдә итә иде.

Ул арып, тәмам аяктан калганчы, Одессаның үзәк урамнарында йөреп, берсеннән-берсе матуррак киенгән, әллә нинди хикмәтле күлмәкләрдән, киң кырлы җиңел эшләпәле хушбуй исе аңкытып йөрүче дамаларга, барышняларга сокланып туялмады. Казакъ сахраларында эчпошыргыч бертөрлелектән узган көннәре аңарда мондый матурлыкка карата чиксез сагыну хисләре уяткан иде, ул һәрбер кешегә исе китеп, күзләрен шакмаклландырып караганын үзе дә сизми иде хәзер.

Ниһаять, аның артык барыр әмәле калмады, ул кечкенә генә бер харчевняга кереп чәй алды, үзе алып килгән бавырсагын чәйдә җебетеп ашады. Аннан бераз хәл кергәч, әкрен генә атлап пристань янындагы казарманы эзли китте.

Складка охшаш итеп агачтан салынган бу корылмага халык шыплап тутырылган. Күпчелек Төркестан, Бохара якларыннан, кавказлылар да аз түгел. Хаҗиларның күпчелеге, эсселеккә чыдый алмау аркасында, ярым шәрә килеш ята. Казарма эченә авыр тир, бәвел исе таралган. Хаҗиларнын кайсы төенчекләрен баш астына кыстырып йоклый; кайсы ашап янсә яшел чәй эчеп утыра. Араларында бер генә дә татар күренми әлегә. Җәгъфәр, берәр якташ табылмасмы дигән өмет белән, эчкә узды, һәм, ниһаять, тәрәзә янындагы эскәмиядә ярым европача киемле берничә яшь кешене күреп, игътибарын шунда юнәлтте.

Татарча әйтелгән сүзләрен ишетеп калды Җәгъфәр. Төенчекләр аша зур-зур атлап шул якка таба ашыкты. Якынлашкан саен тегеләрнең татар икәнлегенә ышанычы арта барды. Бу кешеләрне ул кайдадыр күргән дә кебек иде. Оренбургта түгел, Троицкида да түгел, Казанда булса кирәк.

Җәгъфәр кыю гына исәнләште һәм сораша башлады. Шулай, Казан кешеләре болар, зур мөлкәтле сәүдәгәр балалары. Истамбулга укырга барышлары икән. Ниятләре: башта Төркия буйлап сәяхәт итү, ә аннан соң инде укырга керү икән. Аларның бик нык ышануынча, татар баласына бары Истамбул, Бәйрүт, Шам кебек шәрык мәктәпләре генә югары белемне чын мәгънәсендә тирән итеп бирә ала. Җәгъфәр бәхәскә кермәде, Истамбулга китәргә тиешле пароход турында сорашты.

— Бүген булмаячак, иртәгә көндез унберләрдә китүе ихтимал,— диделәр яшьләр.

Укырга баручылар өч туган — ике егет һәм кыз иде. Алар, яшьләргә хас кызулык белән, менә ике елдан бирле инде, безне Истамбулга укырга җибәрегез, юкса барыбер качып китәбез дип, әтиләренең колак итен ашаулары, әниләренең жылап калуы турында бер-берсен бүлә-бүлә сөйләделәр.

Иртәгәсен таң аткач кына, Җәгъфәр күн букчасына баш төртеп, эскәмиядә черем итеп алды. Соңыннан инде, туташны әйберләр саклаурга калдырып, өчәүләп пароход белешергә киттеләр.

Пристань ерак түгел иде. Билетлар өченче класска алынды. Пароходка утырту башланды. Этешеп-төртешеп, мең бәла белән, ярдан шактый эчтә торган пароходка шлюпкаларда юнәлделәр. Һәм менә бары-сы да тынычланды — хаҗилар Истамбулга барачак зур, ак диңгез пароходына урнаштылар. Бай улларының олырагы куен кесәсеннән көмеш сәгатен тартып чыгарды:

— Сәгать нәкъ унбер, алла боерса, без иртәгә шушы вакытта Истамбулда булырбыз,— диде.

— Алла теләсә, алла теләсә,— диде кыз.

Җәгъфәр исә, каютага кереп урнашу белән, кесәсеннән дәфтәр, карандаш чыгарды. Ул бу сәяхәтнең беренче минутыннан алып азагына кадәр көндәлек язармын дип үзенә сүз биргән иде. Туктыбай абага акчаны, савaплы эш өчен генә тот, чырагым, кайткач миңа хисабын бирерсең, диде! Җәгъфәр дәфтәрен кечкенә өстәлгә ачып салды да, пароход кузгалып киту белән, аның беренче битенә бүгенге көнне, числоны язды. Аннан соң ачык матур хәрефләр белән: «Одессадан кузгалып киттек»,— дип куйды.



## 16

Бер ялгызы авыр көннәр кичерә иде Тукай. Галиәсгар Камал үзенең гаиләсе белән Идел буендагы дачасында, Фатих Әмирхан Кабан күле буендагы Аркадия бакчасында ял итә, аяклары йөрмәү сәбәпле, Казанга бөтенләй килми диярлек. Инде Сәгыйть Рәмиев Казанны ташлап бөтенләйгә Әстерханга китеп барды, Гафур ялын үзенең туган якларында уздыра. Габдулла Кариев гастрольдә. Инде Хөсәеннең дә Кавказга китүе Тукайның күңелен тоташ ямансулык күләгәсе белән каплады. Тукайның бу көннәрдә үзен аңлый торган дуслары арасында буласы, алар белән үзенең кайгы-хәсрәтләрен уртаклашасы килә.

Тукай ачык тәрәзә янына килде дә, урамга караган килеш, уйлар агышында тирбәлде. Көн җып-җылы, ә ул туңа — бизгәк, каһәр төшкере! Тәрәзәне япты да, бөтен урамны яңгыратып шаулаган трамвай тавышлары кимегәч, үзенең караватына ятып моңсу уйларга чумды.

Габдулла кинәт эчтән, әллә ничек, бөркелеп тышка чыккан уфтану тавышына үзе дә сискәнеп китте. Тукай шулай эченнән ялкын чыгарырдай булып уфтана, сагышын авыр кичерә иде. «Их, Зәйтүнә, Зәйтүнә, нигә син миңа шундый хат яздырдың. Синең матур карашың миңа карата бары мәхәббәт нурлары гына балкытып тора иде ич. Нигә, нигә? Мин бит ул хатны Фатих белән киңәшеп, инде синсез яшәргә артык тәкатем калмагач яздырган идем. Ә син? Я, хода, булса да булыр икән! Бөтен дөньясы миңа каршы, туганнан үлгәнгә кадәр шулай булыр ахры...»

Габдулла әчке бер әтәргеч, алгысыну, омтылу белән караватыннан төште, тар бүлмәсе буенча арлы-бирле йөренергә тотынды. Ул, ниһаять, өстәл янына барып кулына каләм алды. Ләкин шигъри образлар, язгы ташудагы бозлар кебек, бер-берсен этеп һәм ватып берсе өстенә берсе өелә, тыныч кына агарга теләмиләр иде. Тукай каләмен өстәлгә ташлады да, кулларын кушырган килеш, тагы йөренергә тотынды.

Кем беләндер менә хәзер сөйләшеп утырасы иде. Һич югында Казан гайбәтләрен сөйләшеп юкны бушка уздырып утырасы иде. «Карый үзенең театры белән мәшгульдер инде,— дип уйлады ул, Габдулла Кариевны хәтерләп.— Кайтмады микән?». Тукай шушы көннәрдә «Сәйяр» труппасының Казанга кайтып төшәчәген белә иде. «Кереп карыйм әле, белмәссең, бәлки бүлмәсендә утырадыр». Тукай пинжәген иңенә салды да бүлмә ишеген бикләү түгел, ябарга да кирәксенмичә чыгып китте.

Шагыйрьнең куанычына каршы, Кариев үз бүлмәсендә, стенага беркетелгән көзге каршында кулларын болгый-болгый роль ятлап йөри иде. Ишектән кемнеңдер рөхсәтсез-нисез килеп керүенә өнәмичәрәк борылса да, Тукайны күргәч, чырае яктырып китте.

— Меңла Карый, минем эч поша бит,— диде Тукай.— Синең белән бераз сөхбәтләшсәк, бәлки күңел ачылыр дип кердем.

— Әйдә, рәхим ит,— диде Габдулла,— минем эш бетте диярлек инде.— Ул көзгә алдыннан китте дә өстәл янынннан Габдуллага урын күрсәтте.— Үзеңне пәрәмәч белән сыйлар идем — кесәдә сыңар бакыр да юк. Мәкәрҗәдән баеп кайтасы урында хәерчеләнеп кайттык.

— Миндә акча җитәрлек,— диде Тукай,— тик ашап-эчеп кенә сагышны басып булыр микән.

Алар күңелсез генә кыяфәттә, бер сүз дә дәшмәстән, тынып калдылар.

— Әйдә «Бәдавам»ны көйлибез,— диде Тукай.

— Кит әле, кеше көләр, билләһи.

— Көлә бирсен, аның каравы, Уральскидагы чакларны искә төшереп бераз онытылырбыз.

— «Бәдавам»ны көйләп утырганчы, әйдә урамга чыгыйк. Син номерыңда утырып күгәреп беткәнсең инде, күңелеңне саф һава шундук ачып җибәрәчәк, йөреп килик, дөнья күрик. Аннан Җамали хәрчүниенә алып кереп син мине кайнар аш белән сыйларсың. Сәваплы эштән күңелең дә күтәрелер. Юкса, синнән яшереп тормыйм, өч көннән бирле минем кайнар аш капканым юк.

— Их син, миллэтебезнең бөек хадиме, татар театрының алласы, әшарыңа юк, өстең юка. Нинди гөнаһларың өчен сине аллаһы тәгалә шулай каргаган икән. Әнә, Хөсәеннең әйткәне дөрес: безгә инкыйлап кирәк, инкыйлап, белдеңме?

Кариев быел «Сәйяр» труппасының Мәкәрҗәдә ифрат авыр хәлгә калуы, бина, реквизитка түләрлек тә акча җыя алмаулары, саран, рәхимсез байлардан бурычка акча алып, мең бәла белән Казанга кайтып егылулары турында сөйли башлады.

Тукай, учын маңгаена куеп, терсәге белән өстәлгә таянган хәлдә Карыйны тыңлаганнан соң:

— Әйдә, алайса киттек,— диде,— үзеңнең ач икәнлегеңне ифрат нык нигезләп аңлаттың.

Алар Печән базары аша чыгып, Московский урамы буйлап вокзал ягына таба киттеләр. Базарда, элеккечә үк булмаса да, һаман әле кызу гына алыш-биреш бара иде. Шау-шу, ыгы-зыгы. Көфер почмагы да гөрләп тора, анда һәркөн йөрүче вак сәүдәгәрләр, кырык тартмачылар, кибет тотучы, кызыл малчы, тирече, кәвешче, кәләпүшчеләр үз эшләре белән мәшгуль, кычкырып-кычкырып товар мактыйлар, узган-барганнан көлеп, оятсыз сүзләр аралаштырып мыскыллыйлар. Тукайның гаҗәпләнүенә каршы, алар артыннан бүген мыскыл сүзләре яудырып калмадылар. Соңыннан аңлашылды. Мөһимрәк вакыйгага булган икән: бер капкадан эләгешкән этләр килеп чыккан, хәзер бөтен көфер почмагы бары шуның белән генә яши, бары шуның белән генә мәшгуль чагы.

— Московскийның теге очына кадәр барыйк әле, ә аннан кайтышлый Җамали хәрчәүниенә сугылырбыз,— диде Карый, Габдуллага ошарга тырышуын ни кадәр яшерергә теләсә дә, булдыра алмыйча.

— Ул кадәр ерак җирләргә барырлык көчең бармы соң? — диде Тукай көлемсерәп,— ачлыктан егылып үлмәссеңме?

Карыйның йөзенә бары мескен бер елмаю билгесе генә чыкты.

Дуслар йомры таш түшәлгән урам буйлап байтак вакыт йөрделәр, юлда очраган кибетләргә тукталдылар, эч серләрен уртаклаштылар, Уральскины искә алдылар, аннан хәрчәүнәгә кереп, өстендә өреләре йөзеп йөргән токмачлы итле аш алдылар. Ашап утырганда Тукай Габдулла Кариевтан түбәнчелек белән үтенде:

— Син, дускаем, труппаң белән озакламый Чистайга китәбез, дидең. Минем хәлемне беләсең, мин сиңа барысын да, ходайга әйткәндәй, түкми-чәчми сөйләдем. Зинһар өчен Чистайга баргач теге эшнең асылын бел әле. Бик үтенәм, дустым.

Карыйның тамагы туйгач, көр күңеллелеге дә әйләнеп кайтты.

— Бу биш тиенлек аш шул эш өчен аванс мени?

— Таллале шаяртуларыңны! Син минем хәлемне аңла.

Тукайның йөзенә, табигатенә хас булмаган ялвару билгеләре чыккан иде. Кариевның Зәйтүнә турында барлык дәреслекне белеп кайтуына ул зур өметләр баглый иде.

## 17

Хөсәен Әстерхан һәм Кавказ якларында айдан артык вакыт булды. Ул кайтканда Казанга көз сулышы кергән, тирә-як кырлар ялангачланган, игеннәр эскертләргә куелган, ваба чире, бик күп корбаннарны үзе белән ияртеп, шәһәрдән башка якларга чигенгән иде. Ашлыклар җыелган булуга карамастан, базар бәяләре төшмәгән, хәтта азык-төлек элеккегә караганда да кыйммәтрәк иде.

Хөсәен үз бурычларын төгәл үтәде. Әстерханда Нариман Нариманов белән очрашты, явка урыннарын яңартты, Үзәк белән бәйләнешнен яңа каналларын булдыруга иреште. Анда атнага якын торды. Туйганчы тәмле балык ашады, карбыз, кавын белән сыйланды, ниһаять, балыкчылар арасында яшерен әңгәмә уздырды.

Әстерханда «Идел» исемле татар газетасы чыга иде. Хөсәен аның идарәсендә булды. «Шәрык клубы»нда еш очрый торган Сәгыйть Рәмиевне анда күрде. Алар, бәләкәй бер бүлмәдә, Әстерхан яңалыклары турында бик озак сөйләшеп утырдылар. Бу нәзакатле, ифрат чибәр шагыйрь, шигырьләрендә бунтарь булып күренсә дә үзенә төпле бер кыйбла тапмаган иде әле. «Вак буржуа йогынтысыннан бу кеше тиз генә арына алмас», дигән фикергә килде Хөсәен; бәхәсләште, булдыра алганча аңлатырга тырышты, тик берни дә кыйрата алмады. Сәгыйтьне үз кучәреннән чыгару өчен күп эшләргә кирәк иде әле. Шулай да алар дусларча аерылыштылар, Хөсәен шул ук көнне Каспий диңгезе аша пароходта Бакуга юл тотты.

Бакудагы Нариманов биргән мәгълүм адресларга яңалары да өстәлде. Бакуга барып төшү белән ул иң элек якташы — Казан егете Догадовны эзләп табарга булды. Ә аннан соң Догадов аша Шаумян белән очраштылар. Юл хәвефле, хәтәр иде. Хөсәенгә соң дәрәҗәдә сак булырга, конспирациянең барлык нечкәлекләрен белеп эш итәргә туры килә иде, чөнки Садыйкка тагылган кебек, Хөсәенгә дә охранка агентларының тагылып йөрүе ихтимал иде. Әмма сәфәр уңышлы узды. Хөсәен сак эш итте. Һәм Казан большевиклар группасына бик кыйммәтле, бик кирәкле материаллар алып кайтты.

Хөсәен чемоданын күтәреп, Казан вокзалында перронга чыгуга, үзенә төбәлгән филерны абайлап алды. Димәк, Хөсәеннен читтә булуын, бүген кайтырга тиешлеген белеп торганнар. Әлбәттә, кулдагы әйберләр фиргавеннәр кулына төшсә, айдан артык йөреп төзелгән бина җимереләчәк, ә үзен төрмәгә тыгачаклар. Хөсәен тиз генә анык бер карарга килде һәм вокзалга кереп, халык арасына чумды. Ә инде килгән поездан төшүчеләр таралгач, ул извозчик яллады да, анда да әле туры өенә түгел, Яңа бистәгә — Мәхмүт Алиевларга китте. Мәхмүт җиденче елдан бирле РСДРП члены, аңа ерак туган тиешле егет иде. Өстәвенә бу мәзин малае охранка тарафыннан бернинди дә шик-шөбһә кузгатмый. Иң кулае: әйберләрне иртәгәчә шунда калдырып, өйгә буш кул белән генә кайтып керү иде.

Күрәсең, филерлардан котылу өчен шул җитеп торды. Хөсәен өенә шактый тыныч кайтып керде. Кичекмәстән килеп төшкән тенту охранкага бернинди нәтиҗә дә бирмәде.

Иртәгәсен Хөсәен арадашчы хезмәтен намус белән үтәүче Юлия Михайловнага Абрам Комлев белән очрашу урынын әйтте.

Алар Абрам Комлев белән Яңа бистәдә, шул ук Алиевларда очраштылар. Харьков шәһәреннән полиция эзләрлекләве аркасында Казанга күчеп килгән Комлев хәзер группада элемтә эшләрен башкара иде. Хөсәен үзе алып кайткан барлык информацияне шуңа тапшырырга, гомумән, милли эшләрдәге директиваларны шуннан алырга тиеш иде. Алар алтынчы еллардан бирле, Комлев Харьковтан Казанга күчкәннән бирле, танышлар. Хөсәен Уфадан һәм Оренбургтан Казанга кайткан араларда Абрамны күрми калмый, аңардан кирәкле мәгълүматлар алгалый иде. Йомшак украин акценты белән сөйләшүче бу сабыр кешегә Хөсәен түкми-чәчми үзе алып кайткан барлык яңалыкны, адресларны, явка урыннарын тапшырды. Хөсәен аркасында революцион юлга кереп киткән өй хуҗасы Мәхмүт бу вакыт тәрәзә янында, урамны күзәтеп торды...

Озаклап утырырга ярамый иде, Мәхмүтнең дә соңгы вакытта күзәтү астында булуы бик мөмкин. Башта Мәхмүт урамга чыгып, тирәюньне күзәтеп керде. Ул кереп, хәвеф-хәтәр булмавын хәбәр иткәч, башта Хөсәен, аннан Абрам кичке эңгер төшкән урамга чыктылар.

Урамда Хөсәен иркен сулыш алды. Күкрәге авыртып куя, һава бөркү, вакыт-вакыт тын алулары авыраеп китә. Ярый әле җил төньяктан исә. Юкса Бакалтай ягыннан иссә, Яңа бистәдә һаваның тын алгысыз булганлыгын Хөсәен бик яхшы белә. Саз исе, Бакалтайга түгелә торган Казан нәҗесе исе, мех эшкәртү мастерскойларының сасы тире исе... Ничек яшәмәк кирәк шундый урында?! Шуңа күрәдер, Яңа бистә халкы арасында гарип-гораба, камыт аяклы рахитиклар адым саен очрый. Алай дисәң, Бишбалта якларында да һава ташка үлчим, дары заводыннан җил исә башласа, күкерт кислотасы исе тамак төбен ачыттырып каезларга тотына.

Хөсәен, шулай уйланып, Пеләтән урамына таба юнәлде. Трамвай тукталышына җитәрәк ул Крестовников заводы ягыннан ниндидер шартлау тавышы ишетте. Кызыксынуы никадәр көчле булса да, «койрык» тагылганчы бу тирәдән тизрәк китү хәерлерәк дип, ул трамвайга менеп утырды һәм ашыгып китүенә соңыннан үкенеп бетә алмады. Бу шартлау Крестовниковларның сабын кайнату цехында булган икән. Газ шартлаган һәм шундук шәм, стеарин цехларына ут капкан. Завод территориясен күз ачып йомганчы ялкын чорнап алган. Насослары белән пожарныйлар килеп җиткәндә бөтен завод ут эчендә калган булган инде.

Бик күп эшчеләр янгын эчендә калып һәлак булдылар. Хөсәеннең ышанычлы дусты, Крестовников заводындагы революцион хәрәкәтнең башында торган Тюнегинның ярдәмчесе Гыйльфан да янып үлүчеләр исемлегендә иде. Бу хәбәрне ишеткәч, Хөсәен агарынып калды. Бер җәй эчендә ике зур югалту. «Эткәй»нең үлеме һәм менә Гыйльфан... Авыр, бик авыр иде Хөсәенгә. Шундук ул Тюнегин белән бәйләнешкә керде. Янып үлүчеләрне күмүне оештыру, митинг уздырырга кирәклеге турында сөйләшеп, митингта хуҗаларның гамьсезлеген, эшче кешегә төкереп каравын ачык итеп фаш итәргә булдылар.

Шулай эшләнде дә. Рус зиратында Тюнегин, татар зиратында Хөсәен Ямашев сөйләде. Газеталар бу турыда берниндн хәбәр язмадылар. Бары Крестовников заводында шартлау һәм янгын булганын гына, тәфсилләп тормыйча, хәбәр рәвешендә бирделәр.

Гыйльфанның исә берсеннән-берсе бәләкәй дүрт баласы торып калды. Хатыны бала-чага күп булу сәбәпле эшли алмый, өй карау белән мәшгуль иде. Ятим калган гаиләләргә ничек тә пенсия чыгару турында кайгыртырга кирәк иде. Хөсәен һәм Галимҗан, Тюнегин белән берлектә, шул эшкә керештеләр. Бу эштә аларга дөрес киңәш бирә алучы Адоратский ярдәмгә килде.

Адоратский белән Хөсәен якын мөнәсәбәттә иде. Владимир Викторович белән Саммер квартирасында беренче тапкыр очрашуы бүгенгедәй исендә иде әле. Адоратский ул вакыт яңа гына Женевадан кайтып төшкән иде. Ул Хөсәенгә Ленин турында сөйләде. Хөсәен өчен Ленинны якыннан күргән беренче кеше иде ул.



## 18

Фәрхетдиннең туган авылы Нәдердә атлыгып кайтырлык бер генә якыны да калмаган иде. Шуңа күрә ул иң беренче булып Әлмәткә тукталды. Арбадан төшеп калгач, туп-туры улын асрамага алган кешенең өенә ашыкты. Өч ел буе һәрдаим хәтергә төшеп уйландыра торган бердәнбер баласы — йөрәк парәсе — Гыйззәтулласы нинди икән хәзер? Ул баланы Фәрхетдин күз алдына да китерә алмый иде. Таныр микән үз этисен?..

Урыс капкалы, калай түбә ябылган шактый төзек өйгә якынлашкан саен Фәрхетдиннең йөрәге катырак типте. Ирексездән адымнарын кызулатты.

Ишегалды тып-тын иде, бер адәм заты да күренми. «Урак өсте бит, мөгаен хуҗалар басуда эштәдер», дип уйлап алды Фәрхетдин. Шулай да ишегалдына узды. Ишек төбендә тукталып, керергә кыюсызланып торды. Югыйсә ишек бикле дә түгел иде. Бәлки баланы берәр корткамазар белән калдырганнардыр әле, дип фараз корды ул. Тик шунда гына искәрде: ишек келәсенә йозак урынына чүпрәк кисәге кыстырылган иде. Димәк, өйдә кеше юк.

Фәрхетдин үзенең бик җайсыз вакытта килүенә ачынып, мондый чакта бөтен авылның басуга күчеп китү мөмкинлеген уйлап, урамга чыкты. Чарасыз булып урам уртасында тукталып калды.

Каршы якта, биек өянке күләгәсендә картлыктан тәмам бөрешкән бер чал бабай утырганын күреп, Фәрхетдин шуның янына ашыкты. Аның өстендә җиңсез сырма камзул, башында мескен бүрек. Күрәсең, картка челләдә дә суык тоела иде булса кирәк, аякларына киез каталгән.

Бабай, Фәрхетдинне танырга теләгәндәй, кызарган күзләрен текәп, бермәл карап торды.

— Бабай, син мине танып белми торгансыңдыр инде,— диде Фәрхетдин.— Мин моннан сигез еллар элек Исхак хаҗида малайлыкта тордым. Мин Фәрхетдин атлы кеше булам.

Карт тешсез авызын җәеп елмайгандай итте.

— Ә-әә, син теге Исхак хаҗиның комганына борыч сибеп качкан Фәрхетдинмени әле? Беләм, белмәскә... Синең малай мена Фәррахта бит.

Фәрхетдин, шулай тиз арада аңлаша алуына шатланып, бабай янына бүрәнәгә чүмәште.

— Ничек соң минең малай, үсәме, рәнҗетмиләрме үзен?

— Ю-ук,— диде карт сузып,— малаең күкәй сарысыдай рәхәттә яши, бик матур булып үсеп килә.

— Ай, рәхмәт, бабай, шатландырдың. Үзең әле өй саклап калдыңмени? Кемнәрең бар соң үзеңнең?

Фәрхетдин кесәсеннән тәмәке янчыгы чыгарды. Бабайга тәкъдим итте. Аның тартмаганлыгын белгәч, ашыкмыйча гына тәмәке төрде, тәмләп төтен суырырга тотынды. Бабай исә үзенең ишле гаиләдә яшәвен, олы улының алты баласы барлыгын, күбесе кыз булганга күрә, имана җиренең дә азлыгын, икмәкнең кыш чыкканчы житенкерәмәвен, малаеның язга таба читкә китеп эшләргә мәҗбүр булуын тезеп китте.

— Иллә мәгәр киленнән уңдым, аллага шөкер,— дип куйды,— әйгәмгәнем булсын, туган атасын да болай карамас кеше, ах итеп тора шул җанекием, әтекәй дип тора. Алла үзенә бәхетле картлык, тигезлек, саулык бирсен инде.

— Үзең дә әйбәт кешесеңдер, бабай, иткән яхшылык җилгә очмый бит ул.

Бабай өметсез рәвештә кул селтәде.

— Алай димә, алла, диген. Әнә минем кордаш Сәмигулла, менә дигән асыл кеше, иллә мәгәр килене килен булмады, дәҗҗал булды. Көн күрсәтми кайнатасына. Йөри, бичара, башын кая куярга белмичә, тизрәк үлсәм икән инде, дип.

Фәрхетдин тәмәке төпчеген җиргә ташлап, аны бик озак итек табаны астында изде.

— Бар инде бу дөньяда төрлесе, бар.

Фәрхетдиннең үз улы турында күбрәк беләсе килә иде, мәгәр карт ул турыда сүзне тиз генә башламады. Әлмәт хәлләрен шактый озак сөйләгәннән соң, ахырда сорап куйды:

— Син малаеңны күреп китмәк булып кайттыңмени?

— Шулайрак иде шул, бабай. Үзем белән алып китү иде исәп.

— Моңарчы бер дә күренмәдең, кайларда шулай озак йөрдең соң?

Фәрхетдин, бераз сәерсенеп, бабайга күз ташлады. Димәк, күршекүлән аның сөргендә булуын белми икән, димәк, Фәррахлар белсәләр дә моны сер итеп саклаганнар.

— Мин ерак җирләрдә булдым, бабай, Себер якларында,— диде Фәрхетдин.

— Шунда эшләдеңмени? Теге Лена буйларындагы приискаларда түгелдер лә? Бер іше халык шунда китә бит.

— Юк, мин ул кадәр еракка китмәдем, Төмән якларында булдым.

— Ничек соң, бик баеп кайттыңмы?

Фәрхетдин ачынып көлеп куйды.

— Бик баетырлар сине ак патша ялчылары. Анда да бит нәкъ бездәге кебек соңгы тамчы каныңны сыгып эчәләр.

Күрәсең, бу турыда артык сүз куертуны кирәксенмәде бабай. Тамак кыргалап алды да:

— Исәбең: малаеңны үзең белән алып китү икән алайса,— диде.

— Шулайрак иде. Озакламый Зөя каласы янында Идел аша күпер сала башлыйбыз. Шунда эшкә урнаштым. Һөнәрем бар. Тимерче мин.

— Тимерчесен тимерчедер дә, тик малаеңны сиңа бирер микән Фәррах...

— Ничек инде?!

— Шулай. Ни теләсә шуны булдыра ала ул Фәррах. Соңгы елларда череп баеды әнә. Каралты-курасын гына кара! Ике батрак тотып көн күрә, хәзер Ильяс бай да аның белән кул биреп исәнләшә.

Фәрхетдин хәйран калды. Әйе, ул Фәррахның шактый нык тормышлы кеше икәнлеген хатлар аша белә иде, тик менә чын мәгънәсендә баеп китүен күз алдына да китермәгән иде.

— Кемгә ничек бит, энем,— диде бабай,— аллаһы тәгалә кемгә ни язган. Бәхет эше. Җир сатып алды башта Фәррах. Синең кебек әтрәкәләмнәрнең җирен җыйды. Җирләре искитмәле уңдырышлы булып чыкты. Өченче елда да, узган елда да уңыш булмады безнең якта, ә аның ходаның рәхмәте, ел саен ташып тора. Менә бәхет эше нәрсә ул! Икмәгең бар икән — тамагың тук, малың симез була. Яши белә ул Фәррах! Әле моны сиңа малаеңны бирмәсләр диюдән әйтәм.

— Юкны сөйләмә, бабай, гөнаһысыннан курык. Малай — минеке. Алайга китсә, теләсәм суд аша алам.

Карт тагы, тешсез авызын җәеп, елмайгандай итте.

— Э-ээ, суд аша-а. Әйтеп торам лабаса, Ильяс бай да аның белән кул биреп исәнләшә дип. Бөтен өяз башлыклары аның яклы булачак.

Фәрхетдин: «Бу карт мине юри ирештерә», дип уйлады. Аның һич тә бәгырьгә үтә торган мондый сүзләрне ишетәсе килми иде, шуна күрә сүзне бөтенләй икенчегә борды.

— Монда берәр әбигә кереп чәй эчеп чыгарлык урын юктыр инде?

— Ник булмасын, әйдә безгә керәбез,— диде бабай.— Тик самавырны үзең куярсың. Минем дә тамак кибеп тора, әйдә, иренмәсәң.

Фәрхетдин моңа бик шат иде. Зур сәке биләгән фәкыйрь өйгә кергәч, ул, бабай әйткәнчә, бер чиләк су сыешлы яньчелеп беткән жиз самавырны куеп җибәрде, капчыгыннан ризык чыгарып киндер эскәтергә турап салды. Бабай белән дөнья хәлләрен сөйләшеп утырган арада самавыр гөжләп кайнап та чыкты, Фәрхетдин Казаннан алып килгән фамильный чәйне пешергәч, ярыклары замазка белән сылап ябыштырылган чынаяклардан чәй эчәргә керештеләр.

Казан күчтәнәчләре бабайга ошады ахры, ул чынаяк артыннан чынаяк бушата торды, теле чишелгәннән чишелә барды. Беренче карашка шактый бәлтерәгән булып күренсә дә, картның хәтере әйбәт иде. Ул Әлмәт кешеләре турында гына түгел, Нәдерлеләр турында да бик күп яңалыклар сөйләде. Алар шулай сәгатьтән артык вакыт тирләп-пешеп чәй эчтеләр, юл килеп тәмам алҗыган Фәрхетдин, бабайның киңәше буенча, чоланга кереп йоклап та алды. Ниһаять, ишегалдындагы тавышка уянып, чәчрәп урыныннан торды. Хуҗаларның ишле семьясы әле генә басудан кайткан икән.

Фәрхетдин, бабайга рәхмәтен әйтте дә, Гыйззәтулласы янына йөгерде.

Фәррахлар да кайтканнар икән. Ишегалды тулы ат-арба. Тавышгауга. Ниндидер ир кеше көр тавыш белән кемнедер шелтәли иде, хуҗа шул булса кирәк. Фәрхетдин кече капканы кыю гына ачып эчкә узды.

— Әссәләмәгаләйкем!

Фәррах үзенең тышкы киемнәре белән, комзол һәм түбәтәен искә алмаганда, ялчыларыннан әз генә дә аерылмый иде. Шундый ук оекчабата, алача киндер ыштан, тезгә җиткән ак күлмәк. Ул, алъяпкычын тоткан килеш, озын буйлы, шадра батрагын әрли иде.

Фәрхетдиннең бу кешене күргәне юк иде шикелле. Һәрхәлдә ул «балаңны фәлән кешегә асрамага бирдек» дигән хәбәрне алгач та, бик озак баш ватып, үзе белгән Әлмәт кешеләрен күз алдыннан кичерде, ләкин Фәррахны анык кына хәтерли алмаган иде. Әле шактый чибәр, кара тутлы, төз гәүдәле, елдам хәрәкәтле кешене күргәч ул, ничектер, аны элек күргән сыман булды. Ләкин кайда, ничек күргәнлеген хәтерли алмады.

Юлчының сәламен алганнан соң Фәррах, Фәрхетдинне танымыйча бермәл аптырап, ни дияргә дә белмичә торды. Ахырда, шактый коры итеп:

— Ни йомыш?! — дип куйды.— Сине кем дип белик? Кунарга сорап керәсең икән — рөхсәт юк. Болай да урак өсте... кә кыл да сыймаган чак.

Ул хәтта борылып китә үк башлады.

— Сез Фәррах бит? — диде Фәрхетдин аның җиңеннән тотып.

— Фәррах,— диде хуҗа ачулы караш ташлап,— ни йомыш?

— Йомышым шул, минем улым Гыйззәтулла сездә тәрбияләнә. Минем җәмәгатем Хафаза үлгәч, аны Якуп байның хатыны Хәдичәбикә сезгә китереп тапшырган. Мин Гәйззәтулланың этисе — Фәрхетдин булам. Тумышым белән Нәдер кешесе үзем. Улымны алырга килдем.

Фәррах беразга югалып калды, Фәрхетдин аның мыек чылгыйлары-

ның очы селкенүен искәрде. Фәррах әле аптырау, әле шикләнү аша Фәрхетдинне башыннан аягына кадәр күздән кичерде. Һәм ачык торган өй ишегенә карап:

— Гөлбаһар, чыгале монда! — дип кычкырды.

Өй эченнән, ниндидер ашыгыч эше булу сәбәпле әле чыгарга җай булмавын әйткән хатынына ул тагы да катырак итеп кычкырды. Бусы инде әмер тонында әйтелде. Ишектән, чәчләрен яулык астына кыстыра-кыстыра, куркынган хатын-кыз йөзе күренде. Ул, авызын яулык чите белән каплый төшеп, ирләр янына килгәч, Фәррах Фәрхетдингә ымлап:

— Менә, кайткан катырҗан,— диде,— безнең Гыйззәтулланы үзем белән алып китәм, ди.

Хатынның соры күзләрендә дәһшәт билгеләре күренде.

— Алып китәм ди? Алладан курыкмыймы?! Кем ими сөтен үз баласына тиешенчә имезмичә аңа биреп тәрбияләгән? Булмаганны! Урамнан килеп кергән һәр зимагурга биреп җибәрә торган малаем юк минем.

Фәрхетдиннең йөзенә кан йөгерде.

— Ул минем улым, минем улым,— диде ачуыннан буылып.— Сез кеше баласына кул сузарга ни имеете право! Тәрбияләгәнсез, рәхмәт. Әгәр расходлары булган икән, мин бурычлы булып калмамын. Тулке сез не имеете право минем улымны алып калырга, мин судка житәчәкмен, но мин аны барыбер үзем белән алып китәм.

— Юк инде, парин,— диде Фәррах сүзгә кушылып.— Ул сине знать не знает, үз балаң икән, себерелеп, әллә кайларда йөрмиләр аны. Balaңны тугач та алалар да тәрбияләп үстерәләр.

— Алладан куркырга кирәк, имансыз зимагур,— диде Гөлбаһар еламсырап.— Нидән үлде дип уйлыйсың соң син минем үз баламны? Ул бит, бичара сабый, Гыйззәтулланы исән калдырам ди-ди безнең тырышудан үлде.

— Ялган бу! Минем Гыйззәтулламны алганчы ук сезнең балагыз үлгән булган инде. Все! Мин улымны алырга килдем, бүтәнне белмим,— диде Фәрхетдин.— Әйтеп торам бит, яхшылык белән улымны бирмисез икән, мин аны суд аша алам.

— Минеке дә, минеке дисең син Гыйззәтулланы. Ничек исбат кылмак буласың? — диде кинәт дулап Фәррах.— Аның атасы әллә син, әллә чурт.

— Мин шаһитлар табачакмын, тапмый калмам.

— Нәрсә ул шаһит. Әллә син аны акчага күндергәнсеңдер? Нәрсә ул шаһит? Дукамит кирәк, дукамит!

— Документын да табармын. Мәчет кенәгәсенә теркәлгән ул. Мин иртәгә үк Нәдергә китәм.

— Нәдерендә синең мәчет кенәгәңне саклаганнар ди. Бар. Карт мулланың үлгәнен, мәчетнең янганын белмәдеңмени?

Фәрхетдин каушый калды.

— Ичмаса, күрсәтегез улымны,—диде ул ялваручан бер тавыш белән.

— Бар, апчык,— диде Фәррах хатынына. Фәрхетдингә карап усалланып әйтте.— Бер карыйсың да, шуның белән — бетте, минем йортымнан ычкынасың. Баланы тәшвишләндереп йөртергә юл куймам. Инде тагы каныгасың икән, мин сине, ристанны, нишләтергә юлларын табармын.

Гөлбаһар өй эченнән Гыйззәтулланы күтәреп чыкты. Аны күрү белән Фәрхетдиннең сулышы кысылды, күзләреннән ирексездән яшь бөртекләре атылып чыкты. Бала нәкъ Фәрхетдиннең мәрхүм Хафазасына охшаган иде. Кара күзле, сызылып киткән нечкә кашлы.

Фәрхетдин калтыранган тавыш белән:

— Улым, Гыйззәтуллам, багалмам,— дип балага таба үрелде.

Ләкин бала үзенә сузылган куллардан куркып Гөлбаһар куенына сыенды, чырылдап йөзен яшерде.

— Ычкын моннан, парин,— диде Фәррах,— ничу сабыйны куркытып, безне газаплап йөрергә. Бар, юлыңда бул. Икенче эзең булмасын минем йортымда.



19

Фәрхетдин улына дип алып килгән күчтәнәчләрен һәм күлмәк-күлмәкләрен дә бирергә кирәксенмичә, йөрәгенә хәнҗәр яралары алган кешедәй, шашынып, Фәррах капкасыннан яшен ташыдай чыгып китте. Ул шул барышыннан тукталмыйча туп-туры Нәдергә китте. Төне буе барды ул. Күзенә берни чагылмады. Кара инде син, аның газиз улын, күз нуры Гыйззәтулласын, аңа юл күрсәткеч якты өмет йолдызы булып янган баласын аннан тартып алдылар. Исең-акылың китмәле!

Таң алдыннан Нәдергә җитеп, якын танышларында черем итеп алды Фәрхетдин. Кояш күтәрелә төшкәч, чәй дә эчмәстән, мулла өенә китте. Чыннан да, карт мулла урынына хәзер яшь мулла калган икән. Әмма, бәхеткә каршы, мәчет янган булса да мулла өендә метрикә кенәгәләре сакланган иде. Анда акка кара белән язган: «1907 нче елның гыйнвар уникесендә Гыйззәтулла дөньяга килде, атасы Фәрхетдин, Гайнулла малае, анасы Хафаза, Шәмсетдин кызы». Нәрсә кирәк тагы?! Фәрхетдин шушы язуны укып, метрикә кенәгәсендә улының язылган булуын ачыклагач, ат яллап, өяз судына мөрәҗәгать итү өчен, Бөгелмәгә юл тотты. Ләкин Фәррах та тик ятмаган булса кирәк, тиешле кешеләрне майлаган, җайлаган ахры, Фәрхетдинне кайда гына барса да караңгы чырай белән каршы алдылар, кайда гына керсә дә иң элек документларын тикшереп, сөргеннән кайтуын сылтау итәргә тырыштылар. Әйе, аларга зур сылтау иде бу. Шуңа карап алар Фәрхетдинне барлык гражданлык хокукларыннан мәхрүм итәргә телиләр. Янәсе, ул ышанычсыз кеше, политически. Аның Бөгелмәгә килеп чыгуы да әле рөхсәт ителә торган эш микән, аны бәлки полиция кулына тапшыру хәерлерәктер. Әлегә төпләнгән урыны, эшләгән җире юк, ә бродяга кебек, хәлле, тырыш, патша хәзрәтләренең верноподданные тәрбияләп үстергән баланы тартып алырга йөрү — ул үзе бер җинаять.

Фәрхетдин тамагы карлыкканчы тавышланып, баланың әтисе үзе икәнлеген исбат итәргә тырышты, метрикә кәгазе турында әйтте.

— Син безнең башны бутап йөрмә әле, каторжник,— диделәр аңа,— бала ясау әле ул әллә ни зур эш түгел, син аны тәрбияләп кара. Менә шул гына аталык хокукын бирә ала сиңа.

Фәрхетдин көн-төн чапты, күрмәгән кешесе калмады, тик берни дә булдыра алмады, һәр җирдә аны караңгы, салкын дивар саңгыраулыгы көтә иде. Фәрхетдин тагы да югарырак барып, губерня башкаласы Уфада эшне кузгатырга булды. Ләкин инде аның хәзер көче дә, ә аннан да битәр, акчасы да Казанга кайтып егылырлык кына калган иде.

Мәскәүдән Зөя күперен салдырырга тиешле инженер Белолюбский Казанда иде инде. Күпер өчен эшче яллау башланган диделәр. Фәрхетдин ялланып Зөягә китте. Иделнең уң ярында, Зөя каласы янында, эшчеләр өчен бараклар салынган иде. Тимерчелек мастерскойлары да әллә ни еракта түгел. Фәрхетдин, баракка урнашып, тимерчелектә эшли башлады. Күңелендә аның хәзергә бары бер нәрсә, ул да булса улын алып кайту уе иде. Ләкин бу эшне җиңел генә башкарып булмаячагын ул хәзер инде төшенде. Гыйззәтулланы алу өчен алда зур эшләр тора әле.

Фәрхетдин өчен ял көннәрен үткәрү аерата авыр иде. Күз алдына үзеннән ятсынган, бөтенләй үз әнисе булмаган хатынга сыенган, аны

якынрак күргән Гыйззәтулла килеп баса иде. Бу аның төшләренә керәп алҗытты. Фәрхетдин сөргендә никадәр генә чыныккан, нык кешегә әверелмәсен, алай да аның көче аталык хисенә каршы торырлык түгел иде. Ул, онытылыр өчен, ял көннәрендә барактан чыгып китә, япа-ялгызы кырларда, урманда йөри, яки Казанга кайта. Казанда исә Шәрифуллаларда яки Гафурларда була. Ә беркөнне ул Хөсәеннәргә барып чыкты. Сөргендә йөреп кайткан кеше буларак, тикшерү астында яшәүче Хөсәенгә бару хәвефле икәнен белсә дә, түзмәде, аның белән бер сөйләшеп утырасы килә иде.

Ял көне булуга карамастан, Хөсәен үзе өйдә юк, эш белән киткән, өйдә исә Хәдичә генә япа-ялгызы керләр өтели. Кайтканын белсә дә әле аның Фәрхетдинне күргәне юк иде. Кунакны каршы алырга дип өй алдына чыккан Хәдичә хәйран калды.

— И, Фәрхетдин, син дә дөньяда икәнсең! Кайтканыңа ни көн үтте, шунда килеп тә чыкмадың.

— Мәшәкатьләр булды, Хәдичә апа,— диде Фәрхетдин, Хәдичәнең җылы, йомшак кулын кысты.

— Шулайдыр, шулайдыр, миңа Хөсәен әйткән иде улың хакында да...

Алар өске каттагы, тәрәзәләре урамга караган ике бүлмәле квартирага керделәр. Фәрхетдин, туза төшкән хәтфә төпле урындыкка утырган килеш, ярым елмайган бер хәлдә, күзләре белән өй эчен сөзеп чыкты. Өстәлнең җәймә җәелгән өлешендә үтүк белән булашкан Хәдичә төпченеп сорашырга кереште.

— Планнарың ничегрәк соң, эшләү шартларың ярыйсымы, табышлымы, торган урының бик уңайсыз түгелме, буш вакытларыңны ничегрәк уздырасың?

Фәрхетдин күңелсезрәк бер кыяфәттә, кулларын кушырып утырган килеш, мөмкин кадәр кыска җаваплар бирде. Сизелә: Хәдичәнең дә күңеле артык күтәренке түгел иде. Тик шулай да ул, Фәрхетдингә якты чырай күрсәтми булдыралмады. Хәер, алай гына идеме соң. Ул хәтта Фәрхетдиннең ялгызлыгын да үз хәленә тиңләде. Хәдичә Фәрхетдинне нәкъ элеккечә беркатлы, уңны-сулны аермый торган надан авыл егете дип исәпли һәм, ни әйтсәң дә бата, ул барысын да кабул итә дип уйлый иде ахры. Һәм шуның аркасында үзенең дөньяга карашын бернинди капкач-калкансыз шәрран-ярып сөйләп бирде.

Хәдичә, керләрен үтүкләп бетергәч, эскәтер җәеп табын әзерләргә кереште. Булган сый-нигъмәтләрен дәстерханга куйды. Бераздан алар, сөйләшә-сөйләшә, чәй эчәргә утырдылар.

— Сиңа бер әйбәт кенә хатын табып тормыш корырга, үз ояңны булдырырга кирәк, Фәрхетдин,— дип киңәш итте Хәдичә, егетнең улы белән булган фаҗигасен үз авызыннан тыңлагач.— Кулыңда хәзер һөнәрең бар, гаиләңне асрарлык акча таба аласың. Менә тормышыңны көйләп җибәрсәң, улыңны янында калдыру да җайланыр. Инде шул хәтлесен дә әйтим: балаларың тагы булыр әле, Гыйззәтуллаң синдә яшәргә теләмәсә дә, баласыз булмассың, дип әйтүем.

Фәрхетдин, уңайсызлануданмы, кызарына башлады.

— Сез, Хәдичә апа, тынычлансын дип миңа шулай әйтәсездер инде, тик мине сез сөйләгән, үзең өчен генә булган матур тормыш кызыктырмый бит хәзер.

— И, Фәрхетдин, Фәрхетдин,— диде Хәдичә рәнҗеп,— беләм мин синең ни әйтергә теләгәнеңне. Тик синнән яшерен-батырын түгел, без хәзер Хөсәен белән дә еш кына бу турыда бәхәсләшәбез. Нигә кирәк ул булмас иллюзияләр белән яшәү. Менә ал инде безнең тормышны. Нинди рәхәт күрде Хөсәен абыең, яки менә мин — аның хатыны. Һаман куркып, тетрәнеп яшәү бит бездә, җан кисәгем. Торырга өебез юк,

жигәргә атыбыз юк. Дөресен әйтсәң, оят билләһи, кунакка киеп барырлык ни Хөсәеннең, ни минем бер җүнле киеме юк. Мин укыйм хәзер, абыең университетка керергә әзерләнә, икебезнең дә үзебезне карау өчен бер генә минут та вакыты юк. Нишләргә кирәк? Әгәр тормыш аз гына адәм рәтле булса, без асрау тотып, иркенләп үз эшебез белән шөгыльләнмәс идекмени? Юк, асрау тотарлык та, тамак ялына гына булса да өебездә берәр ятимә кыз асрарлык та мөмкинлегебез юк. Я, әйт, тормыш мыни бу, Фәрхетдин?

Фәрхетдин уйга калды. Ни булган бу Хәдичә апага? Ул бит андый түгел иде. Ул бит Хөсәен абыйның беренче ярдәмчесе, аның карашларын хуплап торучы иде. Фәрхетдин бермәл кызып Хәдичәгә каты җавап бирергә итте. Ләкин шундук ул уеннан кайтты, сүзне уенга әйләндереп, көләргә тотынды.

— Сезгә, бәлки, бүген шулай тоеладыр, Хәдичә апа,— диде,— тик минем уемча, сезнең тормыш бездәйләрнең күбесенә үрнәк булырлык тормыш ул.

Хәдичәнең ак матур йөзе кызарып алсуланып китте. Аның бу сүзләрне өнәп бетермәвен аңлады Фәрхетдин.

— Үрнәк,— дип куйды Хәдичә тирән сулыш алып.— Үрнәк булырлык ни эш кыйраттык без?

— Хөсәен абый белән сез миндәй күпләрнең күңелендә өмет йолдызы кабыздыгыз, Хәдичә апа. Икенче төрле әйткәндә: сез караңгы төнне ай кебек яктырттыгыз, юл күрсәтеп, бәхетле киләчәккә таба юнәлттегез. Моннан да зур эшне белмим мин, Хәдичә апа.

Хәдичә өметсез бер кыяфәттә кул селтәде.

— Әй, Фәрхетдин, син дә диндар кешеләр кебек татлы хыяллар дөньясында йөзә башлагансың икән.

Фәрхетдиннең бу юлы да көлеп кенә җавап бирергә көче житте.

— Юк, Хәдичә апа, диндар кешеләр алар гомердә булмаслык ахирәт белән юаналар, ә без булырлык эш турында...

— Кемнәр инде ул «без»? — диде Хәдичә, шактый төксе бер кыяфәт белән.

— Хөсәен абый, сез, мин һәм башкалар...

Фәрхетдин ул көнне Хөсәенне күрә алмады, бары Хәдичә белән генә сөйләшеп утырды. Бу сөйләшү исә аның күңел ярасына тоз сипкәндәй булды. Юкса Фәрхетдин казармасыннан кәефе күтәрелсен өчен киткән иде, ә киресе килеп чыкты. Ул Хәдичә апасыннан бөтенләй сөмсере коелган бер хәлдә китте. Балык базарында озак кына буталды. Проломный буйлап йөрде, озак-озак тукталып торгалады. Биш енче елны карагруһчылар үзен эт итеп кыйнап, Гыйззәтулланы үтереп ташлаган урында булды. Хәзер бу биек чиркәүле урамда тынлык хөкем сөрә иде. Ләкин бу тынлык шомлы бер тынлык, озакламый килеп житәргә тиешле тайфуннар каршылаучы тынлык булып тоелды Фәрхетдингә. Әйе, шулай әйтә торган иде бит Кулеша. Политик каторгадагылар әллә нинди сәбәпләр табып бергә җыелалар иде. Үзәктә булган вакыйгаларны белеп торалар, өзлексез укыйлар, үзара сөйләшеп, барсын да аңларга, белергә тырышалар иде. Шундый яшерен җыелышларны Кулеша оештыра. Ул әйткән сүзләр әле дә колакта яңгырап тора: «Бу тынлык — вакытлы тынлык, белегез аны!..»

Фәрхетдин, йөреп арыгач, трамвайга утырды да Пеләтән ягына, Крестовников заводына китте. Зур шартлау булган жирне, байтак эшчеләр янып үлгән урыннарны карарга булды. Аның бит кайчандыр шул заводта эшләгәне дә бар. Билгеле, әллә ни мактанырлык хезмәттә булмады, бары нәҗес ташучы булып кына йөрде, шулай да эшләде.

Тыштан караганда Крестовников заводының кызыл кирпечтән салынган биналарында әллә ни үзгәреш юк иде. Агач коймаларны, тәрәз рамнарын төзәткәннәр иде инде, биек кызыл кирпеч стеналардагы

корым сәламәләре генә бирсдә зур пожар булганлыгын искәртәләр иде.

Фәрхетдин, җәяүләп кенә, Екатерининский урамы буйлап үзәккә таба житте. Сул кул яктагы капка өстенә зур вывеска эленгән Вәисовларның «Мәхкамәи шәргыйә»ләренә житкәч кенә тукталырга мәҗбүр булды. Шул чак бер төркем яшел чапанлыларны полицейскийлар капкадан урамга алып чыктылар да Фәрхетдин барган якка таба алып киттеләр. Арестантлар алдында яшел чалма чорнаган сәрдәр Гайнанетдин үзе. Фәрхетдин аларны күзәтеп барды. «Божий полк» башлыклары, чат саен туктап, тәкъбир әйтәләр. Фәрхетдин кайчандыр үзе дә, ачлыктан интегеп, Казан урамнарында йөргәндә Вәисовларның бер мөрите үгетләгәч, шунда язылырга теләгән иде. Тик анда керү өчен дә акча кирәк икән. Ярый ул чакны урамда Хөсәен абыйсы очрап, аны бу эшеннән дәррәү айнытты. Ләкин шул вакыйга Фәрхетдиндә бу «Божий полк»ка карата кызыксыну уяткан иде, ул сөргендә дә бу турыда уйланды. Нәрсә иде бу: яшәгән тәртипләргә протест йөзеннән шулай, дин исеме белән бунт күтәрүме, әллә гади бер шарлатанлыкмы? Фәрхетдин моны һич аңлый алмады. Инде шарлатанлык дисәң, бу Вәисовчылар патша агентлары тарафыннан эзәрлекләнми мени? Протест дисәң, ни өчен соң ул халыкның, ачлыктан, милли изелүдән интеккән халыкның, мәнфәгатенә лаек программага нигезләнмәгән? Фәрхетдин әле дә шул турыда уйланып барды. Әйе, ул хәзер акны карадан аера белә. Шактый зур мәктәп булды аның өчен Хөсәен белән беренче тапкыр очрашканнан соң узган еллар.

Фәрхетдин, Шиһап хәзрәт мәчете яныннан узганда, тагы Хөсәен турында уйлый башлады. Хәдичәнең сүзләрен хәтерләп, аптырап баш чайкады. Нәрсә диң, матур оя корып күңелле генә яшә, Фәрхетдин, диме? Нинди файдалы эш эшләдек соң без, диме? Фәрхетдиннең ачудан битенә кан йөгерде. Бүген үк, менә бүген үк, Хәдичә апаның Хөсәен абыйны түбәнсетүенә үч итеп, мин эшкә керешергә тиеш. Мин бит тимерче генә түгел! Ул шундый нәтиҗә ясады.

## 20

Хөсәен килеп кергәндә Тукаевның тар бүлмәсе тәмәке төтене белән тулган иде. Хөсәен, әле беркем белән дә исәнләшмәстән, ябык тәрәзә янына ашыкты.

— Әфәнделәр,— диде шактый кычкырып,— үзегезне кызганмыйсыз икән, һич югында өй хуҗасын кызганыгыз.— Ул урамга караган тәрәзәнең ике канатын да төбенә кадәр ачып җибәрде һәм өстәл тирәсендәге кешеләргә таба борылып исәнләште.

Кайсы караватка урнашкан, кайсы өстәл янында утырган кунаклар арасыннан Хөсәеннең күзләре иң беренче бик фырт киенгән Камил Мотыйгыйга төште. Аның сул ягында Галиәсгар Камал, уңында Галимҗан Ибраһимов, каршы якта «Ялт-Йолт» журналының мөхәррире Әхмәт Урманчиев, Зариф Бәшири һәм Сәгыйть Сүнчәләй утыра. Тукай исә өстәлнең ишеккә караган ягында торып нидер сөйләргә җыена иде. Хөсәенгә ул урындык тәкъдим итте һәм кунакларына:

— Сезгә таныш булса кирәк,— диде,— минем иң кадерле кунагым — Хөсәен Ямашев.— Ул, хөрмәтенең олылыгын күрсәтергә теләгәндәй, Хөсәенгә аерата җылы итеп дәште.

— Әә сез, Хөсәен дус, печән базарында йөк артыннан чабып печән йолкучы бу малайларны, шәт, беләсездер?

Хөсәен уңайсызлана төште:

— Мин сезнең мәҗлесегезне боздым ахры, дәвам итегез, зинһар,— диде.— Син, Габдулла, шигырь сөйли идең булса кирәк.

— Юк, ул нотык сөйли иде,— диде Камил чәнчеп,— ул безгә татар теленең нәрсә икәнлеген аңлата.

— Сезнең бит бүген Новый клубта концерт бирәсе көнегез, ялгышмасам,— диде Хөсәен Камилгә карап.— Ничек алай, шундый җаваплы көндә?..

— Концерт булачак, һәм менә дигән концерт булачак. Ләкин элекке дуслык барыннан да кыйммәтрәк.— Мотыйгый Габдуллага күз атты.— Йөрми бит менә бу минем концертларга. Махсус чакырып контрамарка китерә килдем.— Ул елмаеп куйды.— Бәлки сез дә рәхим итәрсез, Хөсәен әфәнде.

— Юк, рәхмәт, минем бүген кичем буш түгел,— диде Хөсәен,— ә сезнең концертларда минем булганым бар. Бик рәхәтләнеп тыңлыйм мин сезне, Камил әфәнде.

Хөсәен Тукай тәкъдим иткән урынга утырды. Ул ашыгыч йомыш белән, бүген «әдәбият түгәрәге»нең чираттагы утырышы булачагын, төнлә мәгълүм урынга барырга кирәклеген әйтер өчен генә кергән иде. Мондый хәлгә таргач, инде бераз утырмыйча булмый. Тукай бүленгән сүзен дәвам иттерде.

— Дәвам итәбез, җәмәгать! Сез дә тыңлагыз, Хөсәен әфәнде, әгәр ялгышсам, төзәтерсез. Безнең эшләр шәптән түгел, әфәнделәр, без хәзер матбугатта үз фикерләребезне, карашларыбызны бәян итә алмыйбыз. Иллә мәгәр без нинди генә шартларда да прогресс ягында, тәрәккыйят ягында булырга тиеш. Менә син, Камил, матбугатта башланган тел мәсьәләсе кирәксез нәрсә, болай да, үзеннән-үзе дә аңлашыла, дисең. Ә бит монда да хәзер ике лагерь пәйда булды. Берсе аның Гаспринский җәнаблары лагеры, икенчесе... икенчесе...— Тукай, туктап ярдәм эзләгәндәй, тирә-юненә каранды.

— Икенчесе Габдулла Тукаев лагере,— дип куйды Камил, чеметтереп.

— Нәкъ өстенә бастың, мелла Камил,— диде Тукай,— бу турыда матбугатта бер генә мәкаләм булмаса да, мин синең тәкъдимеңә каршы түгел. Әйе, Тукай лагере. Беренчесе аның, төрки халыклар өчен уртак әдәби тел кирәк, дип бара.

— «Тәрҗеман» теле,— дип куйды Галимҗан.

— Афәрин, дөрес сүз. Ә икенчесе аның һәр төрки халыкның үз әдәби теле булырга тиеш, дип бара. Бусы Тукай тарафдарлары. Ни өчен бу бәхәс буш бәхәс түгел, хәзер мин сезгә шунсын аңлатып бирим. Чөнки Гаспринский юлы — ул халыктан аерылу юлы, ул — әдәбият халыкка, аның ихтыяҗларына хезмәт итмәсен дигән сүз, ә безнең юл — халыкка хезмәт итү юлы. Димәк, хезмәт итәбез икән, без аның телендә генә сөйләшеп, ул аңлаган телдә генә язып хезмәт итә алабыз. Менә шулай, аңлашыламы, бәдәвиләр?

— Бусы аңлашылды,— диде Ибраһимов,— минем фикеремчә, матбугат рыцарьларыбыз бары саф әдәбиятчы гына була алмый. Чөнки чор аларга галим булырга да куша. Шунсыз мөмкин дә түгел. Менә карагыз, әфәнделәр: бездә тел юнәлеше мәсьәләсе бар, бар имла кагыйдәләре. Ләкин берсе дә ныклап эшләнмәгән бит. Безнең хәзерлекле махсус галимнәребез юк, барысы да һәвәскәрлеккә корылган. Бәс, шулай булгач, бу йөкне язучыларга да тартырга туры килә.

— Яңа татар әдәбияты — халык телендә сөйләшә белә торган әдәбият бишенче елны туды, ул хәзер никадәр генә манигъләр ясамы — үсүеннән туктамый, туктамас дип уйлыйм мин,— диде Галиәсгар.

Габдулла Кариев сүзгә килде:

— Минемчә, сез сәхнә телебез турында әйтергә тиеш идегез, Галиәсгар әфәнде. Сезнең саф, үзебезчә язуыгызны инкарь итеп, ул урам телендә яза дип, сезне аз җәберләделәрмени кадимчеләр?! Сез менә әдәбият, матбугат дисез, егетләр. Әдәбиятны укыса укый укымышлы

кеше, ә театрны һәркем, әлифне таяк дип белмәгән кеше дә карап үзенә гыйбрәт ала. Иң элек телебезнең аңлаешлы булуы сәхнә әсәрләрендә булырга тиеш.

— Бу фикерең дә дөрес, Карый, моңа да кул куябыз,— диде Тукай.— Әле син минә Галиәсгар әфәндегә ташлангач, искә төште. Шушы елның ноябрь башларында Галиәсгар әфәнденең сәхнә әсәрләре яза башлавына ун ел тула. Әгәр дә без моны билгеләп үтмәсәк, барыбыз да тамугта дөрләп яначакбыз.

— Дөрес, дөрес, хәзер үк аның турында уйлый башларга кирәк,— диде Кариев.

— Я, куегыз әле! — Галиәсгар йөзен чытты, кулын селкеп,— нинди юбилей ди ул! Вакыты андыймени! — диде.

— Тик кенә тор, әфәндем,— диде Тукай бармак янап,— синең эшең керфекне идәнгә терәп кенә утыру.

— Мыек чылгыйларыңны салындырып,— дип өстәде Әхмәт Урманчиев.

— Әйе, мыегыңны сыпырып,— диде Тукай,— тик кенә утыру. Ә син, менла кем,— ул Кариевка карады,— синең эшең бөтен «Сәйяр» труппасын аякка бастыру һәм хәзерлек башлау.

Алар, үзара кызып, юбилейны ничегрәк оештыру турында сөйләшә башладылар. Хөсәен фикеренчә дә бу кирәкле бер чара иде. Мондый чын демократ булган прогрессив язучыларны халыкка күрсәтү, аларның үзләрен популярлаштыру өчен генә түгел, гомумән, алдынгы әдәбиятны, шуның аша алдынгы карашларны халыкка тарату, аларның абруена хезмәт итү иде.

Хөсәен сәгатенә карап алды да урыныннан торды.

— Гафу итегез,— диде,— мин сезнең изге ниятләрегезне бик хуп күрәм. Әлбәттә, Галиәсгар Камал әфәнденең ун еллык иҗат юбилеен зурлап уздырырга кирәк. Кызганыч, минем ашыгыч эшләрем бар, сезне калдырып китәргә мәҗбүрмен.

Хөсәен Тукайның искиткеч сизгер кеше икәнлеген һәм мотлак үзен озата чыгачагын алдан ук уйлаган иде — ялгышмады.

Коридорның яшел палас җәелгән аулаграк урынында Хөсәен шагыйрьнең терсәгеннән тотты:

— Бүген төнге унберде үзеңә мәгълүм өйдә безнең чираттагы утырыш була. Шәт, килерсез, шулай бит?

— Әлбәттә,— диде Тукай.

— Ярый, шул гына иде әйтәсе сүзем. Бар, Тукай, анда сине иптәшләрең көтә.

Бүгенге мәҗлестә сүз бик җитди булачак иде. Сүз реакциянең котырынуы һәм моңа каршы алдынгы татар интеллигенциясе күрергә тиешле чаралар турында барачак иде. Казан губернаторы каты карар чыгарырга җыена. Ул карар нигезендә губернада җыелышлар уздыру рөхсәт ителмәячәк, стачкалар тыела. Аерым фатирларда да, кунакханәләрдә дә читтән килгән һәр кеше турында мәгълүмат шундук полициягә хәбәр ителергә тиеш. Димәк, кара реакция үзенең канлы тырнакларын революцион хәрәкәтнең тәненә тагы да ныграк батыра. Бу карар турында Тукайлар белергә тиеш. Алдынгы кешеләр алдан ук аяк киенеп куйсыннар.

Ул шулар турында уйланып урамга чыкты. Көндез халык кайнаган урам хәзер тынып калган иде. Бары көз якынлашу хәбәрен алып килүче җил генә таш түшәлгән урамны себереп, кәгазь кисәкләре очыра. Көз — Хөсәен өчен авыр чак, әле аның яңгырлары башланыр. Юешлек, дымсу һава... Ярар, төкер барысына да. Җайланыр, сәламәтлек тә, үпкә дә, йөрәк тә бер рәткә килер. Тик эш кенә барсын. Эш барсын, Хөсәен университетка керсен.

Җагъфәр палуба кырыеннан диңгезгә карап барды. Диңгезнең әле көләч чагы. Кояш нурлары зәңгәр тирәнлекләргә кадәр үтеп керәләр дә, вак дулкынлыкларда тибрәнеп уйныйлар. Алда да, уңда да, сулда да шул ук, бер үк күренеш. Ләкин ул Җагъфәрнең күзләрен талдырмады. Киресенчә, диңгез аның күңеленә рәхәт бер тынычлык бирә иде. Ничектер, ул әчтән генә елмаю, бәхетле кеше елмаюын кичерде. Ирекле кеше иде ул бу минутта: диңгез һәм ул, ул һәм диңгез. Алда аны шулай ук гүзәл бәхетле киләчәк көтә. Төркия, Истамбул! Бәдәл мәсьәләсе кузгалган көннән башлап ул үзенең сәфәре турында аз уйламады бит. Туктыбайга ризалыгын һәр ягын исәпләгәннән соң гына бирде. Дөресен генә әйткәндә, Мәккә-и-Мөкәррәмәгә бару, бары дөнья күреп кайту күзлегеннән генә кызыксындыра иде аны. Аның өчен иң кадерлесе — Төркия, Истамбул. Ул анда үзенең бөек максатына ирешәчәген барлык әгъзалары белән тойгандай була. Монда төркия мәгърифәте, мәдәнияте — цивилизация чәчәк ата.

Җагъфәр диңгез киңлекләренә текәлгән хәлдә, хыял дулкыннарында тирбәлә иде. Әйтерсең лә, аның уйларын да диңгез өстендәге тымызык җилдән яралган дулкыннар тибрәтә. Әйе, ул Туктыбайның йомышын намус белән үтәр. Мәккәсенә дә барыр, Мәдинәсендә дә булыр, барлык ритуалларны башкарыр, савабын тузан кадәр дә үзенә чагылдырмыйча казакъ баена тапшырыр, ә инде хаҗдан кайтышлый Истамбулга тукталыр, бәлки әле бөтенләйгә үк тукталыр. Кемс бар аның Россиядә, алай ут йотып сагынырлык? Кем көтә аны Россиядә? Җагъфәргә акчаны бай бик бөртекләп санап бирде, аның исәпләвенчә, акча хаҗ кылганнан соң Истамбулга кайтып җитәрлек кенә иде. Син Истамбулга җитү белән миңа хәбәр итәрсең, диде. Мин сиңа телеграф аша шундук җибәрермен. Ни өчен шулай итте Туктыбай? Моның асылына Җагъфәр төшенә алмады. Күрәсең, бирәр сәбәбе булгандыр инде. Әйдә, була бирсен. Минем өчен акчаның Истамбулга кайтып җитәрлек булуы мөһим.

Җагъфәр шулай уйланып барды. Күңелендәге татлы хыяллар, җәннәттәй булып алда күренгән гүзәл тормыш, аны үзенең агымы белән өстерәп алып китә бирде. Ә диңгез һаман чайкала, өстә акчарлаклар кычкыра, гел бер төрле пароход гөрелтесенә үзләренең җылак тавышлары белән аваз өстиләр иде.

Җагъфәр ялыга башлагач, каютага төште дә кечкенә өстәл өстенә иелеп үзенең көндәлегең язарга керешге. Каютадагы юлдашларның өчесе дә үз урыннарына сузылып ятканнар, йоклыйлар. «Бәхетле кешеләр,— дип уйланды Җагъфәр,— нинди дер казакъ бае саваплы булсын өчен түгел, үз бәхетләре өчен, үзләренең хәләл акчаларына укырга баралар. Гырлап йоклаган өч туганның олысына карап торды ул. Мәдрәсәдә җыен чүп-чар чәйнисе килмәгән егет Төркиягә көллиядә укырга барам мин дип әтисе белән дәгъвага кергән. Ике ел укыган, инде әнисе белән сеңелесен дә мондый эшнең безнең заманда иң кулай икәнлегенә инандырган. Һәм менә үзе белән аларны да Истамбулга алып бара. Егетнең исеме Искәндәр. Яшә, Искәндәр! Синдәй егетләребез булса, миллә тәрәкъкый итәр, һаман алга барыр!

Шул Искәндәр Җагъфәргә укып чыгу өчен Истамбул турында бер кечкенә генә китап биреп торган иде. Китап русча. Җагъфәр аны бер кабат укып чыккан иде инде, хәзер ныграк хәтерендә калдыру өчен, үзе кирәкле дип тапкан урыннарын тагы укыштыргаларга тотынды. Китап рәсемле, хәтта картасы да бар, Төркия башкаласының планы да төшерелгән. Зур кешеләрнең исемнәре дә аталган иде.

Җагъфәр китапта язылганнарны укып бик күп нәрсәгә хәйран калды. Мәсәлән, Истамбулда җиде йөз мәчет бар икән. Истамбулның пор-

ты дөньяда иң зур портлардан санала. Аның гаваньнары тирән урында, ул гаваньнарга пароход бөтенләй якын ук килеп туктый ала. Иске һәм Яңа шәһәргә бүленә икән үзе. Шәһәрнең Галата дигән өлеше — сәүдә, портлар урыны, Бәйоглу дигәне — эшмәкәрләр үзәге. Анда банклар, трестлар, конторалар. Шәһәрнең бер өлеше Азия кыйтгасында, ә зуррак өлеше — Европада. Халыч (Золотой Рог) бухтасы бу калкулыклардагы шәһәрнең Европа өлешен икегә бүлеп тора, аның аша күперләр салынган. Истамбулда бик борынгыдан калган гүзәл мәчетләр бар: Ая-Суфия, Кучук-Ая Суфия, Каһрие-Җами, Келәсә-Җами, Зөйрек-Җами, Баязидия, Шаһ-задә, тагы әллә нинди гүзәл мәчетләр. Истамбулның урамнары чиксез күп фонтаннар белән бизәлгән. Я хода, тизрәк барып җитсәк кенә иде, тизрәк гүзәл шәһәрне күрсәк иде! Тизрәк кенә шуның изге урамнарына бер аяк бассак иде. Тизрәк, тизрәк, тизрәк, тизрәк!

Җәгъфәр, җиңелчә тирбәлгән килеш, йокыга талганын сизми дә калды. Кинәт ул каты тавышка уянып китте — күрше каюталардагы халык шаулаша, тышта нидер улый, шарлап пароход өстенә күктән су ташкыны төшә, пароход исә әле бер, әле икенче якка чайкала иде. Җәгъфәр чак сәндерәсеннән мәтәлеп төшмәде. Тотына-тотына көч-хәл белән идәнгә төшеп басты.

— Әгәр күңелегез болганса, миндә лимон бар,— диде Искәндәр.

Җәгъфәрнең алай күңеле болганмый иде әле. Ул түгәрәк бәләкәй тәрәзәгә килде, әмма аннан берни дә күрерлек түгел: тоташ су, дөбердәү һәм дәһшәтле бер улау тавышы гына ишетелә иде.

— Безнең Фәүзия штормны ифрат авыр кичерә икән,— диде Искәндәр,— аны энем тышка алып чыгып китте. Анда диңгезгә карап барса, җиңелрәк булырга тиеш.

— Хатын-кыз бирешүчәнрәктер шул,— дип куйды Җәгъфәр. Бөтен тирә-юнь хәрәкәттә, өстәге лампа түшәмгә бәрелергә җитеп чайкала, идәндәге чемоданнар әле бер якка, әле икенче якка шуып йөриләр иде.

— Менә сиңа, ә, күрәсең булса! — диде Җәгъфәр телен шартлатып.

Шторм сәгатьтән артык дәвам итте. Аннан әкренләп кими башлады. Пароходны коендырган таудай дулкыннар юашлана төште, ниһаять, диңгезнең ачуы кайты, әкренләп тәмам тынычланды. Төн уртасында болытлар да таралып юкка чыктылар, күк гөмбәзен, кара хәтфәгә сибелгән алмаз кисәкләредәй яктыртып, йолдызлар калыкты. Ә бер сәгатьтән соң диңгез өстенә көмеш юл сузып ай калыкты.

Җәгъфәр палубада иде. Ул ай юлы белән яктыртылган тыныч диңгезгә гашыйк булып, бөтен барлыгы белән алга карап барды. Бары аяклары талып, үзен йокы баса башлагач кына ул каютасына төшеп, сәндерәдә йокыга талды.

Җәгъфәр уянып киткәндә Искәндәрләр чәй эчеп утыралар иде. Аны да чәйгә кыстадылар. Җәгъфәр табынга утырганчы юынып алырга дип чыгып китте. Трюмдагы мичкәләр һәм тюклар арасындагы халыкның чуарлыгына исең китмәле: хаҗилар бөтен тирә-юньне каплаган. Тамак ялгау, чәй эчү, кайберсе исә сакал-мыек кыру-төзәтү белән мәшгульләр. Җәгъфәргә юыну өчен шактый вакыт чират көтәргә туры килде.

— Чәй суынып бетте инде,— дип каршыладылар аны.

Җәгъфәр, чәй алыр өчен, тагы халык арасына, тынчу урынга чыгып керде.

— Мин бер яңалык белдем әле,— дип каршылады аны Искәндәр.— Без Истамбулга керер алдыннан дүрт көнлек карантин узарга тиешбез икән. Димәк безгә бүген үк анда барып керү тәтеми.

— Шулаймени? — диде Җәгъфәр күңелсезләнеп. Аның изге шәһәрне тизрәк күрәсе килә иде. Ул сер сынатмады, эчендәген актарып ташламады.

Көндез уникеләрдә пароход Кара диңгез белән Мәрмәр диңгезен тоташтырган бугаз авызында таштан салынган ниндидер борынгы монастырь янында тукталды. Хажиларны шунда пароходтан чыгармыйча дүрт көн тоттылар. Бу карантин Истамбулны күрергә ашкынган татар егетләре өчен генә түгел, төрле яктан җыелган хажилар өчен дә газаплы иде. Берничә тапкыр алар дулап, капитан каютасына менеп тавыш куптарып карадылар, ләкин бу эшнең бернинди нәтиҗә бирмәячәген аңлап, язмышка буйсынырга мәҗбүр булдылар, тагы үзләренең тынчу урыннарына кереп кайнаша башладылар.

Ниһаять, бишенче көнне пароход бугаз эченнән Истамбулга таба юл тотты. Җәгъфәр бу ике гүзәл диңгезне тоташтырган бугазның киңлеге егерме сигез чакрым икәнлеген укып та, ишетеп тә белә иде. Ләкин аның ярлары шул дәрәҗәдә үк сокландыргыч матурдыр дип һич башына китергәне булмады. Ике яр да ачык күренә. Ике ярда да берсеннән-берсе зиннәтлерәк дачалар, биек матур таш сарайлар яшелләккә күмелгән.

Җәгъфәр хәйран калып карап барды. Аның белән янәшә торган европача киенгән бер кеше аңа русча аңлатмалар бирә башлады. «Әнә күрәсезме,— диде,— биектә таштан салынган ак сарайның калдык хәрабәләре... аны күптән түгел яндырдылар. Юкса, ул үзе генә дә бу ун кул ярга аерым бер гүзәллек өсти иде. Беләсезме, күпме кешене кулга алдылар шул янгын мөнәсәбәте белән? Мең дә биш йөз кешене».

— Ни өчен? — диде Җәгъфәр.

— Янгынны оештыруда гаепләп. Чөнки бу — хөкүмәт сарае.— Җәгъфәр бер сүз дә дәшмәде. Ләкин эченнән, шулай кирәк гүзәл сарайны яндырган өчен, дип уйлап куйды.

## 22

Хөсәеннең иң бәхетле көне иде бүген. Ниһаять, максатына иреште. Ул стенага эленгән исемлектән үзенең фамилиясен эзләп тапкач, һич кузгалып китә алмас булып, шактый вакыт шуңа карап торды. Университет студенты диген, ә?! Хөсәен тыела алмыйча үзалдына елмая, шатлыгыннан нишләргә дә белми иде. Университет коридорлары карт һәм яшь студентлар белән тулы. Аларның Хөсәендә гамьнәре дә юк: тыз-быз йөренәләр, әле бер, әле икенче яктан килеп чыгып, Хөсәенгә бәрелеп узалар.

Укырга кирәк, укырга кирәк, диләр иде Хөсәеннең күпне күргән революционер дуслары. Укырга кирәк, укырга кирәк, диләр иде алдынгы татар зыялылары. Ниһаять, ул бүгеннән башлап Казан университеты студенты, юридик факультетта укый башлаячак. Инде ул бернинди дә авыруларга бирешмичә укыр, университетны ташламас. Мондый зур бәхетне аның соңгы елларда татыганы юк әле. Кем белән бүлешергә соң әле мондый шатлыкны, дип уйлады Хөсәен. Иң беренче булып аның күз алдына Хәдичәсе килеп басты. Ләкин ул хәзер өйдә юк, мәктәбендәдер. Галимҗан бар бит әле, ул да бу көннәрдә күренми, Троицкидан кайтканнан бирле икенче квартира алыштырырга җыенып йөри иде. Күрәсең, үзен артык нык сагалыйлар, мәлгуннәр. Хөсәеннең йөзе яктырып китте. Аның җан дусты Мөхетдин бар бит! Алар Мөхетдин Корбангалиев белән күптәнге дуслар иде. Казанда яшәгәндә дә, Оренбург ягында да ул, һәр мөмкинлектән файдаланып, Мөхетдиннәрдә булмый калмый иде. Хәзер инде Мөхетдин Корбангалиев укытучы, өйләнде. Ләкин дуслык алар арасында һаман өзелмәде. Бу тукмак борынлы дус белән Хөсәеннең ботка пешә иде. Сәясәт өлкәсендә алар кайчак бәхәскә керсәләр дә, кеше буларак бер-берсен яраталар иде. Ләкин

бүген, минә хәзер аны да өендә очратып булмас шул, эшендәдер мөгаен.

Хөсәен үзенең якын дусларын, аның бүгенге шатлыгын аңларлык кешеләрне күңеленнән берәм-берәм уздырды. Тик, кызганычка каршы, алар бик күп булсалар да, Хөсәенгә көпә-көндез барырга ярамый, юллар ябык иде. Шул ук Гафурга да, хәтта Тукайга бару да хәзер кыенлашты.

Хөсәен урамга чыкты. Университет бинасының таш колонналары яныннан китәлмичә торды. Ул бит бүгеннән университет студенты инде! Менә бәхет нинди була ул!

Хөсәен Воскресенский урамындагы кондитер кибетеннән бер матур торт, ярты гына кадак кыйммәтле конфет алды һәм, таудан төшеп, туптуры өенә таба юнәлде.

Гаҗәпләнүенә каршы, Хәдичәнең өйдә чагы туры килде. Өстенә халат кына элеп, ялан аягына чигүле чүәк эләктереп ишек ачарга чыккан Хәдичәнең чырае үтә кәефсез иде.

— Нишләп укуда түгел, ни булды, Хәдичә?

— Минем хәлләрем белән дә кызыксынасыңмыни әле син?

Хөсәен бер мизгелгә югалып калды.

— Ничек инде, Хәдичә? Ничек кызыксындырмасын ди синең хәлең?

— Рәхмәт... — Хәдичәнең ирен почмагы калтырап куйды.

Хөсәен өс киемнәрен салып элде, әле суынырга өлгермәгән шатлыгын хатынына житкерергә теләп:

— Мине, Хәдичәкәй, котлый аласың,— диде.— Абзаң — студент первого курса юридического факультета Казанского императорского университета, белдеңме!

Хөсәеннең шатлыктан күзләре нурланган, ябык йөзенә җиңелчә кызыллык йөгергән иде. Ул, кыланышы шатлык дәрәҗәсенә лаек булсын дигәндәй, Хәдичәгә күз кысып, тамак кырды.

— Котлыйм,— диде Хәдичә, салкын гына,— поздравляю.

Хәдичә бу сүзне дә ничектер иреннең өске бер почмагын гына тибрәтеп, йөзендәге бер генә тамырын да хәрәкәтләндермичә әйтте.

— Менә, күрәсеңме нәрсәләр алып кайттым мин,— диде Хөсәен күчтәнәчләрен өстәлгә куеп,— өченче көн бер нәрсә тәрҗемә иткән идем ич, шул акчага... Хәзер тәмләп чәй эчәрбез. Ә син ятып тор, чәй кайнап чыккач, эндәшермен.

Ул кызу-кызу атлап юынгыч янына китте. Кулларын юып кухня якта күздән югалды.

Хәдичә, төксе караш белән, ул чыгып киткән ишеккә төбәлеп торды да, кинәт үксеп, диванга ауды. Хөсәен самавырга кисмәктән чүмеч белән су салып тора иде, Хәдичәнең тавышын ишетү белән олы бүлмәгә атылып керде, идәнгә тезләнеп, Хәдичәне кочаклап алды.

— Хәдичәкәй, ни булды сиңа? Ник шулай җылыйсың?

Хатынының каты бәгырьле кеше икәнен ул күп тапкырлар сынаган иде. Баштарак, өйләнешкән елларны гына, Хәдичә бераз йомшаклык күрсәтте. Ләкин аннан соң, нинди генә авыр минутлар кичермәсеннәр, хатынының күз яшьләрен күрмәде Хөсәен.

— Мин сине аңламыйм,— диде ул,— һич булмаса сәбәбен әйт.— Әллә Чистайдан берәр кайгылы хәбәр алдыңмы?

Кинәт Хәдичә елавыннан тукталды. Ул шулай бермәл тын гына ятканнан соң:

— Чистайдан түгел, Петербурдан килгән хат мине шулай аяктан екты,— диде.

— Нинди хат соң ул, сине шулай җыларга мәҗбүр иткән хат?

— Белмәмешкә салышма, пожалуйста. Петербурдан синең мәгшукаң тагы хат җибәргән.

Хөсәеннең ачуы килеп китте. Ул Хәдичәнең бөтенләй көнче кеше булмаганлыгын белә. Хөсәеннең дә азгын ир дигән яманаты юк. Димәк, бүгенге истериканың башка, зуррак сәбәпләре бар, ә бу хат исә бары бер сылтау гына, сүз башлау өчен бәйләнергә бер сәбәп кенә.

— Хат Суфиядәнме?Ниләр яза соң кызый?

— Укымадым. Син бит минем чит кеше хатын укый торган гадәтем юклыгын беләсең.

— Укымагансың, ә үзең гомердә булмаганча жылый башладың. Бәлки ул минем эшем өчен кирәкле хәбәрләр язадыр.

Чыннан да, Хөсәен Суфияны соңгы тапкыр очратканда бер үтенеч белдергән иде. Петербургның алдынгы татар яшьләре турында тулырак язуын, яшьләрнең революцион хәрәкәткә мөнәсәбәтен хәбәр итүен үтенгән иде. Хат охранкага эләксә, берни аңлашылмаслык дәрәҗәдә эзоп телендә язылсын дип кисәткән, моның юлларын да аңлаткан иде. Әле моннан ике атна элек кенә Петербургка киткән Суфия Хөсәенгә тәгаен шундый хат җибәргән булгандыр.

Ул, Хәдичәнең иңбашыннан кочкан килеш, һаман идәндә тезләнеп утыруында булды.

— Хәдичәкәй, син бит бу хәсрәтләрнең нигезсез икәнен үзең дә беләсең. Нигә син гаиләдә шундый күңелсезлекләр тудырырга үзенә рөхсәт итәсең.

— Мин арыдым,— диде Хәдичә,— мин алҗыдым, минем артык тәкатем калмады. Бу авыр газаплы тормыш аркасында, дөресен әйтим, сиңа булган элекке мәхәббәтем дә эреп юкка чыкты. Үпкәләмә.

— Без соңгы елларда бер-беребездән ераклашканнан-ераклаша барабыз. Әле син минем революцион эшемне ташлауны таләп итәсең, әле милләтчелек өянәге башлана үзеңдә. Аңламыйм. Революциягә гомерен багышлаучыларның хатыннары әнә мәхәббәт хакына ирләре белән сөргенгә киткәннәр. Ә син...

Хәдичә яшьле күзләрен сөртеп алды да:

— Ә мин сөргенгә килмәдеммени?— диде.— Ул Уфада, Оренбурда безнең каңгырып йөрүләр аз булдымени? Җитәр инде, җаным, күрдек. Мин дә кеше бит. Ни өчен мин әз генә, әз генә булса да кешечә яшәргә лаеклы түгел. Мин синең өчен, син, син дип йөреп, туган йортымнан, әти-әниемнән аерылдым. Алар мине хәзер Чистайга хәер эстәргә барсам, бер ят кеше сыйфатында кабул итәләр.

— Мин һәрвакыт анда барып йөрүеңә каршы булдым. Бик күпләр без тапкан кадәрле табыш белән яшиләр. Син теш докторы булып чыгарсың, ә мин...

Хөсәен, әйтер сүзен бүлеп, үзенең нәрсәгә омтылуын һәм бу хакта Хәдичәгә дә ничәмә тапкыр әйтүен хәтерләде. Ул дәрәҗә алу, үзенең матди хәлен яхшырту өчен укырга һич омтылмый. Ул революция хакына, хезмәте саллырак, файдалырак булсын өчен укый. Бүген булмаса, иртәгә — илдә бөек революция булачак. Ул моны жаны-тәне белән тоя, шул чакны яңа тормыш кору өчен белемле кешеләр бик-бик кирәк булачак. Әйе, Хөсәен менә үзен шул көннәргә хәзерли. Шуны уйлап университетка укырга керде.

Моны кабатлаудан хәзер мәгънә юк иде. Чөнки Хәдичә барыбер аңламаячак. Хәдичә, Хөсәеннең ниләр уйлавын сизенгәндәй, тагы телгә килде.

— Син мине күктәге торналар белән юатып килдең, Хөсәен, тик кулыңдагы чыпчыктан коры калма. Минем дә бит түземем чиксез түгел.

— Хәдичә аппагым,— диде Хөсәен, Хәдичәнең иңбашларын тагы да ныграк кысып.— Нигә шундый сүзләр әйтәсең, сине яратканымны беләсең. Тагы ни кирәк? Кайдан килгән аумакайлык, түземсезлек бу?

Мин аңлый алмыйм, нинди сәбәпләр аркасында син минем идеалларыма каршы чыгасың?

— Житәр,— диде Хәдичә,— ул турыда, Хөсәен, бик күп сөйләштек инде. Син үз юлың белән бар, мин үз юлым белән. Хатын-кыз күңелен аңларлык йөрәк юк синдә. Мин шуны белдем.

Ул, шактый дорфа рәвештә Хөсәенне читкә этеп, торып утырды да чәчләрен төзәтә башлады.

— Шул кадәр башым авырта, билләһи, синең йөрәккә борчу салуларың тагы житмәсә!— дип үзалдына сөйләнеп куйды Хәдичә.

— Иң яхшысы, әйдә, без хәзер өстәл янында минем бәйрәмемне уздырыйк. Самавыр кайнап чыккандыр инде.

— Юк, Хөсәен,— диде Хәдичә, тагын үҗәтләнә төшеп,— мин синең белән ачыктан-ачык һәм соңгы тапкыр аңлашу өчен мәктәбемнән кайттым. Дөрес, минем кәефем дә юк, ләкин ул төп сәбәп түгел. Менә шулай, акыллым, канатым, кем әйтмешли. Әйдә, яныма утыр, әйбәтләп сөйләшик.

## 23

Жәгъфәр Истамбулдагы Бабгали урамын бизәп торган Мисрәт кунакханәсенә урнашкач та, кулына көндәлек дәфтәрен алды. Онытылганчы барысын да язып куюю иде исәбе.

«Менә без ят, минем өчен бик сәер яңалыклар белән тулган төрек шәһәрендә. Чәйдән соң йөрергә чыктык. Кая карама урамнарда каһвәханә, эскәмияләрне урамнарга чыгарганнар, кызыл фәсле агайлар хозурланып кофе эчәләр, комган сыман савыт аша гыр-гыр китереп наргилә (кальян)[1] тарталар. Бар икән рәхәттә йөзгән адәмнәр! Дөнья мәшәкатьләреннән азат икән бу кешеләр, көннәрен кәеф-сафа корып кына уздыралар. Тагы кызыгы шунда: без яннарыннан узганда алар барысы да эшләреннән туктыйлар, күздән югалганчы безгә карап калалар. Баксаң-күрсәң, алар без ирләргә бөтенләй бакмыйлар имеш, күзләрен дүрт итеп, ашардай булып, алар безнең сылу кызыбыз Фәүзиягә карыйлар икән. Фәүзия оялуыннан тәмам кызарып чыкты. Күрәсең, хатын-кызларның биредә һәрвакыт йөзе каплаулы булу аркасындадыр инде бу хәл...

Иртәгесен Бәкуглы дип аталган күпернең икенче ягындагы европалылар торган җиргә чыктык. Анда бару өчен күперне кичкәч, туннель аша трамвайга утырып узарга кирәк икән. Трамвай дигәннән, монда атлы трамвайлар да күренә. Бәкуглы ягы бөтенләй башка. Монда Иске шәһәрдәге кебек тар тыкрыклар юк. Өйләре дә балчыктан сыланмаган. Таш биналар, фонтан, скверлар. Ләкин монда да урамнарда товарны ишәкләргә төяп сату итеп йөрүчеләр аз түгел. Виноград, шафталу кебек әйберләр генә түгел, хәтта көянтә-чиләкләргә тутырып ит, үпкәбавыр, эчәк кебек нәрсәләр дә саталар. Менә гаҗәп, шәрыкнең үзенчәлегедер инде. Ә базарлары соң, базарлары? Безнең кебек кешенең андый базарга барып керсә, башы әйләнә, кая барырга белми, юл таба алмый аптырый.

Бәкуглы ягында йөреп, арып-талып беткәч, номерга кайтып ял иттек тә Искәндәрнең элекке танышы Галибәкләргә киттек. Галибәк атлы кеше Истамбулда туган, шунда төпләнеп калган татар. Искәндәрнең сөйләвенә караганда, бик намуслы кеше. Тар гына тыкрыктагы, тыштан балчык сыланган таш өйгә кердек. Эчкә узу белән Фәүзияне хатыннар ягына алып кереп киттеләр. Без исә, ир-ат, үзебезгә билгеләнгән бүлмәгә уздык. Өй эче ярым европа, ярым шәрыкчә җиһазланды-

[1] Наргилә — төтенен су аркылы үткәрә торган тәмәке тарту җайланмасы.

рылган. Диварларда келәмнәр, стена буйларында түшәмгә кадәр диярлек өелгән көрпә-мендәрләр. Уртада өстәл, урындыклар... Безне Галибәк һәм аның бертуган энесе Нияз әфәнде хуш күреп каршы алдылар. Күрәсең, алар тәмам төрекләшеп беткәннәрдер. Мин баштарак бик күп сүзләрен анламыйча оятка калгаладым. Мондый вакытларда миңа Искәндәр ярдәмгә килә. Мин Казан хәлләрен белгән кадәр бәян кылдым, хуҗалар Истамбул хәлләрен сөйләделәр. Мине борчыган хәбәр шул булды: Төркиянең Италия белән мөнәсәбәте бозылырга тора имеш.

— Шулай ук сугыш булыр микәнни?— дип сорадык без куркышып.

— Барысы да хода иркендә,— диде Галибәк әфәнде.

Галибәк әфәнделәр белән шулай күңелле генә сөйләшеп утырганда, бездән йөзен яшереп кенә, аның хатыны Гөлсем ханым өстәлгә икмәк һәм вареньелар китереп куйды. Без бисмиллаларыбызны әйтеп, икмәкне вареньега манып ашый башладык. Ул арада өстәлгә аш та килде. Галибәк әфәнде ашны тарелкаларга үзе бүлеп чыкты. Сагындырган иде өй ашы!

Аш арасында без үзебезнең сәфәр турында сөйләштек. Хуҗа белән киңәштек. Безнең сәфәр болай билгеләнде: башта диңгез юлы белән барабыз. Шамга җиткәч, безнең юллар аерыла. Әле дәресләр башлануга иртәрәк булу аркасында өч туган Котдускә китәчәкләр, ә мин исә — Шам аша хаҗ юлына.

Галибәкләрдә кичен мунчалар кереп, куныл, иртәгесен мин Туктыбайдан акча киләчәк кешене эзләп таптым. Туктыбайга телеграмм сугуын үтендем. Бер кырымлы татар белән танышып кайттым. Калган көнебез юлга хәзерлек белән узды, ә кичен Шаһзадә янындагы төрек театрына бардык.

Театрлары да боларның үзенчәлекле икән. Бер генә дә мөселман хатын-кыз күрмәдем мин анда. Булса да европалы ханымнар гына. Искәндәрнең сөйләве буенча моңарчы андый урынга гомумән хатын-кызны кертмәгәннәр. Соныннан алар өчен тамашалар аерым куела башлаган. Миңа кызык тоелган нәрсә тагы шул иде: мондагы тамашачылар бер дә утырган урыннарыннан кузгалырга яратмыйлар икән. Тәнәфес вакытларында малай-шалай халык арасында су, конфет, шоколад сатарга керешә. Кешеләр, ашап эчеп, урыннарыннан кузгалмыйча, тик утыра бирәләр.

...Иртәгә, ходай насыйп итсә, сәфәр чыгабыз. Истамбулның башка гүзәл урыннарын инде хаҗ кылып кайткач тамаша итәрбез. Ул арада Туктыбайдан акча да килгән булыр...»

## 24

Хәдичә өстәл янына, Хөсәеннең нәкъ каршысына килеп утырды да сүзгә кереште. Әйтәчәк сүзләрен бик күп тапкырлар үз-үзенә тәкрарлап караганлыгы, күп уйлаганлыгы, аның артык кыю, артык өздереп сөйләвеннән үк аңлашылып тора иде.

— Син, Хөсәен, иң мөкатдәс бер хыялыңа ирештең, канатым,— диде ул,— университетка кердең. Синең алдыңда озакламый зур карьерага якты юллар ачылачак. Мин дә менә, алла боерса, исән-сау укуымны бетерермен. Шуннан соң без матур тормыш корып җибәрә алырбыз. Рухи таләпләребезгә лаеклы эшебез дә булачак, матди яктан бер кемгә бәйле саналмабыз. Абруебыз зур, дусларыбыз күп булачак. Нинди генә югары сфералар арасына барып кермик, безне үз итеп, якын күрәчәкләр. Менә нинди тормыш көтә безне, Хөсәен.

Ул, сүздән тынып, иренең йөзенә карап торды. Хөсәеннең йөзендә мыскыллау чалымы, игътибарсызлык күрмәгәч, сүзен тагы да кыюрак дәвам иттерде.

— Сине, Хөсәен, университетка элэгүен бөтенләй яңа бер дәрәҗәгә күтәрәчәк, әлбәттә. Син бөтен сәләтеңне җигеп, уңышлы укып, курсыңны похвальный грамота белән тәмамларга тиешсең. Әмма моның өчен бөтен узган юлың турында яңабаштан уйланырга кирәк, син үзеңә бүтән юл сайларга тиешсең, ниндидер, эшсез, революционер исеме белән масаеп йөрүче авантюрист дусларыңнан ваз кичәргә кирәк сиңа...

Хөсәен урыныннан торып басты:

— Монысы булмас инде, акыллым!— диде.

Хәдичә күзләрен челт-челт йомды, кашларын җыерып куйды.

— Син башта мин әйткәннәрне тыңлап бетер.

Хөсәен тагын диванга утырды, күңелсезләнеп, борчылып тагы Хәдичәне тыңлый башлады.

— Синдә миңа карата әз генә булса да хөрмәт юк, мәхәббәт димим дә инде. Синең уйларыңда — Суфия гына. Әйе, миңа карата әз генә булса да хөрмәт, кеше дип карау юк синдә.

— Мин сине яратам, Хәдичә. Син моны бик яхшы беләсең.

— Ярар, бу сүзләрне әйтергә рөхсәт иткән намусың ни дәрәҗәдә сафтыр, анысына кагылмыйк. Һич югында, син мине үзең белән бергә газаплы юллардан узган бер иптәшең итеп карый аласыңмы? Менә шуңа көчең җитәме?

Хөсәен сабырсызланып башын боргалады, йөзен чытып куйды.

— Мин сиңа бик ачык һәм намусыма һич хыянәт кылмаган хәлдә әйттем, Хәдичә!

— Инде менә шулай икән, минем сүзләремә дә колак сал. Син хыялланып йөргән революция дигән әйбернең булмаячагы хәзер көн кебек ачык. Һәр көнне синең кебекләрне патша охранкасы тотып зинданга ташлый, сөргенгә куа тора. Үзебезнең дә баш өстендә кылыч асылынып торганын, бүген булмаса иртәгә хөкем эскәмиясенә утырачагыбызны да онытма. Әле күптәнме соң безне следователь чакырып допрос алды. Оныттыңмени? Юлыңны үзгәртсәң, хәзер үзгәртеп калырга тиеш син, Хөсәен, юкса, җан кисәгем, соң булачак. Аңлыйсыңмы, соң!?

— Минем юлым, Хәдичәкәй, Учительскаяда укыганда ук билгеләнде. Син моны миңа кияүгә чыккан көнне үк белдең. Ә инде революциянең булырга тиешлеге турында мин синең белән бер тапкыр гына сөйләшмәдем. Үзең дә бик яхшы хәтерлисең.

— Бу дәрәҗәдә үк кире кеше булырсың икән!— диде Хәдичә кинәт усалланып,— мин бит сине, әгәр телим икән, бүген үк, бүген үк...

Ул урыныннан торды, кулларын йомарлап Хөсәенгә таба килә башлады. Ләкин, Хөсәеннең йөзендә елмаю күрепме, акылына килде булса кирәк, яңадан өстәл янындагы урындыкка чүкте. Терсәкләре белән өстәлгә таянып йөзен учлары белән каплады.

Хөсәен, аның янына барып, аркасыннан йомшак кына кочты.

— Кирәкми, Хәдичә акыллым, мине беләсең. Нигә кирәкмәс сүз белән вакыт әрәм итәргә! Әйдә, иң яхшысы — тәмләп чәй эчик!

Хәдичә сулыгып еларга кереште, ул тәмам иелеп төште. Кызганыч иде хатын-кызның җылавын күзәтү. Хөсәен, аның аркасыннан сыйпаган хәлдә, һаман тынычландырырга тырыша иде.

— Я раббым,— диде Хәдичә,— һич булмаса берәр балам да юк бит. Шуның белән юаныр идем, шуңа сөйләр идем үземнең хәсрәтемне.

— Житте, Хәдичәкәй, без бу турыда да бик күп аңлаштык.

Хәдичә кинәт урыныннан торды да, бик каты итеп Хөсәенне кочып алды. Хатынның йөзен мул итеп күз яшьләре чылаткан иде.

— Бәгырем, Хөсәенем, җанымның пәрәсе,— диде ул яшьле йөзен Хөсәеннең күкрәгенә куеп,— син бит минем бердәнберем. Безнең чәчләребез гомергә бәйләнгән. Бер-беребезнең сүзеннән чыкмыйк. Тыңла мине, бәгырем, ике күзем, мин бит сиңа бары яхшылыкка гына әйтәм. Өз аранны тегеләр белән, булмас эшләр куып әвәрә булып йөрүчеләр бе-

лән. Әз генә булса да кешечә, кешечә яшәп калыйк. Бик, бик үтенәм, әгәр телисең икән, алдыңа тезләнеп ялынам, бәгырем, тик сүземне генә аяк астына салып таптама!

Хөсәен хатынының яңакларыннан кысып тоткан хәлдә үзенә каратты.

— Бу нинди мелодрама тагы, Хәдичә? Мондый фокусларыңны моңарчы күргәнем юк иде әле,— диде.

Ул аны каты итеп күкрәгенә кысты.

— Бу өянәгең вакытлыча гынадыр дип уйлыйм, Хәдичә. Узар. Син бик арыгансың. Авыруың да нервыларыңны бик нык какшаткан. Әйдә, ул турыда бөтенләй сөйләшмик. Булдымы?

— Юк булмады. Мин бит сиңа бик анык итеп, бу безнең соңгы тапкыр сөйләшү, дидем.

— Соңгы тапкыр булсын,— диде Хөсәен, риза булып.— Син мине денемнән яздырырга тырыштың, мин риза булмадым. Шуның белән алайса бу турыда бетерик, һәм икенче кабат моңа беркайчан да, беркайчан да әйләнеп кайтмыйк, Хәдичәкәй.

Хәдичә, тайпылып, иренең кочагыннан ычкынды.

— Бу сүзләреңне мин үземчә аңлыйм.

— Ничек инде «үземчә»?— диде Хөсәен аптырый төшеп.

— Әйе, шулай, миңа бердәнбер юл кала, дип аңлыйм.

— Нинди юл?

— Шундый юл менә, мин синнән китәргә тиеш.

— Китәргә?— Хөсәен күзләрен зур ачып, хәйран калып аңа карап торды. Ниһаять, зиһенен туплап сорады:

— Бөтенләйгә... аерылыпмы?..

— Әйе. Бөтенләйгә. Аерылып.

Хөсәен, башын иеп, әкрен генә диванга таба китте. Утыргач та әле гаҗәпсенгән күзләрен Хәдичәдән ала алмады.

— Димәк, кайчандыр, мәңге синең белән бергә, дигән антыңа хыянәт итәргә булдың?

— Әйе, булдым,— диде Хәдичә гасабиланып,— булдым, мин мондый тормышка артык түзеп тора алмыйм.

Хөсәен, бер сүз дәшмәстән, битараф бер кыяфәттә стенадагы сары рамлы картинага текәлде.

— Ихтыярың,— диде ул, ниһаять,— мин сине көчләп тота алмыйм инде.

Ул диванга утырган килеш калды. Хәдичә исә җилләнеп, дуамал бер кыланыш белән үз бүлмәсенә керде дә шартлатып келәне төшерде.

«Үзенең әйберләрен җыя, дигән уй килде Хөсәеннең башына. Кая китмәкче була ул? Юк, һәрхәлдә Чистайга түгел. Берәр ахирәтенә күчеп китмәкче буладыр. Әллә бу бары бер маневр гынамы?»— Хөсәен ничек дип юрарга да белмәстән, шулай баш ватып утырды. Аның күңел түрендә — Хәдичәнең бу өянәге узар, ул элекке хәленә кайтыр дигән өмет өзлексез көйри иде әле. Беренче тапкыр гына телгә килмиләр ич алар. Хөсәенне бу юлы аптыратканы бары шул иде: Хәдичә моңарчы «китәм» дигән сүзне кулланмый иде. «Гаҗәп,— дип куйды Хөсәен, үзалдына сөйләнеп,— гаҗәп, гаҗәп».

Ул Хәдичә артыннан бүлмәгә кереп, аның белән тагы бер тапкыр аңлашып карауны кирәксенмәде. Тынычрак кичерергә тырышты Хәдичәнең ультиматумын. Чөнки моңа әзерлек житәрлек иде инде. Конфликтның чираттагы яңа бер баскычка гына күтәрелүе иде бу.

Хөсәеннең күзләренә өстәл уртасында яткан хат чалынды. Сүз башлануга сылтау булган хат. Хөсәен өстәл янына килеп утырды да, ашыкмыйча гына конвертны ачты. Хөсәен үзе генә аңларлык эзоп теле белән язылган хаттагы хәбәрләр эченә чумды.

Суфия үзенең хатында Петербург студентлары арасындагы татар-

лар турында яза. Аларның революцион хәрәкәткә катнашуы, Трехгорка, Треугольник заводларындагы татар эшчеләре белән бәйләнештә торулары, студентлар арасында һәм Петербургтагы татарларның фәкыйрь катлавы арасында эшләүләрен бәян итә. Суфия хатында Мулланур Вахитов һәм аның Петербургта укучы студент дусты Шәриф Манатов турында аерата күп тукталган, аларның революцион хәрәкәттә бик актив эш алып баруларын тасвир иткән.

Әйе, зифа буйлы, кара күзле кыз Хөсәен абыйсының үтенечен әйбәт башкарган, ул аның барлык әйткәннәрен үтәгән. Бәлки әле шуңа вакытын биреп, укуына да зарар китергәндер...

Бая гына Хәдичәсеннән авыр сүзләр ишеткән Хөсәен Суфия турында ирексездән озак уйланып утырды.

## 25

«Менә без Бәйрүткә җиттек,— дип язды Җәгъфәр.— Безнең пароход ярга бер чакрым чамасы кала тукталды. Әйберләребезне төяп пристаньга чыгуга, гадәттәгечә паспортлар тикшерү, әйберләрне карау, печать сугып рөхсәт кәгазе бирү башланды.

Юлда очраган хәерченең исәбе-хисабы юк. Шәһәр халкы бары хәерчеләрдән генә тора икән монда, дип уйларсың. Озакламый ярда диңгезгә кертеп үк салынган кунакханәгә килеп җитеп, чыбылдыклы караватлары булган бүлмәләргә урнаштык. Монда барысы да гарәпләр икән. Акчалар да бөтенләй башка, вакыт та бүтәнчә.

Бераз ял итеп алгач, Бәйрүтнең атаклы мәдрәсәи көллиясен[1] күрергә киттек. Анда Идриснең танышлары булырга тиеш. Трамвай көллиянең капка төбендә генә туктый икән. Ишегалдында таш биналар — Европа кулы. Көллия хезмәткәрләреннән берсе, безне ияртеп, башта музейханәгә алып керде. Анда финикиялеләрдән калган мумияләр, кош чучелалары һәм башка бик күп нәрсәләр бар. Музейдан чыгып икенче бинага кердек. Мәктәп бик мөкәммәл, зур уку заллары, стеналарда китап киштәләре тезелгән, шунда ук мәктәпне салдыручы французга һәйкәл. Кыйраәтханәдән чыгуга Искәндәрнең танышы Бакиров Закир әфәндене очраттык. Ул безгә мәктәпнең ятакханәсен һәм гимнастика залын күрсәтеп йөрде. Соңыннан барыбыз бергә безнең отельгә кайтып аш ашадык.

Аш дигәннән, Бәйрүттә ашарга җүнле аш таба алмый аптырадык. Авызга кабарлык түгел, тәмсез. Ашлары гына түгел, ашарлык рәтле күмәчләре дә юк. Гарәп икмәге дигәннәре бездәге зур кабартманы хәтерләтә, тик тозсыз. Гарәп, төрек кебек үк, татлы әйбер ярата икән.

...Кичке сәгать алтыда поезд Шам шәрифкә килеп туктады. Кемдер безне шундук тәрәзәдән күреп алды, ачык тәрәзә янына килеп кычкырды: «Әфәнделәр, сез казанлылар түгелме?»

— Сез Талип әфәндеме?— дидек без. Шамда яшәүче татар Талип әфәнденең эше хаҗга баручыларны каршы алу һәм хәстәрләп озату икән. Аның төп вазифасы хаҗиларны «Котдус» кунакханәсенә төшерү. Ул безнең затлырак адәмнәр икәнлегебезне белеп, шыпырт кына, анда сезгә әйбәт булмас, сезгә яхшырак отель табарбыз, диде.

Менә без Шам шәриф урамнарында. Татарның җырларына кергән гарәп шәһәре. Ул хәзер Төркиянең бер чите генә. Тик, күренгәнчә, Төркиянеке дә, гарәпнеке дә түгел, бөтен байлык француз, итальян, англичан, америкаң кулында. Бу мине уйландыра.

Иртәгесен сәгать уннарда Талип агай килде. Ул безне Шамның үзләре яшәгән читендәге Салхия дип аталган җиргә алып барырга килгән

[1] Көллия — университет.

икән. Талип агай кайчандыр, әле яшь чагында ук, бөтен авыллары белән диярлек, Казан губернасыннан Төркиягә күчеп килгән мөһаҗирләрдән. Мөһаҗирләр Шам шәһәрендә урнашып, шунда төпләнеп калганнар. Без трамвайга утырып барабыз. Ул тауга менеп үзенең азаккы тукталышына җитә. Менә шунда икән инде татар мөһаҗирләре урнашкан Салхия дигән урын. Таш һәм балчыктан гына салынган булса да өйләрен, каралты-кураларын төзек, матур итеп оештырганнар. Һәр ишек алдында бакча, җиләк-җимеш куаклары. Талип агайның өе тау уртасындарак икән. Ишегалдында өч өй. Арткы өй артындагы койма ишегеннән бакчага чыгасың. Без арттагы өйгә керәбез. Безне татар карчыгы каршы ала. Әйтерсең лә, мин үз авылыма кайтып кердем. Шәрык өйләренә хас җыештырылган идәнгә миндәрләр тезелгән. Без чәй эчәбез. Җәмилә апа туган якны бик тә инде сагынганлыгын сөйли. Бер генә кайтып күрер идем, ди. Без әби янында Фәүзияне калдырып икенче якка, ирләр ягына керәбез. Монда инде туган яклардан килгән якташларны күрү өчен байтак мөһаҗир җыелган. Алар белән озак гапләшәбез. Тыңлап туймаганлыкларны миңа бик ачык. Ләкин безнең дә бит әле алардан киңәш-табыш аласыбыз бар. Шамда шафталу ашап туенабыз. Аннан да тәмлерәк нәрсә юк. Үзе арзан, батманы — ике куруш. Миңа акчаны бик саклап тотарга кирәк. Бу бай балалары артыннан җитеп булмас. Хәер, соңгы көннәр инде. Безнең юллар озакламый аерыла».

## 26

Җандарм идарәсе начальнигы полковник Калинин үзенең кабинетында подполковник Прогноевский әле генә китереп тоттырган донесениеларны игътибар белән укырга кереште. «Философ» дип имза куючы түләүле агент, Казанда, татар интеллигентлары арасында, әдәби түгәрәкләр исеме астында революцион идеяләр пропагандалау оештырыла башлавын язган. Бу оешмаларның башында охранкага күптән билгеле социал-демократлар булу ихтималын һәм аларның яшәп килгән стройга каршы татар интеллигентларын котыртуын хәбәр иткән иде.

Унынчы ел башларында ук, Бөтен Россия империясендәге кебек, Казан губернасында да революцион хәрәкәтнең тагы җанлана башлавы полковникка мәгълүм нәрсә. Яшерен агентураның хәбәр итүенә карaганда, Крестовников, Алафузов, Дары заводларында эшчеләрнең социал-демократик группалары торгызылган һәм эшкә керешкән. Су юлы эшчеләренең шундый ук оешмасы Идел буе шәһәрендә политик әдәбият тарату белән шөгыльләнгәне ачыкланган иде. Җитәкчеләре күптән кулда булуына карамастан, эшчеләр Беренче май бәйрәмен урманда агач башларына кызыл байраклар элеп уздырдылар. Егерме алтынчы май көнне эшчеләр Алафузовның туку фабрикасында эш ташлап, үзләренең таләпләрен куйдылар. Ул гына җитмәгән, шул ук Алафузов фабрикасында, ниндидер бер Мөхәммәтҗан Мөхәммәдьяров дигән татар эшчесен законсыз эштән чыгарулары аркасында, тагы забастовка булды. Тугызынчы августтан унберенче августка кадәр Алафузовның обмундирование мастерскоенда да эш туктатылды. Болар барысы да жандарм полковнигына билгеле, бер борчу тудырмый калмады. Ләкин полковник, бу чуалышлар эшчеләр катлавына гына хас, ә интеллигенция мәсьәләсендә студентларның ниндидер түгәрәкләр оештырып маташуларын исәпкә алмаганда, аерата татар интеллигенциясенең, болай бирелеп политика белән кызыксынуын ул һич күз алдына китермәгән иде әле. Аның ихластан ышануы буенча, татарларның жандармерияны куркыткан нәрсәсе — ул да булса пантюркизм һәм панисламизм хәрәкәте. Ул моңарчы барлык агентура көчен шул хәрәкәтне

белеп торуга, бастыруга юнәлтте. Күренеклерәк һәрбер татар кешесенә яшерен күзәтү булдырды. Баймы ул, танылган дин әһелеме, я булмаса шагыйрь, доктор, адвокатмы — алар барсы да күзәтү астында тордылар. Шул иде аның иң мөһим эше. Ә инде бүгенге хәбәр — татар эшлекле ләренең икеләтә дошманлык кылу мөмкинлеге турында сөйли иде ана. Бишенче елларда да бу хәл нык кына кабынып киткән иде. Ләкин ул чагында, полковник фикеренчә, татар интеллигенты — журнал чыгару, китап басу белән мавыкты күбрәк.

Калинин, доносны укып чыккач, шактый озак вакыт язманың азагындагы «Философ» дигән псевдонимга тукталды. Бу кушамат астында кем йөргәнен жандарм башлыгы яхшы белә. Университет бетергән татар врачы. Ышанычлы кеше. Җаны-тәне белән бөек монарх-патша хәзрәтләренә бирелгән, морзалардан чыккан кеше, студент вакытыннан бирле жандармериягә тугры хезмәт итә. Аның җасуслыгын беркем дә белми, һәрхәлдә моңарчы аңардан шикләнгәннәре дә сизелмәде. Ләкин ул моңарчы панисламистлар һәм пантюркистларны фаш итү белән шөгыльләнгән иде. Аның күрсәтүе буенча һәр катлау татар эшлеклеләреннән бик күп кеше исәпкә алынды. Күренеклеләре өстеннән яшерен сак куелды. Полковник, бераз уйланып торганнан соң, катгый бер карарга килде, инде «Философ» та кызыксына башлаган икән, димәк тегеләр татар интеллигенциясен ныклап агуларга керешкәннәр. Аны яралгы хәлендә үк юкка чыгарырга кирәк, юкса соң булыр, дигән фикергә килде. Ул үзенең каршында кәнәфидә аякларын чалындырып утырган ярдәмчесенә текәлде.

— Үзе мондамы әле ул — «Философ»?

— Монда, мин аңа көтәргә куштым.

Полковник, ярдәмчесенең тапкырлыгын хуплагандай, җиңелчә елмаеп куйды.

— Керсен. Сөйләшеп карыйк.

Үзенә ятышлы мундир кигән чибәр подполковник дәррәү урыныннан торып чыгып китте.

Ул арада, зәвык белән җиһазландырылган, түр стенасына Николай патша портреты эленгән, киң тәрәзәләре ефәк пәрдәләр белән капланган жандарм башлыгы кабинетына «Философ» килеп керде. Бу — калкурак гәүдәсе бераз калыная төшкән, сары мыеклы, зәп-зәңгәр күзле бер кеше иде. Өстендә европача кием, чәчләре җиту. Кыяфәтенә карап кына аның нинди милләт вәкиле булуын да белү мөмкин түгел. Ул үзен шактый кыю тота, бары күз алмаларының төрле якка тиз-тиз хәрәкәт итүеннән генә, бу хәтәр урынга килеп кергәч, каушый төшкәнлеген абайларга булыр иде.

Киң өстәл артында утырган полковник җасусның сәлам бирүенә каршы ияк кагып кына куйды. Алдындагы кәгазьгә текәлгән килеш, ишарә ясап, уз итүчәнлек белән:

— Утырыгыз, — диде. «Философ» артыннан ук кергән подполковник та үзенең баягы кәнәфиенә утырган иде инде.

Ниһаять, полковик кәгазьдән башын күтәрде. Күрәсең ул, сүз башлар алдыннан, теге язуны тагын бер тапкыр укып чыгуны кирәк тапкандыр, зур соры күзләре белән «Философ»ка текәлде.

— Сезнең монда язылган мәгълүматларыгыз ни дәрәҗәдә ышанычлы?

— Мин анда язылганнарның дөрес икәнлеген мең тапкыр икърар итә алам.

— Икърар итә аласыз. Сез ул кешеләрнең түгәрәгендә булдыгызмы соң?

Җасус бераз уңайсызлана төште.

— Юк, үзем булмадым. Чөнки минем бурычым башкарак, үзегезгә мәгълүм юнәлештәге эшләр башкару...— Ул ашыгып исбат итәргә ке-

реште.— Ләкин монда язылганнар чын дөреслеккә туры килә. Мин аны шул җыелышларга йөргән кешеләр аша белдем. Берсеннән генә түгел, берничәсеннән сорашып белдем. Мин аларның сөйләгәннәрен чагыштырып, хакыйкатьне ачыкладым. Һич шикләнмичә, сезне дә шулай булганлыгына ышандыра алам.

Полковник кайтарып бер сүз дә дәшмәде, тагы алдындагы кәгазьгә төртелде.

— Сез монда катнашучыларны санап чыгасыз...

— Мин барлык катнашучыларны да санап чыга алмыйм. Ләкин ул түгәрәккә җитәкчелек итүчеләр Ямашев белән Сәйфетдинев булуы бик ихтимал. Актив катнашучыларның: шагыйрь Габдулла Тукаев, мөгаллим Гафур Коләхметов, «Сәйяр» труппасының башлыгы артист Кариев, әдип Фатих Әмирхан, драматург һәм нашир Галиәсгар Камал, Мәхмүт Алиев икәнлегенә намусым белән ышандыра алам.

— Ләкин шулай да сезгә аларның җыелышында бер генә тапкыр да булырга туры килмәгән бит. Шуңа күрә, анда нинди сүз барганлыгын үз колагың белән ишетмичә торып, имеш-мимешләргә генә таянып булмый.

«Философ» бераз вакыт уйланып торды, аннан кыюланып:

— Таянып була, ваше высокоблагородие, ул турыда да мин информация җыйдым. Алар анда марксизм идеяләре белән танышалар. Сүзне әдәбияттан башлыйлар, ә аннары... марксизм тәгълиматы... социализм, коммунизм... Үзегез беләсез, пролетариат революциясе һәм башкалар...

Җасус ачы елмаеп сүзен бетерде. Ләкин жандарм башлыгы бик җитди бер кыяфәттә иде. Әмма аның чалара башлаган куе мыеклы симез йөзенә җентекләбрәк карасаң, бу яңалыкны ишетеп пошаманга калуын, ачу утында яна башлавын да чамаларга булыр иде.

Ул салмак хәрәкәтләнеп җасуска текәлде.

— Ярар,— дип куйды, аннан кинәт нидер хәтерләп, ярдәмчесенә күз ташлады.

— Сезнең әйтәсе сүзегез юкмы?

— Бар. Ул кемнәрдән информация алуын язып калдырсын әле.

Җасус: «Рәхим итегез»,— дип кесәсеннән каләм чыгарды.

— Теге якта, теге якта,— диде полковник. Җасус, жандарм башлыгы белән саубуллашып, төче елмайган бер кыяфәттә, чыгып китте.

Ярдәмчесе, «Философ»тан тиешле мәгълүматлар алып, кабинетка яңадан әйләнеп кергәндә, полковник анык бер карарга килгән иде инде. Ул алдына килеп баскан Прогноевскига:

— Минемчә, ул түгәрәккә йөрүчеләрне күздән ычкындырмаска кирәк безгә,— диде.

— Мин дә шундый фикердә. Хәтта...

— Аларның үз араларына кереп, даими рәвештә күзәтү алып барырлык башка кешегез юкмы соң?

— Бар, Александр Вениаминович. Мин нәкъ шул турыда сүз катмакчы булган идем дә әле сезгә.

— Ниндирәк кеше соң ул, ышанычлымы?

— Бик ышанычлы, сез аны беләсез. Ул әлеге мәгълүм «Житель» — ышанычлы агент, Уфа морзаларыннан. Аңа бу даирәгә керү бик ансат булачак. Чөнки ул үзе дә әдәбиятчы. «Таң йолдызы» дигән газетада мәкаләләр, хәтта шигырьләр бастырган кеше.

— Алайса менә шул агентны әзерләгез. Ә бу «Философ» үз эшендә калсын. Департамент, үзегез беләсез, бу туземецларның панисламизм, пантюркизм байрагы астында оешып, империягә зарар китерү куркынычын иң зур куркынычлардан саный. Әлбәттә, татар арасындагы җәдитчелек хәрәкәте дә безнең өчен кулай түгел. Департамент кадимчеләргә ярдәм итәргә куша. Ләкин болары әллә ни түгел.

Подполковник килешкәнлеген белдереп ияк кагып торды.
— Мин «Борис»ны да бу эшкә тартырга кирәк дип табам.
— Нинди «Борис» тагы? Ә, әйе, хәтерләдем, теге шәкерт. Өтек. Сез ничек карыйсыздыр, минемчә, ул бик ышанычлы кешегә охшамый.— Полковник эре нык тешләрен ялтыратып елмаеп куйды.— Интуиция әйтә, ул бәндәгә нык ышанма, полковник, ди. Йомшак ул, мескен. Ә безнең эштә көч кирәк. Көч һәм иман!
— Мин сезне аңлыйм, Александр Вениаминович. Минемчә, эш шунда, ул бит әле безнең яшь агент. Менә бу конкрет эштә без аны яхшылап сыный алачакбыз. Әгәр инде яраксыз булып чыга икән...
— Берсен икенчесе тулыландырыр һәм...
— Һәм беренче информациянең дөреслеккә туры килүенә контроль ясар дип уйлыйм. Ни әйтсәң дә инородецларга артык ышанып булмый.
Полковник «Әй-е» дип сузып куйды.
— «Житель» белән «Борис»ны күреп сөйләшегез. Бу эшне үзегез генә башкарыгыз инде, зинһар, минем башка эшләрем дә муеннан ашкан.
— Баш өсте.
Икенче көнне иртәнге якта ук Прогноевский «Житель» кушаматы белән доnoслар язып торучы җасусны чакыртты. Подполковникның беренче сигналы белән үк жандарм идарәсенә йөгереп килгән «Житель» «Философ»ка караганда гадирәк киемле, татарның әле европалашып җитмәгән зыялысы кыяфәтендәге шадра бер кеше иде. Өстендә казаки, башында хәтфә кәләпүш, бармакларында алтын һәм көмеш йөзекләр. Ул беренче карашка мескенрәк кеше булып күренсә дә, йөзенә дикъкать беләнрәк карагач та, аның шактый рухи көчкә ия, үз сүзен сүз итү өчен барысына да барырга әзер бер агент икәнлеген чамаларга була иде. Подполковник аның белән үз кабинетында сөйләште. Яшерен түгәрәк турында даими рәвештә мәгълүмат биреп торуны җасусның алдына бурыч итеп куйды. Ахырда Прогноевский айлык илле сумның бушка бирелмәгәнлеген җасусның исенә төшерде.
Шул ук көнне, өйләдән соң, Прогноевский «Борис» кушаматлы яшь җасусны да үз кабинетында кабул итте. Бу җасус исә, тышкы кыяфәте белән, кыю эшләр башкара алырдай кешегә бер дә охшамаган иде. Маңгаендагы ике тиенлек бакыр зурлыгындагы миңе дә подполковникка ошамады. Артык күзгә ташлана торган билге. Җитмәсә, бу «Борис»ның йөзендәге курку, дәһшәт чалымнары идарәгә кергәннән алып чыкканга кадәр китмәде. Бер мәл подполковник икеләнә дә калды. Бәлки моны бу эшкә тартмаскадыр? Ләкин, шулай да сынап карыйк әле, дигән карарга килде һәм иплән кенә җасуска эшнең нидән торганын аңлатырга кереште. Башта вакытлы матбугатта катнашырга, хәбәрләр, мәкаләләр язарга, әгәр булдыра алса, шигырьләр дә чыгарып газеталарга илтергә кушты. Аннан язучылар, иҗади интеллигенция белән ныклы танышлык булдырырга, ышанычларын казанырга, үзен бик хөр фикерле бер кеше итеп танытырга һәм шулай итеп жандарм идарәсенә дөрес мәгълүматлар биреп торырга.
«Борис» барысына да риза иде. Ул бүген үк эшкә керешәчәк, тик аны кыерсытмасыннар гына. Ул әңгәмә бетү белән, подполковник белән саубуллашырга да онытып, тиз генә чыгып китте.
Прогноевский аптырап һәм ачуы килеп башын чайкап калды: «Менә кабәхәт татар!»

27

«Без инде югары балконга мендек. Моннан бөтен Шам шәриф күренә. Бу манара турында ишеткән идек инде. Шушында хәзрәте Гайса иңәчәк имеш. Бу манарага бер заман Гайса исемле җирле гарәп мен-

гән дә, озак тамаша кылу аркасында булса кирәк, тыштан мәчетне бикләп киткәннәрен сизми калган. Төшеп ишек кага башлаган. Бикче, «Кем бу?» дигәч, теге «Гайса» дигән. Шул ук минутта бу хәбәрне ишетеп тетрәнгән бикче, халык чакырып, хәзрәте Гайса инде, Гайса инде, дип хәбәр салган. Бөтен Шам аякка баскан. Музыкалар уйнатып, тиз арада хәзрәте Гайсаны каршы алырга килгәннәр. Ишекне ачып җибәрсәләр... үзләренә күптән мәгълүм кеше килеп чыккан. Сөйләүләренә караганда шамлы Гайса үлемнән чак котылып калган.

Шамда байтак изге һәм тарихи урыннарда булдык. Пәйгамбәребезнең хатыннары Сәлимә, Хәбия, жариясе Мәймүнә, кызлары Рокия, Өммегөлсем каберләрен зиярәт иттек. Уникенче гасырда гарәп мәдәниятын саклап калуны оештырган данлыклы Мисыр солтаны Сәләхетдин Әюби хәзрәтләренең каберендә дә булдык. Кая гына барма, анда кесә бушатырга кирәк. Я намазлыгында тәсбих тартып утыручы шәехкә, ә хәерчегә сәдака бирү лазым. Ә бирмәү гөнаһ ди. Хәерче дигәннән, алар бөтен урамнарны тутырган, әйтерсең лә мондагы халыкның төп кәсебе хәер эстәү. Ә бик искиткеч бай як үзе. Каян килә бу хәерчелек?

Озакламый мин ялгыз гына калам. Искәндәрләргә нияләшенгән иде. Алар кирәкле юлдаш иде. Җитмәсә төрле шомлы сүзләр ишетелә. Узган ел хаж сәфәрендә коточкыч хәлләр булган. Гомердә булмаганча кар яуган. Кар шул кадәр күп яуган ки, хәтта Шамнан Бәйрүткә поездлар йөрмәс булган. Кайбер хаҗилар Шамнан Хифага китә башлаган, ләкин Хифаның бухтасы юк, пароход анда туктала алмый икән. Шулай итеп Шамда сигез мең, Хифада ике мең хажи юллар ачылганны көтеп, газапланып ятканнар. Инде тагы болай сөйлиләр: мең хажи кәрван белән Бәхреахмәр буенча коры юлдан Мәккә-и-мөкәррәмәдән кайтып килә икән, юлда үзләрен болганчык су ташкыны баскан. Бу хәл 24 гыйнварда Кариятелмәшәих дигән бер авыл янында булган. Шунда алты йөз хажи һәлак булган.

Безнең арада Фәүзия туташның булуы үзенә күрә бер күңелсезлек тудырды. Гарәпләрнең нииндидер бәйрәмнәре иде. Урам тулы халык, музыкалар уйнатып, хатыннарыннан лю-лю кычкыртып йөриләр, урамнан извозчиклар үтә алмый. Ләкин анысы әле ярый, түзәрлек бер хәл. безнең фаэтонны ирләр сырып алды. Алар Фәүзиянең йөзен күрергә омтылалар, ятып та, үрелеп тә карыйлар. Ахырдан түзә алмыйча Фәүзия йөзен зонт белән каплады. Җыларга житеште. Ә безгә, ул җүнсезләргә кул тидерергә ярамый, диделәр. Искәндәр әйтә, Шам гарәпләре ифрат усал, алар шундук теткәләп ташлаулары мөмкин, ди.

Кадәм шәриф дигән изге урынга бардык. Ул шәһәр читендә икән. Без авылга кердек. Урамнар тар булу аркасында аттан төшеп жәяүләп киттек. Бер капка янына туктадык. Мәчет диделәр. Ишек алды уртасында бер бина. Ишек алдында бер төркем бала, күзләрен йомып, селкенә-селкенә коръән укып утыра. Бер шәкерт мәчеткә кереп хәлфәләрен алып чыкты, эчкә кердек. Бик начар гына мәчет. Түрдә тәрәз төбендә пәйгамбәрләребез һәм аның дөясенең ак таштагы аяк эзләре, диделәр. Артык кечкенә тоелды миңа ул эзләр. Шуны карап хәлфәгә сәдака биреп чыгып киттек. Чыксак, капка төбе тулы хәерче бала. «Танин зиярәт, я хажи»,— дип кулларын сузып торалар. Янәсе сәдака бирсәң, зиярәтең кабул булыр. Безне озатып йөрүче Талип агай аларны тезеп куйды да сәдака өләшергә кушты...

Икенче көнне безне тар гына урамнар буйлап ифрат биек бер тау янына алып килделәр. Юл борылып-борылып менә. Көн артык эссе. Тау башында ике катлы бер бина күренде. Өй янына койма тотылган. Өйдә безне бер шәех каршы алып, югары катка мендерде. Монда салкынча, рәхәт иде. Идәнгә җәелгән намазлыкларга утырып ял иттек. Шәех яңгыр суы да эчерде. Исемнәребезне стенага язарга кушты. Без

язык та, сәдака биреп, аска төштек. Анда башмакларыбызны салып, бер карангы җиргә кердек. Шәех шәм яндырды. Стенага эленгән аятьләрне укыды. Анда шул тау һәм таудагы мәгарә турында язылган икән. Бу тауга халык «Кырыклар тавы» дип исем кушкан. Шушы тау тишегенә кереп киткән кырык иранлы юкка чыккан имеш. Тагы бер бүлмәгә кердек. Анда эчкә батып торган урында хәзрәте Гали, Госман, Әбүбәкернең таҗ урыны икән. Күрше бүлмәдә кара ташта биш бармак эзе бар. Бу Һабилнең бармак эзе имеш. Ул Кабилгә таш атмакчы булган да бармак эзләрен калдырган. Мәгәр ташны Җәбраил аттырмаган. Шул ук бүлмәдә бәләкәй генә бер караңгы тишек тә бар. Теге гаип булган иранлылар шуннан кереп киткәннәр имеш. Алар һәр бәйрәм саен шул тишектән чыгып, Хөзыр галәйһиссәләм белән күрешәләр икән. Тагы түшәмдә күзгә охшаш бер уенты бар. Аннан су тамып тора. Кабил Һабилне үтергәч, бу тау алладан Һабил өчен кыяматкәчә җылап торыймчы дип үтенгән икән. Теләге кабул булган. Уң якта нәкъ авызга охшаган тагы бер зур тишек бар. Эчендә хәтта телгә охшаган, теш урыннарын хәтерләткән ташлар күренә. Бу тауның авызы дип аңлатты шәех. Хәзрәте Адәм Һабилне эзләп йөргәндә тау телгә килеп, «аны Кабил үтерде», дип әйткән имеш. Без бинадан чыгып тагы тау башына мендек. Анда Һабилнең каны бар. Тау башыннан ике сажин чамасы булып агып төшкән кара тап. Бу канның җиде мең ярым елдан бирле саклануын могҗиза дип белдерде шәех. Ул безгә дә берәр кисәк кара таш бүләк итте.

Мин Шам могҗизаларын артык карамаска булдым. Бәлки гөнаһысы бик зурдыр. Ләкин нихәл итмәк кирәк. Акча хаҗдан Истамбулга кире кайтып егылырлык калырга тиеш. Түземсезлек белән Искәндәрләрдән аерылуны көтәм.

...Юлдашларымны бүген Котдускә озатып җибәрдем. Поезд кичке җидедә китте. Искәндәр сеңелесе белән энесен, Котдүсне күрми китәргә ярамый, дип барырга күндерде. Тегеләр, бик арган булсалар да, кызыксынулары җиңде — риза булдылар. Ә мин исә иркен бер сулыш алдым. Чөнки алар исәбенә йөрү дә, алар алдында саранлану да килешми бит. Ләкин бергә байтак җирләр гизеп, без бер-беребезгә инде тәмам ияләшеп беткән идек, аерылышу, ни әйтсәң дә, җиңел түгел. Бәлки бу аерылышу мәңгегәдер».

## 28

Габдулланың бүлмәсе иртәдән кара төнгә кадәр ачык. Бу тар, шыксыз бүлмәгә керәләр-чыгалар, утыралар, гапләшәләр, тәмәке тарталар, хуҗадан рөхсәт сорау-ниту юк, һәркем бирedә үзен хөр һәм тулы хокуклы дип саный. Тукай, әгәр кәефе булса, аңгәмәгә катнаша, бизгәге килгән чак икән, аспирин эчеп, йомарланып караватына ята. Инде күңелендә яңа шигырь туса, кеше-кара дип тормый, тәрәзә янына килә дә, язарга керешә. Бик матавыклы, шау-шулы тормыш монда. Хәер, Тукай шундый тормышны гына чын тормыш дип саный да. Юкка гына ул Яңа бистәдәге Вахит мәзиннең тын, иркен өеннән китеп, янадан үзенең «Болгар»ына кайтмады ич.

«Болгар» номерында ул бүген япа-ялгызы, кәефе әйбәт түгел. Җитмәсә әле генә кулына килеп эләккән «Чүкеч» журналы тагы... Оренбургта чыга торган бу көлке журналы Тукайга карата нинди генә мыскыллаулар язып бастырмады инде. Әле бу соңгы санда да аны тәнкыйтьләп чыкканнар.

Габдулла укыды, башта авторның тозсызлыгыннан, мәгънәсезлегеннән көлде, журналны атып бәрде. Ләкин шулай да рәнҗү, хәтер калудан котыла алмады. Авыр тойгы күңеленә кан төере булып урнашты.

Ул, кулларын кушырып, гасабиланып, бүлмә буенча әрле-бирле йөренгәләргә тотынды. Аннан караватына барып утырды, берәз тынычлангандай булды. Моннан соң ул дошманнарының мыскылларыннан үзен өстен санап, аларны санга сукмаганлыгын ачык сиздереп, игътибарсызлык күрсәтергә булды. Хәтта ул үзенең әдәби дошманнарына каршы язган «Җавап» шигырен дә дөньяга чыгармаска булды.

Әйе, Тукай үзен дошманнарыннан өстен куйды. Ләкин аның тиз яраланучан күңеле шулай да вакыты-вакыты белән бик каты сыкрана иде. Исхак Байчурин шагыйрьнең бүлмәсенә килеп кергәндә, Тукайның шундый авыр бер вакыты иде.

— Исәнмесез, Тукай әфәнде сез буласызмы? — диде егет.

Тукай, иң әвәл, егетнең маңгаендагы ике тиенлек бакыр зурлыгындагы күгелҗем миңенә игътибар итте.

— Без булабыз Тукай әфәнде. Миңлебай энем.

— Юк шул.— Исхак мин, Миңлебай түгел.

— Ярый,— диде Тукай.— безгә Исхак дигән исем дә ошый. Узыгыз, сезне ни йомыш минем хәҗрәмә китерде?

Исхак, каушаудан тәмам хәлсезләнеп, тиз генә өстәл янындагы утыргычка таба ашыкты. Кесәсеннән ашыгып язулы кәгазьләр чыгарды.

— Мин сезнең фатихагызны алырга килгән идем, Габдулла әфәнде. Минем фикеремчә: татарда сездән дә бөегрәк шагыйрь юк. Мин дә шигырьләр язарга мөбтәля[1], тик мин белмим, барып чыккан микән алар. Сезгә күрсәтмәкче идем, башта.

Тукай, пинжәген иңбашына салган килеш, хөкемне түземсезлек белән көткән Исхак янына килде, кулъязмаларны алды. Кашларын җыерган хәлдә шактый вакыт укып торганнан соң, егеткә ягымлы бер караш ташлады.

— Бик тырышсагыз, Миңлебай...

— Миңлебай түгел — Исхак.

— Әйе, Исхак... сездән шагыйрь чыгу ихтималы юк түгел.

— Рәхмәт, Габдулла әфәнде. Мин бик тырышып язармын. Тик зинһар мина сездән өйрәнергә, сезнең белән аралашырга рөхсәт итегез.

— Минем хөҗрәмнең ишеге нәге теләк белән килүче һәркем өчен ачык, Исхак.

Тукай егеткә шигырь нинди булырга тиешлеге турында сөйли башлады.

## 29

Гаиләдәге мөнәсәбәтләр көннән-көн катлаулануга карамастан, Хөсәеннең шәхси тормышын гына уйлап яшәүгә мөмкинлеге юк иде. Илдә башланган һәм Казанда да канатын җәйгән революцион күтәрелеш, аңардан бөтен булган көчен шуңа багышлауны таләп итте. Казан большевиклары Казан РСДРП комитетын яңадан аякка бастыру өчен нык-лап көрәш башладылар. Ирекtәге партия оешмасы членнары тарафыннан эшчеләр белән бәйләнеш көчәйтелде, кулга алынган Казан большевикларының житәкчесе Лотов өчен акча җыюны да хәл иттеләр. Крестовников заводы слесаре Шеваров ничек итсә итте, мәгәр заводта большевистик оешма булдырды. Шундый ук группалар Свешников, Алафузов, Дары заводларында да дөньяга килде. Су юлы оешмасындагы иптәшләр революцион әдәбиятны Идел буе шәһәрләренә таратуны тәэмин иттеләр. Большевиклар алдынгы карашлы укытучылар һәм төрмәләрдән котылып кайткан крестьяннар аша авылларда, өязләрдә революцион әдәбият таратырга керештеләр, каникул вакытларында өйгә

[1] Мөбтәля — дучар булучы.

кайтучы урта һәм югары мәктәп укучылары авылларга прокламацияләр тарата торган булдылар. Нинди генә каты чаралар күрелмәсен, Казан эшчеләре Беренче май бәйрәмен иттеләр. Казаннан ерак түгел, хәрби лагерь тирәсендәге урманда кызыл комачларга «Яшәсен Беренче Май» дигән лозунглар эленде. Бишенче ел көрәшләрендә шәһит киткән кешеләрнең каберләрен дә онытмадылар, аларның өстенә «Мәңге истә сез. Җәлладларга ләгънәт яусын!» дигән язулар куйдылар.

Эш ташлаулар завод-фабрикаларда көчәйгәннән-көчәя торды. Казан студентлары да активлашты. Алар гомуми җыелышлар җыеп, анда карагруһчы Пурешкевичның Думадагы речен тикшерүне таләп иттеләр. Рөхсәт булмады. Университет студентларының чыгышлары шул дәрәҗәгә җитте ки, ректор тәртип урнаштыру өчен полициягә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булды. 1911 елның 3 февралендә университетта гомуми сходка оештырылды. Анда мең ярымнан артык студент катнашкан иде. Җыелыш булган тәртипләргә каршы баш күтәрергә дигән карар чыгарды. Комитет унынчы февральдә провокаторларны һәм студентлар арасына оялаган полиция кешеләрен фаш итеп, воззвание басып чыгарды. Февраль башларында ветеринарный институтта да чуалышлар башланды. Сигезенче февральдә аның уку залында гектографта басылган өндәмәләр пәйда булды. Алар һәр өстәлдә табылды. Аларны студентлар хәрәкәтенең коалицион комитеты бастырган иде. Студентлар хәрәкәтен оештыручылар арасында Хөсәен Ямашев та бар иде.

Парижда Ленин катнашында чыга торган «Рабочая газета» ул көннәрдә Казан студентлары турында «Студентлар баш күтәрә» дип язып чыкты.

Саратовта әле һаман «Урал» эшен тикшерү дәвам итә, шуңа күрә Хөсәенгә бик уйлап, сак хәрәкәт итәргә туры килә. Заводлардагы татар эшчеләре белән элемтә, татар иҗат интеллигенциясе арасында эш, студент түгәрәкләре, уку — боларның барысын да берьюлы алып бару Хөсәенгә җиңел түгел иде.

Вакыт тукталып тормады. Көз үтте, көз артыннан кыш килде. Унберенче елның декабре кискен ачы суыклар белән башланды. Ләкин һава нинди генә булмасын, башкарылырга тиешле эш, Хөсәен фикеренчә, кичектерелә алмый. Бүген ул университетта лекция тыңлаганнан соң, Гафурны алдан сөйләшелгән урында очратып, иртәгә буласы түгәрәк утырышы урынын билгеләргә тиеш. Аннан соң Шәрифулла абзыйны күреп, татар эшчеләр түгәрәгенең кайчан һәм кайда булачагын анькларга, ә аннан инде «Казан мөхбире» газетасындагы соңгы материалларга карата үзенең протестын белдерергә, Галиәсгарне күрергә, әгәр җае туры килсә, Тукай бүлмәсенә кереп шагыйрьнең хәлен белеп чыгарга тиеш. Бары шуннан соң гына ул үзенең тау башындагы котсыз квартирына кайта ала.

Хөсәен, Учительскаяда укыган чактагы сыман, дәфтәрләрен чалбар каешына кыстырды да пальтосын бик әйбәтләп төймәләп урамга чыкты. Ач салкын җил шундук аның үпкәсенә кадалгандай булды. Үпкәне сакларга кирәк иде. Әле җиденче елны ук, Хөсәен күп шәһәрләр гизеп «Урал» газетасын чыгаруны дәвам итәргә мөмкинлек таба алмыйча Казанга кайтып егылгач, үпкә чире белән бик нык газапланган иде. Әгәр, партиядәге иптәшләре ярдәм итеп, кымызга, аннан коньякка, диңгез буена җибәреп кайтармасалар, тәгаен, гомере өзелгән булыр иде аның. Көрәсен, нык ихтыяр көче һәм яшәячәгенә ышаныч Хөсәенне ул вакыт үлемнән саклап кала алды. Ләкин үпкә тагы бирешә башлады, авыру бу юлы да көчәйсә, ничә еллардан бирле хыялланып та, ниһаять, максатка ирешелгән уку өзелеп калачак. Юк, юк. Хөсәен моңа юл куймаска тиеш! Ул, пальто якасын күтәреп, шарфын муенына кысыбрак

бәйләде. «Бирешмәбез,— диде үз-үзен тынычландырып,— моннан хәтәррәкләренә дә бирешмәдек бит әле».

Пассаж эче халык белән тулы: ике яклап тезелгән кибет ишекләре бер ачыла, бер ябыла, сәүдәләр кызу бара. Гафур Хөсәенне күптән күтә иде инде. Аның мимикага фәкыйрь йөзендә моңарчы күренмәгән аерата көчле борчылу чалымнары бар иде. Хөсәен дустының зур кулын кысып:

— Ни булды?— дип сорады.

— Юк, әйтерлек бер ни дә юк. Түгәрәк утырышын Шәмсия апаларда уздырырга кирәк дигән фикергә киленде...

Шәмсия Гафурның туган апасы иде. Алар Екатерининский урамында торалар. Өйләре хәзергә тыныч урында, хуҗалар ышанычлы. Бу өйдә моңарчы да берничә тапкыр яшерен җыелышлар тыныч кына узган иде.

— Ярар,— диде Хөсәен.— Ләкин дустының йөзеннән борчылу һаман китмәгән иде әле. Димәк тагы нидер бар.

— «Койрык» юкмы? Әйдә, кибетләрдән бер әйләник, миңа подтяжка кирәк иде.

— «Койрык» юк әлегә, мин аларны әллә каян сизәм,— диде Гафур. Алар ашыкмыйча гына галантерея товарлары кибетенә киттеләр.

— Менә нәрсә,— диде Гафур прилавкадагы товарларны караган арада.— Кичә минем өйгә Фәрхетдин килеп чыкты, ул сиңа барырга кыймаган. Егет тик ятмый икән. Күпер салучылар белән эшне шактый яхшы көйләгәннәр.

— Беләм мин аны,— диде Хөсәен.— Фәрхетдиннең үзеннән ишетеп түгел, башкалардан ишетеп. Коточкыч шартларда яшиләр бит. Аерата кессондагылар. Унике сәгать эш көне, көненә бер сум егерме тиен эш хакы.

— Су астында, тынчу һавада,— дип өстәде Гафур.

— Романовлар династиясенең өч йөз еллыгына Идел аша күпер өлгерергә тиеш бит. Шуңа күрә акчаны «җәлләмиләрдер»,— дип куйды Хөсәен ирония белән.— Ә Фәрхетдиннең Гыйззәтулласы белән эш ничегрәк тора икән?

— Һаман искечә,— диде Гафур күңелсезләнә төшеп,— баланы Фәрхетдингә бирмәскә исәпләре. Бала асрау өчен мин күпме расходландым дип әйтә ди теге бәндә.

— Ә суд?

— Судның ни икәнен үзең беләсең инде...

Шактый вакыт алар, шулай сөйләшә-сөйләшә, кибетләрне әйләнгән булдылар. Хөсәенгә подтяжка сайлап та, яраклысын таба алмыйча, уртада фонтан торган коридорга чыктылар. Таш фәрештәнең чүлмәктән су агызып, гөнаһлы адәм баласын юганын карый-карый тагы бераз гәпләшеп алдылар.

Хөсәен дустының нинди дер кичерешләре барлыгын, ләкин әле һаман әйтер сүзен яшереп калырга тырышуын сизенә иде. Ул сүз арасында Гафурның кылларын тартып карады.

— Я, тагы ниләр бар соң?— диде.— Син үз тормышың турында берни дә әйтмәдең бит әле.

— Шушы көннәрдә Суфия, доктор исеме алып, Петербурдан кайтып төшәчәк.

Хөсәен, ихтыярсыздан, Гафурның үзенә текәлгән зур кара күзләренә карап алды. Ул күзләрдә шом сизелә иде. «Ә, менә нидә икән борчылуга сәбәп» дип уйлап алды Хөсәен. Суфияның Хөсәенгә булган мәхәббәте өчен Гафурның хафада яшәвен әлек тә сизенә иде ул. Көлемсерәп Гафурга текәлде, берни дә аңламагандай, елмаеп:

— Бик әйбәт, Суфияны батырлыгы өчен чын күңелдән тәбрик итәргә кирәк,— диде.— Минем Хәдичә дә озакламый теш врачы булып чыгачак.

— Шулай анысы,— диде Гафур, сүзен дәвам итәргә кыймыйча тамак кыргалап алды.— Шулай анысы...

Хөсәен шаркылдап көлеп җибәрде, кулын Гафурның иңбашына салды.

— Борчылма, җанкисәгем, күңелеңне нинди кортлар кимергәнен беләм. Барысы да нәкъ син теләгәнчә булачак.

Гафур бер сүз дә дәшмәде, бары аскарак карап, тамагын гына кыргалады.

— Яхшы,— диде Хөсәен житдиләнеп,— миңа хәзер Шәрифулла абзыйларга барырга кирәк, без аның белән...

Хөсәен, извозчик яллыйк та бергә барырбыз, димәкче иде. Ләкин Гафур аны туктатты.

— Кирәкми,— диде,— анда барып йөрүнең хаҗәте юк, чөнки мин Шәрифулла абзыйны бүген иртә белән очраттым.

Гафур элемтәче картның әйткәннәрен түкми-чәчми Хөсәенгә җиткерде.

*Дәвамы киләсе санда*

## Нури Арсланов

### Дүрт атым

Умырзая сагышлары сулап,
Эреп бетте кар да.
Тарпып [1] басты яшел яллы порак [2],
Уйнаклады алда.
Тар булгандыр чая яз атына
Салкын кыш абзары.
Төшеп куна яшел канатына
Инде кыр казлары.
Мин шул атта хыял тотмак булам, —
Тылсым иле монда!
Бөтен тирә-ягым яшел томан,
Серле миңа дөнья.

Алма үскән, җиләк пешкән чакның
Иртәләре чыклы.
Ал япмасы алмачуар атның
Комач-кызыл чуклы.
Ул кояшның утлы тәгәрмәчен
Тартып күккә аша,
Якут тояклардан ата яшен, —
Болытларга баса.
Ялкын яллы алмачуар атка
Мендем мин ир-егет,
Алда дүрт юл, юнәлгән дүрт якка,
Сайла үзең белеп.

Аркасына көзге уңыш арткан,
Сыгылмалы билләр!
Тояклары алтын сары аттан
Тамып тора тирләр.
Ак күбектә сары атның савыры,
Күтәрелә парлар;
Бөтен дөнья гәрәбәдәй сары —
Тулып ташкан амбар.
Алтынияр салып, сикереп мендем
Алтын яллы атка,
Карап туймыйм илнең иминлеген,
Күңел уяу, сакта.

---

[1] Үрә басу.
[2] Канатлы ат.

Елның дүрт фаслыдай гомернең дә
Бар дүрт аргамагы:
Дүртенчесе — ял-койрыгы бөдрә,
Кырау төсле агы.
Көмеш тояк, көмеш авызлыклы,
«Кыш» исемле ул ат.
Кичеп үткән барлык авырлыкны,
Атлый салкын сулап...
Бәллүр боздан ияре ул «Кыш»ның,
Мин атландым менеп:
Көрәшләрдә дүрт ат алыштырдым
Кули-Чурлар [1] кебек.

Сиксән яшьлек батыр Кули-Чурга
Кемнәр куәт биргән:
Өч ат егылып яуда, акбуз юрга
Дүртенчегә килгән!..
Гомернең дүрт вакыты атта үткән,
Яуда үлем тапкан...
Мең ел инде... булса да бик күптән,
Даны безгә кайткан.
Мин сокланып яшим шул язмышка —
Ерак узганнарга:
Чал атымда чабам зур ярышта,
Көмеш бураннарда!

*1981*

## Тынычлык кошы

*Бөек Ватан сугышы башланганга кырык ел тулуга*

Күгәрчен гөрли балконда,
И шуның гөрләүләре! —
Хәтерлим сугыш хакында,
Окопта күргәннәрне...

Үзара килешкән кебек,
Атышлар тынган иде.
Шунда бер күгәрчен килеп
Түбәгә кунган иде.
И гөрләде түбәдәге
Күгәрчен безгә карап,
Арлы-бирле йөргәләде,
Баш иде кабат-кабат.
Солдатлар тынычлык кошын
Тын алмый тыңладылар:
Берәүләр Ватан сугышы
Бетүгә юрадылар.
Берәүләр диде: — Бүген дә
Исән калырга булсын,
Шатлыклар тулсын күңелгә —
Хатлар алырга булсын...

Кинәт дошман һөҗүм итте.
Ут ачты ике як та.
Тик гайрәтләре тиз бетте —
Кабат чиктеләр артка.
Тагын тын. Тагын күпмегә
Үлемне кире кактык!?.
Теге күгәрченнең генә
Гәүдәсен үле таптык...
Каты диләр солдат күңеле,
Юк сүзме, әллә чынмы?
Ләкин күзгә яшьләр килде
Кызганып күгәрченне...

Күгәрчен гөрли балконда,
Уятып узганнарны.
Тузмасын иде атомга
Һәлакәт тузаннары...

*1981*

---

[1] Атаклы полководец, төрки халыклар батыры.

## Балтик буенда

Бу якның да күге зәңгәр икән,
Бүген таңда күреп ышандым.
Алтын кояш башы күккә тигән —
Шатлыгыннан җәйгән кочагын.

Юкса көнен-төнен тоташ болыт
Кара шәлен җилкән иттереп,
Күкнең зәмрүд гөмбәзенә тулып,
Йөргән иде яңгыр сиптереп.

Дөнья гизеп кайларга гына барма,
Бездәгегә охшаш күк төсе,
Ае да шул, шул ук йолдызлар да...
Тик бәхетле түгел күп кеше.

Сугыш дигән өрәк кулын суза,
Куләгәсен ташлап илләргә.
Шиккә төшеп, каушап гомер уза,
Тимер кием киеп иңнәргә...

Дөнья зәңгәр оя булсын дисәң,
Кояш булсын дисәң учагы:
Кешеләрнең башы күккә тисен,
Иминлеккә тулсын кочагы!

Бу теләгем ашсын иде чынга —
Охшап күкнең аяз чагына!
Нурлы таңда шуңа борчуым да,
Шатлыгым да бергә чагыла...

*1981*

## Туфан булып

Олы җанлы иде: кинә, үпкә,
Рәнҗешләрне истән чыгарды.
Еллар үтә, заманалар үтә, —
Ил онытмый андый чыдамны!

Иҗат шатлыклары кичерсә дә,
Борчулары булды тау кадәр:
Илһам аңа ширбәт эчерсә дә,
Агу бирде кайбер бәндәләр.

«Кер чайкыйлар кызлар...» аның төслә
Җиң сызганып, бозлы суларда, —
Җиңәр өчен кыргый, тупас көчне,
Матур яшәп, рәхәт суларга.

Гомере үтте тормыш керен чайкап.
Пакьләр өчен күңелен купләрнен,

Шигъриятне кылыч итте айкап,
Калкан итте кайнар күкрәген.

Сүнде безнең прометейнең күзе,
Ә ялкыны калды янарга:
Очкыннарын сибәр шагыйрь сүзе,
Җан җылысы сулый аларда.

Арабыздан «соңгы мамонт» китте,
Ни әмәл бар уфтан-уфтанма!..
Туфан булып шагыйрь гомер итте,
Шигърияте ташты туфанга!

*1981*

## Үзем генә беләм

Исән кайттым сугышлардан,
Озаткан, я көтеп алган
Булмагангадыр, белмиләр:
Син ветеранмыни? диләр.

Эчтән көеп, тыштан көлеп
Йөри торгач җиткән килеп
Җитмешем, шуны белмиләр:
Син шулай картмыни? диләр.

Күңелләрдән күчә-күчә
Сүзләр кәгазьләргә төшә:
Теләмәгәннәр белмиләр,
Ә белгәннәр: Шагыйрь! диләр.

Белмәгәннәргә шаккатмыйм,
Мин кем! диеп түш тә какмыйм,
Хәтер бирсен түземлегә, —
Барысын беләм үзем генә...

*1981*

## Сарай

*«Дан орден»нарының тулы кавалеры*
*мәрхүм Рөстәм Халитовка багышлыйм*

Сарай салмак булды бакчасында
Башкалардай ул да:
Теләкләре әверелмәде чынга —
Калды ярты юлда.
Ирешми шул кеше теләгенә
Язмыш усал көлсә:
Йөрмәс иде Рөстәм бер дә генә
Болай булырын белсә...

Батыр булган, дәһшәтләрне үткән,
Тир, яшь тозын таткан...
Ул инанган — җиңү өмет иткән,
Җиңеп исән кайткан.
Ул инанган безнең бабайларның
Үлмәс йоласына:
Хәрабәдән яңа сарайларның
Үсеп чыгасына.

Сөйли иде безгә төрле хәлләр:
Яуда алышканын,
Солдат булып киләчәккә мәрмәр
Сарай салышканын.
Шул төзелешкә карап, башкалардай,
Ул бик горурланды.
Ә «Идел»[1]дә гади такта сарай
Төгәлләнми калды...
Эшкәртмәгән бакча урыны боек,
Сарай моңсу, үксез.
Гүя минем бер канатым сынык:
Күрше идек бит без...

*1981*

## Спутникка карап

Күп йолдызлар арасыннан үтте
Бер спутник, бизәп күгемне:
Соклandырып бер бәхетле итте,
Бер каушатты тыныч күңелне...

Кеше акылы, космос серен ачтың,
Бар табигать сиңа буйсына!
Хикмәтеңдә син күкләргә аштың,
Күпләр тели изге юл сиңа.

Тик изге юл! Ә син шул теләкне
Аклар өчен хезмәт ит иден,
Саклап кояш сүрелгәнгә хәтле
Кешелекнең имин, шат илен.

*1981*

## Диңгез якасында

Кыланасың, диңгез, кыланасың,
Бу кадәрле ник дулкынланасың?

Исем китми сиңа карап бер дә:
Дулкынландырмагач мине бергә.

Күпме генә атылып-бәрелсәң дә,
Дәү булсаң да, син кызганыч хәлдә.

[1] «Идел» — бакчачылык җәмгыяте исеме.

Җилләр китә болытларны куып,
Син каласың һаман ярда шуып.

Яткан җирдән торып киталмыйсың,
Йолдызларга менеп җиталмыйсың.

Нинди мәгънә ташып-кайнавыңнан —
Дулкын атып, чуер кайравыңнан?!

Соры сагыш шуңа төсләреңдә;
Акчарлаклар көлә өсләреңдә...

*1981*

## Томанда

Томан, томан, томана,
Томаласаң томала!
Киң булса да колачың
Кыланып ни кырасың?
Тиңләшмәссең тиңсезгә —
Әверелмәссең диңгезгә,
Утлы кояш күзендә
Юкка чыгар эзең дә.

Ә минем — кояш күргәч —
Шатлыктан йөзем көләч:
Аяз итче таңнарым,
Таралсын томаннарым.

*1980*

## Болытлы төндә

Ертык болытларның арасыннан
Ай бакчама тели карарга;
Үзен тоя зур яктырткыч сыман,
Ә охшаш тик бакыр табага.

Кеше дә бит үзен зурга саный,
Аннан башка дөнья юк сыман...
Ә мин — дәрвиш beләм! Дөнья фани,
Һәм үземне үзем юксынам.

*1981*

## Су-сылу

Бер якта нарат урманы —
Зәңгәр күләгә.
Тынлыкта диңгез буйлары.
Сүрелгән шәфәкъ нурлары, —
Офык күгәрә.
Хисапсыз йолдызлар сипкән
Моңлы сары ай.
Бик тирәндә, төптә микән,
Су-сылулар гомер иткән
Гәрәбә сарай?

Бер кытыкланса — чын бала
Бит кызыксыну:
Сараеннан чыккан анә,
Җир матурлыгын күрмәгә,
Өскә су-сылу.

Чәче диңгез төсле соры,
Алма күкрәкле,
Карашлары тирән, серле,
Тәне тәңкә-тәңкә сырлы,—
Көмеш күлмәкле...

Чү, җилсез дулкынлы суның
Ак ялларында
Йөзеп чыккан су-сылуым
Кинәт үзгәртте бит сыйын
Күз алларымда.

Хыял бетте... Менә алда
Җир кызы туды:
Ул атлап китте тын ярга,
Ерак түгел эскәмиягә
Барып утырды.

Бер карап алды матурым
Елмаеп кына;
Булмасаң да су-сылуым,
Сиңа карап алдануым
Үзе ни тора!

*1981*

## Чытык җәйдә

Тып-тын. Тузгып төшкән толымнары,
Болыт кызы түгә яшьләрен,—
Бөтен дөньям тынычлыкка талды,
Оныткандай күкрәп-яшьнәвен.

Киләчәгем килеп җиткән инде,
Узганнарны сагынып файда юк:
Кайберәүләр өчен күптән инде
Мин исәпкә бар тик, санга юк.

Шәүкәтледән шәфкать үтенмәдем,
Хәер сорамадым алардан:
Яшәгәнем өчен үкенмәмен
Шулай горур китсәм арадан.

*1980*

## Күршең белә

«Күршеңнән сора хәлеңне»,—
Күршеләр әйтмәс ниләр:
«Үзеңнең кем икәнеңне
Син бит белмисең!» диләр.

Ник аңа бик исегез киткән,
Бер дә бит гаҗәп түгел,—
Минe сез белгәч шул җиткән,
Башкасы хаҗәт түгел.

Үзең турында белмәүдән,
Шулай да, бер файда юк;
Булмаса ни, андый хәлдән,
Шулай ук, зыян да юк!

*1981*

Альберт Хәсәнов

# АВЫР МИССИЯ

хикәя



Дәүли агай билетны Норлат ягына узучы скорыйга алды. Аның бер иңбашында калын бәз сүрү эченә төреп тыккан байрак. Кулында үзе белән буровойга алып йөри торган кечерәк кенә соры чемодан. Агайның кәефе яхшы, йөзе җиз самовар төсле балкый. Аның Норлатка, үзләре белән ярышучы бригадага байрак илтә барышы.

Юл йөрүне, җае чыкканда бераз дөнья гизеп, чит җирләр, яңа йөзләр күреп кайтуны кем яратмый инде аны, егетләр. Агайның да бу сәфәре күктән көткәнне җирдән бирде дигәндәй килеп чыкты бит әле. Аңа менә шундый зур йомыш йөкләделәр. Ләкин шунысы гаҗәп, өйдәгеләр генә аңламадылар аны. Агайның бу сәфәргә чыгуына аяк терәп каршы булдылар. Барыннан бигрәк Кара кашы, нечкә билле прәннеге, нурлы Нуриясе инде, әлбәттә.

— Алырга булсамы?! Барлыгыңны да белмәсләр, исләренә дә бер кертеп чыгармаслар иде. Ә менә илтергә булгач, син тилене йөртәләр. Йөрмәсәңче, атасы, кеше көлдереп, дәрәҗәңне төшереп,— дип картының бу сәфәргә чыгуына Нурия җиңгәй башы-аягы белән каршы булды.

— И нечкә билле прәннегем, мондый ситуацияләрдә син нәрсә понимаешь, я! — дип агай үзенекен исбатлады. — Килде-китте генә эш белән йөрмим бит. Байрак илтәм! Күпләргә гомер эчендә бер тәтеми торган дәүләт күләм важный йомыш!

Дәүли агай мондый акыллы сүзләрне буровойдан, мастерлары Җиһаншин авызыннан ишетеп кайта. Ә хәтере аның киптергеч кәгазь кебек, мастерлары авызыннан чыккан шундый сүзләрне күңеленә сеңдереп кенә тора. Ә кирәк чакта пәч иттереп үзе дә бик урынлы куллана.

— Понимаешь син, миңа почетлы миссия тапшырдылар. Беләсең килсә, мин хәзер «миссионер»! Әгәр бик телисең икән, әйдә, үзең дә җыен. Юл уңае бит, бер җәһәттән баҗаларга да сугылырбыз, безнең аларда булганыбыз юк.

Дәүли агайның нурлы Нуриясе бу турыда тагын да сүз куертуның файдасыз булуын күрепме, ничектер кайта төште.

— Ике аягымның берсен дә атлыйсым юк. Үзең хет теләсәң нишлә. Күрәселәрең, адәм хурына каласыларың бардыр, шуңа җилкенүеңдер,— дип өстәлгә тегү машинасы алып куйды. Кич утырып, ике-өч мендәр тышын бер итеп, сүрү текте. Ходай сакласын, байрак хәтле бай-

ракны юлда пычратса. Кадак-мазарга элэктереп ертса, акланырга сүзен, бирергэ җавабын таба алмассың. Дәүли агайның алтынчы класста укыган төпчек игезәкләре Рамил белән Камил байракны әйләндереп-әйләндереп карадылар да нидер пышын-пышын килештеләр. Аннары зур сер чишкәндәй итеп:

— Әткәй, беләсеңме нәрсә? Син бу байракны күлмәк астыннан ура,— диделәр. Игезәкләрнең сүзен Нурия җиңги дә хуплады.

— Чынлап, аталары, хөкүмәт әйберсе дисәм генә аз булыр. Байрак бит, Кызыл Байрак! Тегендә куеп, монда калдырып югалтсаң, нишләрбез. Тыңла акыллы киңәшебезне. Әллә чынлап, мәйтәм, күкрәгеңә урыйсыңмы? Безнең дә җаныбыз тыныч булыр.

— Китегезче! Сез инде бигрәк тагын! — агай кулын гына селекте.— Мин бит аны дошман тылыннан алып чыкмыйм. Норлаттан күп булса ун-унбиш чакрымнар ераклыктагы бер авыл янындагы бораулау бригадасына тапшырам да кайтам. Биш ел буе бездә торды. Үзебез белән буровойдан буровойга йөрттек. Берни дә булмады. Бу юлы да берни булмас. Аннары әле шунысы да бар бит, энекәйләре. Кызыл Байрак күтәреп бару безнең кебек кешегә үзенә бер пачут. Монысын да понимайт надо!

— Пачуты пачуттыр да, ул-бу хәлгә тарый күрмә, хәвеф-хәтәргә юлыкма, диюебез ләбаса.

Агаебыз яшисе гомеренең инде байтагын яшәгән, чәчен бәс сарган, эре сөякле, туры холыклы, күрер күзгә күркәм генә ир уртасы. Тормыш йөген яннан гына түгел, бик яшьлидән төп тәртәгә җигелеп тартып килә. Менә элеге миссияне башкарырга да, бер уңайдан берәз кеше арасында булып, аралашып, дөнья күреп кайтыйм дип, риза булды. Чөнки соңгы ике-өч ел эчендә аларның тормышы диетиклар өстәленә куелган аш сыман гел бертөрлегә әйләнеп бара: буровой да өй, өй дә буровой. Әлегрәк исә аларны, я шунда социалистик ярышка йомгак ясаргамы, я күршеләрдәге алдынгы тәҗрибәне өйрәнергә дипме, Куйбышев, Краснодар, Төмән өлкәләренә хәтле җибәрәләр иде. Күршеләрең белән йөрешеп, кул биреп күрешеп, булган тәҗрибәң белән уртаклашып тору бик кирәк нәрсә югыйсә. Менә бит әле үзләреңдә генә нәрсә килеп чыкты. Алай начар да эшләмәгән төсле иделәр. Көнлек норманы һәрчак үтәп, айлык планнарын метрга метр тутырып бардылар. Ә менә күршеләре алардан да уздырган. Байракны алар яулагач, шулай булып чыга бит инде. Ничек, кай яклап, нинди яңа алымнар кулланып алга чыкканнар? Аны белгән, кызыксынган кеше дә юк. Мастер Җиһаншин үзе дә аптырашта.

— Менә шул-шул. Йөрешмәү, бер-береңбелән аралашмау галәмәте бу,— дип уйлап куйды агай.

Билетны купелы вагонга алды ул. Хәер, агайның күкрәгендә балкыган медальләрен, Почет билгесе орденын күргәч, кассир кыз сорашып та тормады, аңа билетны купелы вагонга язды. Агай моңа күңеле булып: «Хезмәт кешесенең пачуты кайда да зур шул»,— дип, канәгатьләнү белән уйлап алды.

Ул арада поезд да килеп җитте. Агай үз вагонын чамалап тамбурга күтәрелде. Купега кереп урнашты. Агайның юлдашлары ерактан ук киләләр булса кирәк. Араларына бөтен йөзе белән балкып килеп кергән Дәүли агайга игътибар да итеп тормадылар. Башларын да күтәрми пәч тә пәч карта сугуларын гына белделәр. Араларыннан тик берсе генә урыныннан күтәрелеп:

— Әһә, агай, молодец, келәмнең бик затлысын эләктергән, ахры. Каян алдыгыз? Кыйбат торамы? Үзебезнекеме, әллә импортмы? — дип, аңа әйберләрен өске шүрлеккә куярга булышты.

— Келәм, ди сиңа! — дип мыгырданды агай рәнҗү белән. — Әллә мине берәр спекулянт калдыгы дип белделәрме? Андый нәрсәләргә мөкиббән китүчеләр түгел без, энем. Ә кирәксә, келәмнәрнең персидскиләрен дә өебезгә китереп бирәләр. Зурлап, олылап, бүләк итеп. Җиңнәребезне беләктән югары сызганып, тәртәгә җигелеп эшләгән өчен.

Кеше дигәнең кызык кына бит ул. Шул юк кына сүздән агайның кәефе кырылды да китте. «Соңгы вакытта черки урынына үрчеде бер вак халык,— дип сукранды ул эченнән,— бер-берсе белән узышып башларын мал җыюга салдылар». Болары инде, аларның мастерлары Җиһаншин әйтмешли, чыннан да, мещанлык коллары. Дәүли агайның исә бу өлкәдә үз фәлсәфәсе, үз кыйбласы. Бер кат кияреңә бармы? Бар. Утырыр-ятар җиреңбармы? Бар. Балаларыңны кеше төсле тәрбиялисеңме, укытасыңмы? Тәрбиялисең, укытасың. Шулай булгач, тагын ни җитмәгән? Ә нәфес дигән комсыз нәрсә кемдә дә бар. Ләкин бит аны тыя белергә кирәк. Юкса, ул сине үзенең гомерлек колы итәргә дә күп сорамас. Әле менә хәзер дә бит, сорау юк, танышу юк. Агай келәмнең затлысын эләктергән, имеш. Юк, ялгышасыз, Дәүли абзагыз бу сәфәргә мал җыярга чыкмады ул.

Бу кешеләр аңа кергә керешкә үк ошамадылар. Вагон бит ул рәхәтләнеп гәпләшеп, бер-береңне тәмле сүзләр белән сыйлап, яшьлектә, гомер эчендә баштан узган гыйбрәтле хәлләрне искә алып бару урыны. Ә боларңы күр! Муеннарында куш йодрык хәтле төенле галстуклар. Түшләрендә вуз бетергәнлеккә «калкавычлар». Инженерлар булып чыга ич инде болар. Һич тә килешми югыйсә үзләренә карта сугып бару. Күрмәгән, уйнамаган нәрсәләре мени. Бу бит, төптәнрәк уйлап карасаң, аны — бораулау остасы Дәүли агайны — санга сукмау дигән сүз. Шунда уеннарыннан арынып бер сүз генә катсыннар. Агай кояштай балкып ачылып китәчәк. Үзенең кем булуын, кай якларга сәфәр тотуын сөйләп җибәрәчәк. Үз нәүбәтендә, артык тирәннән төпченмичә, аларның кем булуларын, кая баруларын, кай якларны гизеп кайтуларын сораштырыр. Гәп бит ул шулай куера. Ат кешнәшеп, адәм баласы сөйләшеп таныша.

Менә аларның бригадасында ул яктан җан рәхәте ичмасам. Шул бер үк егетләр: мастерлары Җиһаншин, верховой Әгъзәм, помбур Сәет. Буровой сукмагын ничә еллар рәттән бергә таптыйлар. Бер уйласаң, бер-берләренә сөйләр, уртаклашыр нәрсәләре дә калмагандыр кебек. Шулай дип кара егетләргә, бар. Үзеңне шунда ук әвереп ташламагайлары. Вахтаны тәмамлап автобуска утырышып кына алсыннар, аннары гәп китә инде, күпләргә әле чират җитми.

Агай юлдашларын кергә керешкә ошатмаса да, «дипломатик мөнәсәбәтләрне» кисеп кенә өзәргә дә ашыкмады. «Ир кешенең күңеле өстәл артында ачыла», дигән уй килде күңеленә. Өстәл өстенә кыздырган тавык, вак-вак кына тозлы кыярлар, авызыңа үзләре тәгәрәргә торган кызыл помидорлар чыгарды. Термосын алып чәен бутады. Чү, җәмагать! Монысы нәрсә тагын! Чемодан төбендә тагын нидер бар бит. Бу тастымалга төреп тыкканы нәрсә тагын дип караса, күзләре шар булды: нурлы Нурия җиңги картының кеше арасында сер бирергә яратмаганын белә. Вакытлы-вакытсыз рестораннарга сугылып, станция буфетларында йөрмәсен, дигәндер. Чемодан төбенә бер бәләкәй «акбаш» та салган. Тәмам түп-түгәрәк килеп чыккан табынга агай юлдашларын да дәште.

— Бик рәхмәт, абзый. Без сездән алда гына ашап алган идек,—диештеләр тегеләр. Берәр телем кыяр, берәр помидордан гына авыз иттеләр дә, түтәл җимешләренең тәмлелеген, аларны үстергән хуҗаларны мактый-мактый, янәдән үз уеннарына бирелделәр.

Дөрес шул, агай үзе сыйлаганда сыйланучы, сораганда башлап җырлаучы. Әмма гомерендә шушы «акбашның» колы булмады. Әле

менә хәзер дә стакан төбенә генә салып берәр йотым тотты да, калганың бөкеләп, тургәрәк этәрде.

— Исәбегез булса, йокы алдыннан рәхим итәрсез,— диде.— Күрәм, сезнең белән ботка пешмәс, ахры. Алайса, мин дә үз эшемә керешим. Абразив бораулар белән ике-өч кенә вирей катламы бораулап алыйм.

— Нинди борау? Нәрсә бораулларга җыенасыз? — диде, кызып карта уйнаучыларның берсе.

— Анысын инде менә бер биш-алты минуттан күрерсез,— дип, Дәүли агай бораулаучыларга гына хас тән-сөяк җиңеллеге белән өске шүрлеккә менеп утырды. Урын хәстәрләп йокларга җыенды.

Поезд агайны бишектәге бала кебек иркәләп тирбәтсә дә, «вирей катламын бораулларга» алай тиз генә керешеп китә алмады әле ул. Көтүченең дә түшенә көндез үзе йөргән болыннары, матур тугайлары, качкалак сыерлары кереп аптырата, ди. Агайның да күз алдына буровойлары килеп басты. Аның урынына бүген вахтага кем чыкты икән. Мөгаен, алар бригадасына җәйге практикага кайткан студент егет Валерийны билгеләгәннәрдер. Егетләр бүген забойга колонна төшерергә тиешләр иде. Төшерделәрме, торбалары җиттеме икән?

Кичә буровойга мастер килгәндә, төшке ашка утырганнар гына иде. Кашлары җыерылган, чырае сытык Җиһаншин ишектә күренүгә, нидер булганын Дәүли агай шунда ук шәйләп алды. Алай да дәшмәде. Аларның төшке ашка туктаган чаклары гына иде.

— Иптәш мастер, тәмле булсын, дисәңче инде шунда,— диде дә, кашыгын алып тәлинкәсе өстенә иелде.

— Тик шуңа гына мохтаҗ булсагыз, тәмсез ашларыгыз шуның белән генә тәмләнер дисәгез, аннан гына тормабыз, — диде мастер төксе итеп. — Тәмле булсын!

Мастерның дилбегәсе көпчәккә чорналган чагы икәне күренеп тора. Торса соң? Андый чак кемдә булмый. Җиһаншин миләш капкан дип, бөтен бригада авызына балан кабарга тиеш түгел бит инде. Дәүли агай, араларында иң өлкән кеше, сүзне уенгарак күчермәк булды.

— Менә монысы безнеңчә! Әйдә, үзең дә рәхим ит. Аш ул бергәбергә тәмле була.

Әмма мастерлары өстәл артына утырырга ашыкмады әле. Йонлач беләкләрен терсәктән югары сызганып, операциягә әзерләнгән хирург сыман кат-кат сабынлап, бик озаклап юынырга керешге.

Мастерларының сырт йоны җилгә каршы кабарган цкәнен помбур егет Сәер Сәет кенә күрми. Ул кешенең йөзенә гомерендә күтәрелеп карамас. Кешегә төбәлеп торуың синең кемгә хаҗәт, ди ул. Хәйләкәр зат синнән яшерергә теләгән мәкерле уй-фикерләрен барыбер яшерәчәк. Кеше мие төпсез диңгез. Ә кирәк сүзен әйтергә аның теле бар. Шушы Сәет бораулаучылар хәзерли торган профессиональ-техник училище генә тәмамлаган. Ә сөйләшеп китсәң, бу әллә бер-бер профессор-мазармы, диярсең. Белмәгән нәрсәсе юк аның. Әмма, шуңа да карамастан, шул кадәр беркатлы үзе. Дәүли агай аның турында: бу мәхлук җан алда ничек көн күрер, ничек кенә тормыш итәр икән дип, чын-күңеленнән борчылып уйлап куя. Аның беркатлылыгы артык яшьлектән, тормыш ачысын тик китаплардан укып кына татудан килә торгандыр. Сәет әле менә хәзер дә һич урынсызга:

— Гәрәй Исламович, сез үткән киңәшмәдә генә республикабыз нефтьчеләре алдында һәр тонна «кара алтынның» үз кыйммәтен төшерү бурычы тора, дип сөйләгән идегез. Ә менә безнең буровойда ун җиде кешегә бер ашханә. Шуңа махсус ике вагон биләп, бер баш, ике ярдәмче повар тотабыз. Алар бит безгә метрлар бораулларга булышмыйлар. Ә бораулланган метрларның үзкыйммәтен генә арттыралар. Әйтегез өстәге абзыйларга, ашханәне япсыннар. Ә бер шешә сөт белән

бер сынык ипине һәркем өеннән дә алып килә ала, — дип, бөтенләй пүчтәк нәрсә сөйләп утыра. Әле аның шунысы да бар. Башкалар белән бик коры фигыльле Җиһаншин шушы Сәер Сәет белән үзен бөтенләй бүтәнчә тота. Буровойга килү белән иң беренче итеп аның белән күрешә. Эшнең кым-кырыс чагы булмаганда, аңардан кайда яңа вулкан атуын, дөньяда нинди яңа ачышлар булуын, галимнәрнең хәзер нинди проблемалар өстендә баш ватуларын сораштырып утыра. Менә хәзер дә, мондый ахмак тәкъдимнәр белән башка берәү баш катырып утырса, мастерлары аның тетмәсен тетеп, сүгеп ташлаган булыр иде. Ә Сәеткә бу юлы да каты бәрелмәде.

— Синең саулыгың туган илеңә мең тонна нефтьтән дә кыйммәт. Теләсә кайсы вакытта төрле каты-коты ашап ашказаныңны бозсаң, метрлар бораулыйсы урында аптека сукмагын таптый башласаң, синнән ата-анаңа да, туган илеңә дә файда юк, — дип, ак тешләрен ипигә батырды. Теләр-теләмәс кенә ашарга кереште. Бер-ике генә капты да, токмачларын тәлинкә буйлап куып йөртә башлады. Аннары кинәттән генә:

— Ашны авызга алышлы түгел. Тозны капчыгы белән тондырганмы? — диде.

Барысы да сәерсенеп тагын мастерларына төбәлделәр. Биредә баш ватып утырыр җир калмады. Ачык бары да. Мастерларының егетләренә бәйләнәсе, аларның тетмәсен тетеп орышасы, сүгеп ташлыйсы килә. Нигә? Хуҗа кеше, җитәкчеләре ич. Сүгәм дисә сүгәргә, сөям дисә сөяргә хакы бар. Алай да беренче булып кашыгын шапылдатып өстәлгә верховой Әгъзәм куйды, аларның Прәмуй Әгъзәмнәре. Ташаяк тоз савытын кулына алып, әйләндергәләп торды да:

— Шулпага килсәк, иптәш мачтыр, телеңне йотарлык,— диде.— Әгәреңки дә мәгәреңки, безгә притинзияң-мазар бар икән, кыеклап маташма. Давай безгә прямуй наводка белән.

Мастер бригада исеменә нинди үпкә сүзе әйтсә дә, нинди авыр хәбәр җиткерсә дә, төп өлешен үз өстемә алам дигән төсле, Әгъзәм киң күкрәген тагын да киерә төште.

Мастер Җиһаншин байракка ымлады:

— Турысы-кыегы шул. Байрак бездән ту-ту! Аны Норлат бораулаучылары яулаганнар. Бүгеннән аны биредә тотарга безнең хакыбыз юк. Әле бирегә килешли бурком председателе туктатты. Үзегезнекеләрдән берәрсе илтеп тә кайтсын, диде.

— Нигә аны без илтергә тиеш? Җиңгәннәр икән килеп алсыннар.

— Тәртибе шулай. Безгә дә бит китереп биргәннәр иде, җиңеп яулаган байракны эзләп барып алмадык. Кыскасы, байрак кулдан ычкынган. Безнең аны бер генә көн дә тотарга хакыбыз юк. Ул хуҗаларына тапшырылырга тиеш. Я, кайсыгыз илтә?

Башта беренче булып Сәер Сәет чәчрәп чыкты:

— Үзем илтәм!

Күзләрен әлҗе-мөлҗе китереп нидер уйланып торды да, шунда ук баш та тартты. Юк, булмый икән, янәсе. Алда сессияләр тора, аның имтиханнарга хәзерләнәсе бар. Шушы хыялый баш читтән торып Казан университетында укый, тарихчы, археолог булам, дип сөйләнә.

Кулындагы стаканнан вак-вак кына итеп чәй йотып куйганнан соң, Прәмуй Әгъзәм дә телгә килде.

— Байракны мин илтсәм дә була, — дип куйды. Аның артыннан электрик Хафиз, дизелист Костя да теләк белдерделәр. Әмма соңыннан тегесенең теге, монысының бу эше булып чыкты. Байракны җиңүчеләргә илтеп тапшыруны Дәүли агайга йөкләделәр. Йөкләделәр дип инде, әгәр үзе ризалык бирмәсә, аны берәү дә мәҗбүр итә алмаган булыр

иде. Байрак илтү кайчаннан бирле хурлык эшкә, дәрәҗә-абруеңны төшерә торган нәрсәгә әйләнде соң ул әле! Ә Сәет аңа әнә нәрсә диде? Дәүли агай, сиңа бик почетлы миссия йөкләнә. Җиңүчеләргә байрак илтү почетлы сәфәр, почетлы миссия!

...Беләгеннән җиңелчә генә тартканга Дәүли агай дырт итеп сискәнеп уянды. Караса, карта уйнап барган егетләрнең берсе икән.

— Абзыкай, зинһар, вирей дигән катламның бораулаган кадәресе дә житеп тормасмы? Югыйсә, перекурга да туктамыйча тоташтан өченче сәгать дулатасыз бит.

Дәүли агай сәгатенә күз салды. Күр генә, аңа төшәргә дә күп калмый икән, ләбаса. Агай торып, юынып килде, киенде. Юньләп танышырга да өлгермәгән юлдашлары белән һәркайсына кул биреп саубуллашып чыкты. Чал чәчләрнең берсе, аны уятканы, өске шүрлеккә күрсәтеп:

— Келәмегезне онытып калдыра күрмәгез тагын, — диде. Дәүли агай бу юлы түзмәде:

— Аптыратты тәмам. Каян килеп келәм булсын ди ул! Байрак ул. Кызыл Байрак.

— Байрак!? — диештеләр барысы да бер авыздан. Егетләр мендәрләреннән башларын күтәрә төштеләр.

— Әйе, социалистик ярышта җиңеп чыгучыларның кулына бирелә торган Кызыл Байрак. Нигә аңа шул хәтле исегез китте?

Юлдашларның өлкәнрәк күренгәне, күзлеген зур борыны өстенә атландырып, агайга төбәлде:

— Гафу итегез, бик сәер кешегә ошыйсыз сез. Шулай юлда япаялгызы байрак күтәреп йөрүчене беренче тапкыр очратам. Сатып алдыгызмы соң?

— Әллә берәр слет-мазардан, алдынгылар киңәшмәсеннән кайтуыгызмы, шунда тапшырдыларммы? — диде икенчесе.

— Ах, егетләр, тәмам аптыраш сезнең белән, — дип куйды агай, ботына чабып. — Менә мин үзем шушы байракны җиңүчеләргә тапшырырга барам. Ярышта җиңеп чыгучыларга. Биш ел безнең бригадада торды... Хәзер менә...

— Торды да очты инде алайса? — диде арадан яшьрәк күренгәне. — Күңелсез хәл, җәнишне...

«Кара-кара, күр син бу тишек борынны! Чананы нәкъ тау төшкәндә чалулатырга маташа. Игезәкләремнең сүзен тыңлыйсым калган икән. Байракны әйбәтләп кенә әчтән күкрәгемә ураган булсам, ак сакаллы карт буласы икәнмен».

Ул арада поезд әкренли башлады. Теге ачу китергечләргә, сару кайнаткычларга җавапның бик зәһәрен бирергә агайның теле бик кычытса да, өлгерә алмады, төшәргә ашыкты.

Норлатка бик тә вакытсыз, төнге сәгать өчләр тирәсендә генә килеп житте ул. Алай да аптырап калмады. Бу яклар аның өчен гомер аяк басмаган, белмәгән, күрмәгән җирләр түгел. Аларның идарәләрен Ромашкино нефть мәйданына күчергәнгә хәтле үзе дә шушы якларда разведкада эшләп, «кара алтын» ятмалары эзләде. Житмәсә, Норлатның үзендә үк баҗасы да яши аның. И-и, улмы? Дөнья бәясе егет! Аның белән бер күрешүең бер гомер. Килеп кереп бер чынаяк чәй эчәргә өлгермисең, шифоньер башыннан үрелеп кенә уникe телле тальянкасын ала. «Менә, баҗа, син килешкә яңа бер җыр оттым әле» дип, ике тез башына атландырган гармунын биетә генә. Уйнап җибәрсәме? Баҗасының арба кендегедәй юан бармаклары гармун телләрен буйлап, чабышка чыккан юртаклар төсле берсен-берсе узышып йөгерешәләр. Оста уйнавы әле аның бер хәл. Һәр көйне үзенчә чыгарып, синең йөрәгеңә атлан май итеп ягып уйный бит әле ул, каһәр! Молодец та егет инде.

Аннары дөнья хәлләренә күчәләр алар. Апалы-сеңелле җан сөйгәннәренең чибәрлекләрен, уңганлыкларын, нәрсәгә барып тотынсалар да кулларыннан гөл тамып торуын бер-берсенә арттырмый, күпертми макташып, үзләренең дә алай төшеп калганнардан түгел икәнлекләрен раслап, кунак өстәле артында гөр килеп күп тапкырлар утырганнары бар. Агай менә хәзер дә туп-турыдан баҗасына китмәкче булды. Сөендерсен әле шулай һич көтмәгәндә килеп чыгып. Түбәсе күккә тисен. Шунда ук күңелендә шик тә туып куйды. Тышта җиде төн уртасы. Бу вакытта станция тирәсендә кем йөрмәс тә, күрәсеңә каршы, алдыңа кем килеп чыкмас. Агай башта кыю адымнар белән вокзал каршындагы милиция бүлегенә китте.

Яшь кенә кече лейтенант аны башта иренеп кенә тыңлады. Төне буе керфек какмый дежурда утыру җиңел түгел, күрәсең.

— Иптәш кече лейтенант дисәм дә, энекәш дисәм дә үпкәләмәссез. Мине кунак йортына хәтле генә булса да озатырга кеше бирмәссезме, дип кергән идем. Менә бу сүрү эчендә байрак, аны җиңүчеләргә илтә баруым. Төн бит. Станца тирәсендә кем йөрмәс,— Дәүли агай, орден-медальләре күренерлек итеп, җиләнен чишеп җибәрде. Монысын инде гозерен үтемләндерү өчен.— Кунак йортында әллә урын бар, әллә юк. Минем монда бер дигән баҗам яши. Шуңа хәтле озатып куйсагызчы.

Агайның баҗасына алар икәүләп киттеләр. Араларны бераз булса да якынайтып җибәрү өчен агай сүз катуны кирәк тапты.

— Шулай инде, энекәш, дөнья дигәнең катлаулы нәрсә ул,— дип куйды.— Төптән уйлап карасаң, беребезнең дә хезмәте майлы ботка гына түгел. Менә, безне генә алыйк. Төнге смена бит. Буровоены аударып ташлардай булып җил үкерә, күз ачкысыз буран котыра. Эшкә бер керешеп алгач, ышанасыңмы, шуны сизмибез дә. Таң атканчы ике йөз метр тау катламын шапылдатып бораулап та ташлыйбыз. Ә төн буена буран-давыл котыруын тик иртән, радиодан һава торышын тыңлагач кына беләбез.

Милиционер егет агайның болай сөйләнеп килүен килештермәде.

— Син, абзыкаем, тел тегермәнен тарттырырга бик мастак күренәсең. Эшкә дә шулаймы икәнсең белми-и-м? Анысына шигем зур. Һәр төнне икешәр йөз метр шапылдаткач, нигә соң байракны кулдан ычкындырдыгыз? Абзыкаем, туры сүземне авырга алма, син бит байрак алырга бармыйсың, тапшырырга барасың. Чаманы җуймыйча, әзрәк тыйнаграк «шапылдатсаң» да, абзыкаем, ярап куяр,— диде. Шушы сүзләре белән Дәүли агайның ачуын китерәсе килде, күрәсең.

— Ярыш бит, энекәш, ярыш. Ә байрак шундый нәрсә, ул бүген синең кулыңда, иртәгә аны күршеләрең яулаган. Уч төбеңә төкереп, җиңеңне төптәнрәк сызганып бер дуылдатып алсаң, ул тагын синең кулда.

Тәмле телле милиционер егет, агайның кызмавын, кабынмавын күреп, үзе дә йомшый төште.

— Миңа сезнең эш караңгы инде,— дип куйды.— «Шапылдатып бораулыйбыз», дигәч кенә әйтүем.

Алар шулай бәхәсләшә-бәхәсләшә зур поселокны аркылы кисеп чыкканчы, таң да атып өлгерде. Урамнарда кешеләр дә күренә башлады. Ниһаять, баҗасының йорты каршына килеп туктадылар. Аның ишегалдында җанлылык. Әнә, балдызы алъяпкычын япкан, сыер саварга әзерләнеп йөри. Баҗасы битлек киеп алган, умарталар багарга җыенган.

— Абау! Баҗай! Син түгелме соң бу! Милиция белән! — дип бераз сәерсенеп, әмма гадәтенчә якты йөз белән каршы алды ул Дәүли агайны. Ике баҗа бер-берсенең хәл-әхвәлен сорашкан арада, балдызы алма бакчасына табын әзерләде. Шул арада самовары да кайнап чыкты. Өстәлгә салкын каймак, табада кыздырган йомырка, яңа гына аерткан бал чыгарып утыртты. Кире китәргә ни омтылып караса да, озата ки-

лүче егетне дә җибәрмәделәр, табынга утырттылар. Семья-гаилә хәлләрен сораштырып бераәр чынаяк чәй эчкәч, баҗасы алма агачына сөяп куйган байракка ымлады:

— Кара син, баҗа! Сорарга онытып торам икән, бу ни соң? — Дәүли агай, мөмкин хәтле кыска тотып, бер-ике сүз белән генә эшне аңлатып бирде. Әмма баҗасы, хәйләкәр нәрсә, аңламаганга салышты:

— Инде, мәйтәм, байтактан күрешкән дә юк, дөнья куып хатларны да сирәк язышабыз. Үзең, шәт, шул буровой сукмакларын таптыйсыңдыр бит? — дип сорады. Аның бу соравы агайның йөрәгенә җәядән аткан ук булып кадалды. Белә ул баҗасының, бурсыкның кыек атып туры тидерә торган гадәтләрен. Аның кебек хәйләкәр җанны эзлисе, табасы бар әле.

— Буровойда булмыйни соң! Егерме елдан артык гомеремне багышлаган һөнәремә хыянәт итү мөмкинме! Алай да кем, баҗа, тиктомалдан гына минем биографиям белән ни дип кызыксынуың әле бу?

— Әллә, мәйтәм, профсоюз тирәсендә лидер-мазар итеп куйганнармы. Байрак хәтле байрак күтәреп килеп чыккач, нәрсә генә уйлап бетермәссең.

— Шулай диген аны. Бу байракка синең нинди катнашың бар, диген, — диде агай, ачуы кабара барганын сиздереп. — Нигә булмасын? Безгә аны социалистик ярышта җиңгән өчен биргәннәр иде. Биш ел бездә яшәде. Ә менә хәзер сезнекеләр җиңгән байракны алар иулаган. Мәйдан батырларын тәбрикләргә, кулларын кысарга килүем.

Ә нигә шулай димәскә? Баҗасы да, күркә борын, утырмасын әллә кем булып, ачу китереп. Аннан чынлап торып сорау алырга кирәште бит әле. Профсоюз тирәсендә чәчәк атмыйсыңдыр бит, янәсе.

— Бер уңайдан сезне дә күреп чыгармын, дидем. Югыйсә, кайчан күрешкән булыр идек әле.

— Их, баҗа-баҗа! Минем белән бердәнбер балдызыңны сагынган булсаң, күрешүнең аның башка җаен да тапкан булыр идек, — диде баҗасы, уеның-чынын бергә кушып. — Син инде дөресен әйт, монда чит кеше юк, барысы да үзебезнекеләр, яшермә. Булмады, диген. Җиңелдек, диген. Кара инде, кара берни капмый утырасың. Әйдә, катык-каймагыннан авыз ит, чәеңне бал кабып эч. Үрел, барына җитешеп утыр әле, аларны бит карар өчен генә куймадык... Сигез тулу белән кибет ачыла. Кече малайны хәзер бидон белән сырага йөгертәм. Әйдә рәхәтләнеп сыйланып утырыйк әле бер. Асыл кош кулдан ычкынган икән, аңа пошынудан хәзер ни файда? Байрак түтү икән, әйдә, түтү була бирсен. Аның өчен бүген офтандың ни дә, офтанмадың ни. Бар булганыннан иреш әле, баҗа, син миңа бертуган абзам кебек якын кеше бит. Менә, кайнар килеш, тәбәсенә дә җитеш.

Баҗасының бу «кыстауларыннан» агайның бугазына йодрык хәтле бер төер утырды. Кая ул кайнар тәбәләргә җитешү, тамагыннан бер йотым чәй үтми. Баҗасы, эчкерле җан, үзе аны сыйлаган була, үзе әнә ничек аны мыскыллап утыра. Нигә соң әле ул үзен шулай кимсеттерә, хурлаттыра?

Агай чәшкәсен әйләндереп каплап, табын түренәрәк этәрде. Ашыгуын, китәргә җыенуын сиздереп, күтәрелергә өлгергән кояшка ымлады.

— Якты йөзегез, сый-хөрмәтегез өчен зур рәхмәт. Юл кешесенең юлда булуы хәерле.

Бәлешкә майны артыграк тамызуын баҗасы хәзер генә сизде. Күтәрелде, бәрелде, агайның бер артына, бер алдына төште.

— Ниткән кузгалу, ди ул! Бер кич тә кундырмый мин сине аяк та атлатмыйм. Балдызың анда әнә мунча өлгертеп йөри. Аңарчы әле ятьмә өстерәп күлгә төшеп менәбез. Син килешкә дип яңа җыр отып куйдым. Кичкә күршеләрне дә дәшеп бераз күңел ачып утырырбыз. Юк,

юк, бажакаем, мин сине аяк та атлатмыйм. Ә иртәгә энекәшнең «Москвичы» белән буровойга үзем илтеп кайтырмын, — дип аның тирәсендә бөтерчек булып бөтерелергә керешә. Әмма соң иде инде. Кунагың алай кадерле булгач, бераз теләңне тыялар аны.

Дәүли агай үзенең бик ашыгырга мәҗбүр икәнен, бригадаларында болай да кеше җитешмәвен, мастерларының мөмкин хәтле тиз әйләнергә кушып калуын аңлатты. Бажасы белән дә, балдызы белән дә салкын гына саубуллашып, чыгып китте.

Байрак тапшырылырга тиешле бригада Норлаттан ун-унике чакрымнар чамасы бер авыл читендә икән. Агай шул авылга бара торган юл өстендә машина көтә башлады. Әллә инде шимбә көн булганга, әллә инде аның юлы шулай кире булды, ул барасы якка ник бер машина үзсын. Җитмәсә, рәхимсез итеп кояш кыздыра. Агай юлның икенче ягына чыгып утырды, байракны коймага сөяп, яшел чирәмгә сузылды.

Агай берни турында да уйламаска, күк түбәсенә менеп кунаклаган ак болытларга карап тын гына ятарга, ял итәргә булды. Үч иткән шикелле ул барасы якка машина түгел, арба таккан трактор-мазар да узмый. Гомердә болай кире килгәнен хәтерләми. Бу юлы ул чынлап нindидер уңышсыз сәфәргә чыкты, ахры. Өйдә хатыны килештермәде, ризалыгын бирмәде. Байракны илтә баруына аяк терәп каршы булды. Поездда килгәндә, бу нинди келәм дип, теге хәсрәтләр канына тәмам тоз салды. Озата килүче милиционер да сару кайнаткыч бер нәрсә булып чыкты. Ә бажасын инде әйткән дә юк.

Чуалган йомгакның очын эзли торгач, агай күңеле белән бригадаларына әйләнеп кайтты. Чынлап, нигә соң байракны ычкындырдылар алар? Болай начар да эшләмәделәр шикелле. Аңа калса, кояшта да таплар бар. Усал ният белән төпченсәң, җитешмәгән якларны кайсы бригададан табып булмый. Шунда ук үзе тагы бригадабызны юкка гына канат астына алам, урынсызга артык мактап маташам, дип тә уйлап алды. Дөресен генә әйтсәң, алай күкрәк сугарлык, чаң кагарлык эшләр кырган юк бит әле. Ә тәртип дигән нәрсә соңгы вакытта бөтенләй чатнады. Тәртип кенәме соң! Бригадада эшләр кеше калмады. Тегесе читтән торып укый, монысы кичке мәктәпкә йөгерә. Әлеге Сәер Сәет, әйтик, елына икешәр тапкыр Казанга имтихан тотарга китә. Аңа карап бригадага биргән планны киметмиләр бит. Кайчакларны агай вахтага үзенә бер дәрт, үзенә бер илһам белән чыга. Эшкә кулы кычытып тора, күңеле белән таулар ишеп ташлардай була. Бер төн эчендә ике-өч норма проходка бирү турында хыяллана. Ә буровойга килгәч, аның бу хыяллары таш идәнгә төшкән стакан төсле челпәрәмә килә. Синең белән иңгә иң терәп эшләргә тиешле биш кешенең вахтага я дүртесе, я өчесе генә чыккан була. Алар белән генә әллә ниләр майтара алмыйсың шул инде.

Ярар, укыган кеше укысын да, ди. Читтән торып укый, мәктәпкә йөгерә. Эшләп уку аларга да бик җиңел бирелми торгандыр. Әле бит бригада члennары арасында укымаганнары да эш дип янып-көеп йөрмиләр. Бораулаучы Игнат, аның яшьтие, улымны өйләндерәм дип, узган айны гына ун көн эшкә чыкмады. Аннары кодаларына кунакка китте. Үз хисабымнан дигән булып тагын ун көнгә ял алды. Бу көннәрне бригада Игнатны түгел, бораuланырга тиешле, әмма бораuланмый калган метрларны югалтты. Ярар, монысы әле аның бер хәл. Игнат югалтканын кайтара торган оста. Әнә помбур Мәхмүтне ал әле син. Хатыны белән икәүләшеп өч бүлмәле фатирларына сыешмыйлар. Әле кайчан гына унбиш тәүлек утырып чыкты.

Юк, мастер Җиһаншинны да мактап булмый. Тәрбия эшен бөтенләй йомшартты. Мәхмүтне нишләтте диген? Аның урынында Дәүли агай булсамы? Ул тел бистәсенең җиде кат тиресен тунаган булыр иде. Бригададан куар иде ул аны. Әйе, мастерлары аларның йомшаграк

холыклы кеше. Шуңа күрә коллективта тәртип юк. Саңга да сукмыйлар.

Шул вакыт агайның күңел түрендә икенче Дәүли калыкты. Усал, үҗәт, туганына турысын әйтүче Дәүли монысы. Беренче сүзе итеп ул:

— Син, агайне, гаепне кешедән эзләмә. Башта үзеңне бел! — диде. — Шул Мәхмүтне бригада җыелышында тикшергәндә басып бер сүз әйттеңме? Юк. Тыныңны да чыгармый утырдың. Ах, агайне-ак мыек, бер-беребезне какмыек фәлсәфәсе көчле синдә. Шул эшлексезнең тетмәсен тетеп ташларга иде. Күрсең, сизсең иде ул бригаданың көчен. Ә син шунда намус саклаган булып утырдың. Хәзер инде мастерыгызны йомшаклык күрсәтүдә, принципиаль булмауда гаепләп ятасың. Ул бит бер үзе, ничек җиңә алсын.

Әйе, агай, байракны җиңүчеләргә илтүне сиңа йөкләп, мастер Җиһаншин дөрес иткән. Ул моны махсус шулай китереп чыгаргандыр әле. Коллективта хезмәт дисциплинасын ныгытуда, егетләрнең активлыгын күтәрүдә син, картлач, миңа мыскал да ярдәм итмәдең. Менә ярышта җиңелү гарьлеген дә чүмече, кисмәге белән үзең таты инде, дигәндер.

Дәүли агай сискәнеп киткәндәй булды. Кинәт кенә яткан җиреннән күтәрелде. Син гафу ит инде мине, иптәш мастер, дип куйды. Җанлы бер нәрсәгә мөрәҗәгать иткәндәй байракка дәште:

— Йөдәтеп, юл тузаннары йоттырып йөргәнем өчен гафу ит, туганкай. Кирегә борылабыз. Мин сине болай җиңел генә тапшыра алмыйм икән. Бу эш булмый миннән. Башканы җибәрсеннәр. Өйгә кайтабыз.

Агай беренче эше итеп костюм түшенә тезгән орден-медальләрен сүтеп алды. Килешми. Сәфәре ул түгел. Аннары кызу-кызу адымнар белән станцага таба китте.

Кире якка билетны гомуми вагонга гына алды. Анда кереп утыргач та тынычлана алмады әле. Алай-болай йокымсырап китеп байракны югалтмагаем, берәрсе эләктереп чыгып китмәгәе дип, борчылып утырды. Менә аннары булыр хәлләр. Бригадага ни йөзең белән кайтып керерсең. Шул ук Мәхмүт ниләр сөйләп бетермәс.

Агай, кеше-кара юграк чакны чамалап, тамбурга чыкты, байракны төргән калын сүрүне сүтте. Аның алтын башлы сөңге очын салдырып чемоданына тыкты. Байракның үзен, игезәкләре белән хатыны Нурия җиңги өйрәткәнчә, күлмәге астыннан күкрәгенә урады.

Поезд тигез шпаллар өстеннән төн ярып чабуын белә. Вагонда халык байтак. Күбесе утырган көйгә генә йокымсырап баралар. Дәүли агайның күзләренә генә йокы төшми. Агай әледән-әле үзен капшап ала, күкрәген сыпыра.

## Галимҗан Латыйп

# ТОРМЫШ ҺӘМ ГАДЕЛЛЕК

●

Утызынчы еллар.
Безнең яшьлек
Утлар якты сүнгән учакка.
Кулак безгә обрезлардан атты,
Кулын сузды канлы пычакка.

Әле монда,
Әле теге якта
Яңарттылар безнең яраны.
Без кабызган утны дошман өреп
Сүндерергә теләп карады.

Җырга кереп яши безнең яшьлек,
Ышанычлы, сынмас канатлы.
Ак бәхеткә кулын сузган дошман
Ничә тапкыр борынын канатты.

Безнең яшьлек кыю, чая яшьлек,
Хыял җитмәс зәңгәр күкләрдә.
Төзи, бизи яңа калаларны,
Кирәк икән чирәм күтәрә.

Ачык безнең якты максатыбыз —
Без менәсе үрләр бар әле.
Ике арага дуслык күпере салып,
Кушасы бар каршы ярларны.

Күңелләр ак, йөзләр якты булса,
Табыла ул, дуслар табыла.
Күчә дөнья, күчә — туктап калмый —
Гаделлек һәм хаклык ягына.

## Самолетлар оча

Самолетлар оча һаваларда,
Болытлардан өстә,

Югарыда.
Зәңгәр утлар әләм,
Зәңгәр утлар
Иминлеккә һава юлларына.

Самолетлар оча һаваларда,
Болыт диеп тормый — көн саен.
Берәү китеп бара,
Берәү кайта,
Сагышлары тарта, мөгаен...

Самолетлар оча һаваларда,
Көтеп ята берәү якыннарын,
Сәгатьләрен,
Минутларын санап:
«Килеп җитәр микән,
Сонламаслар микән,
Бахырларым!..»

Самолетлар оча һаваларда,
Ил хәстәре,
Җир хәстәре белән.
Илчеләрнең аяк асларына —
Хәере белән! —
Җәям зәңгәр келәм.

●

Арышларның яңа серкә койган чагы,
Башак исе бөркеп тора басу ягы.

Тирә-якта көне буе тургай җыры,
Зәңгәр диңгез кебек ята иген кыры.

Күктә кояш, ут шарыдай янып тора,
Басуларга җем-җем нурлар тамып тора.

Бу кырларны бабаларым сөргән, чәчкән,
Ул аларны иртә таңнан эшкә дәшкән.

Тамган аңа игенченең кайнар тире,
Килгән еллар — бер ел уңай, бер ел кире.

Тимер чыңы колагында тимерченең,
Төшләренә керә кырлар игенченең.

Ничегерәк килер икән тагын еллар!..
Кайчакларда тартылганнар нечкә кыллар.

Еллар үткән саен өмет ныгый, арта,
Җир үзенә игътибарны ныгырак тарта.

Карап йөрим басуларны — җан сөенә,
Җир әйләнә күчәрендә үз көенә.

Җир әйләнә. Имин булсын иминлекләр,
Ачык булсын, каралмасын зәңгәр күкләр.

Кеше җирнең гомер-гомер үз баласы,
Җир — кешенең каш астында күз карасы.

●

Бу дөньяда Кол Галиләрдән соң
Хөр Галиләр яшәсеннәр дип,
Яшьни алган кадәр бар көченә
Рәхәтләнеп яшьнәсеннәр дип,

Язды шагыйрь үз канына манып,
Әче нәфрәт белән җырларын.
Инанып һәм нык ышанып язды
Яңарачагына дөньяның.

Шагыйрьләрнең язмышлары төрле,
Ләкин алар серле түгелләр:
Барсы ачык, барсы ярылып ята,
Күләгәле, керле түгелләр.

Берәүләрне зинданнарга бикләп,
Сөргеннәрдә җанын алдылар.
Эшафотка яки тере килеш
Дөрләп янган утка салдылар.

Берәүләре азатлыкны яклап,
Ятып калды ерак җирләрдә.
Ул тау булып басты, каушамады
Ил өстенә бәла килгәндә.

Берәүләре бомба белән бергә
Шартладылар танк астында.
Үзеннән соң җыр һәм таңнарыбыз
Каралмасын — исән калсынга.

Телдән телгә, җырдан җырга күчте
Аклык, пакьлек, кылган батырлык.
Биегәя барды зәңгәр күкләр,
Арта барды җирдә матурлык.

Гасырларны, дәверләрне үтеп,
Мәңгелеккә атлый яхшылык.
Үлем түгел,
Тормыш һәм гаделлек
Бу дөньяга яшәр баш булып.

●

*Хәнифәгә*

Йортымның яме — син.
Ашымның тәме — син.
Күңелнең көрлеге,
Дөньямның мәне — син.

Үзең дә беләсең,
Син барга — мин яшим.
Син кайда — мин шунда,
Мин янам, мин яшьним.

Кулыңда — дүрт чәчәк [1].
Дүртесе — дүрт төсле.
Берсе дә ким түгел,
Һәркайсы өлешле.

Аларга син үзең
Төс бирдең, көч бирдең.
Шатлыктан, кайгыдан
Әчмичә исердең.

Яуга да ял кирәк!
Син бераз тынычлан.
Синең дә йөрәгең
Түгел бит корычтан.

Яндырдың, дөрләттең
Ничәмә учакны.
Дөньяның күзенә
Туп-туры карарга
Син хаклы:

Синең бит җаныңнан
Моң ага, нур ага.
Изгелек кылырга
Килгәнсең дөньяга.

Беләмсең, берәүләр
Яралый,
берәүләр
Дәвалый йөрәкне.
Мин сиңа бирергә
Кул куям — дөньяда
Иң олы бүләкне.

●

Якты алан.
Җем-җем чәчәкләр,
Кош оясы куак төбендә,
Әниләре балаларына
Сабак бирә кошлар телендә:

«Мин өйдә юк чакта, оланнар,
Килә калса берәр куркыныч,
Сөйләшмәгез, кыймылдамагыз,
Утырыгыз, яме, тып-тыныч

[1] Бертуган дүрт бала турында сүз бара

Сак булыгыз, сизгер булыгыз,
Калуың бар йортсыз-бишексез.
Килдең икән инде дөньяга,
Син яшәргә тиеш, һичшиксез.

Яши белеп яшәгәннәргә
Бу дөньяда бәхет җитәрлек.
Булса булсын барлык гомерең
Бүтәннәрне гашыйк итәрлек».

Әниләрнең җаны тынгысыз,
Яна, көя, балам дия ул.
Сер сынатмый сырты сынса да,
Үз иңенә барын өя ул.

Балаларың булу янында
Бу дөньяда үзе зур бәхет.
Дәүләтең нык,
Йортың-илең нык,
Синең кулда, димәк, пайтәхет.

●

Шатлыкларым булды синең белән,
кайгыларны уртак бүлештек.
Бер атнага китсәм,
ел торгандай,
кочакларны җәеп күрештек.

Көне түгел,
сәгатьләре белән
сагындыра белдең,
сагындым.
Аллаларга ышанмасам да мин,
аллам итеп сиңа табындым.

Бәхет дигәннәре
нәрсәдер ул,
шул турыда һаман уйланам:
Әнкәй миңа,
«Бәхетле бул!» диде,
Әйткәннәрен аның
татымыйча,
китеп бармам микән дөньядан?

# ДУСЛАР ҖЫРЫ

*Тугандаш Башкортстан поэзиясендә Әнгам Атнабаев, Марат Кәримов, Рафаэль Сафиннар буыны... Без шигъриятка бер үк чорда, илленче еллар башында килдек. Узган юлыбызда — утыз еллап иҗат гомере. Кайберебез инде гомернең алтынчы дистәсендә яши, кайберебез иллегә якынлашып килә. Язу алымнары төрле булуга карамастан, бер үк уйлар, бер үк хисләр белән яну безне якын дуслар итте. Шул бәхетле утыз ел дәвамында без бер-беребезнең иҗаты-тормышы белән якыннан кызыксынып, ярдәм итешеп, кунаклашып яшәдек.*

*Узган ел Рафаэль дус мине үзенең туган җиренә — Әй буена алып барды. Шул чакны мин каләмдәшемнең шигъриятен яңа яктан ачтым. Башына бөркетләр генә менеп җитәрлек биек кыялар; бер яктан таулар, икенче яктан зифа каеннар белән иркаләнеп аккан тиз агышлы Әй, әз генә җил исү белән борынгы башкорт көен уйнарга торган курайлы урманнар илендә туган Рафаэльның ни өчен романтик җанлы шагыйрь булуын йөрәгем белән тойдым мин. Әй ташларына басып, үзе сыздырган баянына кушылып, башкорт, татар көйләрен җырлап җибәргәч исә, мин ике дус халык йөрәгендәге моңнарның игезәк икәннәрен янә бер кат расладым. Рафаэльның Әй һәм Иөрүзән буйларыннан өзеп алган курайлары бар. Курай тавышында мин Әй белән Иөрүзәннең кызу агышын да, аларның бер-берсе белән кавышырга теләп тә, хыялларына ирешә алмау сагышын да, безгә мәңгелек яшьлек юраган кәккүкләр тавышын да, беркайчан да түбәнгә төшмәгән бөркетләрнең канат кагышын да ишеттем. Рафаэльның шигырьләрендә дә шундый ашкынулы агышлар, җанга якын тавышлар...*

*Сандугачлар, кәккүкләр, чишмәләр, әллә инде җырлы-моңлы булганга, картаймыйлар... Син яшәп туйгысыз гаҗәеп, серле-җырлы, курайлы-тугайлы, зәңгәр күкле-кәккүкле дөньяда ярты гасыр гына яшәдең әле, Рафаэль дус! Киләчәктә дә картаюны белмә, әнә бит үз җырларың, шигырьләрең, драмаларың, Әй кәккүкләре булып, сиңа озын иҗат гомере юрыйлар...*

ИЛДАР ЮЗЕЕВ

## Рафаэль Сафин

### Җирем моңы

Уелам инде, уелам,
җырга-моңга уелам.
Үзәкләрне өзәрлек моң
агыла Әй буеннан.

Кем ул җырлый сузып шулай
язның аулак кичендә?
Ак баланнар уйга талып,
тыңлый әңгер эчендә.

Бөгелә таллар, бөгелә,
бөгелә җилгә түгел,
талларда да бар шикелле
моңлана торган күңел.

Кемнәндер саф мәхәббәте
әйләнгән дә җыр-моңга,
сагынуларын сөйли кебек
үзе моңлы болынга.

Уелам инде, уелам,
җырга-моңга уелам.
Ташларга җан керер төсле
Әй буеның моңыннан.

Моң тирбәлә һәр куакта,
битләүләрдә, үзәндә.
Чү! Карасам, бөтен бу моң
үземдә бит, үземдә.

Ул озата бара мине
сәфәрләргә юл алсам.
Мин үзем дә югалырмын,
әгәр ул моң югалса.

Җирем моңы... Гомерем буе
тартыр Әем буена.
Уелам инде, уелам
җиргенәмнән моңыннан.

# Юлдагы бер очрашу

Юк, яз түгел, җәй дә түгел,
ялкын өрде кар тыны,
өшегән җанны җылытты
мартның соңгы салкыны.

Юк, яз түгел, җәй дә түгел,
йөрәгемне нурлады,
йөрәгемә моңнар салды
мартның соңгы бураны.

Юк, яз түгел, җәй дә түгел,
яланда кыш типтерде,
мартның соңгы буранына
төреп сине китерде.

Кем идең син? Карсылумы,
язсылумы, кем идең?
Актарылган бозлар сыман,
актарылды күңелем.

Очырдың да күңелемә
өмет карлыгачларын,
китеп бардың, оныттырып
җирдә салкын кыш барын.

Көткән язым килде инде...
Аһ, мин инде яңадан
язгы көләч көнгә карап,
март буранын сагынам.

●

Шырпы сыздым. Шырпым төшеп
китте,
яна-яна, кинәт кулымнан.
Ни галәмәт? Тоткан бер әйберем
төшеп китә, ни соң кылырга?

Картаелдымы әллә? Талдымы әллә
эштә бәхет тапкан бу куллар,
кышкы чилләләрдә балта тоткан,
җәен печән чапкан бу куллар?

Бар гомерем утта янды кебек.
Тансыгымны янып кандырдым.[1]
Көннәремне, айлар, елларымны
йөрәгемә сызып яндырдым.

Көннәрем дә, айлар, елларым да,
сиздермичә барган юлымда
берәм-берәм төшеп китә торды,
шырпы төшкән кебек кулымнан.

Төшеп китте шулай шатлыкларым,
йөрәгемдә әрнү калдырып.
Төшеп китте шулай, тоталмадым,
мәхәббәтем янып, яндырып.

Э-эх, мәңгелек түгел бер нәрсә дә!
Бердәнбер көн барыр юлымда
төшеп китсәм иде үзем дә мин,
яна-яна, дөнья кулыннан.
Яна-яна!

# Юрау

— Нәрсә булыр икән? Үткән төндә
бөтен җаным балкып уяндым.
— Күктә яңа йолдыз кабынгандыр,
җирдә яңа шагыйрь тугандыр.

— Нәрсә булыр икән? Бүген төндә
җаным тетрәп, куркып уяндым.
— Күктә берәр йолдыз сүнгәндер дә
җирдә шагыйрь дөнья куйгандыр.

# Яратам

Әле кичә генә ишеткән күк
яшьлегемнең яшел тавында
Әй кызының тәүге сөю сүзен,
Әй буе шау чәчкә чагында.

Әй, гомернең изге минутлары,
кабатланмас мәле гомернең!
Калды торып, калды Әй буенда
зәңгәр томаннарга күмелеп.

[1] Сусауны бастым.

Яшьлегемнең яшел тавы калды.
Сары тауда атты сары таң.
Сары тауда әйтте кыймый гына
сары чәчле сылу: — Яратам!

Язың үткән инде, куй, димәде,
бүләк итте кайнар назларын.
Әйтерсең лә, килде кире әйләнеп
яшьлегемнең яшел язлары,
акылымнан мине яздырып.

Язда гынамыни бу гомернең
дөрли-дөрли янып балкуы!
Өтеп алыр сымак, кагыл гына,
каеннарның сары ялкыны.

Һәр агачның алтын телендә бит
чыңлап тора шул сүз: «Яратам!»
Димәк, дускай, без яшибез әле,
яратам дип атса сары таң.

•

Күз ачылды. Акман-токман[1] тынды.
Бураннан соң көнгә карагач,
урмандагы төсләр ачыкланды,
үзе булып калды һәр агач.

Мин урманнан киләм. Шундый тыныч.
Шулай атлап бар да бар гына.
Җирдә сафлык, җирдә юк
                    пычраклык,
бар тирә-як кар да кар гына.
Шулай атлап бар да бар гына.

Ләкин җаным никтер тыныч түгел.
Ник әле мин һаман моңаям?
Әллә дөнья миннән туйдымы соң,
әллә минме — кырыс дөньядан?

Юк, дөньядан күңелем кайтмады
                    һич,
ил алдында камил иманым,
ничек булса, шулай кабул иттем
җил-яңгырын, әче буранын.

Юк, дөньядан күңелем кайтмады
                    һич,
күңелем кайтты үзем җан эткән
кешеләрдән. Алар хыянәте
килеп-килеп екты аяктан.

Алдаштырды, бугай, дөнья мине,
адаштырды, бугай, еш кына:
аккош, дисәм, күңлем бакчасына
бик еш кына каракош куна.

Җан карая кинәт — аклык өчен,
хаклык өчен утка кергәндә,
пәйгамбәрдәй ирнең табынында
иблис биегәнен күрәм дә.

Ә син күрмә, диләр. Ә мин күрәм.
Бер катлы син, диләр, бер катлы.
Шуңа да шул синең тормышың да
булмады бит, диләр, бик татлы.
Бер катлы шул, әйе, бер катлы.

Уйлый идем, гомер юлларыма
гөл сибелеп калыр, дип, элек,
әле баксам, анда йөрәгемнең
ярчыклары ята сибелеп.

Һәм еш кына күңелем яралары
сызлавыннан китәм уянып.
Шулай белә кеше кешеләрне,
бара-бара, башын яра-яра,
шулай белә кеше дөньяны.

---

[1] Акман-токман — март бураны.

Әхәт Гаффар

# СИКСӘН БЕРЕНЧЕ ЕЛ ИКМӘГЕ



Былтыргы 81 нче ел урагында игеннең камылыннан башлап кибәгенә кадәр амбарларга, салам эскертләренә, силос чокырларына җыйнап куйдылар — корылык шундый сабак бирде. 72 нче һәм 75 нче елгы корылыклар игенчеләрне фәкать үз көчләренә таянганда гына тотрыклы уңыш алып булырына ышандырып, хәвеф-хәтәрсез генә узып киткән иде. Җир кешесе быел да сынатмады. Биш сәям җир тирәнлегеннән космоска шайлы дым әсәре бетеп торды: җиргә һәм андагы үсемлекләргә сихәте тиярдәй соңгы яңгыр апрель азагында кинәндереп китте, бәрәңге, чөгендер ише игеннәр беренче шифалы яңгырга 29 нчы августта гына тиеште. Дүрт ай буена һәр нәрсәне кешеләр белән кояш кына карап торды.

Кешеләребезнең быелгыдай җәйдәге хезмәт каһарманлыгы онытылмас җыр рәвешендә байтак гомер хәтердә торыр әле. Аны авылда да, шәһәрдә дә сөйләрләр, сөйләмичә булдыра алмаслар, сөйләргә тиешләр. 81 нче елның хәвеф-хәтәрсез тынычлык, шөкранә генә муллык, ыгы-зыгысыз, кабаланусыз һәм лаеклы ышаныч белән озатылган җәен тормыш итү мәктәбенең баш иярдәй тәҗрибәсе сыйфатында халык каһарманнарга куелган һәйкәлләргә биргесез төстә хәтерендә тотар!

## I. Иген бөртеге һәм пуля

Пуля, ядрә, бомба, торпеда һәм континентара ракеталар бодай бөртегенә охшатып ясалганнар. Шулай әйбәтрәк һәм төгәлрәк очалар. Пуля белән бодай бөртегенең аэродинамик күрсәткечләре бер төрлерәктер. Кем үлчәп, санап караган? Бодай бөртегенә охшаган пулялар...

Мин Буа районындагы Ленин орденлы «Татарстан» колхозының ындыр табагында басып торам. Биредә хәрби тәртип — амбарлар белән ангарларга номер сугылган, чиста һәм пөхтә, бернинди чит кеше юк. Полигон шайлы асфальт мәйдандагы бер көшелдә өч хатын-кыз ашлык җилгәреп ята, бүтән бер җирдә механик токтан чыгарылган икенче сорт бодайны машинадан бушатып торалар.

Ындыр табагындагы һәр аваз миңа таныш, якын, әтинең гармунда уйнаганын яңадан бер генә булса да ишетәсе килгәне кебек сагынычлы.

Бала чакта, кайнар һавада әлсерәгән ябык тәннәребезне без чикерткә тавышы белән тырылдаучы кечкенә ак моторлы ашлык пультыннан сузылып чыккан иген шарламасы астына кереп суыта, ә көзгә табан, көннәр салкынаю төшкәч, көшелләрнең җил тимәгән ягына ятып, аларның эчке җылысы белән җылыта идек.

Хәзер дистә метрларга сузылган көшелләрне күргәндә минем хәтеремне үткәннәр белән тоташтырган чыбыклар анамның эшләп талчыккан һәм тупасланган учындагы кытыршы сызыклардан башлана шикелле. Ындыр табагы әнинең алга, киләчәккә

таба сузылган учларына охшаган. Мин ул кулларның гомер юлларын терелтеп юрыйм, алар буенча, чишмәләр сыман, киләчәкнең ышанычы тулып ага.

Ындыр табакларында ашлык елгаларыдай өзлексез әйләнеп торган транспортерлар. Ә элгәре иң ышанычлы транспортерлар аталарыбызның тупас авыр арыш капчыклары күтәрүдән көчәнеп бүртенгән кул һәм муеннарындагы алсу-зәңгәрсу кан тамырлары иде...

Минем яныма таякка таянган бер абзый якынлаша, аның каршысына атлыйм.

— Нихәлләрегез бар? — дип эндәшәм.

— Әйбәт кенә.

Мин үземне, ул үзен атап танышабыз, кул бирешәбез.

Вәзыйх Хәсәнов. 1926 елгы. Сигез ел армиядә хезмәт итә. Күп еллар колхозда прораб, тәэминатчы булып эшләгән, корылыклы 1975 елда ындыр табагы мөдире булып торган, шуннан соң авырган һәм быел тагын шушы эшкә куйганнар. Әйбәт абзый, кешеләрнең яхшы эшләвенә сөенә, колхозчыга мал асравы кыенга киләчәгенә көенә, тик кайгырудан мәгънә чыкмаганлыгын яхшы аңлый. Крестьян үз башыннан ни генә кичермәде. Җирдә нинди генә бәла-каза чыкмасын, бөтенесе крестьян иңенә килеп асылына, ул бусыннан да сыгылып төшмәс, шәт. — Ашлыгыгыз кайда соң сезнең? — дип сорадым мин аннан, буш ындыр табагына ишарәләп. Соравымны үз уйларымны тикшереп карыйсым килгәннән генә бирдем. Мондый коры елны ындыр табагында ашлык тоткан колхоз уңмаган килен пешергән чиле-пешле икмәк белән бер ул. Бөртекләр коры, амбарларга сал да куй, аннары чистарт, чәчүгә орлыгын аер, дәүләткә сат.

— Бер ишесен чистартып, бер өлешен болай гына салып куйдык,— диде Вәзыйх абзый. Аннары нәкъ минем үз күңелемдәге шикне дә кабатлады:— Кисәктән яңгыр китсә, алган уңышыңның да юкка чыгуы бар ич.

Җирдә дым заты булмаган көнне крестьян агай телендәге бу сүзләр кайберәүләрне көлдерер, икенчеләрен ышандырмас, кемдер сүз иясенең күңеле ихласлыгына шикләнер, күп белдекләнә дип уйланыр иде. Иген игү — борыңгыдан ук стратегия ул, игенче мәңгелек солдат булган, корылыкка да, яңгырга да, чит баскыннарга да бердәй каршы торырга әзерләнгән. Бераздан мин баш агроном белән очрашачакмын, һәм ул нәкъ менә Вәзыйх абзый сүзләрен кабатлар. Кабатламас, ә гади крестьян шөгыле таләп иткәнчә:

— Без чәчкәндә корылыкка да исәп тотып чәчтек,— дияр.— Орлыкны тирән күмдермәдек, биш-алты сантиметрга гына эшкәртеп, каты җиргә салдык. Академик Терентий Мальцев шулай чәчеп, иң коры елны да гектардан унбиш центнер алам ди, ә безнең бодай унтугыз центнер чыга.

Менә ул — игенче стратегиясе. Менә ул игенчене солдат иткән сыйфат, менә ул яшәү диган кылның иң нык җире.

Пулялар һәм ракеталар саклана торган урыннарга чыпчык та үтмәле түгел. Бодай кешеле янына теләсә кем уза ала. Ындыр табагы — иң бай сый-хөрмәтле кунак өстәле ул. Ядрә амбарларының йозагындагы пластилин мөһерне сәгать саен тикшереп торалар. Пулялар уналтылап яки егермеләп бик пөхтә катыргы капларга төрелгән. Бодай бөртекләре чиган шикелле: кая гына күчмиләр, кая гына түгелмиләр.

Тик пуля белән бодай бөртеге язмышларының уртак тәмамланган мизгеле дә бар. Берсе дә югалмый торган пуляда үлем ихтималы посып ята. Башак булып, кырда калган, юлда яткан бөртекләрдә яшәү диган бөек көч үлә. Атылган пуля белән югалган бөртек — бер үк төрле җинаять. Бөтен кешелек тарихының гасырын гасырга, елын елга, аен айга, тәүлеген тәүлеккә, сәгатен сәгатькә чәчеп, үз йөрәгеңнең авырткнанын акыл колагың белән сагаеп тыңлагандай, актарып кара — җәядән атылган ук белән көпшәдән чыккан пуляның да, өстәлгә менми калган бер бөтен икмәкнең дә яшәүгә аяк чалганын күрерсең.

Нигәдер, пентагоннар белән элеваторларны, корал заводлары белән ындыр табакларын чагыштырып карыйсы килә. Бу чагыштыру августның башында бөтен Җир шарында тагын кемнең башына килде икән? Чынбарлыкның бу нәрсәләрен чагыштырып була микән соң? Кайдадыр түгел, ә шушы ындыр табагы белән янәшәдә генә (Җир диган бәләкәй планетада бөтен нәрсә янәшә) атом-төш сугышының реаль мөм-

кинлеге хакында сөйләнгән бер вакытта пентагоннар белән элеваторларны, корал заводлары белән ашлык амбарларын бер бизмәнгә салып үлчәү, чагыштыру бөтен кешелек дөньясының иң зирәк эше булыр иде!

Алай да бу капма-каршы торган, һич килешмәс җимерү һәм төзү полюсларын кайчан янәшә куеп була соң? Икмәкнең стратегик куәткә ия көч икәнен күз алдында торганда, игенченең мәңгелек көрәшче икәнен истән чыгармаганда.

Ындыр табагына яшел кулмәкле кеше килеп керде.

— Баш агроном Нурислам килде,— диде Вәзыйх абзый.— Җамалетдинов. Хәзер наряд. Председатель дә була.

Председатель килеп җитмәде, Нурислам безне ышыкка, кыр вагонына әйдәде. Сөйләшеп утырдык. Сүзгә мул. Үз эшен яхшы белгән, кешеләрне яраткан белгечнең сүзе җитәрлек була инде аның. Ә сүзнең тәме — мәгънәсендә.

Бер мәлне мин аларның һәр икесенә карап:

— Сез бер патронның күпме торганын беләсезме? — дип сорадым. Алар бер-берсенә карашып алдылар да, уңайсызланган шикелле елмаеп, иңбашларын җыерып алдылар. Нурисламның күзендә мине аңларга тырышу чаткысы сизелеп куйды. Күнегелмәгән сорау, шулай бит?

— Ә бер центнер бодай ничә сум тора? — дидем мин.

— Тугыз сум егерме тиен,— диде Нурислам. Ул икмәккә кагылышлы теләсә нинди санны белә. Колхозчыларга быел 6 мең центнер ашлык бүлергә кирәклеген әйтә, дәүләткә 44 мең центнер ашлык сатуның быел җитди мәсьәлә икәнен бөтен җаваплылыгын аңлап атый, быел колхоз җирләренең уртача 12—13 центнер уңыш биргәненә канәгатьсез. Узган бишьеллыкта аларның җиреннән уртача 24 центнер уңыш чыккан. Быел көнбагыш белән кукуруз сыек, ә солы 20 центнер бирә. Быелгы ел өчен бик әйбәт саннар атады Нурислам.

Мин үземнең: «Сез бер патронның күпме торганын беләсезме?» дигән соравымны «тегендәге» берәр капиталистка, бизнесменга, конгрессменга яки сенаторга биреп карыйсым килә. Хәер, аларның бер патрон бәясен белгәннәренә минем иманым камил лә! Алар өчен ашлык бөртеге дә, пуля да — бары тик товар гына. Бер үк көчкә ия товар, аларның политикасына һәм ахыргы максатына яраклаштырып кулланыла торган товар. Шулай булмаса, алар халкы ач илләргә корал, ә муллыктагы дәүләтләргә ашлык сатмаслар иде!

Ә Ленин орденлы «Татарстан» колхозының баш агрономы Нурислам Җамалетдинов белән ындыр табагы мөдире Вәзыйх Хәсәнов бер патронның күпме торганын белми. Моны шушында эшләп йөрүче механик Солтан Җаббаров, Гөлүсә Гыймадиева, Мәсгудә Сираҗиева, килгән-киткән машиналарны бушаткан арада гармунга биюче мактап кызлары да белми. Шулай ук — комбайнчы егетләр Равил Баһаветдинов та, Ади Җамалетдинов та, Салих Җәләлов, Рәис Фәсхетдинов, җир сөрүче тракторчылар Фаяз Гайнетдинов, Мансур Җамалетдинов, Рафаэль Баһаветдинов, 30 еллык стажы булган тракторчы Фәгыйм Гайнуллов, Рәшит Шәкуров, Сәгыйть Абдулнасыйров та.

Моны мин дә белмим.

Без — яшәү көрәшчеләре, үлем сәүдәгәрләре түгел.

XX гасырның һәммә елы игенче өчен тоташ көрәштән генә гыйбарәт. 80 нче еллар 70 нче елларны кабатлый. Ел шаена еллар туры килми: былтыр тоташлый яңгырлар яуды, быел тоташлый корылык. Үткән җилләр артына посып 21 нче, 72 нче елларның ачкүзле табигате карап тора: кешеләр нишләр икән, янәмәсе.

Ә тук еллар сукыр, саңгырау, хәтерсез. Бар чагында икмәк бәһасез, ә бер дә юк вакытта бигрәк тә кыйммәт. Хәрби объектларга якынаюга, кайдадыр фотоэлементлар теләгә килә. Күз уңыдай кадерләп, иң әүвәлтен ашлыкны саклау фарыз. Тик, авыз кебек үк, икмәккә йозак асмыйлар. Икмәк — телсез. Башак җирдә калса — кычкырмый, ипине чыгарып атсалар — үтенеп еламый, тыйнак.

Кызык: тимер рудасы алына торган җирнең бер гектарыннан ничә центнер пуля чыга икән? Минемчә, иген игелә торган җирдә бодай бөртекләре уңышы күбрәк булса кирәк.

Сәер чагыштыру, шулаймы? Бик гадәти чагыштыру! «Булса кирәк» дигәне генә тәгәл түгел. Әлбәттә, җирдән теләсә нәрсәгә караганда да иген күбрәк алына. Җир — хатын-кыз кебек: яратсаң, торган саен юмартрак була белә.

Бер пуля тугыз граммлы. Бер граммга 30 бодай бөртеге керә. Бер пуля авырлыгы 270 бөртеккә тигез. Ә бер тонналы бомба ничәгә?

Юк, юк, җип-җиңел мәсьәлә бу: бер пуля да, бер атом бомбасы да бары тик үлемгә генә тигез. Ә теләсә нинди иген бөртеге — яшәүгә.

«Татарстан» колхозының Суксу, Карлы авылларында торучы кешеләр иген игә, мал-туар үрчетә, бура бурый, юына, бала-чага карый, ашый-эчә, җырлый-бии, корылыкка көенә, яңгыр көтә, йоклый, уяна гына белә. Ә тимердән пуля коя белми. Пуля коя алмаган кеше дөньядагы теләсә кайсы кешедән булдыклырак.

Атом бомбасына зират тыгып куя алган кеше — адәми затларның иң булдыксызы ул. Водород бомбасын уйлап чыгарыр өчен акылдан язган булырга кирәк. Ә нейтронын ясаганнары шашканнар гына микән?

Иң авыр эш — иген игү. Ашлык бөртекләрен станокта кырып булмый. Аның алтын кисәге кебек, әзере дә ялтырап ятмый.

Ындыр табакларыннан елга булып ашлык ага. Игенчегә ни булып әйләнеп кайтыр икән ул? Йөрәгенә таба очып килүче пуля гына, өенә төбәлгән туп ядрәсе генә, ындыр табагы өстенә төзәлгән ракета гына булмасын. Кайдадыр, кемдер бодай бөртекләрен пуляга да әйләндерә.

Ындыр табагы — алтын умарта. Амбарлардагы ашлык бүлемнәре бал белән тулы кәрәзләрне хәтерләтә. Ә бодай бөртекләре пуляга охшамаган. Алар Вәзыйх атлы абзый йөзендәге тыйнак елмаюга күбрәк тартым.

Күктә болыт түгел, тилгән дә юк. Тычканнар, акваланглар кебек, җир тирәнлегенә чумганнар. Бер метр тирәнлегеннән алып, космоска кадәр дым әсәре күренми. Җирне һәм андагы кешелекне игенченең маңгай тире генә туендырып тора. Җәйрәп яткан туфракның һәр учына игенче йөрәгеннән кан юллары тоташкан.

Игенче — Җир планетасына үз канын бушлай бирә торган мәңгелек донор ул.

## 2. Маяклар дәшә

Рөстәм Туктаров Буа районының «Маяк» колхозында тугызынчы председатель. Авыл хуҗалыгы институтын тәмамлагач, бирегә ул биш ел агроном, бер ел парторг булып эшләгән. Инде менә икенче ел — председатель.

Тугыз председатель. Колхозның ярты гасырлык тарихында әллә ни күп тә түгел шикелле. Тик ул ярты гасырның яртысында (24 ел) хуҗалыкны Садыйк Вәлиев җитәкләгән. Туктаровка кадәрге җиде председательгә җәмгысе 26 ел туры килә, һәркайсына бүлгәндә 3 ел да 7 ай. Алай да гаделлек хакына арадан берсенең 9 ел эшләгәнен әйтү кирәк. Димәк, калган алты председатель өчен уртача сан тагы да кими әле: 2 ел да 8 айга кала.

Садыйк Вәлиев чорында «Маяк» колхозы үз исеменә муафыйк хуҗалык булган. Хәзер ул гадәти, уртача хәлле.

Күзәтүемчә, элеккеге председателе озак еллар һәм яхшы җитәкләгән колхозлар, алар киткәч, еш кына, яңа хуҗасына авыр иярләшкән ат сыман, югалып, аптырап кала. Кайсысы бирешергә үк керешә, тернәкләнә башлады дигәндә дә байтак ара игә килә алмый. Хәзер «Маяк» та шундый хәл кичерә.

Мин Садыйк Вәлиевне күреп белмим. Алай да аның үз эше өчен дөньяга килгән зат икәнлеге шик уятмый. Заманында алдынгы саналган хуҗалыкның бүген урталыкта бару бөтен председательләрнең Вәлиев осталыгын кабул итеп һәм күтәреп алып китә алмауларын сөйли. Нык чылбырның кайсыдыр бер буыны йомшаган, һәм башка председательләр, аны ныгытасы урынга, өзелмәслек итеп кенә тартып алып киткәннәр. «Җан биргәнгә җүн бирер әле»,— дигән сымаграк. Моның инде традициягә әверелеп киткәнлеге хуҗалык белән танышуның беренче сәгатьләрендә үк күренә.

Рөстәм Туктаров үз язмышын хуҗалык һәм аның кешеләре язмышына менә шундый шартларда бәйләп җибәргән кеше. Ул — коммунист, җаваплы эшкә җиде кат үлчәп, бер кат кискәч кенә керешкәне фараз йөртмәстән дә аңлашыла. Башына яңа уйлар килгәндер, эшне яхшыга үзгәртергә күп ниятләр коргандыр.

В. И. Ленинның җитәкчелек итү, гомумән, яшәү, алга баруга карата әйткән, бүгенгегә дә, иртәгегә дә бердәй туры килә торган, һич искермәс зирәк сүзләре бар. Революционер яки коммунист булу гына җитми, ди ул, һәр мизгелдә чылбырның бөтен көч белән тотынырга мөмкинлек биргән аерым буынын таба белергә кирәк. Моны ул унсигезенче елда әйткән. Күрәсең, Садыйк Вәлиев кебек өлкән буын председательләре — минем аларны гвардиячеләр дип атыйсым килә — үз йөрәкләрен һәм зиһеннәрен гомуми эш чылбырының иң кирәкле буынына ялгый белгәннәр. Гвардиячеләр хәзер сирәгәйгәннән-сирәгәя баралар, тик бүгенге һәр эшебездә без аларның кыю фикерләрен, армый-талмый яңаны эзләнүләрен, тормышны, аның шатлыкларын һәм фаҗигаләрен зирәк аңлауларын, тирән хисләрен һәм әхлакый сафлыкларын тоеп яшибез.

Билгеле, хәзер күп нәрсә үзгәрде, яңарды. Экономика катлауланды, социаль көнкүреш таләпләре үзенчәлекле, колхозчының психологиясе бүтән. Шул ук вакытта председательләр, хуҗалык белгечләре сафы туктаусыз хәрәкәттә. Рөстәм Туктаров — шундый хәрәкәтнең, алмашынуның бер чагылышы. Дипломлы белгеч, Казан авыл хуҗалыгы институтын көндез укып тәмамлаган агроном. Җитәкчелек итүнең беренче баскычларын сынатмыйча үткән, аңа 33 яшь. Нәселләре — игенчеләр.

Ә өч ел да җиде ай дигән уртача сан киртәсен уңышлы узар өчен болардан кала тагын бер сыйфатка ирешү зарур әле. Теләсә кайсы җитәкчене алтынны билгели торган проба кебек сурәтли торган тагын бер мөһим сыйфат бар — шәхес булып җитлегү. Кешеләрне әйдәү, хуҗалыкны алга чыгару өчен бу яктан үзеңә кадәргеләрдән эрерәк масштабларга күчү, югарырак баскычка күтәрелү сәләтенә ия була белү фарыз. Моның өчен бер маяктан икенчесенә адашмыйча бара белү генә җитми, моның өчен ул маякларны үзең билгеләгән юл буенча үзең кадап чыга алу шарт.

...«Маяк»та бөтен эш нарядтан башлана. Рөстәм Туктаров аны көндезге ике белән өч арасында уздыра. Колхоздагы һәммә белгеч, дүрт бригададан дүрт бригадир, ферма мөдирләре һәм башкалар көндезге иң киеренке сәгатьтә бүгенгегә йомгак ясап, иртәгә эшләнәсе эшләрне ачыклар өчен идарәгә җыелыша. Кайнар көрәш барган бер мәлне һәммә командирның фронттагы алгы сызыктан штабка җыелуы кебегрәк. Ә моның өчен сугыш тынган араны сайларга кирәклеге барлык солдатка мәгълүм түгелмени? Туктаров тактикасында андые да бар — иртәнге «бишминутлык». Анысында бүген хәл ителәсе мәшәкатьләр кузгатыла.

Минем андый сөйләшүләрдә булганым бар, эчтәлеге һәркайда бер. Гадәттә, нарядлар калейдоскоптагы пыяла китекләре хәрәкәтенә тартым. Иң мөһим мәсьәләләр дә, вак эшләр дә буталыша — агачның тамыры, кәүсәсе, ботагы, яфрагы кушылып бетә. Белгечләр кузгаткан күп кенә сүзләр, мәсьәләләр, проблемалар яманаты чыккан аккош, кысла һәм чуртан тырышуын хәтерләтә. Билгеле, зур эшләр кечкенә мәшәкатьләрдән тора, ләкин аларның барысы да «бер тегерменгә коелган су» булырга тиеш. Ленин, төп эшне белмәүчеләр һәм аны үти алмаучылар вак эшләр белән чикләнәләр, әмма иртәме-соңмы алар барыбер үзәк мәсьәләгә әйләнеп кайтырга мәҗбүрләр, дигән.

Белгечләр председательгә: «Тегене болай итсәм, ничегрәк булыр икән?» — дигәнчәрәк мөрәҗәгать итәләр. «Мин болай хәл иттем»,— дип түгел. Киңәшләшү яхшы, әмма билгеле бер эш өчен җаваплы һәм шуның өчен хезмәт хакы ала торган белгечнең инициативалы булуы зарур. Өч ай ярым эчендә бәләкәй генә бер яңгырдан соң иртәгә нишлисен штабта киңәшү ни дәрәҗәдә хаҗәт? Шулай ук кырны иңләп, җир сөреп йөрүче тракторчыларның: «Хәзер ягулык бетә, китererләр микән?» дигән соравына, (бу вакытта сәгать кичке тугызынчы иде инде) председательнең: «Иртәгә булыр»,— дигән җавабы ни? Минем үземә моның белән председатель шөгыльләнмәсә дә ярый кебек тоела. Бу гамь баш инженер вазифасына карый, хәтта аныкына да түгел, ә тракторчылар бригадирыныкына. Җир сөрергә билгеләгәндә ягулык ничек онытылып калырга мөмкин?

Бераздан тракторчылар кыйммәтле вакытны юкка сарыф итеп кайтып китәчәк. Менә-менә күзгә чәчү башланырга тиеш, ә вак кына мәсьәләне хәл кылу иртәгәсе көнгә кала.

Туктаров көне буена үзен эзләп килгән күпме кеше белән сөйләшә, күпме телефон шалтыравына җавап бирә. Исәпләргә җайлы булсын өчен йөз санын алып карыйк (ә

ул реаль сан). Һәркайсысы белән бишәр минут кына сөйләшсә яисә аларның йомышын бишәр минут уйлап чара күрсә дә, аңа сигез сәгать ярым вакыт кирәк. Гадәттә, ул йомышларның күбесе турыдан-туры аның вазифасына карамый, байтагын белгечләр дә хәл итә алыр иде. Шушының аркасында председательнең көне кирәгеннән артык яки тиешледән киеренкерәк уза, ул өлгерми, житешми, димәк, аңа бәйле эшләрдә дә киеренкелек килеп чыга. Быелгы урак үзенчәлекле иде, әмма табигать булган уңышны җыеп алуга һич нинди киртә куймады, шулай да комбайннар кырларда кирәгеннән озаграк — август уртасыннан да ашып йөрде. Ә шушы ук районның «Искра» колхозында ул икенче августта ук тәмамланды инде. Урак өсте алдан билгеләнгән вакытка сыешмый икән, моңа иң әүвәл хуҗалык командирлары гаепле. Аннары соң «фронт» дигән сүзнең эчтәлеге бик хикмәтле. Эшне фронт белән чагыштырып, шуңа тиңләү бер яктан фидакарьлекне, батырлыкны чагылдырса, икенче яктан киеренкелек һәм авырлыкны да белгертеп тора. Яхшы белгечнең чын сәләте тыныч эшне тыныч итеп оештыра белүдә күренә.

«Маяк» колхозы белгечләре яшь кешеләр. Парторг Рәшит Сәлахетдинов утызда. Элек 7 ел ферма мөдире булып торган зоотехник егет. Баш инженер Әсхәт Ваһапов шушы арада гына институт тәмамлаган. Председательгә районнан яшь зоотехник кандидатурасын атаганнар, ул аңа риза. Алар үз бурычларының колхозны авыл хуҗалыгы индустриясе таләпләренә җавап бирердәй дәрәҗәгә күтәрү икәнлеген яхшы беләләр. Индустрия конвейердагыча ритм һәм һәр урындагы эш кешесенең шуңа көйләнгән психологиясе сумМасы ул. Авыл җирендә бу җиңел бирелә торган нәрсә түгел. Әлегә исә күп эш йөгерү, табу, тарту-сузу, юнәтү, өлгерү, аннан йолкып, монда ямауга корылган. Әйтергә кирәк, бу ысул алдынгы хуҗалыкларда да күзәтелгәли, шундый ысул белән эшләүнең кардиограммасы аларда да бик үк сәламәт түгел. Мондый чакта күбрәк аяк астына карыйсың, киләчәккә карасаң, абынып егылуың бар, чөнки баш теләгәнгә аяк өлгерми. Ә шәхес — бүгенге бер карыш адымын киләчәкнең бер адымы итеп атлый белүче кеше ул. «Маяк»та исә бүгенге бер адым кичәге һәм иртәгәге бер адымга гына тигез. Мондый хәрәкәтне таптану диләр. Урталык. Үсеш акрын. Әйтик, хуҗалыкны орлык, фураж, колхозчыларны икмәк белән тәэмин итәр һәм дәүләткә ашлык сату йөкләмәсен үтәр өчен бер гектар җирдән 25 центнер иген алырга кирәк. Әлегә тотрыклы рәвештә моңа җиткәннәре юк. 360 гектарлы шикәр чөгендере басуының һәр гектарыннан 200 центнер җыйганда гына доход килә. Уңыш төрле елны төрлечә, әле артыграк, әле кимрәк; нәтиҗәдә саннар гел уртада тирбәлә. Тезелешләр арта, әмма моңа пропорциональ тестә дәүләткә әҗәтләре дә артканнан-арта бара. Ә бу аяк-кулны бәйли, мөстәкыйльлекне чикли, мөстәкыйльлек чикләнгән җирдә исә эшкә иҗади мөнәсәбәт мөмкин булмастайга әйләнә. Иҗат булмаса, шәхес юк.

Рөстәм Туктаров идарә итүнең катлаулы, фидакарьлек таләп итүче фәнен үзләштерә генә әле. Без аның белән Норлат бригадасы басуларын әйләндек, ындыр табагына килеп чыктык. Норлат авылы халкы дүрт ай яңгыр әсәре күрмәгән. Җир генә түгел, буа сулары, чишмәләр дә сусап беткән кебек. Без күренер алдыннан гына яңгыр сибәләп, яфраклар битен юган һәм юл тузанын шадралап киткән.

Ындыр табагында смена алмашынган ара. Виканы сортка аералар икән. Фуражга чыкканында бөтен орлыклар, исән солылар калган. Мин менә мондыйрак сөйләшү шаһиты булдым.

— Тагын бер чистартырга кирәк,— дип кушты председатель.— Центнеры 32 сум.
— Нинди иләк аша үткәрергә икән? — дип сорый ток механигы.
— Унберле, унөчле белән.
— Кайда икән соң алар?

Председатель иләкләрнең кайда булырга тиешлеген аңлата.

Бик кызыклы диалог бу. Мондый сөйләшү никадәр аклана икән соң? Иләкләрнең кайдалыгын белү кем вазифасына керә? «Чистартырга кирәк» дип ник аңа әйтмиләр, кушканны көтеп торалар? Мондый ваклыклар председательнең үзәк мәсьәләләрне уйлавына комачауламыймы? Житәкчелек итү стиленең вак мәсьәләләрне шәхси хәл итүгә корылуы да бик ихтимал. Тик сүз чорга яраклы идарә ысулы турында. Һәр сүзе һәм эше якын яисә ерак перспективаны исәпкә алып әйтелә яки эшләнә торган шәхес

була белү хакында. Бер яктан, председательнең иләкләрне күз уңында тоткан булуы хәерле хасияттер — гаилә башлыгы үз йортындагы һәр кадакны исәптә тотса шәп — тик ул вакытта ток механигы нигә? Ә ындырb табагы мөдире, запас кирәк-яраклар складлары мөдире, бригадир, орлыкчылык агрономы? Хуҗалык шактый зур, ә Туктаров, ышануымча, һәр инәнең кайдалыгын хәтерендә тота булса кирәк. Анысы, дөрес, инә белән кое казып була, әмма җитәкчелек фәненең иң беренче бурычы эшне оештыру максатын күз алдында тотудан гыйбарәт ләбаса, иң әүвәл кешеләрне намус белән эшләтерлек итеп тәрбияли, тота белүдән.

Районның «Ватан» колхозы председателе Әгъзәм Хәсәнов кешеләрнең үзләрендәге бөтен потенциаль мөмкинлекне биреп эшләвен дәгъвалый. Ул үзе дә янып, ахырынача җигелеп эшли, башкалардан да шуны ук таләп итә. Баш зоотехник Мансур Исмәгыйлов белән чирек гасырдан артык иңгә-иң таянышып эшлиләр, күпме белгечләренә җитәкче куәсе иңдереп, тирә-күрше хуҗалыкларга таратты. Рөстәм Туктаров — аның шәкерте. «Искра» колхозы председателе Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов та.

«Маяк» колхозындагы белгечләр белән танышканда куанычлы һәм, шикләнми әйтергә була, кабатланмас бер күренешкә тап булдым. Председатель Р. Туктаров үзе генә түгел, партоешма секретаре Р. Сәлахетдинов һәм баш инженер Ә. Ваһапов та күршедәге «Ватан» колхозы егетләре. Кайчан да булса алар үз тормышларының күрше колхозда бер җепкә тагыласын күз алларына китереп карамаганнардыр. Хәер, уйлау гына түгел, шуны максат итеп куйган шәттә дә моңа ирешү җиңел булмас иде. Әйе, кабатланмас, матур бер күренеш. Өчесе дә яшьләр, дәртлеләр, омтылышлылар, уртак максат белән яшиләр. Мондый язмыш очраклы була алмый. Очраклылык дисәң, бу өч җитәкченең тормыш юлларындагы бик күп борылышлар да очраклылыкка кайтып калыр иде. Ата-бабалары эшенә тугры калу, җирне үз тәнеңдәй ярату, кешеләр ышанычын казану аларның охшаш һәм уртак язмышындагы бик закончалыклы маяклар.

Иртән Рөстәм Туктаров Чувашия ягына хуҗалык өчен рәшәткә юнәтергә дип чыгып китте. Үзе...

## 3. Җырланасы җыр

Өермәдәй тузан туздырып, Яңа Тинчәледә бер абзый көпә-көндез капка төбе себереп ята иде. Капка төбе ындыр табагы шайлы, себерә-себерә урам уртасына җитә язган инде. Зиһенем нәрсәнеңдер тиешенчә түгеллеген искәрергә өлгерде. Минем якынлашуымны күреп ул туктап калды, җилпучтай киң учы белән маңгай тирен сыпырып алды.

Хәлен белешеп сүз каттым.

— Ару гына,— диде ул.— Кайчан кайттың?

Ул мине авылдашы дип кабул итте ахрысы. Хәер, авылда чит кеше белән дә җәелеп хәл-әхвәл белешәләр.

— Ай-яй синең йорт-җирең! — дидем мин.

Шуны гына көткән кебек, ул рәшәткә буеннан машина-фәлән үтмәскә аркылы сәлынган юкә бүрәнәгә килеп утырды да, күкрәк кесәсеннән «Феникс» кабы чыгарып, сигаретына ут элде. Мине дә сыйлыйсы килгән иде, тартуны ташлаган чагым, рәхмәт кенә әйттем. Бүрәнә озын булса да читкәрәк шуышып, ул миңа янәшәсендә урын күрсәтте. Утырдым.

— Эштә түгелмени? — дидем мин.

— Урак бездә әллә кайчан бетте инде. Икенче августта ук. Безнекеләр шәп эшли.

— Яши дә белә ахрысы! — дидем мин, тагын аның йортына ишарәләп.

— Зарланмыйм,— диде ул, бөтенләй читкә, аклы-каралы сыер шикелле җәелеп яткан буш кырларга карап.— Авыл кешесенә күпме кирәк соң?

— Йорт-җирең бай күренә, әзгә генә дә канәгать күренмисең әле.

— Соң, кул кушырып утырган юк. Ка семьсот кертеп чабындырырлык мунчам гына бар минем. Диванга ике сыер кереп ятса да, хатын белән миңа гына урын кала

әле. Холодильник шакмак-шакмак боз эшләп тора, тегеннән соң...— ул гөпелдәтеп тамак астына чиртеп алды,— боз килешә икән. Хәзер үз законыбыз, эшли дә беләбез, яши дә.

Абзый, яши белгәнен үзенчә дәлилләргә исәпләп, өйгә кыстый башлады, тик вакытым тар иде, кузгалдым.

Монда беренче карашка барысы да тиешенчә кебек иде. Мин борылып карадым да алай ук түгеллеген абайлап алдым. Зиһенем рәшәсендә туган авылымдагы үз урамыбыз төсмерләнеп алды: бездә дә ишегалды белән капка төбе чүбен урам уртасына себереп түгү гадәткә кергән инде. Әүвәлтен чокыр-чакырга илтеп, тиреслеккә чыгарып түгәләр иде. Абзыйның йорты яңа, капка төбе киң булса да, хәтта кунак итергә теләп кыстаса да, күңеле таррак икән, дөресрәге, сукыррак.

Авыл кешесе таза тормыш белән яши. Күпме яңа йорт җиткезеп кергәннәр, күпме мотоцикл, машина, суыткыч, телевизор алганнар.

Тинчәледә мин былтырлы-быеллы күпме алмагач утыртулары белән кызыксындым. Җавап алу җиңел булмады. Кызык, тормыш матди җәһәттән мулланган саен, авылларда алмагачлар кими. Салкын тиеп корыганнарын әйтмим. Яңармаслармы дип бер ел, ике ел көтteләр дә кисеп ыргыттылар, куллары тимәгәннәренеке хәзер дә корып утыра. Мин мәнә шулар урынына яңалары утыртылмауны әйтәм. Элегрәк, тормыш авыррак чагында, авыллар яшелрәк иде. Хәзер агач яшеллегеннән буяу төсләре күбрәк. «Искра» колхозындагы (Яңа Тинчәле — аның төп авылы) Яңа Чынлы авылы хәзер 80 генә йортлы, бушап калган йорт урыннары акаеп ята, алай да анда агач күбрәк. Тинчәледә колхоз яңа урта мәктәп салдырган, ничәнче ел эшли инде, ә тотып алынган җирендә сыңар агач та юк. Авыл культура йорты (аныcы да таштан, өр-яңа, 350 урынлы) тирәсендә дә шул ук хәл. Шәһәрнекенә биргесез кибет яны да тап-такыр. Быел ике катлы колхоз идарәсе бинасы төзеп кергәннәр, каршыда гына 90 балага исәпләнгән бакча-комбинатка нигез салып яталар. Бөтенесе бергә матур бер урын ташкил иткән. Культура йортындагылар да, мәктәптәгеләр дә агач утыртырга өлгермәдек әле диләр, ә берсе тугызынчы, бүтәне өченче ел эшли инде. Тик шушы тирәдә агач утырту ихтималы искә-өнгә дә килми, күрәсең.

Монда гына шулай булса иде ул! Минем туган авылым Олы Әшнәккә борылган юлда «Туган җиребезне гөлбакча итик!» дигән язу кадаклап куйганнар. Язуы бар, чәчәге генә юк. Эшлиләр — хак, ә чәчәк утыртмыйлар. Җавабы кайда да бер: кул җитми, өлгермибез. Ашханә белән рестораннарда юарга сабын, сөртенергә сөлге элеп куярга да вакытыбыз юк. «Өлгермәү» түгел бу. Бу — бары тик культурасызлык кына. Бер буын өлгерми, икенче буында өлгермәү гадәткә әйләнә. Ә гадәт — тормыш итү рәвеше ул, гадәт традициягә әверелсә, үзгәрми, аны уйламый да башлыйлар, шулай тиеш дип кабул итәлә, күнегелә. Күз иялашкач җан күнегә, ямьсезгә күнеккән җан матурлыкка сукырая. Менә шул чагында ишегалдындагы тиресне, капка төбендәге чүп-чарны урам уртасына себереп ташлау башлана да инде. Урам беркемнеке түгел, янәсе. Әмма урам — бөтенебезнеке, ул авылның көзгесе.

Матур яшәү, мул тору, яхшы ял итү — гаять мөһим социаль казаныш ул. Совет кешесенең хезмәткә хокукы ялга хокук белән ныгытыла. Ялның рухи ягы бар — матурлык дөньясы җимешләреннән файдалану, шул җимешләрне үзең дә үстерешү. Матди ягы бар — куйган хезмәтеңә, туккан тиреңә күрә тән сихәте алу, сәламәтлегең какшаган шәттә дәүләт һәм бөтен халык биргән ял һәм дәвалану мөмкинлекләреннән файдалану. «Искра» колхозы кешеләре кайчандыр мәктәптә укыган географияне хәзер яңадан үтә. Китап битләреннән түгел, байтагының тормыш сәхифәләре хәзер илгә, бөтен дөньяга билгеле географик ноктолар белән бәйле. Геленджик, Цхалтуба, Нальчик, Кимери, Адлер, Боржоми, Ессентуки, Ликани, Васильево, Ливадия, Кавказдагы төрле исемдәге турист базалары һәм башкалар хуҗалык кешеләренең көнкүрешендәге «сервант», «рок группа», «газ» кебек гадәти атамаларга әйләнеп беткән. 1980 елда колхозның ике дистәдән артык кешесе курортларда булып кайткан. Профсоюз оешмасы председателе Гөлфия Хисаметдинова эш өстәленнән яшькелт һәм кызгылт кәгазьләр алып күрсәтә: кемнәрен көтеп ятучы яңа юлламалар. Теләсә кемгә дип җибәрелмәгәннәр, кемнәре билгеле, алдан гариза язып соратылганнар. Быел 8 кеше булып кайткан инде.

Былтыр умартачы Фәния Гыймадиева Сакки курортында ял иткән, тезүче Гомәр Сибгатуллин — Цхалтубада, комбайнчы Җәвит Хәсәнов — Адлерда, сыер савучы Фәһимә Исмәгыйлова — Васильево ял йортында... Бүген дә эшли торган хезмәт һәм сугыш ветераннарына профсоюзларның район советыннан исемнәре язылган махсус юлламалар кайта. Монда эшләгәннең кадерен беләләр, хәтер калырлык, үпкәләрлек урын юк.

Матурлыкка сокланырга вакыт бар. «Вакыт юк», «Өлгереп булмый» дию «Искра» колхозы кешеләредәй уңганнарга килешми. Парлашып курортларга барып, ир хатынына, хатын иренә яңадан гашыйк булып йөрер замана.

Унсигез көнлек ял — бу инде суыткыч алып кую кебек генәме?! Кеше дөнья күрер өчен яратылган ләбаса. Ялга хокукны совет авылы кешесе Конституциябез сәхифәсеннән генә укымый, ТУ-134, ИЛ-62 самолетларының курортларга юнәлгән рейсларыннан күрә. «Искра»да кая гына барсаң да — бушлай. Путевкалары да, юл чыгымнары да. Колхоз фермалары һәм кырларына эшкә чыккан яшьләр башта 250 сумлык ярдәм ала. Быел урта мәктәпне тәмамлаган яшьләрнең күбесе авылда калган.

Өч ашханә эшләп тора, 35 тиенгә — шулпа, гаҗәп хәтсез ит салынган «икенче». Сыер савучылар өчен махсус кибет килеп китә, терлекче йортларында — телевизорлар. Китапханәгә, «Миңа ризык юкмы?» дип, почта ташучы Ясәви Яфизов кебекләр килеп җитә — яңа китап сорый, элеккеләрен укып бетергән. Бирелә 29 исемдәге газета-журнал укый аласың. Уку залы иркен, пөхтә. Китапханәче Әлфия Алиәкбәрованың 1200 даими укучысы бар. (Хикмәт диген: миңа үзе җитәкләгән колхоз хакында атна-ун көн элек газетада чыккан зур мәкаләне укымаган бер председатель белән дә очрашырга туры килгәне бар. Аны уңайсыз хәлдән ындыр табагындагы колхозчылар коткарды: сөйләп бирделәр).

Китапханә каршысында каһарман авылдашлары истәлегенә куелган обелиск бар. Ә төбендә әрем белән алабута үсә. Курортларга юл шуның янынннан үтә.

— Яңаны салачакбыз, зурны,— диде Гөлфия.

Һәйкәлләр — аналар белән бер ул: аларның искесе-яңасы, олысы-кечесе юк, бар да тигез кадер-хөрмәткә мохтаҗ. Дөресрәге, алар бер нигә дә мохтаҗ түгел, һәйкәлләрне кадерләү һәм хөрмәтләү кешеләргә кирәк, моңа алар мохтаҗ. Һәлак яки вафат булганнар исәннәр яшәсен өчен үлгән, исәннәр туасылар тусын өчен яши.

Иясез калган ул обелиск, күзгә кергән чүп сыман, курортларга йөрү хөрмәтенә ия колхозчыларның җанын тырнап тормый микәнни? Матурлык та ике яклы шул: кайберәүләр аның үзенә хезмәт иткәнен, үзе аңлый торганын гына кабул итә. «Ка семьсот кертеп чабындырырлык мунча»лы абзыйның урам йөзен чүп-чар белән җәрәхәтләп куйганы шикелле инде, үзе ашамаган тәлинкәгә төкерсәң дә ярый дигән кебек.

Кешеләребезнең быелгыдай августтагы хезмәт каһарманлыгы, онытылмас җыр булып, байтак гомер хәтердә торыр әле. Аны сөйләрләр, сөйләмичә булдыра алмаслар, сөйләргә тиешләр. Дүрт ай буена яңгыр күрмәгән 81 нче елның хәвеф-хәтәрсез тынычлык, шөкранә муллык, лаеклы ышаныч белән озатылган җәен сабак рәвешендә халык каһарманнарга куелган һәйкәлләргә биргесез төстә хәтерләр. Хәтерләргә ачы әрем генә үсмәсен иде. 81 ченең комбайннары елга буйларында мунча керделәр дә, паркларга тезелешеп бастылар. 81 ченең августы бүрәнәгә тезелешеп, дөнья хәлләрен кузгатып утырган ил агайларын да шул арыган, тузган, мәгәр җиңгән комбайннарга охшатырга куша төсле.

Курортларда «бәрхет сезоны» башланып китәр көннәр җитте. Районның 300 ләп хезмәт кешесе дә шунда юлга чыгар. Аларның курортлардагы иң татлы, горур сүзләре быелгы урак булырына кем икеләнер икән?

Үзенчәлекле урак өстендә Буа районы партия һәм хуҗалык оешмалары әллә ничә семинар үткәрде. Бу елның җәе игенче өчен авыр сынау гына түгел, җитди өйрәнү мәктәбе дә булды. 72 нче һәм 75 нче елгы корылыкларны җиңеп чыккан игенче быелгы елны да тәҗрибә сыйфатында кайта-кайта искә алыр әле.

Эш турындагы семинарлар файдалы, гыйбрәтле уза. Ә шулай да минем Буа рай-

онында Матурлыкка багышланган киңәшмәне дә күрәсем килә. Ирешелгән уңышлар белән беррәттән, сөелми калган яр сыман, утыртылмый калган алмагачлар турында, онытылган җыр булып боегып утырган һәйкәлләр, нахакка җәберләнгән намус шикелле, чүп-чарга күмелгән, техникага таптатылган урамнар, кайгылы күзгә охшап, сүнәр-сүнмәс кенә сулкылдаган ятимә чишмәләр хакында җыелып сөйләшсәсе иде. Шундый мәҗлескә кунак йөзендә чакырыласым килә.

Буа шәһәренең автобус тукталышында элеккеге артиллерист Хәбибулла Хәмзин басып тора. Чүпрәле районының Фрунзе исемендәге колхоз кешесе. Ленинград фронтыннан. Уң кулы, сул аягы юк. Әүвәлге машинасын вакыты узганга язын ук китереп тапшырган да яңасын кайгыртып йөри. Хәленә керергә ашыкмыйлар әле. «Искра» колхозындагы кул тиерергә онытылган обелиск сыман читләтеп, кешеләр автобуска анпан алда кереп китә. Аның аягы астына чәчәкләр куярлыктыр...

Безнең тормышыбызның иске янсә яңа, зур янсә кечкенә обелисклары юк, безнең тормышыбызның тере кешеләргә тиң һәйкәлләре, һәйкәлләргә тиң кешеләре бар. Без шуның белән көчлебез, без шуның белән җиңелмәс, без шуның белән бәхетлебез. Җырларыбыздагы көч, җырларыбыздагы җиңелмәслек, җырларыбыздагы бәхет тә шулар.

Җырланасылары күбрәк әле.

*Буа — Казан*

# Укучының күңел дәфтәренә

**Әфган [пуштун] мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Әгәр суймасаң, әтәчең булам.*
*Оятсыз хатын — тозсыз пешкән аш.*
*Коры утын белән бергә чи агач та тиз яна.*
*Тол хатын ике төш күрә: булган һәм буласы ирен.*
*Ял итү — эш өчен бүләк.*
*Ут белән мамык дус була алмый.*
*Хаклык бар җирдән ялган тиз кача.*
*Күз күздән ояла.*
*Аска төкерсәң — сакал, өскә төкерсәң — мыек.*
*Иләк кувшиннан көлә ди: «Син бит тишекле икән!»*
*Мал — байлык түгел, байлык — йөрәктә.*
*Буш кул белән якга бармыйлар.*
*Эсседә эшлә, салкында аша.*
*Корылмаган бер мылтыктан ике кеше бергә курка.*
*Фәкыйрь мулланың азанын бер кеше дә тыңламый.*
*Тегермән дә начар тарта, бодае да кипмәгән.*
*Тук бодай тегермәнгә килми кала алалмый.*
*Үз башыңдагы чәчне үзең кыра алмыйсың.*

# УҢЫШЛАР БЕЛӘН ТЫНЫЧЛАНМАСКА!

**1972 елның гыйнварында КПСС Үзәк Комитеты «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында» карар кабул иткән иде. Бу карар күпмилләтле совет әдәбияты өчен зур вакыйга булды. Ул әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшләүче бик күп иҗат кешеләрен һәм, гомумән, барлык язучыларны, сәнгать работникларын яңа үрләргә рухландырды, алар өчен тагын да киңрәк мөмкинлекләр ачты.**

**Ә менә безнең республикадагы әдәби иҗат процессына партиябезнең бу мөһим карары ничегрәк тәэсир ясады икән! Шул уңайдан журнал редакциясе бер төркем язучыларга түбәндәге ике сорау белән мөрәҗәгать итте.**

**1. «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карар республикадагы әдәби иҗат процессына ничек тәэсир итте дип уйлыйсыз!**

**2. Безнең әдәби тәнкыйть алдында хәзер нинди кичектергесез бурычлар тора!**

**Язучыларның редакциягә җибәргән җавапларын урнаштырабыз.**

## Мөхәммәт Гайнуллин: «ӘДӘБИ ПРОЦЕССКА ЛЕНИНЧА МӨНӘСӘБӘТ».

1972 елның гыйнварында КПСС Үзәк Комитеты «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында» карар кабул итте. Ленинчыл рухта булган бу карарны барлык совет язучылары шикелле Татарстан язучылары да шатланып каршы алды. Республикабызда әдәбият тәнкыйте мәсьәләләре җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгенә куелды. Бу тарихи карар, беренчедән, республикабызда әдәбият белеме һәм тәнкыйтенең җанлануына, тәнкыйтьчеләребезнең тагын да кыюрак, нәтиҗәлерәк эш итүләренә киң юл ачты. Әдәбиятчыларыбыз һәм тәнкыйтьчеләребез шул карар белән рухланып, илһамланып, яңа дәрт белән эшли башладылар.

Икенчедән, карарны тормышка ашыру өчен кирәк булган мөмкинлекләр киңәйде: газета-журналларыбыз әдәбиятны һәм сәнгатьне өйрәнү-анализлауга караган хезмәтләргә, җеруча тәнкыйть мәкаләләренә, рецензияләргә тиешенчә урын бирә башладылар. Бу, үз нәүбәтендә, төрле жанрда басылып торган әдәбиятка, театрларда — сәхнәдә куелган әсәрләргә объектив бәя бирергә мөмкинлек тудырды.

Барыннан да бигрәк әдәби тәнкыйтьнең сыйфаты яхшырды, фәнни дәрәҗәсе ышандыру көче артты. Әдәбият-сәнгать әсәрләренең идея-эстетик кыйммәтен объектив бәяләгән, үзенчәлекләрен тирәннән аңлап, дөрес күрсәтеп, әдәби зәвык белән язылган мәкаләләр саны артканнан арта барды. Өлкәнрәк буын тәнкыйтьчеләр (Р. Мостафин, Ф. Мусин, Ф. Миңнуллин һ. б.) сафына өметле яшьрәк каләмнәр (Р. Мөхәммәдиев, М. Вәлиев, Р. Кукушкин һ. б.) кушылды. Язучыларның үзләре арасыннан да әһәмиятле проблематик мәсьәләләрне күтәреп чыгучылар (Г. Бәширов, М. Мәһдиев, Д. Вәлиев һ. б.) булдылар һәм алар да әдәби тәнкыйтьне үстерүгә зур өлеш керттеләр.

Бу тарихи карарга кадәр тәнкыйтьчеләребезнең хезмәтләре, хәтта аларның әдәбиятыбыз үсеше өчен бик әһәмиятле булганнары да, газета-журналларда бер мәртәбә басылу белән генә кала иде. Бу хәл, әлбәттә, укытучыларга, әдәбият белгечләренә аларны кабат алып файдалану мөмкинлеген чикли иде. Шулай ук бу хәл тәнкыйть әдәбиятының үсешенә дә мәгълүм дәрәҗәдә комачаулык итеп килде, стимул бирә алмады. Үзәк Комитет карары чыкканнан соң Татарстан китап нәшрияты тәнкыйтьче-

ләр һәм әдәбият белгечләре хезмәтләренә игътибарны көчәйтте. Соңгы 10 елда, еп саен дип әйтерлек, берничә тәнкыйтьче һәм әдәбият белгеченең җыентыклары дөнья күрде. Бу, әлбәттә, республикабызда әдәбият белеме һәм әдәбият тәнкыйтенең үсешенә әһәмиятле стимул булу белән бергә, гомумән, әдәби процессыбызга да уңай йогынты ясады. Шуның белән тәнкыйтьчеләребезнең абруе да үсә бара.

Элек, Үзәк Комитетның бу карарына кадәр булган съездларда, әдәби тәнкыйть турында сүз чыкканда аның артталыгы турында күбрәк сүз барган булса, соңгы съездларда исә әдәби тәнкыйтьнең әдәби процесста тоткан уңай роле, үсеше бик хаклы рәвештә уңай бәяләнеп үтелде. Менә бу уңышларга ирешү Үзәк Комитет карарын тормышка ашыру юлында тәнкыйтьчеләребезнең үз бурычларын тирәннән аңлап, чын күңелдән бирелеп эшләүләре нәтиҗәсендә мөмкин булды.

Без, карт буын, әдәбиятыбызның, әдәби тәнкыйтебезнең соңгы еллардагы үсеше белән горурланабыз, яшьләребезнең әдәби тәнкыйть өлкәсендә кыю һәм нәтиҗәле эш алып баруларын күреп чын күңелдән куанабыз.

Инде бер теләкне дә белдерик: Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан һәм Г. Тукайның әдәби тәнкыйть мәкаләләре эчтәлекләренең тирәнлеге, уйландырырлык философик фикерләргә бай булулары белән аерылып торалар. Безнең тәнкыйтьчеләребезнең дә әнә шундый мәкаләләрен ешрак күрәсе килә.

УҢЫШЛАР БЕЛӘН ТЫНЫЧЛАНМАСКА

## **Фатих Хөсни:** «ЭЗЛӘНӘБЕЗ, ЯК-ЯККА КАРАНАБЫЗ...»

Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы мәгълүм карарыннан соң үткән ун ел, ышанып әйтергә була, бер әдәбият өчен дә эзсез генә узмагандыр. Шул җөмләдән, әлбәттә, татар совет әдәбияты да аның игелекле йогынтысын үзендә кичермәде түгел.

Иң элек бер фактны билгеләп үтәсе килә: илкүләм һәм, мәгълүм дәрәҗәдә, дөнья язмышы белән бәйләнешле зур эшләр алып баручы безнең партиябез әдәбиятның мөһим бер тармагы булган тәнкыйть мәсьәләсенә кагылырга да вакыт тапты. Бу үзе үк игътибарга лаек вакыйга һәм, бер үк вакытта, әдәби тәнкыйтьнең җитди игътибар үзәгендә торырга тиешле бар тармак булуы турында сөйли. Кампания рәвешендә генә түгел, һәр даим игътибар үзәгендә!

Аерым алганда, безнең әдәбият өчен кай яклары белән тәсмерләргә мөмкин соң бу ун елны? Билгеләп үтелергә тиешле якларның берсе: тәнкыйть өлкәсенә байтак яшь һәм өметле каләмнәр килде. Икенчедән, тәнкыйть һәм әдәбият белеме өлкәсендә эшләүче өлкән буын вәкилләре, яшьләрдән калышмаска тырышып, әдәбият белеме һәм тәнкыйть «арбасына» ныклабрак җигелеп эшли башладылар. Бу яктан мин, барыннан да элек, Ибраһим Нуруллинның рус һәм татар телләрендә чыккан «Тукай» китабын күрсәтер идем. «Молодая гвардия» нәшрияты тарафыннан «Данлыклы кешеләр тормышы» сериясендә чыккан бу зур һәм төпченеп эшләнгән хезмәт әлеге унъеллыкның күзгә күренгән һәм горурлык белән күрсәтергә мөмкин булган бер казанышы.

Инде байтактан эшләп килүче Рафаэль Мостафин, Флүн Мусин кебек тәнкыйтьчеләребезнең бездәге тәнкыйть фикерен «өй эчебездә» генә бикләп калдырмыйча, союз күләменә чыгаруда куйган тырышлыклары, шулай ук, игътибарга лаек эшләрнең берсе.

Әйе, билгеләп үтәрдәй эшләребез юк түгел. Ләкин, бер үк вакытта, уйландыра торган яклар да бар.

Тәнкыйть фикеренең тарлыгы, масштаблырак мәсьәләләрнең әле һаман «күтәрелмәгән чирәм» булып кала килүе — әллә соң бу уйландырмаска тиешлеме безне? Менә шул мәсьәләләрдән тагын берсе. Шагыйрь Хәсән Туфан яшәп китте безнең арада. Кызыклы һәм бай яшәү белән яшәп китте. Зур иҗади мирас калдырды. Туфан турында тәнкыйть сүзе бөтенләй әйтелмәде дип булмый, әйтелде. Ләкин ничектер өзек-өзек, очрактан-очракка гына. Хәсән Туфанның бөтен иҗатын колачлап, аның төп асылын ачып салырдай һәм гомумиләштереп әйтелгән сүз булмады. Хәлбуки Хәсән Туфан иҗатыннан без кеше күңеленең барлык нюансларына — күтәрелеш, очы-

ну минутларына да, эзләнү, таба алмыйча өзгәләнү һәм юксыну-сагыш халәтләренә дә тәңгәл туры килә торган юлларны, строфаларны, бөтен бер шигырьләрне күпләп-күпләп табабыз. Шушы бәйләнештә алганда Хәсән Туфанны, һич икеләнмичә, к ү п п л а н л ы ш а г ы й р ь дип гомумиләштереп әйтергә мөмкин. Ә без, шагыйрь үзе исән чагында, мондый гомумиләштерү сүзе әйтә алмадык.

Безнең тәнкыйтьтәге тагы бер җитди кимчелек: әле без һаман да як-якка каран-галап тәнкыйтьләүдән узмыйбыз. Күреп торасың, әйтәсе килә иптәшнең, сүзе дә бар, ләкин тәвәккәллек җитенкерәми. Иң яхшы дигәне: көтү, сабыр итү. Бәлки, кем дә булса бүтән бер кеше әйтер. Менә шундый салкын сабырлык, кешедән көтү, тәвәк-кәллекнең җитмәве, як-якка карангалап эш итү — безнең тәнкыйтьне эчтән кимерә баручы яман шеш түгел микән? Моны, икенче төрле итеп әйткәндә, намуслылыкның җитмәве дип тә атарга мөмкин булыр иде. «Яки әшәкелек, яки намуслылык... ярты-лаш кына намуслылыкның дөньяда булуы мөмкин түгел», ди Лобачевский.

Аның каравы икенче очракта — үз дустыңның чыпчык мае хәтле генә фикер са-лынган урта кул китабын мактаганда без инде тәвәккәллекнең аргы чигенә барып чыгабыз. Үзәк Комитет карарында әйтелгән комплиментарлык турындагы фикерне онытып җибәрәбез.

Әйе, эзләнәбез. Табышларыбыз да юк түгел. Ләкин эшкә җитди карап керешер-гә тиешле якларыбыз да бар әле...

## Аяз Гыйләҗев: «ТӘНКЫЙТЬ УЯУ БУЛСЫН!»

1. Тәнкыйтьнең дәрәҗәсе үсте. Бу үсеш конкрет кешеләрнең эшчәнлегендә бик ачык чагылды. Әдәбиятны аерым кисәкләргә бүлгәләп, ваклап, кечерәйтеп, бары тик үзләренең тар карашларыннан гына чыгып бәяләп килүче тәнкыйтьчеләрнең эш алымнары тиешле бәя алды. Тәнкыйтьне фән дәрәҗәсенә күтәргән, әдәбиятны тоташ һәм өзлексез тере агым итеп карый алырлык әзерлекле яшь тәнкыйтьчеләр мәйдан-га килде. Әгәр без бүген татар әдәби дөньясында Р. Мөхәммәдиев, М. Вәлиев, Р. Ку-кушкин кебек тәнкыйтьчеләребез бар дибез икән, без тулаем әнә шул мәшһүр ка-рарга бурычлы. Тәнкыйтьчеләрнең үз иҗади йөзен халыкка танытып өлгергән шушы буыны артыннан кыю, әзерлекле, принципиаль яшьрәк буын да үсеп килә. Журнал-ларда, газеталарда күренеп-күренеп киткән мәкаләләр, рецензияләр шуны раслый. Гомумән, әдәби тәнкыйть белән әдәбият янәшә, бергә, бер-берсенә уйланырга азык биреп, бер-берсен куәтләп яши башладылар. Тәнкыйть — әдәбиятның көзгесе ролен үтәргә кереште. Тәнкыйть укучы белән әдәбият арасында җитәкче роленә ирешә бара. Мәсәлән, мин үзем тәнкыйтьнең иҗатыма тәэсирен турыдан-туры сизә барам. Кайбер иптәшләрнең мәкаләләре мин абайламаган, мин күрми киткән, мин бәяләп бетермәгән байтак нәрсәләрне ачып салды. Тәнкыйть язучының ярдәмчесе дә бу-лырга тиеш! Үтә субъектив карашлы әрсез эшкуарлардан чын талантларны саклап калу бурычы да тәнкыйтькә йөкләтелгән. Минемчә, безнең тәнкыйтьчеләр бу миссия-не үти башладылар.

2. Мин проза турында сүз алып барырга уйлыйм.

Безнең прозабызны, кызганычка каршы, урта кул әсәрләр басып китте. Дөнья әдәбияты югарылыгыннан торып, совет әдәбияты үрнәкләре белән янәшә куеп караганда безнең романнарыбыз, повестьларыбыз бик нык оттыралар. Без бүселеп чыккан күләмле теләсә нинди проза әсәрен роман дип атый баш-ладык. Романның үз таләпләре барлыгын бөтенләй оныттык. Әдәбият теориясе мәсь-әләләре безнең хәзерге әсәрләребезне укыганда бөтенләй читтә кала. Күп романнар әрсезлек белән генә роман ярлыгы алып басылып чыгалар! Ч. Айтматов, Н. Думбад-зе, Ф. Абрамов романнары янәшәсенә куеп карарлык романнарыбыз юк дәрәҗә-сендә. Без урта кул әсәрләрне «яхшы» дип кабул итәргә өйрәнеп барабыз түгелме? Яшьләребезне дә әнә шул уртачалык зәвыгы күнектерә түгелме?! Яшь прозабызның үтә кыюсыз булуын, акрын кыймылдавын башкача ни белән аңлатырга?! Дөрес, әдә-би процесс катлаулы, әдәбият бер чакта да, Атилла ага Расих әйтмешли, «сөңгеләр-дән генә тормый!» Мәгәр аның сөңгеләре булуы да шарт! Кайбер тәнкыйтьчеләр-

безнең хикәя жанрының торышы белән килешүен дә һич ничек тә аклап булмый. Хикәя жанры да бездә кризис кичерә. Тәнкыйть исә әлегә бу хакта сүз әйтергә кыймады. Гомумән, тәнкыйть әдәби процессның турылыгын билгеләп баручы компас дәрәҗәсенә ирешергә тиеш.

Заманыбыз катлаулы, заманыбыз язучыларга искиткеч зур бурычлар йөкли. СССР язучыларының VII съездында без әдәбиятның нинди зур, мәгърур көч булуына ышанып кайттык. Димәк, гомум эшебездә без дә артта калырга тиеш түгел. Әдәбиятыбызның көчләре бар, тик ул көчләрне туктаусыз эштә, хәрәкәттә, көрәштә күрәсе иде. Әгәр язучыга канәгатьлек хисе килә икән, бу аның өчен һәлакәт минутлары! «Кайгылы йөрәктә май булмый!» дигән Г. Кандалый! Ә безнең байтак йөрәкләрне май басып бара түгелме? Без бер-беребезне макташабыз, әсәрләрдән булмаганны да казып чыгарабыз. Кайбер тәнкыйтьчеләребез дә шундый ук юлда торалар.

Тәнкыйть уяу булырга тиеш. Уяу! Яхшылыкны да, яманлыкны да ул бердәй җитезлек белән күреп алсын иде. Шул чагында гына әйбәт әсәрләр белән рәттән, матур киемнәргә төренгән, әрсез һәм төче халтура да үз бәясен һәм кискен хөкемен алыр иде! Дөрес итеп һәм үз вакытында бирелгән бәһа, бердән, язучының үзе өчен ифрат мөһим булса, икенчедән, укучылар массасы алдында әдәбиятыбызның сугышчанлыгын ныграк һәм ачыграк күрсәтә алыр иде!

Онытмыйк: тәнкыйтьнең торышы әдәбият үсешен билгели торган мөһим һәм төп факторларның берсе!

## Ибраһим Нуруллин: «СҮЛПӘНӘЙМӘДЕКМЕ ИКӘН?»

1. Теләсә нинди карар, аңнарны биләп алса, аны тормышка ашыручылар күңелендә даим яңарып торса һәм үтәлеше өчен җаваплы кешеләрнең һәрвакыт күп астында һәм күз уңында булса гына җитди көчкә әверелә. Әдәби хәрәкәтебезнең мәгълүм карар чыкканнан соңгы өч-дүрт елы әнә шуны бик матур раслады. Төрле мәҗлесләр һәм матбугатта җанлы сөйләшү, фикер алышулар башланды, әдәби тәнкыйтьнең казанышларын барлау, кимчелекләрен һәм йомшак якларын ачып салу, яхшырту өчен чаралар билгеләү юнәлешендә күп кенә эшләр башкарылды.

Нәтиҗә дә үзен озак көттермәде. Танылган тәнкыйтьчеләр активлаша төште, яшьләр белән эшләүнең яхшыруы сәбәпле талантлы яшьләр килде. Тәнкыйть эшләклерәк төс алды, тирәнәйде, уңышларга карата сизгеррәк, кимчелекләргә карата түземсезрәк булып китте. Бәхәс һәм дискуссияләр гамәлгә керде. Әдәби тәнкыйтьнең «палитрасы» да байый төште, жанр ягыннан төрләнде.

Хәтерем алдамаса, гомере буе артта калуда гаепләнеп килгән татар совет тәнкыйте шушы вакыт аралыгындагы зур мәҗлесләрнең берсендә ниһаять мактау сүзе ишетте.

Ләкин кызганычка каршы, соңгы биш-алты елда әдәби тәнкыйть өлкәсендә эш сүлпәнәя төште. Безнең тәнкыйть карарга кадәрге хәленә кайтты диярлек. Бәхәс кимеде, мактау һәм макташулар шактый артты, як-якка карагып, ул-бу булмагае дип эш итү гамәлгә керде. Әдәби хәрәкәттә, гомумән, ниндидер тынлык, тынычлык сизелә башлады.

Сәбәп, күрәсең, атта да, тәртәдә дә. Без, тәнкыйтьчеләр, карарның күп кенә мөһим күрсәтмәләрен оныта төштек шикелле. Бу документны, табып алып, күздән кичерергә иренә башладык булса кирәк.

2. Кичектергесез бурычлар? Аз түгел алар.

Барыннан да элек, әдәби тәнкыйть үз-үзен, үзенең бурычларын дөрес аңларга тиеш. Югыйсә без һаман әле «нәрсә ул әдәби тәнкыйть?» «аның үзенчәлеге нидән гыйбарәт?» «кемгә адреслана ул?» дигән өч нарат арасында адашып йөрибез.

Кистереп әйтергә кирәк: тәнкыйтьнең төп адресаты — меңләгән укучылар. Төп бурычы — шул укучылар массасын иҗтимагый-политик һәм эстетик яктан тәрбияләү. Моннан аның спецификасы килеп чыга.

«Кыйссаи-Йосыф» турындагы мәкалә әдәби тәнкыйтькә карамаган кебек, яңа гына табадан төшкән әсәрнең эчтәлеген кыскача сөйләп биргән аннотация дә тәнкыйть кысасыннан читтә тора. «Фәлән әсәрнең теле» яисә «...композицион үзенчә-

леге» тибындагы мәкаләләрне әдәби тәнкыйтькә кертеп карау шулай ук дөрес түгел.

Әдәби тәнкыйтьнең предметы — бүгенге әдәби процесс, бүгенге язучы, бүгенге әсәр. Методы — шушы өч нәрсәне социаль-иҗтимагый, әхлакый һәм әдәби факторлар белән тыгыз бәйләнештә тикшерү, икенче төрле әйтсәк, иҗтимагый һәм әдәби контекст эчендә бербөтен итеп күрсәтү. Хәтта аерым бер әсәргә багышланган мәкалә яки рецензиядән дә кимендә ике бәйләнештә карау таләп ителә. Тормыштагы нинди социаль һәм әхлакый үзгәрешләр тәэсирендә туган бу әсәр? Әдәби процесста ул нинди урын тота? Социологик һәм эстетик анализның органик берлегеннән башка әдәби тәнкыйтьне күз алдына китереп булмый.

Фикерне укучыга җиткерүнең алым һәм чаралары ягыннан тәнкыйть күпмедер дәрәҗәдә матур әдәбиятның үзенә якын торырга тиеш. Тәнкыйть мәкаләсе, әдәби әсәр кебек үк, киң катлау укучылар тарафыннан яратып укылсын. Укылмый икән — тәнкыйть бушка әйләнә, ул — юк.

Тагын нинди бурычлар? Һын тәнкыйтьнең аерылгысыз сыйфаты булган фәннилек, объективлык, принципиальлек кебек билгеле материяләр турында сүз озайтырга хаҗәт юк. Тәнкыйтькә йөкләнә торган бер мөһим бурычка гына тукталмый ярамый. Ул да булса — оперативлык. Укылып беткән һәм онытыла язган әсәр турында мәкалә язудан яисә әдәби процесс турында әйтелгәнне кабатлаудан мәгънә юк. Тәнкыйтьче берничә адымга гына булса да, укучыдан алдарак барырга тиеш.

Бер генә әсәр дә рецензиясез калмасын, дигән лозунгка мин шикләнеп карыйм. Чөнки бу реаль түгел һәм кирәге дә юк. Кайвакыт дәшми калу — үзе тәнкыйть. Әмма бик үк еш тумый торган югары художестволы әсәрләрне күрми калу яки соңгарып абайлау — гафу ителмәслек хәл. Чөнки әдәби процессның закончалыклары шундый әсәрләр аша уза. Бу бәйләнештә уңышларыбыз юк димәс идем. Мисал өчен олылардан Р. Мостафинны, яшьләрдән Р. Мөхәммәдиевне күрсәтергә мөмкин.

Ләкин бит, һәр замандагыча, хәзер дә уртакул әсәрләр күпләп чыгып тора, ара-тирә халтура да күренгәли. Бу очракта безнең тәнкыйть өлгерлек күрсәтми генә түгел, өркеп кала, дәшми калу җаен карый. Моның өчен тәнкыйтьчеләрне, билгеле, гафу итеп булмый. Шул ук вакытта алар хәленә дә керми ярамый.

«Уртакул» авторлар гадәттә бердәм булалар. Тавышлары ачы, демагогиягә осталар. «Тәнкыйть объектив һәм иптәшләрчә булырга тиеш» дигән булып, алар тәнкыйтьчене тенденциозлыкта, шәхси исәп-хисапта яисә башка нәрсәдә гаепләргә тырышалар.

Боларны мин каләмдәшләремне өркетү, тәнкыйтьтән биздерү өчен түгел, бәлки җәмәгатьчелекнең игътибарын мәсьәләнең тагын бер ягына юнәлтү өчен әйтәм. Әдәбиятыбызның киләчәге өчен янып-көя торган тәнкыйтьчеләр исә моңа карап үз эшләрен ташламаслар!

## Туфан Миңнуллин: «ӘДӘБИЯТНЫ САКЛЫЕК!»

*Агай-эне ак мыек*
*Бер-беребезне какмыек.*

(Халык җыры)

Әдәби тәнкыйть мөстәкыйль жанр буларак кайчан формалашкандыр, белмим. Әмма аның әдәбиятның башлангычы булган халык иҗаты әсәрләре белән бер үк вакытта туганына шигем юк. Чөнки кем дә булса җыр чыгарган икән, ул җырга бәя бирүчесе шунда ук табылгандыр. Бер акыллы агай: «Җырлама шул җырыңны, аның мәгънәсе юк, тозсыз җыр» дигәндер, әйбәт җырны исә үзе дә җырлагандыр. Җырны күтәреп алырга башкаларны да өндәгәндер. Әдәбият әдәбият булып җитлеккән чакларда да, теге яки бу әсәргә бәя бирүчеләр табылган. Әдәбият үсү белән бергә тәнкыйть тә үскән. Кем белә, бәлки киресенчәдер, тәнкыйть үскәнгә әдәбият үскәндер? Бик күп танылган тәнкыйтьчеләрнең исемнәрен атап тормастан, мәшһүр Белинскийның рус әдәбиятын үстерүдәге ролен әйтеп китсәк тә җитә.

Тәнкыйть кирәкме, кирәкмиме дип бәхәсләшүнең урынсыз, мәгънәсез сөйләшү икәне инде күптән расланган. Татар әдәбияты өчен тәнкыйтьнең зарурлыгы мәсьәләсен бөек Тукаебыз 1907 елда ук язып чыккан. Хәзерге вакытта сүз тик әдәби тәнкыйтьнең ролен үстерү турында гына бара.

КПСС Үзәк Комитеты карары нәкъ үз вакытында дөнья күрде, әдәбият тәнкыйтен тагын да үстерүдә искиткеч зур этәргеч ясады. Шикләнми әйтергә мөмкин — безнең тәнкыйтьчеләребез елдан-ел остара, профессиональләшә баралар. Теге яки бу әсәрне чүп дип атап, аны язучыны ахмак диючеләр, ходайга шөкер, бетте. Фәнни исбатлау, төгәл логика, кешеләрчә такт белән эш итәләр тәнкыйтьчеләребез.

Ләкин мин тәнкыйтьчеләребезне мактау белән бергә, аларга әз-мәз дәгъва белдерергә дә уйлыйм. Минемчә, безнең бүгенге әдәбият тәнкыйтебез ат арбасының артына асылынган чиләкне хәтерләтә. Үзе төшеп тә калмый, үзе бик кирәк тә (күчәрләрне майлар өчен дегет салынган була анда), әмма ул ни әйтсәң дә арба артына асылынган. Безнең тәнкыйтебез дә әдәбиятның башка жанрларына ияреп кенә бара сыман тоела. Басылган тәнкыйть мәкаләләренең барысында да бер уртаклык бар кебек: фәлән язучы фәлән әйбер язган, фәлән турында, фәлән ягы яхшы, фәлән ягы җитешми. Бу гына аз, минемчә. Тәнкыйть — ул әдәбият корабының компасы. Ул китапны укучыга да, аны язучыга да юнәлеш бирерлек хәлдә камил, төзек булырга тиешлеген онытып җибәрмибезме? Тәнкыйтьче үзенең белеме, эрудициясе ягыннан язучыдан бик күпкә өстен булырга тиеш дип саныйбыз. Бездә ул шулаймы?

Тәнкыйтьченең иң беренче бурычы — әсәрне генә түгел, ә бәлки авторның эстетик зәвыкларын, дөньяга карашларын да яхшы аңлау. Мин, мәсәлән, «фәлән язучы үзенең фәлән әсәрен ни өчен язган?», «нинди факторлар мене шушы әсәрне язарга мәҗбүр иткән?» дип сорау куйган һәм шул сорауга җавап таба алган тәнкыйтьчене, хәтта мине тәнкыйтьләсә дә, дус күрер идем. Язучы күтәргән проблеманы ул тәнкыйтьче күзлегеннән тагын бер кат анализлап чыкса, барыбызга да файда, ләбаса. Бәлки мин, язучы буларак, проблема дигән булып вак нәрсәләр тирәсендә буталамдыр? Бик матур гына итеп эләктереп алсын да мине, тәнкыйтьче: «Агай-эне, эт мыек, бер-беребезне какмыек. Шулай да әдәбият изге нәрсә, аны бергәләп саклыйк!» дисен. Минем ачуым килер килүен, әмма бик шәпләп аңлатып биргәч, гафу үтенермен дә, уйлабрак язармын. Яки язуымны бөтенләй ташлап, бүтән эш белән шөгыльләнә башлармын. Тик син миңа әйбәт итеп әйт, аңлашылырлык итеп. Күсәк белән башыма сукма. Әйдәле, шулай эшлик! Ярдәм ит миңа, тәнкыйтьче. Мин синең ярдәмеңә мохтаҗ. Чөнки мин җырымның мәгънәсез булуын теләмим, аны күтәреп алып җырлауларын телим.

## Рафаэль Мостафин: «ТОРМЫШ ТУРЫНДА УЙЛАНЫЙК!»

Бу карарның республикабыз әдәби иҗат процессына ясаган шифалы йогынтысы турында миңа күп мәртәбәләр язып чыгарга туры килде. Әйе, һич шикләнүсез әйтергә мөмкин — аның файдасы бик зур булды һәм моны барыбыз да бик яхшы сизде. Ләкин без шуңысын да истән чыгармыйк: бу карар озак елларга исәпләнгән хәрәкәт программасы, ул кыска бер чор өчен генә түгел. Әнә шуңа күрә карарда әйтелгән бер фикергә — әдәби тәнкыйтьнең тормыш белән элемтәсен ныгыту кирәклеге хакындагы күрсәтмәгә ныграк тукталырга уйлыйм.

Без күп кенә очракларда тәнкыйтьне әдәбиятның үзаңы дип кабул итәбез. Бу билгеләмә, әлбәттә, дөрес, ләкин ул тулы түгел. Чөнки болай караганда, әдәби тәнкыйтьнең бурычы әдәбиятның эчке мәсьәләләре белән генә чикләнә, ул саф әдәби мәсьәләләр белән генә шөгыльләнергә тиеш сыман килеп чыга. Ә минемчә, әдәби тәнкыйть — ул тормышны танып-белү чарасы. Әдәби әсәрне тулы һәм тирән аңлау юлы белән танып белә ул тормышны.

Һәм шулай ук әдәби тәнкыйть ул тормышка тәэсир итү чарасы да. Ул әдәби әсәрләр белән бергә, алар белән берләштә тәэсир итә тормышка.

Ә ничек, ни рәвешле тәэсир итә?

Минем уйлавымча, бу тәэсир укучының эстетик зәвыгын тәрбияләү, аның дөньяга карашын һәм әхлак нормаларын формалаштыру аша бара.

Соңгы елларда безнең тәнкыйть фәнни һәм методологик яктан ныгыды. Әмма шуның белән бергә аның бер йомшаклыгы да ачыграк күренә башлады — ул уку өчен күңелсез, төссезрәк икән, аның тәэсир итү көче азрак икән. Бөтен жанрлар да әйбәт, бары тик күңелсез жанр гына начар икәнен без инде беләбез. Мәнә шушы сүз әдәби тәнкыйтькә дә караганын истән чыгармасак икән. Чыннан да, әгәр дә авторның язганын кызыксынып укып булмый икән, аны укырга күңел тартып тормый икән — андый кешенең югары эрудициясеннән нинди файда бар соң?! Минемчә, андый язмаларның тәэсир көче нульгә тигезләшә.

Соңгы елларда без әйберләрне үз исемнәре белән атап, акны ак, караны кара дип сөйләшүне оныттык шикелле. Без еш кына очракларда әйбәт әдәби әсәр турында да һәм урта кул язмалар хакында да бер төсле итеп, бердәй тыныч, шома тел белән язабыз. Хәтта, әйберләрне дә исемнәре белән атамыйча язуга күнеккән аерым тәнкыйтьчеләр дә пәйда булды шикелле. Аларның мәкаләләрендә төрле терминнар, төрле катлаулы сүзләр бик күп, ә менә әсәр яхшымы яки начармы дигән иң гади сорауга җавап табып булмый. Шулай ук әлеге әсәрнең әдәби процесстагы урыны хакында да дәшми үтә автор.

Билгеле, мин бу фикерем белән тәнкыйтьчеләрне кискен һәм аяусыз эш итәргә чакырмыйм. Бары тик әле һаман очрый торган һәм партия карарында басым ясап әйтелгән «комплиментарлык» турында гына кисәтергә телим. Чөнки безнең әдәби тәнкыйтькә ул һаман комачаулап тора әле.

Әдәби тәнкыйтьне фикере ягыннан ачык, сәнгатьчә эшләнгән һәм төпле, гадел итеп күрәсем килә минем.

## Мөхәммәт Мәһдиев: «ЭШЛӘРЕБЕЗ КҮП ӘЛЕ...»

1. Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары минем өчен бик шатлыклы һәм әһәмиятле булды. Шул карар нигезендә безнең матбугатта әдәби тәнкыйть җанланып китте. Журналларда һәм нәшрияттә әдәби тәнкыйтькә күбрәк урын бирелә башлады. Ниһаять, тәнкыйтьче белән исәпләшү дәрәҗәсе күтәрелде. Югыйсә, язучылар арасында, «үзе язып та булдыра алмагач, тәнкыйтькә тотынган» дигән караш яшәп килә иде. Дөрес, татар әдәбияты 40—50 нче елларда андый тәнкыйтьчеләрне дә күрде, әмма соңгы ун елда безнең әдәбиятта киң карашлы, безнең әдәбиятны бөтенсоюз әдәбияты югарылыгында үлчи торган тәнкыйтьчеләр төркеме тәрбияләнеп үсте. Кайбер тәнкыйтьчеләр шул яңа атмосферада арткы планда калдылар. Аннан соң КПСС Үзәк Комитетының бу карары бик тормышчан, эшкә этәрүчән булып чыкты: тәнкыйтьчеләр бу карарның теге яки бу положениеләренә таянып кыюрак эш итәргә өйрәнделәр.

2. Шулай булуга карамастан, безнең әдәби тәнкыйть өлкәсендә кичектергесез бурычларыбыз байтак әле. Арадан берсе — рецензияләрнең бик бертөрле булуы, проблемалар куелмавы, ә гадәттәгечә — шәрехләп бирү. Безнең күп кенә рецензияләребез шәрехләп, сөйләп чыгудан гыйбарәт.

Аннан соң безнең тәнкыйтьтә, башлыча прозага караган мәкаләләрдә, поэтика мәсьәләләре бер дә күтәрелми. Русларда бу инде аерым жанрлар буенча гына түгел, аерым чорлар, аерым язучылар буенча да эшләнеп килә. Бездә аерым язучыларның иҗат алымнары да өйрәнелми тора. Журналларда басылып чыккан иҗат портретлары бик тә бер төсле, бездә бөтен язучы — бер төсле.

Мәктәп дәреслекләренә, хрестоматияләренә кергән әсәрләр, язучылар турында да уйланырга бик вакыт. А. Гыйләҗев, Т. Миңнуллин, Р. Мостафин кебек язучылар дәреслеккә урын алырга тиешләр. Шагыйрьләр дә хәзер бик яңарды. 30—40 ел буе гел бер үк шагыйрьләрне генә укытып килү миңа, мәсәлән, бер дә аңлашылмый. Мәктәп дәресләренә 1940 елны ук кертелгән хикәяләр әле бүген дә әдәбият йөзен билгеләп килләр, дәреслекләр заман йөзен чагылдырмыйлар.

Менә шулар турында нык уйланырга иде.

## Зөлфәт: «ӘДӘБИЯТНЫҢ КЫЛЫЧЫ ҺӘМ КАЛКАНЫ...»

Тәнкыйть әсәрләрен чын әдәби әсәр итеп күрәсе, укыйсы килә. Дөрес, тәнкыйть фәнни нигезләнгән булырга тиеш. Ләкин бездә, нишләптер, күбесенчә әдәбиле<не фәннилек күмеп китә, яки, киресенчә, фәнни сайлык псевдоәдәбилек белән каплаштырып куела.

Әдәби тәнкыйтьне язучы белән укучы арасындагы бер күпер итеп кенә күрәсе килми. Рухи дөньядагы һәрбер талпынышны, һәрбер янарышны үзенә туплаган, шуларның иң ачык һәм дөрес чагылышы булган сәнгати гадел көч итеп күрәсе килә аны. Укучылар да бүген тәнкыйтьчене «язучылар язганны тәнкыйть итеп йөрүче» дип кенә кабул итмиләр бит. Тәнкыйтьнең башка жанрлар шикелле үк әдәбият һәм сәнгать организмындагы сизгер нерв булырга тиешлеген һәркем белә. Шуңа күрә укучы әдәби тәнкыйтьтән күпне көтә.

Тәнкыйтьне һаман бер үк мәгълүм исемнәр тирәсендә йөрткән «әйләнчекле<» чиреннән дә савыгып барабыз бугай. Тәнкыйтьнең ул чирдән тизрәк котылуын күрәсе килә.

Тәнкыйть, әлбәттә, әдәби үсешнең кылычы һәм калканы. Кызганычка каршы, безнең тәнкыйтьтә кылыч урынына калкан, калкан урынына кылыч куллану очраклары шактый.

Һәм тагын да күңелсезрәге, шактый әсәрләр калканнан мәхрүм калып ялгызы гына көрәшергә мәҗбүр була, ә кылычка лаеклылары тыныч кына яши бирә.

Яшь буын тәнкыйтьчеләренең соңгы вакыттагы кайбер чыгышлары күңелләрдә зур өмет уята, әлбәттә.

Ләкин, шулай да ничә еллар «затлы ризыкка» — зур һәм чын тәнкыйтькә «ач» яшәгән әдәбиятыбыз тәнкыйтьтән канәгать дәрәҗәгә җитте дисәк, һич тә дөрес булмас иде.

Күп, һай бик күп кирәк әле!

## Ринат Мөхәммәдиев: «ҺӘММӘБЕЗ КАЙГЫРТЫРГА ТИЕШ»

Партия Үзәк Комитетының әдәбият-сәнгать тәнкыйте эзмышы турында атзларча кайгыртуының ачык мисалы булган мәгълүм карар әле генә кабул ителгән иде кебек. Инде тәгәл ун ел вакыт үтеп киткән — озак елларга карап төзелгән документның бүген түгәрәк датасын искә алабыз. Бу карарның әдәби тәнкыйтебез үсешенә һәм бер үк вакытта әдәби хәрәкәткә булган уңай йогынтысы хакында икеләнми сөйләргә була. Әдәби тәнкыйтебез теория һәм методология күзлегеннән бай һәм тирәнәя төшү белән бергә, әдәби процесс һәм әдәбиятның тормышка мөнәсәбәтен яктыртуда, иң яхшы казанышларыбызны пропагандалау юлында игътибарга лаек уңышларга ирешә. Матбугат органнарыбызның һәм китап нәшриятының да әдәби тәнкыйтькә мөнәсәбәте күзгә күренеп яхшыру ягына барды.

Ә инде Р. Мостафин, Ф. Мусин, Т. Галиуллин кебек үзәккә җигелеп эшләүчә тәнкыйтьчеләребез сафына иҗат индивидуальлегенә ия бер төркем яшьләр — яшь тәшләрнең килүе, мактану булмасын, урынлы рәвештә аерым билгеләп узуга лаеклы факт. Мансур Вәлиев һәм Фуат Галимуллин, Равил Кукушкин һәм Салих Маннапов лар тәнкыйтьне кәсеп итеп түгел, намус һәм фидакарьлектән башланган игелекле иҗат эше санап, аның кыенлыкларын ачык аңлап килүчеләр. Хәер, килүчеләр дию бигүк дөрес тә булмас, алар инде килгән, иҗатта үз темаларын, стильләрен табып бүгенге әдәби хәрәкәтебезнең иң җитди проблемаларын күтәреп чыгарга сәләтле һәм күтәреп килүче тәнкыйтьчеләр.

Әмма, күтәрелмәгән чирәм, әле, ай-һай, байтак. Канәгатьләнү хисе белән кул кушырып утырырга әле бик иртә. Әдәби тәнкыйть алдында заман куйган проблемалар, перспектив бурычлар партиябезнең тарихи XXVI съезды документларында ап-ачык билгеләнгән.

Иң элек, тәнкыйтебезнең әлегә әдәби процессның регистраторы функциясе белән артык мавыгуы борчый. Анализлау, бәя бирү һәм кире кагу — тәнкыйтьнең

изге бурычы. Әмма болар гына аз, болар гына булганда аның әдәби иҗат эше икәнлеген дә исбат итү шактый кыен булыр иде. Чынбарлык — иҗади шәхес — әдәби әсәр — укучы һәм тамашачы — чынбарлык. Иҗат эшенең, әдәбиятның әлеге буыннары тәнкыйтебездә әлегә тулы чагылыш табып анализлана килә дип раслау мөмкин түгел. Мәгәр аның олы миссиясе шушы звеноларның аерылгысыз бөтенлеген танып, үзләрен бер дәрәҗәдә колачлый алуда. Бары шул чакта гына тәнкыйть үзенең әдәби процесска юл ярып бару функциясен тулысынча үти алачак. Бары шул чакта гына тәнкыйть хакында үткәнгә борылып түгел, ә киләчәккә үрелеп искә алачаклар. Тормыш һәм әдәбият күренешләрен үсештә, перспективада күрергә омтылу — бүгенге тәнкыйтебез алдында торган беренче бурыч дип саныйм.

Тәнкыйтебезгә принципиальлелек җитми. Һәм бу тәнкыйтьчеләр адресына даими рәвештә әйтелә килгән кимчелек. Әмма монда бер алар гына гаепле микән?! Тарихтан һәм соңгы елларда иҗат итүче әдипләрдән, белмим кайсы, ничәсе, үз адресына әйтелгән тәнкыйть сүзен аек акыл һәм ихлас күңел белән кабул итте микән? Кайсы шагыйрь, кайсы прозаик үзенең теге яисә бу әсәрендәге уңышсызлык һәм җитешсезлекләргә күрсәтеп узган тәнкыйтьче каршына килеп, аның кулын кыскан икән? Турысын әйткән — туганына ярамаган, дигәндәй килеп чыккан очраклар сирәк түгел шул, кызганычка каршы. Ә бит югары культуралы, киң күңелле һәм бай рухлы әдип өчен принципиаль тәнкыйтьне кабул итү, инде алай түгел дип тапкан очракта да аек акыл белән фикер йөртү мөмкин булган эш. Менә шушы хәл тәнкыйтебез үсешенә даими рәвештә аяк чала килә. Менә шушы күренеш сәләтле генә тәнкыйтьчеләрне юлдан яздырып, каршылыксыз, җиңел иҗат юлына йөз тотуга этәргеч ясый. Нәтиҗәдә, тәнкыйтьче аерым шәхесләргә «хезмәт итүче»гә әйләнеп кала, өзлексез яза торса да, фикер йөртергә сәләтле укучы өчен эзсез югала. Ә принципиальлелеккә чакырулар дәвам итә. Үз иҗатына яисә аерым әсәренә карата әйтелгән принципиаль бәяне кабул итмәгән каләмдәшләр, уңга-сулга карамый, принципиальлелеккә чакыралар... Тәнкыйть һәм тәнкыйтьчене сыный торган проблемалы ситуацияләрнең берсе шундый. Ә уйлана һәм саный китсәң алар байтак әле.

Әдәби процесстагы һәм әдәбияттагы күп кенә җитешсезлекләрне тәнкыйтьтән күрү тенденциясе дә сүнәргә җыенмый. Бигрәк тә укучы алдында таныла, укучы күңеленә үз була алмый газапланган каләм ияләренә хас бу. Үзләрен тәнкыйтьтән югары хис иткән, таләпчән һәм принципиаль тәнкыйть сүзен җиткерү көннән-көн кыенлаша барган авторларның саны үсү дә борчу уята. Матбугат органнарыбыз да, аерым очракларда, моңарга юл куя килә. Һәм нәтиҗәдә, әлеге күренеш әдәби тәнкыйтьтә критерийларның күзгә күренеп төшүенә китерә. Әдәби продукцияне укучыларның киң катламына тәкъдим итүдә җаваплы кешеләрнең кайвакыт тәнкыйть сүзенә колак салып җиткермәве, тәнкыйть күрсәткән кимчелекләре бөтенләй искә дә алынмаган йомшак язмаларның дөньяга чыга килүе дә әдәби тәнкыйтьнең җәмәгатьчелек алдындагы абруена суга.

Димәк, әдәбиятның үзаңы булган тәнкыйтьнең үсеше өчен без һәммәбез бер дәрәҗәдә кайгыртырга тиеш булып чыгабыз.

Мансур Хәсәнов,
филология фәннәре докторы, профессор

# ӘЙДӘ ХАЛЫККА ХЕЗМӘТКӘ!

Партиябезнең XXVI съездында Леонид Ильич Брежнев: «Әйе, совет кешеләре иртәгәге көнгә ышаныч белән карый... Хезмәтнең көченә ышанганга күрә, без — оптимистлар. Үз илебезгә, үз халкыбызга ышанганга күрә, без — оптимистлар. Үз партиябезгә ышанганга, ул күрсәткән юлның бердәнбер дөрес юл булуын белгәнгә күрә, без — оптимистлар!» — дигән иде.

Кешегә ышаныч, киләчәккә ышаныч — дөньяга карашыбызның үзәген тәшкил иткән, тарихның катлаулы хәрәкәтен фәнни-материалистик аңлауга нигезләнгән иң мөһим фактор. Әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен сугарган кешелеклелек пафосы, тарихи оптимизм рухы да — дөньяга әнә шундый якты өмет, ныклы ышаныч белән карау нәтиҗәсе ул. Социалистик реализм әдәбиятының төп сыйфат үзенчәлекләреннән берсе — коммунистик идеаллар белән янып яшәү, үткән һәм бүгенге эшләребездә киләчәк көннең яралгыларын күрә белү, һәм ул заман чынбарлыгында ныклы нигез таба. Әлеге чынбарлыкның иң характерлы билгеләре — революция һәм яңа тормыш җырчысы Такташ әйткәнчә, «яңа чор, яңа кеше өчен зур дау алып бару», кешеләр арасындагы иҗтимагый һәм шәхси мөнәсәбәтләрнең өзлексез камилләшә, яңа сыйфатлар белән байый баруы.

КПССның чираттагы форумында җәмгыятебез үсешенә кагылышлы барлык социаль-экономик мәсьәләләр асылда бөтен кешелек язмышы белән бәйләп, киләчәк һәм кеше интересларын күздә тотып тикшерелде. Ил тормышының төрле аспектларына караган әһәмиятле гомуми перспективалар һәм бурычлар һәркайсыбызның хезмәт эшчәнлегенә, яшәү шартларына турыдан-туры кагылган кебек, әдәбият-сәнгать, әдәби-эстетик фикер үсешенә дә һичшиксез зур йогынты ясый. Отчет докладының өченче бүлеге — хезмәткә яңа мөнәсәбәтне ныгыту, сәламәтлек, белем һәм тәрбия мәсьәләләре, совет кешеләренең тормыш шартларын яхшырту турында партиянең даими кайгыртучанлыгын чагылдырган бүлек — әдәбият-сәнгать эшлеклеләренә аеруча якын. Бу бүлектә социалистик яшәү рәвеше нигезләрен ныгыту, җәмгыятебезнең рухи тормышын баету, яңа тип шәхес формалаштыруда әдәбият һәм сәнгатьнең роле һәм әһәмияте ачык билгеләнә. Гомумән, докладтагы, XXVI съездның башка документларындагы әдәбият-сәнгать үсешенә кагылышлы положенияләр иҗат союзлары, гыйльми үзәкләр, матбугат органнарының озак вакытлы, фәнни нигезләнгән эш программасы буларак кабул ителә. Съезд әдипләр алдында яңа иҗат офыклары ачты, аларның игътибарын колачы һәм тарихи яңалыгы белән аерылып торган катлаулы бурычларны үтәүгә юнәлтте.

Леонид Ильич Брежнев иҗат работникларының хезмәтен югары бәяләп, «совет сәнгатендә яңа бер дулкын күтәрелүен» билгеләп үтте. Шуның белән бергә, ул «художникның үз халкы алдындагы югары җаваплылыгына» аеруча басым ясап әйтте: «Тәнкыйтьчеләребез, әдәби журналларыбыз, иҗат союзларыбыз һәм, беренче чиратта, аларның партия оешмалары теге яки бу якка сугылучыларны төзәтә белергә тиешләр»,— дип белдерде. Отчет докладының әдәбият-сәнгатькә багышланган бүлеге «профессиональ бәя бирү — әдәбият тәнкыйтьчеләре һәм сәнгать белгечләре эше» дигән сүзләр белән башлануында да тәнкыйтькә зур ышаныч, аның әһәмиятлелеге

ассызыклана. Шул рәвешле, XXVI съездның әдәбият һәм сәнгать әһелләре алдына куйган бурычларында, КПСС Үзәк Комитетының моннан ун ел элек кабул иткән «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары билгеләгән проблемаларның дәвамлылыгы, үзара бәйләнеше чагыла. Мәгълүм булганча, ул Карарда тәнкыйть һәм әдәбият белеменең гомуми торышы тирән анализланган, үсеш юллары, хәл ителәсе мәсьәләләр ачык күрсәтеп бирелгән иде. Карар тәнкыйтьчеләр һәм галимнәр алдына әдәбият-сәнгать процессындагы яңа күренешләрне, тенденция һәм закончалыкларны тирәнрәк анализлау, эстетик фикер хәрәкәтен житдирәк тикшерү бурычын куйды, рухи культурабыз үсешенең магистраль юлын ачыклады. Аның әдәбият һәм сәнгать үсешенә йогынтысы гаять зур һәм дәвамлы булды.

«Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карар тәнкыйтьнең иҗтимагый тормышыбызда зур роль уйнавын һәм аның һәрьяклы кайгыртучанлыкка мохтаҗ булуын тагын бер кат раслады. Карар кабул ителүгә үк иҗат һәм матбугат оешмаларында, фәнни үзәкләрдә җитди сөйләшүләр үткәрелде һәм тәнкыйтьне үстерү юнәлешендә актив чаралар билгеләнде, булган резервлар ачыкланды. Газета-журналлар әдәби тәнкыйтьнең гомуми торышына һәм үсеш тенденцияләренә багышланган чыгышлар аша җәмәгатьчелек фикеренә йогынты ясарга омтылдылар, әдәбият-сәнгатькә кагылышлы материалларга тагын да киңрәк урын бирделәр.

«Социалистик Татарстан» газетасы язучылар, әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләрне әдәбият белеме һәм тәнкыйть мәсьәләләре турында фикер алышу өчен «түгәрәк өстәл» янына чакырды. Бу сөйләшүләрдә катнашкан күренекле әдипләр, тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият галимнәре татар әдәби тәнкыйтен үстерүнең мөһим мәсьәләләрен күтәрделәр, конкрет тәкъдимнәр һәм киңәшләре белән уртаклаштылар.

«Казан утлары» журналы яңа басылган китапларны рецензияләү эшен активлаштыра төшү белән бергә, хәзерге татар прозасы һәм поэзиясе турында зур сөйләшүләр оештырды. Татарстан китап нәшрияты да әдәбият белеме һәм тәнкыйть буенча китапларга игътибарны көчәйтә төште.

Үзәк Комитет карарын тормышка ашыру юнәлешендә матбугатта басылган мәкалә һәм рецензияләрдә төпле анализга, дәлиллелеккә ныграк игътибар бирелә башлады. Карарда куелган таләпләргә җавап бирергә омтылып, татар әдәби тәнкыйте тормыш белән элемтәсен ныгытырга, иҗтимагый һәм эстетик фикер формалашуга ныграк йогынты ясарга тырышты, әдәбият һәм сәнгатьнең рухи тормышыбыздагы ролен күтәрүгә шактый зур өлеш кертте. «Хәрәкәттәге эстетика»бызның максатчан һәм нәтиҗәле эшчәнлеге әдипләр, сәнгать осталарының иҗатына шифалы яңгыр сыман тәэсир итте. Тәнкыйть агымдагы әдәбиятның йөзен билгеләрлек әсәрләрне үз вакытында күрә килде һәм аларга укучының игътибарын җәлеп итүне кичектергесез бурычы итеп санады.

Ел йомгаклары, актуаль мәсьәләләрне уртага куеп тикшергән «түгәрәк өстәл»ләр, дискуссияләр, проблемалы мәкаләләр әдәби тормышыбызның күптөрлелеген, байлыгын күрсәтте, әдәби-эстетик фикернең активрак, нәтиҗәлерәк була баруын раслады, әдәбияттагы уңышлы эзләнүләрнең, яңа тенденцияләрнең тормышчанлыгын яклады.

Соңгы елларда әдәбиятның заман тормышы, социалистик чынбарлык белән элемтәсе тагын да ныгыды. Күпчелек әсәрләрдә геройлар һәм проблемалар эреләнде, гуманистик башлангыч көчәйде һәм фәлсәфи эчтәлек тирәнәйде. Бу сыйфатларда заман таләпләренә җавап бирергә омтылучы әдәбиятның гражданлык пафосы чагыла. Тәнкыйтьтә әдәби-эстетик мәсьәләләрне тормышның актуаль проблемалары белән тыгыз бәйләнештә карау ихтыяҗы көннән-көн арта бара. Бары шул чакта гына теге яки бу әсәрдә чынбарлыкның әдәби үзләштерелү дәрәҗәсен, ул әсәрнең рухи тормышыбыздагы урынын һәм ролен билгеләргә мөмкин.

Әдәби тәнкыйть язучыларыбыз иҗатындагы яңа сыйфатларны күрү-атау гына түгел, аларның төп үзенчәлекләрен һәрьяклап анализларга, гомумиләштерергә, әдәбиятның алга таба үсешенә йогынты ясарга омтыла. Татар әдәбиятының бүгенге торышы, төрле жанрлардагы уңышлар һәм кимчелекләр турыдан-туры тәнкыйтьнең гомуми үсеш дәрәҗәсенә бәйле.

Ун ел эчендә безнең тәнкыйтьнең социаль роле, идеологик җаваплылыгы, фәннилек дәрәҗәсе күтәрелде. Бу чор әдәби тәнкыйтьнең иң әһәмиятле сыйфатлары нәр-

сәдә дигән сорауга мин: «Ил тормышында, социалистик яшәү рәвешенең рухи нигезләрен ныгытуда турыдан-туры катнашырга омтылу, агымдагы әдәби хәрәкәткә киң караш, милли әдәбиятны Бөтенсоюз әдәбияты контекстында өйрәнү һәм аны күпмилләтле әдәби процесс масштабларыннан, критерийларыннан чыгып бәяләү»,— дип җавап бирер идем.

Соңгы еллар тәнкыйть продукциясендә социологик анализ белән әдәби-эстетик анализның органик рәвештә бергә кушылуы өстенлек ала. Тәнкыйтьчеләребез әдәбиятсәнгать күренешләрен бәяләгәндә эстетик җегәр һәм сәнгатьчә зәвыклык юлыннан үсә баруларын раслыйлар. Әдәбият һәм сәнгатьнең нәфислегенә, нәтиҗәле иҗади эзләнүләргә, художникның осталыгына һәм талант үзенчәлегенә игътибар көчәйде. Тәнкыйть тематик-тасвирый метод белән генә чикләнүдән дә котыла бара.

Әдәби тәнкыйть тагын шундый күренешкә игътибар итте: замандашларыбыз рухының асылын өйрәнүче, аларда тормышка иҗади мөнәсәбәт тәрбияләргә омтылучы әсәрләребездә кешелеклелек төшенчәсе зуррак һәм катлаулырак мәгънә белән баетыла. Язучы мөрәҗәгать итә торган проблемаларның зурлыгы, мөһимлеге аерым шәхеснең, аның эшләрен һәм кичерешләрен, язмышын игътибар үзәгенә кую белән раслана. Чорның кискен идеологик каршылыклары һәм җәмгыять үсешендәге социаль процесслар геройларыбызның рухи тормышында чагыла, тирән конфликтларның нигезендә ята. Шундый шартларда кешелеклелек төшенчәсенең аерым шәхесләрне һәм вакыйгаларны бәяләүдә ачык сыйнфый мөнәсәбәттән аерылгысыз булуы бигрәк тә мөһим. Бу инде утызынчы-кырыгынчы еллардагы әдәбият һәм чынбарлык мөнәсәбәтләрен берьяклы, үтә гадиләштереп аңлаткан вульгар социологизм түгел. Бу — ныклы фәнни нигезгә корылган әтрафлы социологик анализ. Партия безне сәнгать күренешләрен тормыш һәм катлаулана баручы чынбарлык белән әнә шулай чагыштырырга өйрәтә.

КПССның XXVI съездында иптәш Л. И. Брежнев: «Партия сәнгатебезнең идея юнәлешенә битараф булмады һәм була алмый»,— дип әйтте. Бу — әдәбият-сәнгать тәнкыйте алдында торган мөһим бурыч — тормышта да, сәнгатьтә дә сыйнфый һәм гомумкешелек башлангычлары нисбәтен диалектик карау бурычын тагын бер кат искә төшерү булды. Шушы програм бурычны тормышка ашыру юлында тәнкыйть әдәбиятта гына түгел, заманның идея көрәшендә дә актив катнашып килә.

Карарда соңгы еллар тәнкыйте һәм әдәбият белемендә социалистик реализм әдәбиятының тәҗрибәсен өйрәнүгә, аның проблемалары өстендә эшләүгә зур игътибар бирелде. Социалистик реализм сәнгатенең идея-эстетик байлыгы, бүгенге көн уңай героен тасвирлау, классик мираска мөнәсәбәт, тугандаш әдәбиятларның үзара йогынтысы кебек җитди мәсьәләләрне өйрәнү һәм ачыклау дәвам итте. Аерым язучылар һәм сәнгать осталары иҗаты актив өйрәнелде, әдәбият тарихының кайбер сәхифәләре өр-яңадан ачылды.

Тәнкыйтьчеләребезнең профессиональ осталыгы үсүен, катлаулы күренешләрне анализлауда тәвәккәлрәк һәм зирәгрәк була баруларын билгеләп үтәргә кирәк. Шуның бер чагылышы буларак, бүген әдәби тәнкыйтьнең методологиясе һәм фәннитеоретик нигезе ныгый, фәлсәфи эчтәлеге тирәнәя. Традицион тикшерү алымнарын камилләштерә барып һәм башка фәннәрдә кулланылган методлардан да файдаланып, әдәбиятчыларыбыз иҗат процессын һәм әсәр структурасын комплекслы өйрәнүгә, системалы анализлауга омтылалар.

Соңгы еллардагы күпчелек тәнкыйть чыгышларында гомумиләштерүче фикер колачы һәм әдәби процессның аеруча актуаль, үзәк проблемаларына һәр яклап якын килү игътибарны җәлеп итә. Фикерләүдә һәм бәя бирүдә таләпчәнлек новаторлыкны, социалистик реализм методының төп өстенлекләрен ачыкларга мөмкинлек тудыра, тәнкыйди фикернең җитдиләнгән һәм җитлеккәнлеген күрсәтә. Әдәбиятның состав өлеше буларак тәнкыйтьнең роле һәм абруе үсте, ныгыды. Тәнкыйтьче һәм әдәбият галимнәнә Г. Тукай исемендәге республика Дәүләт премиясе бирелүе дә әнә шуны раслап торучы бер дәлил.

Әйе, тәнкыйть белемлерәк, дәрәҗәлерәк, таләпчәнрәк һәм өлгеррәк була бара. Аның киң карашлы булуы, партиячел принципиальлеге, оперативлыгы, бер яктан, тәэсез һәм художество ягыннан зәгыйфь әсәрләргә юл куймау, икенче яктан, әдәбиятның үсешенә ярдәм итәрлек яңалыкны, эзләнүләрне тану һәм яклау өчен кирәк.

Тәнкыйтьчеләребезнең әдәбиятка һәм дөньяга карашы киңәю татар әдәби тәнкыйтенең Бөтенсоюз мәйданына чыгуына да нигез булды. Биредә бигрәк тә Р. Бикмөхәммәтов, Ф. Мусин, Р. Мостафин хезмәтләре күздә тотыла. Алар татар язучылары иҗатын зур контекстта, башка әдәбиятларда барган процесслар белән бәйләп карыйлар. Милли әдәбиятларның үсеш тенденцияләрен чагыштырма планда анализлау, уртак проблемаларны хәл итү юлларын ачыклау совет әдәбияты белемен тулыландыруга зур өлеш кертте. Безнең тәнкыйтьчеләр татар әдәбияты ирешкән уңышларны күмәк табынга чыгару белән бергә, язучыларыбызны ил күләмендәге казанышлар, таләпләр биеклегеннән яңа иҗади эзләнүләргә рухландыралар.

Бу яктан 1978 елда Казанда «Совет Көнчыгыш әдәбиятларында социалистик реализм эстетикасы һәм поэтикасының актуаль проблемалары» дигән Бөтенсоюз фәнни конференциясе үткәрелү аеруча игътибарга лаек. Мәскәүдән, Ленинградтан, союздаш республикалардан Казагыстан Фәннәр академиясе член-корреспонденты З. Ә. Әхмәтов, филология фәннәре докторлары Р. Бердибаев, А. А. Гаджиев, Л. И. Залесская, А. Н. Иезуитов, З. С. Кедрина, М. К. Кошчанов, Ю. И. Суровцев, Г. Б. Хөсәенов, М. Ш. Шөкеров, Татарстаннан Й. Г. Нигъмәтуллина, Н. Г. Юзиев һ. б. лар катнашкан әлеге форумда социалистик реализм методологиясе һәм теориясенең уртак проблемалары, милли әдәбиятларның идея-художество, стиль һәм жанр ягыннан яңарыш мәсьәләләре тикшерелде. Хәлбуки, проблемалар зур һәм җитди, ачыклыйсы моментлар бик күп әле, һәм бу юнәлештә яңа эзләнүләр, тупланган тәҗрибәне теоретик гомумиләштерүләр сорала. Р. Бикмөхәммәтовның илебез әдәбиятлары бердәмлеген өйрәнүнең торышы турында уйланып язылган җитди мәкаләсе («Вопросы литературы» журналы, 1981 ел, 8 нче сан), мәсәлән, әнә шул зур сөйләшүнең дәвамы булып яңгырады. Анда күтәрелгән актуаль проблемалар, аларны милли әдәбиятларны комплекслы тикшерү нигезендә хәл итү күпмилләтле совет әдәбиятының идея һәм эстетик бердәмлеге төшенчәсенең асылын ачуда яңа аспектлар билгеле.

Әдәбиятларның үзара багланышларын фәнни-тәнкыйди өйрәнү өлкәсендә башкарылган бүтән хезмәтләр дә күз алдында (Х. Хәйри, И. Нуруллин, Ф. Мусин һ. б.). Әдәбият-сәнгатьтә миллилек һәм интернациональлек сыйфатлары диалектикасының, әдәби багланышларның теоретик һәм методологик мәсьәләләрен өйрәнүгә игътибар арта төште (К. Гыйззәтов, Й. Нигъмәтуллина һ. б. хезмәтләре). Нык үскән социалистик җәмгыятьтә милли әдәбият һәм сәнгатьләрнең бер-берсенә йогынтысы, бер-берсен баетышуы проблемалары буенча Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты үткәргән фәнни-теоретик конференция (1973 ел) материаллары шул хәзинәгә бер өлеш булып кушылды. Үткән ел «СССРда социалистик һәм коммунистик төзелеш тарихы» гыйльми советы, СССР Фәннәр академиясенең СССР тарихы институты, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты, Казан дәүләт педагогия институты тарафыннан оештырылган һәм Казанда үткәрелгән Бөтенсоюз фәнни конференциясе дә СССР халыклары культураларының үзара багланышы мәсьәләләренә багышланды.

Язучыларыбызның иҗатында да совет кешеләренең тугандаш гаиләдә яшәвен, социалистик интернационализм үзенчәлекләрен тасвирлау зур урын ала. Соңгы еллар әдәбиятыннан Г. Ахуновның «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» дилогиясен, Х. Камаловның «һәркемнең гомере бер генә», Ш. Бикчуринның «Каты токым» романнарын, Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» һәм «Моңлы бер җыр», Д. Вәлиевнең «Сиңа тормыш бүләк итәм» пьесаларын һ. б. әсәрләрне искә төшерик. Ш. Бикчурин романындагы рус, татар, украин, казакъ, әрмән һәм башка милләт вәкилләренең бер-берсенә якын хезмәттәш дусларга әверелүе, Татарстанны икенче туган яклары итеп кабул итүләре — совет кешесенең интернациональ коллективта, уртак хезмәттә рухи баюы һәм ныгуына бер мисал түгелмени? Әдәби тәнкыйть тә «Каты токым»ның нәкъ менә шул асылына игътибар итте, татар әдәбиятында социалистик реализмның хәзерге чордагы үсеш юлы әдәби һәм иҗтимагый багланышлардан башка мөмкин түгелләген исбатлады.

Совет әдәбиятларын, аерым алганда, төрки телләрдә иҗат итүче совет әдипләре әсәрләрен чагыштырма-типологик өйрәнгәндә башка бик күп үзенчәлекләр дә ачыла. Шуларның берсе — соңгы елларда төрки телле әдәбиятларда революция тарихын,

халык тарихын, аның уртак Ватандагы язмышын гәүдәләндерүгә багышланган әсәрләр иҗат ителүе. Татар әдәбиятында — А. Расихның «Ямашев» трилогиясе, Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» романы, С. Хәким һәм И. Юзеев поэмалары, Н. Фәттахның «Кол Гали» трагедиясе... Халкыбызның Бөек Ватан сугышында һәм тылда күрсәткән батырлыкларын тасвирлаган әсәрләр дә (Т. Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» пьесасы, М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романы һәм «Кеше китә — җыры кала» повесте, М. Юнысның «Биектә калу» повесте, С. Хәким поэмалары һәм шигырьләре һ. б.) язучыларыбызның тормыш чынбарлыгына, документаль башлангычларга игътибары артуы хакында сөйли. Бу әсәрләр тарихилыкның яңа сыйфатын чагылдыру, халыкның үткәне һәм бүгенгесе арасындагы өзелмәс рухи бәйләнешләрне ачу, замандашларыбызның кыйммәтле иҗтимагый-әхлакый тәҗрибә варислары булуын танулары белән үзенчәлекле. Заман һәм җәмгыять проблемаларына көннән-көн тирәнрәк үтеп керү ягыннан әлеге әсәрләр тәнкыйтьтә зур сөйләшүләргә нигез булды, хаклы рәвештә әдәбиятыбызның соңгы еллардагы җитди уңышы буларак бәяләнде. Шуның белән бергә, әдәби тәнкыйть язучыларыбызны бүгенге көннең уңай героен тасвирлау, аның рухи дөньясын киңрәк һәм тирәнрәк ачуга юнәлтте.

Мәгълүм булганча, әдәбият белемендә берара «идеаль герой» концепциясе, «кечкенә кеше» теориясе шикелле чиктән-чиккә ташлану, схемага салырга омтылу күренешләре булып алган иде. Бу карашлар әдәбият теориясенә һәм практикасына шактый зыян китерде. Зур һәм катлаулы мәсьәләләрне әнә шулай берьяклы, гадиләштереп аңлатуларга реакция рәвешендә, «уңай герой» төшенчәсеннән дә качарга тырышу чоры булды. Ләкин «уңай герой»ны «замандаш образы», «халыкчан характер» кебек сүзләр белән алыштырганда, тәнкыйтьнең төп критерийларыннан берсе — халыкның рухи тәҗрибәсен гәүдәләндерүче, иң югары идея-художество таләпләренә җавап бирә торган сыйфатларны үзендә туплаган шәхескә йөз тоту — югалды.

«Уңай герой» проблемасына яңадан игътибар арту әдәбиятның яңа уңышлары белән бәйләнгән. Соңгы елларда ил тоткасы булырдай масштаблы уңай герой характерлары иҗат ителде. Кара алтыны һәм бөек төзелешләре белән данлы республикабыз эшчеләре, фидакарь игенчеләребез турындагы китаплар совет әдәбиятында ныклы урын алды. Киң җәмәгатьчелеккә танылган ул әсәрләрнең геройлары күбрәк гадәти хәлләрдә һәм, производство-хезмәт конфликтларыннан бигрәк, дөньяга карашлар, әхлакый принциплар бәрелешендә ачыла. Алар аңлы һәм актив хәрәкәт итүче шәхесләр буларак рухи һәм әхлакый йөзләренең бөтен катлаулылыгында сурәтләнәләр. Коммунистик идеалларга ия булган яңа кеше концепциясендә язучыларыбызның дөньяны марксистик диалектика кануннарына нигезләнеп аңлавы, актив тормыш позициясе чагыла.

Тәнкыйть һәм әдәбият белеме замандаш геройлар мәсьәләсен өйрәнгәндә социалистик реализм сәнгатенең яңа сыйфатларын ачуга һәм аңлатуга иреште. Менә шул рәвешле әдәбиятта «яңа дулкын күтәрелү», бүгенге чынбарлыкны үзләштерүдә аның эчке мөмкинлекләре арту һәм әсәрләрдәге тормыш дөреслегенә тугрылыклы пафос тәнкыйть фикерен дә активлаштыруга булышлык итте. Г. Халит, Н. Юзиев, Х. Хәйри, Ф. Мусин, А. Әхмәдуллин мәкаләләрендә әдәбиятыбызның үсеш дәрәҗәсе югары критерийлардан чыгып билгеләнде, геройның эчке дөньясын, күңел диалектикасын ачуда язучыларыбызның осталыгы, әсәрләрнең жанр-стиль төрлелеге, яңа художество чараларын үзләштерү ягыннан үсеше анализланды. Ләкин бу активлашуның, чын мәгънәсендә профессиональләшүнең төп шарты — КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы мәгълүм карары булды.

Бүгенге татар тәнкыйте язучыларның эзләнүләрен социалистик реализм сәнгатенә хас халыкчанлык, партиялелек, тарихи дөреслек юлына юнәлтә белә. Ул инде агымдагы әдәби процессны тикшерү белән генә чикләнмичә, әдипләребезне яңа биеклекләргә рухландырырга, әдәби хәрәкәткә йогынты ясарга өйрәнеп килә. Безнең Ф. Мусин, Р. Мостафин, Р. Мөхәммәдиев кебек яңалыкка омтылып иҗат итүче, күтәрелмәгән чирәмне күтәрә белә торган сәләтле һәм җитди әзерлекле тәнкыйтьчеләребез бар.

Әдәбият-сәнгатьнең һәм тәнкыйтьнең яңаруы — бүгенге мәдәни тормышыбызның иң күренекле сыйфатларыннан берсе. Язучы һәм тәнкыйтьче сүзе җәмгыятебез тормышында көннән-көн активрак роль уйный. Шуңа күрә бүген тәнкыйтьтән тормыш һәм

әдәбият күренешләрен бәяләүдә аеруча зур җаваплылык, фәнни тирәнлек таләп итә-лә. Моңа нисбәтле рәвештә тәнкыйтьнең теоретик һәм методологик базасын ныгыту, фәнни фикерләүнең ышанычлы һәм нәтиҗәле ысулларын табу бурычы куела.

КПСС Үзәк Комитеты карарыннан соң әдәби тәнкыйтьнең тикшерү алымнарына, әдәбият белеме методологиясенә игътибар бермә-бер көчәйде, тәнкыйтьнең торышын һәм үсеш тенденцияләрен анализлаган хезмәтләр дөнья күрде. (Мәсәлән, Н. Юзиевның «Хәрәкәттәге эстетика — хәрәкәттә» һәм «Әдәбият фәне методологиясенә — камиллек!», Ф. Әгъзамовның «Әдәби тәнкыйть һәм вакытлы матбугат», Р. Мостафинның «Рецензияләр турында сөйләшик» һәм «Тәнкыйтькә тәнкыйть уты» дигән мәкаләләре һ. б.). Бу елларда татар әдәбияты тарихына яңа материаллар туплау, аларны җентекләп анализлау һәм гомумиләштерү нәтиҗәсендә байтак хезмәтләр язылды, социалистик реализмны хәрәкәттәге һәм үсештәге процесс буларак өйрәнү, әдипләребезнең бүгенге иҗатын аның үзәк принциплары яктылыгында тикшерү көчәйде. Әдәби тәнкыйть методологиясе мәсьәләләренә игътибарның артуын, татар тәнкыйтенең әдәбият белеме белән бәйләнешләре ныгуын, аерым алганда, 1976 елда Татарстан китап нәшриятында «К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында» дигән җыентыкның дөнья күрүе һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында хәзерге татар әдәбият белеменең һәм әдәби тәнкыйтенең актуаль методологик мәсьәләләренә багышланган фәнни-теоретик киңәшмә үткәрелүе дә раслап тора.

Гомумән, соңгы елларда әдәбият тарихының иҗтимагый фикер үсеше белән күпьяклы бәйләнешләрен, әдәби әсәр структурасы һәм стильләренең тарихи үсешен өйрәнүдә уңышлы омтылышлар ясалды. Мәйданга проблемалы, аналитик тәнкыйть, әдәбият белеме казанышларына таянган җитди тәнкыйть килде. Ул инде әдәбиятның «чишмә башы»н, традицияләрен, үсеш закончалыкларын, ил-халык, җәмгыять тарихы белән бәйләнешын киң колач белән, фундаменталь нигездә өйрәнә башлады. Бу уңайдан тәнкыйть һәм әдәбият фәненең кулга кул тотынышып әдәби мирасны үзләштерүдәге хезмәтләрен, шулай ук Тукай, Ибраһимов, Г. Камал, Коләхметов, Акмулла, Такташ һәм Җәлил юбилейларының зур хәзерлек белән, югары дәрәҗәдә уздырылуын билгеләп үтәргә кирәк. Әдәбият тарихын өйрәнүдә әдәбиятчы галимнәр Х. Госман, Г. Халит, М. Гайнуллин, И. Нуруллин, Б. Гыйззәт, В. Воздвиженский, Н. Хисамов белән бергә тарихчылар Р. Нәфыйков, М. Госманов, философ Я. Абдуллин зур хезмәт куйды. М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтының күренекле галимнәре җитәкчелегендә ил күләмендәге академик басманы — «Күпмилләтле совет әдәбияты тарихы»н язуда катнашу — татар әдәбият галимнәренең җитди казанышы дип бәяләнергә лаек.

Татарстан китап нәшрияты әле яңа гына татар теленең өч томлык аңлатмалы сүзлеген чыгарып бетерде. СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының Л. Т. Махмутова фәнни җитәкчелегендәге тел секторы гыйльми хезмәткәрләре тарафыннан башкарылган мондый зур һәм җитди эш, тел белеме өлкәсендә югары бәяләнү белән бергә, гомумән культурабыз үсешендә мөһим вакыйга итеп саналырга хаклы.

Татар халкының гасырлар буена җыйналып килгән тел байлыгын үзендә туплаган бу капиталь хезмәт, һичшиксез, әдәбиятчыларның һәм журналистларның, сәнгать иясләренең иҗат эшчәнлегенә зур ярдәм итәчәк, гомумән халкыбызның тел культурасы үсешенә уңай йогынты ясаячак. Тел, әдәбият һәм тарих институтында әзерләнә торган күптомлы татар әдәбияты тарихы шулай ук үзенең колачы белән генә түгел, фундаменталь характеры, фәнни тирәнлеге ягыннан да кыйммәтле хезмәт булыр дип өметләнәбез.

Әдәби мирасны барлау һәм укучыга җиткерү эше соңгы елларда эзлекле һәм күп очракта фәнни-методик яктан җиренә җиткереп башкарыла башлады. Татарстан китап нәшриятында 1975—1976 елларда Җәлил әсәрләренең дүрт томлыгы, 1975—1977 елларда Тукай әсәрләренең дүрт томлыгы дөнья күрде. Бу җыентыклар текстологик камиллеге, шәрехләү фәннилеге һәм төгәллеге ягыннан татар әдәбият фәненең зур уңышы дип бәяләнергә тиеш. Г. Ибраһимов, Г. Камал, М. Гафури, Ш. Камал, К. Нәҗми, һ. Такташ әсәрләренең фәнни җыелмалары да (аларның дөнья күргән өлеше үк инде) Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәренең, Татарстан китап нәшриятының

классиклар мирасын туплап чыгару эшенә югары профессиональ әзерлек, зур җаваплылык белән керешүе хакында сөйли.

Соңгы елларда әдәби мираска игътибарның аеруча көчәюе тагын бер сәбәп — бүгенге әдәбиятта «кеше һәм заман» проблемасы, рухи-әхлакый дәвамчанлык юнәлешендәге эзләнүләр белән дә бәйле. Бу җәһәттән, Г. Камал исемендәге Академия театрыбызның эзлекле рәвештә классикага мөрәҗәгать итүе, аны яңача укуы игътибарга һәм хуплауга лаек. Г. Коләхметовның «Яшь гомер» драмасы буенча куелган спектакльне һәм Д. Вәлиевнең Г. Коләхметов драматургиясен, аерым алганда, «Ике фикер» әсәрен яңадан укуын («Казан утлары» журналы, 1981 ел, 5 нче сан) без кызыксынып һәм канәгатьләнү белән кабул иттек. М. Гафуриның «Кара йөзләр» повесте үзенчәлекле опера сыйфатында («Каһәрләнгән мәхәббәт» — Г. Рәхим либреттосы, Б. Мулюков музыкасы) сәхнәгә күтәрелде.

Һәр әдәби әсәр, язучының тулаем мирасы — тормыш кебек үк катлаулы, күп мәгънәле күренеш һәм аны тагын бер кат игътибар белән өйрәнү-уку игелекле хезмәт. Әлбәттә, әгәр бу «уку» безгә тормышны тирәнрәк аңларга ярдәм итсә һәм әсәрдән алган эстетик ләззәтне тагын да көчәйтә төшсә!

Язучы иҗатын этрафлы аңлауның бөек үрнәге — В. И. Ленинның Толстой фигурасын төрле яктан яктырткан мәшһүр мәкаләләре. Ленин, язучы шәхесен һәм иҗатын чор көзгесендә карап, Толстой сурәтләгән чорны — «революцияне хәзерләү эпохасының «бөтен кешелек дөньясының сәнгать үсешендә алга таба бер адымы» буларак бәяли. (Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 16 том, 328 бит). Революция юлбашчысының шушы дәһи гомумиләштерүе зур методологик әһәмияткә ия.

Әнә шушы ленинчыл методология әдәби мираска, үткәндәге язучыларга мөнәсәбәтне билгели. Бүгенге фән, берьяклы аңлатулардан котылып, язучы тормышын һәм иҗатын бөтен каршылыклары белән һәр яклап өйрәнү бурычын уңышлы хәл итеп килә. Художник шәхесе белән тирән кызыксыну әдәби эзләнүләргә дә үтеп керә. Н. Фәттахның «Кол Гали» трагедиясе, С. Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә» поэмасы, И. Юзеевның «Очты дөнья читлегеннән...» шигъри трагедиясе һәм «Соңгы сынау» драматик легендасы, Ә. Еникиның «Гөләндәм туташ хатирәсе» повесте, Т. Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» трагедиясе — Кол Гали, Тукай, Сәйдәш, Җәлил образларын әдәби гәүдәләндерүгә омтылуның уңышлы үрнәкләре.

Классикага катып калган формула итеп түгел, ә бәлки җанлы, хәрәкәттәге, үсештәге күренеш буларак карауның, үткәннең бөек фигураларын «терелтү»нең тагын бер сәбәбе бар. Ул да булса — әле генә санап үтелгән әсәрләрдә яшәешенең мәңгелек проблемаларына мөрәҗәгать итү. Кешенең дөньядагы миссиясе нәрсәдә, аның социаль, әхлакый асылы нидән гыйбарәт дигән сорауларга җавап эзләү. Безнең тәнкыйть һәм әдәбият белеме культурабыз хәзинәсенең чын кыйммәтен менә шул күзлектән дә чыгып бәяләргә өйрәнде. Күпчелек галимнәрнең әдәби күренешләрне зур дәверләр эчендә үсештә каравы, тулаем масштаблы фикер йөртүе, комплекслы һәм системалы анализ, теоретик синтез принципларына таянуы фәнгә фидакарьләрчә хезмәт итү үрнәге булып тора.

Бүгенге язучылар иҗатын анализлаган иң яхшы тәнкыйть чыгышлары да әнә шул яктан — әсәрнең проблематикасын тормыш агышына нисбәтләп, чор контекстына куеп өйрәнүгә омтылулары белән характерлы. Тәнкыйть бит теге яки бу әсәрне, Максим Горький әйткәнчә, кешедә иҗади, культуралы, революцион тормыш итәрлек ихтыяр тәрбияләргә ни дәрәҗәдә сәләтле булуыннан чыгып бәяләргә тиеш. Г. Халит, И. Нуруллин, Н. Юзиев кебек фән докторлары, Ф. Мусин, А. Әхмәдуллин, Р. Мостафин, Т. Галиуллин, Ф. Миңнуллин, Ф. Хатипов кебек тәҗрибәле тәнкыйтьчеләребез, яшьрәк буыннан Р. Мөхәммәдиев һәм М. Вәлиев, әдәби иҗат кысаларында гына йомылып калмыйча, әсәрләрне тормыш позицияләреннән, иҗтимагый үсешнең иң мөһим проблемаларыннан чыгып, ил һәм дөнья әдәбиятындагы әйдәүче тенденцияләр белән чагыштырып бәялиләр. Р. Бикмөхәммәтов, Ф. Мусинның үзәк матбугатта басылган мәкаләләрендә заман күренешләренә үтеп керү, замандашыбызның дөньяга карашын формалаштыру өчен әдәбият биргән фактлардан һәм үз күзәтүләреннән файдалана белү сыйфатлары көчәя бара.

Тәнкыйть һәм әдәбият белеме буенча соңгы елларда дөнья күргән китаплар бу-

генге әдәби процессның аеруча актуаль, узәк проблемаларына комплекслы якын килү ягыннан әһәмиятле. Сәнгать әсәрен анализлау, әлбәттә, язучы теркәгән күренешләрне безгә таныш тормыш белән янәшә куеп чагыштыру гына дигән сүз түгел. Тәнкыйтьче тормыштагы үсеш-үзгәрешләрнең эчке логикасын аларның тарихи мәгънәсен киңрәк масштабларда күрергә бурычлы. Тәнкыйтьчеләребез бу таләпләргә җавап бирергә омтылалар, соңгы чор татар әдәбиятында, бигрәк тә Т. Миңнуллин, И. Юзеев, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев әсәрләрендә тормышны сурәтләүнең төрле формаларына таянуны социалистик реализм үсешенең бер закончалыгы дип бәялиләр. Шундый шартларда социалистик реализм методологиясе һәм поэтикасын әдәби әсәр структурасы, художество осталыгы мәсьәләләрен тикшергән төпле теоретик хезмәтләрнең әһәмияте аеруча арта бара. Бу җәһәттән Х. Госман, Г. Халит, Н. Юзиев, Й. Нигъмәтуллина, Р. Бикмөхәммәтовларның гыйльми-тәнкыйть эшчәнлеге татар әдәбият белемен яңа ачышлар, җитди казанышлар белән баетты. Күп кенә башка тәнкыйтьчеләребез хезмәтләренә дә өйрәнелә торган мәсьәләләргә конструктив якын килү, методологик яктан дөрес юл табу һәм эстетик гомумиләштерү осталыгына ирешә бару хас.

Татар әдәби тәнкыйте үсешендә икенче мөһим юнәлеш — чагыштырма-типологик өйрәнү дә активлашып килә. Й. Нигъмәтуллина, Н. Юзиев, Р. Бикмөхәммәтов хезмәтләрен бу юлдагы беренче казанышлар дип санарга мөмкин. Аларның әзеннән фәнни фикерләү куәсе белән сокландыручы, бай мирасны өйрәнгән яшь галимнәр, тәнкыйтьчеләр килүен күрү аеруча куанычлы.

Бүгенге тәнкыйтьнең барлык жанрлар үсешен, басылып чыккан әдәби продукциягә игътибар һәм таләпчәнлек белән күзәтеп баруын билгеләп үтәргә кирәк. Бу, иң беренче чиратта, КПСС Үзәк Комитеты карарыннан соң туган әйбәт иҗат атмосферасына бәйле. Карарга җавап йөзеннән тәнкыйтьчеләрнең үз-үзләренә таләпчәнлеге артты. Аларның чыгышлары эшлеклерәк, активрак төс алды. Әлеге активлык әдәби тәнкыйтьтәге төрле формаларның үсешендә дә чагылды. Аерым жанрлар һәм проблемалар буенча күзәтүләр, «түгәрәк өстәл»ләр һәм дискуссияләр, диалоглар, иҗат портретлары әдәби тәнкыйтьнең форма ягыннан байлыгын, тәнкыйди фикернең тәэсирлерәк була баруын күрсәтә. Әнә шундый эчтәлек һәм форма бердәмлеген раслаган чаралардан «Казан утлары» журналында ел буе дәвам иткән поэзия турында дискуссия һәм хәзерге әдәбиятта яңалык тойгысы мәсьәләсенә багышланган түгәрәк өстәл, «Социалистик Татарстан» газетасында «Заман һәм роман» дигән темага барган сөйләшү аеруча игә калырлык булды. Бу сөйләшү-киңәшүләр актуаль проблемаларны тәнкыйтьчеләрнең һәм әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең бергәләп, һәрьяклап өйрәнергә һәм хәл итәргә омтылуы ягыннан характерлы. Әдәбиятта һәм сәнгатьтә иптәш Л. И. Брежнев әйткән «яңа дулкын күтәрелүе» тәнкыйть алдына зур бурыч куя: шушы күтәрелешнең конкрет әсәрләрдә ни дәрәҗәдә чагылуын билгеләргә, бүгенге әдәби процессның иң мөһим тенденцияләрен һәм үсеш юлларын ачыкларга иҗат продукциясенә чын мәгънәсендә профессиональ бәя бирергә кирәк.

Шушы таләпләрдән чыгып караганда, әсәрләрне тулаем җентекле анализ нәтиҗәсендә бәяләүче, әдәби һәм иҗтимагый проблемалар нисбәтен тирәнрәк күзәтә баручы тәнкыйтьчеләребез эшчәнлегендәге аерым кимчелекләр дә бик ачык күренә.

Кызганычка каршы, күзәтү характерындагы, зур гомумиләштерүләргә дәгъва итүче кайбер мәкаләләрнең (ә алар соңгы елларда сан ягыннан аеруча күбәеп китте) сыйфаты канәгатьләндереп бетерми. Тирәнлек җитмәүне «киңлек» белән капларга омтылыпмыдыр, конкрет анализ урынына дистәләгән исем санау белән мавыгыла, нәтиҗәдә, җанлы әдәби процесс урынына аның проблемаларын гына күрү, әдәби әсәрләрдән бигрәк, тәнкыйть мәкаләләреннән рухланып язу — «куян шулпасының шулпасы» килеп чыга. Яисә, киресенчә, әдәби әсәрләрне, язучылар иҗатын җентекле өйрәнүдән туган нәтиҗәләрдән бигрәк, аерым мисалларны алдан әзер схемага туры китереп, шактый мәгълүм фикерләргә иллюстрация төсендә генә тәкъдим итәлгән язмалар күңелне борчый. «Түгәрәк өстәл» һәм дискуссияләрдәге аерым чыгышларның конкрет әсәрләр турында сөйләшүдән читләшеп, гомуми, адрессыз сүз көрәштерүгә күчү очраклары да бик еш кабатлана. Күләмле, шактый шома һәм зурдан кубып язылган аерым мәкаләләрдә мәсьәләнең асылына төшмичә әзер хакыйкать белән эш итү, фикер сайлыгы үзен сиздерә. Проблемаларны кую һәм. аңлатуда бертөрлелек, салкын, авыр тел аларның тәэсирен һәм нәтиҗәлелеген киметә, кайбер очрак-

ларда хәтта иҗади фикерләү мәгълүм информацияне эшкәртү белән алыштырыла, күптән билгеле нәрсәләр, таушалып беткән өлге-стереотиплар кабатлана. Шул җөмләдән, мәсәлән, «фәлсәфи» дигән бәяләмәне дә гадәти бер штампка әйләндереп, тормышны фәлсәфи үзләштерүнең исе дә килмәгән әсәрләргә карата куллана башламадык микән? Бу хакта һичшиксез уйланырга урын бар. Без әдәби тәнкыйть фикеренең колачы проблемалылык белән аерылгысыз бәйләнгән булуын, зәвыксыз тәнкыйтьнең зәвыксыз әсәрләргә каршы көрәшә алмавын һич тә истән чыгармаска тиешбез.

Сер түгел: тормышны өстән-өстән генә чагылдыра торган, идея-художество ягыннан җитлекмәгән әсәрләр дә дөнья күргәли әле. Асылда натуралистик тасвирдан гына торган, хис-кичерешләрне ваклаган зәвыксыз китаплар өчен үз вакытында һәм принципиаль рәвештә үз сүзен әйтә алмаган тәнкыйть тә җавап бирә. Юк, беркем дә яман аты чыккан «күсәк»кә чакырмый. Безнең тәнкыйть, гомумән, иптәгатьлелеге, тактлылыгы белән аерылып тора. Хәтта артык «тәүфикъланып», ягъни, әдәбият күренешләрен бәяләүдә урталыкта калырга өйрәнеп китмәдеме икән әле ул? Ә бит кирәк урында уңышка чын күңелдән сөенү, уңай күренешне ашкынып яклау, зәгыйфь әсәрләргә ярсып каршы чыгу җитми. Мондый академик урталыкта тигезләү, кимчелекләрне дәшми калу кемгә файдалы? — Билгеле «уртакул»ларга һәм «уртакуллар»дан түбәнрәкләргә. Талантлы әсәрне яклаудан, талантлы язучыны зур итеп, масштаблы итеп күрсәтүдән курыкмаган кебек, төссез, акылга да, йөрәккә дә бернәрсә бирми торган китапны вакытында тәнкыйть уты астына алудан да качмаска кирәк.

Соңгы вакытта комплиментар тәнкыйть мәкаләләре күбәюе борчый. Комплиментар тәнкыйть, нигездә, анализ критерийларының тотрыксызлыгыннан, эстетик культура җитмәүдән килә. Акланмаган бәяләр бүгенге әсәрләрне анализлаганда гына түгел, кызганычка каршы, аерым очракларда үткәндәге мирасны барлаганда да үзен сиздергәләп ала.

Гомумән, әдәби мираска мөнәсәбәт җәһәтеннән, башкарылган хезмәтләрнең зурлыгын таныган хәлдә, бу юнәлештә шактый җитешсезлекләргә дә игътибарны юнәлтү урынлы булыр. Иң беренче чиратта мирасны өйрәнү, аңа бәя бирү эшендә тупланган тәҗрибәнең бүгенге эзләнүләрдә искә алынып бетмәве сизелә. Кайбер хезмәтләрдә әдәби үсешнең аерым чорларын (мәсәлән, 60 нчы еллар поэзиясен) башка чорларга каршы куеп, берьяклы күрсәтергә тырышу өстенлек ала башлады. 60 нчы еллардан соң әдәбият тарихын язу башкарылмаган эш булып кала. Үткәндәге аерым әдипләребез һәм сәнгатькәрләребезне бүгенге фән казанышларына таянып, тарихилык позицияләреннән чыгып дөрес аңлату, алар калдырган мирасның кыйммәтле өлешен аерып алу да җитми әле. Беренче рус революциясе дулкыны белән турыдан-туры иҗтимагый көрәш һәм әдәбият мәйданына чыккан Ф. Әмирхан, Г. Коләхметов һәм Г. Камал кебек олы шәхесләрнең әдәби иҗаты һәм җәмәгать эшчәнлеге зур тикшеренүләргә, махсус монографияләргә мохтаҗ. Такташ иҗатының татар поэзиясенең озак елларга үсеш юлын билгеләгән үзенчәлеген һәм әһәмиятен ача торган хезмәтләр дә җитешми. Ә С. Сәйдәшев, К. Тинчурин, Ф. Яруллин, сәхнә осталарыбыз турында, аларның рухи дөньяларын, кабатланмас шәхси үзенчәлекләрен ачкан хезмәтләр?.. Бу юлда фәнни-популяр әсәрләр иҗат итү. «Атаклы кешеләр тормышы» сериясе тибындагы китаплар булдыру турында да уйланырга кирәк.

Классик мирасны бәяләүдәге хәл иteләсе мәсьәләләрнең бер өлеше методологик бәхәсләрдән конкрет эстетик күренешләрнең асылын өйрәнүгә күчә алмый торуга да бәйле. Теге яки бу әсәрнең нинди социаль шартларда иҗат ителүен ачыклавы кыен түгел, ә менә ни өчен аның бүгенге буыннар акылын һәм йөрәген биләргә сәләтле булуын еш кына аңлатып бирә алмыйбыз әле. Мәктәп өчен язылган әдәбият дәреслекләребездә беркадәр схоластикага юл куелуы да әнә шуннан килә шикелле.

Хәзерге әдәби процессны тирән анализлауга нигезләнмәгән фаразлар, мәсәлән, төрле агымнар һәм юнәлешләр турындагы теоретик бәхәсләр дә берьяклы мавыгулар сукмагыннан алып кереп киткәли. Бу мәсьәләләрдә еш кына ачыклык булмау тәнкыйть чыгышларының көчен һәм йогынтысын киметә, аерым әсәрләрдә реалистик нигезнең йомшаруына принципиаль бәя бирергә комачаулый. Әдәби процесстагы үзгәрешләрне вакытында күреп, бәяләп, гомумиләштереп бармаулары тәнкыйтьчеләребезнең үзәк матбугат оештырган дискуссияләрдә актив катнашмауларына китерә.

Мәгълүм хезмәтләрне истә тоткан хәлдә дә, татар әдәбияты казанышларын Бөтенсоюз укучысына җиткереп бара алмаган кебек ук, үзебезнең матбугатта рус, совет һәм прогрессив дөнья әдәбиятын пропагандалауга да тәнкыйтьчеләребезнең өлгерлеге җитми әле. Ә бит культура өлкәсендә «тел, лөгать вә гадәт алмашу»ыбызның тирән традицияләре, үзара йогынты ясау, бер-береңне баетуның игелекле нәтиҗәләре һәркайсыбызга мәгълүм. Революциягә кадәр үк татар газета-журналлары М. В. Ломоносовның тууына ике йөз ел, Н. В. Гогольгә, В. Г. Белинскийга, Т. Г. Шевченкога йөз ел тулуны зурлап билгеләп узалар. Татар демократик матбугаты үзенең укучыларын рус әдипләре иҗаты һәм дөнья сәнгать осталары әсәрләре белән таныштырып бара. Бу эш совет чорында Г. Нигъмәти, Г. Гали, М. Гайнуллин, Х. Хәйри кебек күренекле тәнкыйтьчеләр, әдәбият галимнәре тарафыннан уңышлы башкарыла. Әнә шул данлы традицияләрне өйрәнү һәм дәвам итү, үстерү бурычы партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында да куелган иде.

Шулай ук сәнгать, бигрәк тә театр өлкәсендәге бүгенге эзләнүләр, ирешелгән казанышларның, нигездә, тәнкыйть игътибарыннан читтә калуы да сер түгел. Соңгы бер-ике елда татар сәхнәсенең эшчәнлеген киң планда анализлаган, аның проблемаларына тирән үтеп кергән хезмәтләрне искә төшерүе кыен. Татар драматургларының әсәрләре ил сәхнәләрендә куелган бер вакытта театр тәнкыйтенең сүлпәнлеген әлеге өлкәдә эшләүчеләрнең җитмәве белән генә аңлатасы килми. Шулай да бу хәл Тел, әдәбият һәм тарих институты, культура институты, консерватория галимнәрен, университет һәм педагогия институтларының татар теле һәм әдәбияты кафедраларын борчырга тиеш. Студентларны һәм аспирантларны тәнкыйть проблемалары буенча махсус хәзерләү мәсьәләсендә сүздән эшкә күчәргә вакыт җитмәдеме икән?!

Әдәбият-сәнгать тәнкыйте өлкәсендәге кимчелекләр, хәл ителмәгән проблемалар әнә шулай, күбесенчә, булган мөмкинлекләрне эшкә җигә белмәүдән дә килә. Тәнкыйтьчеләребезнең гомуми активлыгы үсү фонында әлеге кимчелекләр аеруча күзгә ташлана. Аларны киметә бару һәм бөтенләй бетерүнең мөмкин булуын «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында» карар кабул ителгәннән соң күрелгән чараларның нәтиҗәлелеге дә дәлилләп тора.

Билгеле булганча, шушы карардан соң тәнкыйтьче кадрлар тәрбияләү мәсьәләсенә, тәнкыйть өлкәсендә эшләргә омтылыш күрсәткән сәләтле яшьләргә игътибар һәм ышаныч бермә-бер артты. Матбугатта да, нәшрият планнарында да яшь авторларның исемнәре ешрак күренә башлады. КПСС өлкә комитеты, аның культура бүлеге үткәргән чараларның практик әһәмияте зур булды: «Казан утлары» журналы редакциясендә яшь рецензентлар түгәрәге үзенең эшен җәелдереп җибәрде. Яшь тәнкыйтьчеләрнең республика семинары зур оешканлык белән үткәрелде, яшьләребез Бөтенроссия һәм Бөтенсоюз семинарларында да актив катнаштылар. Шушы семинарларда иҗатлары югары бәяләнгән, беренче китапларын чыгарган Р. Мөхәммәдиев һәм М. Вәлиев бүген «хәрәкәттәге эстетика»ның алгы сызыгында баручы тәнкыйтьчеләребез булып җитлекте. Аларның хезмәтләре әдәби процесста лаеклы урыннарын тапты. Балалар әдәбиятын өйрәнүгә зур активлык белән керешкән Р. Кукушкин, әдәби күренешләрне бәяләгәндә тәфсилле анализга таянырга омтылучы Ф. Галимуллин, Э. Нигъмәтуллин һәм С. Маннапов мәкаләләре дә тәнкыйтькә теоретик әзерлекле, әдәбиятка хезмәт итүне яшәү максаты итеп алган яшьләр килә дип ышанырга ныклы нигез бирә. Шунысы куанычлы, тәнкыйть мәйданына яшь алмаш аяк басуы иҗат өчен аеруча зур мөмкинлекләр туган вакытка туры килә. Әдәбиятыбызның башка жанрларындагы кебек үк безнең тәнкыйть өлкәсендә дә төрле буыннар арасында үзара тулы аңлашу хөкем сөрә. Шундый идея-иҗат бердәмлеге шартларында әдәби тәнкыйтьнең сыйфатын, нәтиҗәлелеген, әдәби процесска йогынтысын тагын да күтәрү өчен тәҗрибәле остазлары белән бер сафка яшь тәнкыйтьчеләр дә баса. Хәерле юл аларга!

Әйе, Үзәк Комитет карарыннан соң тәнкыйтьче кадрлар хәзерләү җәһәтеннән булсын, тәнкыйтьнең әдәби процесска һәм укучыга йогынтысын көчәйтү ягыннан булсын — байтак оештыру эшләре башкарылган, уңай шартлар тудырылган һәм шул кайгыртучанлыкка җавап йөзеннән тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият галимнәре зур иҗади ашкыну белән ныклап эшләгәннәр, тәнкыйтьнең эстетик куәтен һәм социаль җаваплылыгын күтәрү юлында шактый гына нәтиҗәләргә ирешкәннәр икән. Шулай да

әле иске гадәт буенча әдәби тәнкыйтьнең «артта калуы» турында сөйләнергә яратучылар бар һәм, күрәсең, ул инерцияне туктатуы җиңел түгелдер. Чир китәр — гадәт калыр, диләр бит. Кызганычка каршы, кайбер иҗат кешеләре арасында үзләренең әсәрләре киң яңгыраш алмауны да тәнкыйтьтән күрүчеләр, принципиаль тәнкыйть сүзенә үпкә саклап йөрүчеләр, хәтта төрле юллар белән шуңа каршы чыгарга азапланучылар очрап куя. Бу уңайдан Леонид Ильич Брежневның: «Тәнкыйтьне кысучыларга бернинди дә юл куймаска — һәм партия, һәм дәүләт законының таләбе шундый!» — дигән кисәтүен югары идеялелек һәм югары зәвык тантанасы өчен көрәшүче әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында сүз алып барганда да онытмаска тиешбез.

Шул ук вакытта тәнкыйть ирешелгәннәр белән канәгатьләнеп, үз эченә бикләнеп калмаска, әдәби процессны, сәнгать үсешен әйдәп барырга тиеш. Бездә әле укучы һәм тамашачы фикерен, аның рухи ихтыяҗларын өйрәнү җитәрлек түгел. Китап укучылар конференцияләре еш кына формаль төстә үтә, язучыларның халык алдындагы чыгышлары күпчелек очракта аудиториянең теләкләрен искә алмыйча оештырыла, шунлыктан аларның нәтиҗәлелеген билгеләү кыен була. Партиянең социаль политикасындагы иң мөһим бурычларның берсен үтәүдә — совет кешеләренең рухи интересларын һәм ихтыяҗларын формалаштыруда катнашу өчен, табигый ки, әлеге ихтыяҗларны белү кирәк. Тәнкыйтьнең бурычы, Рәсүл Гамзатов әйткәнчә, «начар язучыдан укучыны тартып алу». Ләкин моның белән генә чикләнеп булмый, иң мөһиме — укучының игътибарын яхшы язучыга, яхшы әсәрләргә юнәлтү, әлеге әсәрләрне тирәнтен аңларга өйрәтү.

Еш кына тәнкыйтьнең адресаты турында сүз чыга. Бу уңай белән шуны әйтергә мөмкин. Тәнкыйть укучыга да, язучыга да кирәк. «Тәнкыйтьче кем өчен яза?» дигән мәсьәләне хәл итүнең классик мисаллары билгеле. Тургенев әсәрләрен укыгач, мәсәлән, Некрасов аңа үзенең соклануын белдереп, аны зур шагыйрь дип атап язган хатын болай тәгәлли: «Юк, синең повестьларың турында бер мәкалә язарга кирәк иде,— ул чакта миңа уңайрак булыр — синең өчен түгел, публика өчен язармын дә, бәлки, сиңа язучы буларак үз-үзеңне ачып җибәрерлек нәрсәдер әйтермен: тәнкыйтьнең иң мөһим эше — шул...»

*

* *

КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары, партиябезнең соңгы съездлары ачкан офыклар әдәбият һәм сәнгатьтә яңа илһам чыганагы булып тора, иҗат өлкәләрендә җәмгыятебезнең рухи культурасына керткән өлешләре өчен җаваплылык хисен үстерә. Соңгы елларда чынбарлыкны чорлар масштабында алган, гомумкешелек, яшәеш категорияләре белән фикерләүче әсәрләр мәйданга чыга. Ә. Еники, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев прозасында, С. Хәким, И. Юзеев, Р. Мингалимов, Р. Харис поэмаларында, Т. Миңнуллин, Д. Вәлиев драматургиясендә образ һәм проблеманың яңа диалектикасы ачыла, художестволы фикер тормыш материалы белән яңа мөнәсәбәтләргә керә. Кешенең тирәлек белән түгел, үз күңелендәге каршылыклар белән көрәше, мәңгелек сорауларга җавап эзләве алгы планга чыга, әсәрләрдә автор концепциясе көчлерәк яңгыраш ала бара. Бу сыйфатлар бүген татар әдәбиятының үсеш биеклекләрен билгели һәм аларны дөрес аңлау һәм аңлату өчен әдәби процессны анализлау рәвешен дә камилләштерү таләп ителә. Соңгы елларда тупланган идея-художество тәҗрибәсен тикшерүдә һәм гомумиләштерүдә әдәби тәнкыйть фикеренең колачы, иң беренче чиратта, проблемалылык критерие белән аерылгысыз бәйләнгән булуын истән чыгармаска кирәк. Бүген татар тәнкыйте үз алдына соңгы еллар әдәбиятыбыздагы проблемалар, тенденцияләр һәм эзләнүләрне киң колач, фәнни тирәнлек белән анализлау, методологик юнәлешләрне һәм әдәби процессның яңа этабында хәл ителәсе мәсьәләләрне ачыклау һәм, әсәрләрдәге геройлар кебек үк, «вак-төяк мәшәкатьләр даирәсендә бикләнеп калмау, бәлки... кыюрак хезмәт белән тулы тормыш, гаделлек һәм яхшылык тантанасы өчен ныклы көрәш белән яшәү...» (Л. И. Брежнев) бурычларын куя. Бу — әдәбият-сәнгать тәнкыйтенең коммунистик җәмгыять төзелешендә актив катнашуы, партия һәм халыкка тугры хезмәт итүе дигән сүз.

Хәсән Хәйри

# ЯҢА ДУЛКЫН

## КЫСКАЧА БЕР КҮЗӘТҮ

Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында билгеләнгән бурычлар бүген дә көн тәртибеннән төшмәгән. КПСС-ның XXVI съездында иптәш Л. И. Брежнев әйткәнчә, «Партия иң яхшы әсәрләргә хас гражданлык пафосын, кимчелекләр белән килешмәүне, сәнгатьнең җәмгыятебезне дулкынландырган проблемаларга актив катнашуын хуплый». Бу сүзләр татар совет әдәбиятына, аның сугышчан бер тармагы булган әдәби тәнкыйтькә дә карый. Бүген әдәбиятчылар һәм тәнкыйтьчеләр сафы тагы да ныгыды, сәләтле яшь тәнкыйтьчеләрнең активлыгы көчәйде, тәнкыйть материалларының төрләнә һәм тирәнәя бару тенденциясе билгеләнде, таләпчәнлек арта төште.

Әдәби тәнкыйтьнең гомуми торышын соңгы вакытта матбугат битләрендә басылып чыккан төрле мәкалә, очерк, рецензияләр саныннан ук күрергә мөмкин. Үткән елның сентябрендә «Социалистик Татарстан» газетасы «Әдәбият һәм сәнгать» сәхифәсенең бер меңенче санын чыгарды, һәм без аны иҗтимагый-мәдәни тормышыбызның мөһим бер факты итеп каршыладык. Әлеге сәхифәләрдә яңа әсәрләргә аннотацияләр һәм рецензияләр, проблемалы мәкаләләр, иҗат портретлары, әдәби хәрәкәтне өйрәнеп анализлаган фәнни мәкаләләр дә шактый басылган. «Түгәрәк өстәл» янында сөйләшүләр оештыру да үзен раслады. Гомумән, «Социалистик Татарстан» газетасының әдәби хәрәкәтебездә шактый актив роль уйнавын билгеләп үтәргә кирәк.

Әдәби тәнкыйтьнең киң мәйданы — ул, һичшиксез, әдәби журнал битләре, «Казан утлары» журналы бу юнәлештә тырышып эшли, иҗат мәсьәләләрен киңрәк куярга, әдәбият үсешен тарихи планда да тулырак ачарга омтыла. Яшь тәнкыйтьчеләргә ярдәм кулы сузу, аларның беренче тәҗрибәләрен бастыру буенча күзгә күренерлек эшләр эшләнә. Мин биредә журнал каршында оешкан яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәген дә күз алдымда тотам. Бу түгәрәк әле үзен республика күләмендә сиздереп өлгермәде, ләкин ул яшь тәнкыйтьчеләр тәрбияләү үзәгенә әверелерлек бер авторитетлы «нокта» булып үсеп китә ала. Журналның «Яшь тәнкыйтьче сүз сорый» дигән яңа рубрикасы, анда басылган материаллар — укучы игътибарын җәлеп итәрлек әйбәт башлангыч.

Күрәсез, сүз үзеннән-үзе яшьләр, яшь тәнкыйть көчләренең үсеш авырлыклары, активлыгы мәсьәләсенә күчте. Әллә яшьлек искә төшә, әллә әдәби тәнкыйтьнең яңа күтәрелешен яшь көчләрдә күрергә омтылу теләге өстенлек итә инде... Чынлап та, һәр әдәбият, аның һәр тармагы үзенең киләчәк буыны турында уйламыйча булдыра алмый. Бүгенге тәнкыйтебездә дә сәнгать нечкәлеген бөтен йөрәге белән тоеп, киң караш белән язарга омтылган яшь талантларны күрәсе килә. Ә бездә андый сәләтле яшьләр җитәрлек. Аларны күрә белергә, олы юлга чыгу омтылышын котлап каршы алырга, кайгыртучанлык белән бер үк вакытта зур таләпчәнлек тә күрсәтергә кирәк.

Мәсәлән, «Идел» альманахының 12 нче санында (1980 ел) ике рецензия басылган. Ф. Зөлкәрнәевнең Гәрәй Рәхим иҗаты турындагы мәкаләсе һәм М. Гайнетдиновның Зөлфәтнең «Утлы бозлар» җыентыгына рецензиясе. Һәр икесендә поэзиясе аңлау, хис итү, шагыйрь иҗатының үзенчәлеген ачарга омтылу бар. Ләкин яшь тәнкыйтьчеләр соклану, мактау сүзләре белән чамасыз мавыгалар, әсәрләрдә бүгенге көн

рухы, замандашыбызның эчке дөньясы, хыялы, көрәше, эше шигъри образларда, лирик авазда ничек сизелгәнең, чагылганын бигүк ачып бетерә алмыйлар, урыны-урыны белән поэтик үзенчәлекне тышкы билгеләр белән генә үлчәүгә кайтарып калдыралар. Менә бу кимчелек, ягъни формаль сыйфатларга игътибар итеп тә, әсәрнең эчке идея пафосы, халык рухы, халык яшәешенә лаеклы шигъри пафос мәсьәләләренә тиешенчә игътибар бирмәү, гомумән, шактый яшь иптәшләребезгә хас.

Яшь авторларның зона конференцияләрен үткәрү, олы әдипләр белән очрашу практикасы, яшь тәнкыйтьчеләрне дә шул җанлы эш процессына тарту бездә матур һәм гадәти күренешкә әйләнде. Шулай да язучылар союзы каршындагы яшь әдипләр белән эшләү комиссиясенең һәм тәнкыйтьчеләр секциясенең бу тармакта әле тулы көчкә эшләмәвен искәртеп үтү урынсыз булмас. Секция утырышларында яшьләр нигәдер сирәк күренәләр: оештыру, кызыксындыру, башлангыч хезмәтләренә игътибар итү җитешмидер, күрәсең.

Соңгы вакытта матбугат битләрендә яшь тәнкыйтьчеләрнең кыюрак сүз алуы куанычлы хәл. Р. Кукушкин, Ф. Галимуллин, Э. Нигъмәтуллин, Салих Маннапов, Л. Хәйдәрова, Ф. Зөлкарнәев һәм башка яшь авторларның мәкаләләре, рецензияләре еш кына күренә башлады. Аларның активлыгы тагын да артсын, сүрелмәсен иде. Алар арасында балалар әдәбияты үсеше белән кызыксынучы иптәшләр бар. Балалар-яшьләр әдәбиятының үзенчәлеген аңлап язылган тәнкыйть сүзе әле бик сирәк ишетелә.

Тәнкыйтьнең дәрәҗәсен тагын да күтәрү өчен бездә мәйдан җитәрлек. Язучылар союзы сафында тәнкыйтьчеләр саны егерме биштән артык, яңа көчләр дә өстәлә тора. Ләкин активлык дәрәҗәсе төрлечә шул. Соңгы елларда публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләре, очерк, рецензияләре белән даими чыгыш ясап килгән иптәшләрнең кайберләрен атап үтәргә дә мөмкин: И. Нуруллин, Р. Мостафин, Н. Юзиев, Ф. Мусин, А. Әхмәдуллин, Т. Галиуллин, Ф. Әгъзәмов, Р. Мөхәммәдиев, Ф. Миңнуллин, М. Вәлиев, И. Ахунҗанов, Р. Сверигин, Ф. Урманчиев һ. б. лар. Кайбер күренекле язучылар да тәнкыйтьтән читтә яшәмиләр, үз фикерләре, теләкләре белән уртаклашып, кимчелекләрне үткен тәнкыйтьләп язалар. Мәсәлән, Г. Ахунов, Ф. Хөсни, С. Хәким, Т. Миңнуллин, М. Мәһдиев, Р. Фәйзуллин һ. б.ларның чыгышларын искә төшерик. Билгеле, язучы сүзе шәхси тәҗрибә, иҗади кичерешләр белән дә аерылгысыз бәйләнгән, кайчак субъектив рәвешендә дә була. Бу — табигый нәрсә. Бирелә сүз тәнкыйть хезмәтләренең, тәнкыйть өлкәсендә эшләүчеләрнең саны турында гына бармый (анысы да мөһим фактор, әлбәттә). Иң мөһиме — тәнкыйтьнең идея-эстетик кыйммәте, теоретик тирәнлеге, киңлеге, аның гомуми дәрәҗәсе...

Безнең әдәби хәрәкәтне күпмилләтле бердәм совет әдәбиятының катлаулы үсеш процессыннан аерым күз алдына китерү мөмкин түгел. Уртаклык та, төрлелек тә бар анда. Тәнкыйтьченең, әдәбият белгеченең аны күрә һәм тоя белергә тиешлеген гомуми бер хакыйкать буларак яхшы ук аңлыйбыз шикелле. Шулай да бездә әле ул киңлек, зур мәйданга чыгып сөйләшү бигүк җитешми. Бөтенсоюз матбугатында, кызганычка каршы, мәкаләләребез, күзәтү, рецензияләребез сирәк күренә. Соңгы елларда үзәк матбугат битләрендә Р. Мостафин, Г. Ахунов, Ф. Мусин, И. Нуруллин хезмәтләренең шактый еш басыла башлавын уңай бер тенденция дип билгеләп үтәргә кирәк. Мәсәлән, Ф. Мусинның яхшы ук эчтәлекле һәм проблемалы ике мәкаләсе «Правда» газетасында басылды. Р. Мостафин СССР Язучылар Союзының бүләгенә лаек булды. Бу юлда сәләтле яшь тәнкыйтьчеләребезнең дә активлашуын теләр идек. Мәйдан киң — сәләт, тырышлык һәм теләк кенә булсын.

Тәнкыйть хезмәтләрен аерым китап итеп чыгару мәсьәләсен дә онытмаска тиешбез. Монда да оперативлык, таләпчәнлек кирәк. Тәнкыйть сүзе заман сораулары, бүгенге бурычлар белән аеруча тыгыз бәйләнгән. Татарстан китап нәшрияты моңа игътибар итми, дип әйтә алмыйбыз. Ел саен берничә исемдә тәнкыйть китабы басылып чыга. Мәсәлән, 1980 ел китапларының дүртесе, 1981 ел китапларының бишесе (шулардан икесе рус телендә) турыдан-туры әдәби тәнкыйтькә карый. Гомумән алганда, күп түгел бу.

Соңгы елларда басылып чыккан һәм күңелдә тирән эз калдырган кайбер китаплар турында махсус сүз әйтәсе килә. Әдәбият белгече һәм тәнкыйтьче М. Хәсәновның «Интернационализмның җанлы традицияләре» исемле китабына 70 нче елларда язылган мәкаләләре тупланган. Җыентык рәвешендә төзелгән булса да, ул киң эчтә-

лекле һәм проблемалы җитди бер бөтен хезмәт булып тора. М. Хәсәнов интернационализмның тарихи традицияләре, яңа дәвердә кабатланмаслык яңа әдәбият үсүе, новаторлыкның идея-эстетик сыйфатлары турында шактый киң итеп яза, татар әдәбиятында социалистик реализм формалашуының кайбер үзенчәлекле якларын ача, үсеш баскычларының чикләрен, этапларын тәгәлрәк билгеләргә кирәклеген әйтә, хәл ителеп бетмәгән бәхәсле мәсьәләләрне куя. Чынлап та, уйланырлык, фикер алышырлык нәрсәләр бар бу китапта. Анда бүгенге әдәби хәрәкәткә багышланган ике мәкалә дә бар. Татарстанның 60 еллыгы уңае белән язылган публицистик мәкаләдә автор хәзерге әдәбиятыбызда сәләтле яңа көчләр арта баруы, гомумән әдәби-иҗат эшләренең җанлануы турында сөйли. «Героик хезмәт, күтәренке рух, киләчәккә ышаныч тантана итә» дигән бәясе-нәтиҗәсе бик урынлы, бик дөрес.

Бүгенге драматургияне тикшергән, аның теоретик проблемаларына багышланган зур тәнкыйть хезмәтләре бездә бик сирәк күренә. Андый һәр хезмәт — үзе бер вакыйга диярлек. Азат Әхмәдуллинның «Сәхнә әдәбияты һәм тормыш» дигән китабын шундыйларның берсе итеп исәпләргә мөмкин. Бу җыентыкта татар драматургиясенең 60—70 нче еллардагы үсеше чагылдырыла, театр һәм драматургиянең бик мөһим мәсьәләләре тикшерелә, аерым драматургларның иҗат портретлары бирелә. Авторның төп игътибары бүгенге драматургиянең торышын, үзенчәлекле осталар иҗатын өйрәнүгә юнәлтелгән. Мәкаләләр шактый җанлы һәм үткен язылганнар, танылган драматургларыбызның әсәрләренә, минемчә, автор объектив бәя бирә, һәркайсының үзенчәлеген, новаторлык сыйфатларын ачарга омтыла. Кызганычка каршы, төрле елларда язылган мәкаләләр булгангамыдыр, җыентыкта урыны-урыны белән кабатланулар очрый (мәсәлән, Туфан Миңнуллин иҗатын тикшергәндә һ. б.).

1980 елда Ринат Мөхәммәдиевнең «Әгәр без янмасак...» дигән җыентыгы чыкты. Башта ук шуны да әйтеп үтик: Татарстан китап нәшрияты «Яшь тәнкыйтьченең беренче китабы» сериясен башлавы белән бик уңышлы һәм эшлекле адым ясаган. Мондый практик чаралар партия Үзәк Комитетының әдәбият-сәнгать тәнкыйте һәм иҗат яшьләре белән эшләү турындагы мәгълүм карарларын үтәү юлында конкрет эш үрнәге булып тора.

Ринат Мөхәммәдиевнең нигездә бүгенге поэзиябез мәсьәләләренә багышланган җыентыгы зур кызыксыну белән укыла. Тәнкыйтьчегә бигрәк тә шигърият музыкасы, шигъри фикер, шигъри моң якын. Ул поэтик образлар системасын художникларча тоя, поэзиябездәге эзләнүләр һәм яңа ачышлар турында дулкынланып сөйли, аерым мисаллар нигезендә бу процесска төгәл бәя бирә. Җыентыкны ачып җибәрүче «Әгәр син янмасаң, әгәр без янмасак...» дигән шигъри исемле мәкаләнең төп рухы «шигъриятебезгә гражданлык күзлегеннән бер караш» дип билгеләнгән. Тәнкыйтьче поэзиянең гражданлык йөзе халыкчанлык рухы мәсьәләсен тикшерә, шагыйрь һәм халык тормышы, халык моңы турында уйлана, бүгенге заман кешесенең коммунистик җәмгыять төзүче кешенең үй-тойгылары, идеаллары иҗат үзәгендә булырга тиешлеген күрсәтә. Татар әдәби тәнкыйте формалашу үзенчәлекләрен, анда олы әдипләрнең ролен автор бай материалга таянып анализ ясау аша ача.

Әдәби тәнкыйть — матур әдәбиятның аерылгысыз бер өлеше, «хәрәкәттәге эстетика». Рус әдәбиятында «Критика как литература» дигән махсус хезмәтләрнең чыгуы да бер дә очраклы түгел. Тулаем әдәби хәрәкәтне тәнкыйтьтән башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Кайчак безнең арада әдәбият тарихчыларын тәнкыйтьчеләргә каршы кую, тәнкыйтьчегә ничектер түбәнсетеп карау кебек ямьсез күренешләр очрый. Мәгънәсез һәм зарарлы нәрсә бу. Һәркайсының хөрмәткә лаеклы үз урыны бар. Тәнкыйтьче бигрәк тә иҗатка, әдипләрнең эчке рухына якын тора. Язучы шәхесе, индивидуаль иҗат йөзе турында без еш сөйлибез, үзенчәлекле тәнкыйтьче шәхесе сыйфатларын да, минемчә, дөрес күрергә һәм аңларга кирәк. Мәсәлән, Г. Нигъмәти һәм Г. Галине без бик үзенчәлекле иҗади шәхесләр итеп искә алабыз. Бүгенге тәнкыйтьтә Н. Юзиев, И. Нуруллин, Р. Мостафин, Ф. Мусин, А. Әхмәдуллин, Т. Галиуллин һ. б. иҗатлары зур кызыксыну уята.

Соңгы ун елда безнең әдәбият фәнебез дә яңа тикшерүләр белән баеды. Тарихи һәм теоретик хезмәтләр, һичшиксез, әдәби тәнкыйтебез үсешенә дә уңай йогынты ясый. Биредә мин тарихи хезмәтләргә, андагы уңышларга һәм бәхәсле мәсьәләләргә тукталуны кирәкле тапмадым. Бу турыда гыйльми утырышларда махсус сөйләшүләр булып тора.

Бүгенге әдәби тәнкыйть мәйданы, әйткәнебезчә, торган саен киңәя бара, аның уңышлары да кечкенә түгел, әмма кимчелекләр дә шактый әле. Татарстан китап нәшрияты ел саен йөз егермедән артык төрле әдәби әсәрләр дөньяга чыгара. Аларның шактый өлеше турында миңа калса, әлегә җитди тәнкыйть сүзе җитенкерәми. Тәнкыйтьтә жанр төрлелегенә ирешү, аның идея-эстетик тирәнлеген, политик үткенлеген көчәйтү буенча да әле нык эшлисе бар.

Җитди бер гомуми кимчелек турында аерым басым ясап әйтеп үтәсе килә. Ул хакта КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында да бик ачык әйтелгән иде. Язучы иҗатын төрлечә бизәп, күккә чөеп язылган кайбер тәнкыйть мәкаләсен яки рецензияне укыганда нигезсез мактау сүзләренең кире күләгәсе сизелә башлый. Әйе, мактауны кем генә яратмас! Әмма ул гадел булсын, дәлилле булсын, язучының иҗатын дөрес аңларга ярдәм итсен. Иҗади эш, әдәби хәрәкәт шактый катлаулы һәм каршылыклы да бит. Язучы һәм заман, бүгенге кеше образы, бүгенге герой характеры, халык тормышында барган бөек социаль, психологик, әхлакый үзгәрешләр процессының теге я бу иҗатта, аерым әсәрдә ни дәрәҗәдә тирән мәгънәле итеп ачылуы кебек мөһим мәсьәләләр тәнкыйтьче игътибарының үзәгендә торырга тиешлеге күптән мәгълүм. Традицияләрне дәвам итү һәм новаторлык үзенчәлеген тикшергәндә дә боларны онытырга ярамый. Гел мактап язылган бер тип, төссез мәкалә яки рецензияләр әдәбиятның төрле талантларга бай булуын аңларга, әчке рухын тоярга ярдәм итмиләр. Аларның укучыда ризасызлык, бертөрлелек, яссы бер күренеш кенә тудырулары ихтимал. Бу турыда рус прозасының зур остасы Юрий Бондаревның сүзләре, күзәтүләре бик кызыклы. Шушы уңай белән менә нәрсә ди ул: «...много раз я читал, что такой-то писатель известен, самобытен, талантлив, ярок, своеобразен, и в конце концов оказывается, что известны, талантливы, своеобразны, ярки, серьезны, даже замечательны (это уж определение никак невозможно понять) почти все, кто пишет книги, независимо от того, современный Потапенко в поле зрения или современный Чехов. Таким образом, мы уравниваем нашу литературу, одновременно принижаем самих себя, славу нашей культуры перед читающим миром...»[1] Бик хак сүзләр, әдәбиятчыга да, тәнкыйтьчегә дә кагыла торган туры әйтелгән сүзләр. Моңа аңлатма кирәкмидер.

Билгеле, хикмәт анда гына түгел. Әдәби хәрәкәттә, иҗат эшендә тәнкыйтьченең урыны аеруча киң һәм җаваплы. Чын әдәби тәнкыйть иҗтимагый-әхлакый тормыш мәсьәләләреннән, идеологик көрәштән, идеологик-рухи тәрбия эшеннән читтә яшәми. Киресенчә, ул һәрвакыт мондый мәсьәләләрдә сизгер була, үзәктә тора. Тарихи күренешләрне бәяләүдә яки хәзерге идеологик көрәш фактларын аңлауда партиялелек, сыйнфыйлык позицияләрен «оныту» кебек нәрсәләр очрый икән, безнең тәнкыйть моңа үзенең ачык мөнәсәбәтен белдерергә тиеш. Культура, әдәбият һәм сәнгать тарихына караган мәкалә яки информацион белешмәләр аерым очракта кайбер сорау-бәхәсләр дә тудыралар икән, моны матбугатта ачык әйтеп чыгу әле бездә җитешми.

Иптәш Л. И. Брежнев үзенең докладында бу мәсьәлә уңае белән бик ачык итеп аңлатып үтте. «Идеясезлек күренешләре, дөньяга караштагы талымсызлык, аерым тарихи вакыйгаларга һәм шәхесләргә тәгәл сыйнфый бәя бирүдән читләшү хәтта талантлы кешеләр иҗатына да зыян китерүе мөмкин,— диде ул.— Тәнкыйтьчеләребез, әдәби журналларыбыз, иҗат союзларыбыз һәм, беренче чиратта, аларның партия оешмалары теге яки бу якка сугылучыларны төзәтә белергә тиешләр. Партия сәнгатебезнең идея юнәлешенә битараф булмады һәм була алмый». Язучы да, тәнкыйтьче дә идеология көрәшенең иң алдынгы сафында тора. Бөек Белинскийның да моңа шулай караганлыгы мәгълүм.

Күп милләтле совет әдәбияты социалистик реализмның партиялелек һәм халыкчанлык принциплары нигезендә бердәм әдәбият булып үсә, милли әдәби-иҗади үзенчәлекләр җирлеге яңа тарихи шартларда яңара, үзгәрә бара, иң зур уңышларыбыз уртак хәзинәгә кушыла. Хәзер бездән, Бөтенсоюз әдәбиятының киң иҗат тәҗрибәләренә таянып, әдәбиятның бердәм, комплекслы үсешенә караган бурычлар яктылыгында уйлану, иҗади эшнең яңа үрләренә күтәрелү юлында армый-талмый эшләү таләп ителә.

[1] «Новый мир» журналы. 1980, 12 сан, 230 бит.

# ХӨСӘЕН ЯМАШЕВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

## Хөсәен Хәсәнов

# СҮНМӘС УЧАК

Әхмәтҗан хәлфә Хөсәенне «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга бирергә киңәш итте. Заманның алдынгы уку йортларыннан саналган бу мәдрәсәдә дин дәресләре белән беррәттән дөньяви фәннәр дә укыталар. Хөсәен ата-аналарының ризалыгы белән шул мәдрәсәгә керде. Шәкертләрнең ирege гаять чикле. Хәкимлек итүче кеше — мулла. Аның боерыгыннан башка бер нәрсә дә эшләргә ярамый. Уку программасы да бик үк канәгатьләнерлек түгел, иң күп урынны дин дәресләре алып тора. Шулай да мәдрәсәдә математика, табигать, тарих, әдәбият фәннәре дә укытыла. Хөсәен төп игътибарын шуларга бирә.

«Мөхәммәдия» яшь Хөсәеннең аң үсешендә билгеле бер баскыч булды. Биредә ул җәмгыять тормышындагы катлаулы мәсьәләләрне аера белерлек хәлгә килде, илнең төрле якларыннан җыелган шәкертләр белән танышты.

Әмма дини мәктәп белән чагыштырганда күп өстен торган «Мөхәммәдия» дә хәзер Хөсәенгә белем дөньясы өчен чикле булып күренде. Алдынгы шәкертләр мәдрәсә белән генә чикләнмиләр, гимназия, университет һәм институтларга керәләр. Байтак татар яшьләре Учительская школада укый. Ямашев яшьләр дөньясындагы бу үзгәрешләрне йотлыгып күзәтеп тора. Берничә атналарга сузылган уйланулары нәтиҗәсендә ул мәдрәсәдән китәргә була.

Җиде классны тәмамлау белән Хөсәен үзенең теләгән ата-аналарына әйтә: «Мин учительская школага керәм»,— ди. Ләкин атасы Минһаҗ агай моңа баш-аягы белән каршы килә. Аның бердәнбер улын үз тирәсендә инсафлы итеп үстерәсе, сәүдә эшенә өйрәтәсе килә. Тик алдынгы фикерле таныш-белешләренең үгете белән генә, улын укырга алуны сорап гариза бирә. 1897 елның октябреннан Хөсәен Учительская школада укый башлый.

Учительская школа Хөсәенгә бөтенләй икенче дөнья ачып җибәрә. Укучылар фән, җәмгыятькә кирәкле эшләр турында җитди фикер йөртәләр. Уку ысуллары да башка. Хөсәен укыган елларда анда Ахмаров, Терегулов, Гаржавин һәм Табиров кебек күренекле галимнәр дәрес бирә.

Школада төрле карашлы яшьләр бар. Берәүләр либераль агымга иярде, икенчеләре вак-буржуаз идеологиясе юнәлеше белән китте, өченчеләре анархизм чире белән авырды. Ямашев демократик карашлы яшьләр белән дуслашты. Аның фикердәшләре Колахметов, Әхтәриев, Юскаев, Сакаев һ. б. булдылар. Сан ягыннан күбәя барып, алар үз карашларын катгый яклаучан куәтле бер төркемгә әверелделәр. Үткен сүзле, төпле уйлаучан Ямашев бу төркемнең җитәкчесе булып китте. Аның фикере белән исәпләшәләр, әйткәннәрен тыңлыйлар, кисәтүләрен искә алалар.

Школада укыганда ук Ямашев политик әдәбият белән кызыксына башлый. Шушы теләк аны рус революционерлары белән якынлаштыра, ул А. Кулеша, В. Адоратский һәм Е. Табейкин белән таныша. Тәҗрибәле рус революционерлары белән бәйләнеш тоту аның политик аңы үсешендә гаять зур роль уйный.

1902 елда Ямашев Учительская школаны уңышлы тәмамлады. Белемнең кирәклеген яхшы төшенеп өлгергән Хөсәен укуын дәвам иттерергә — университетка керергә ниятли. Ул белгән революционерларның күбесе Казан университетында укыйлар. Татар социаль-демократларыннан Ибраһим Әхтәмов та студент булган.

Учительская школа урта белем бирсә дә университетка керү хокукын бирми. Аның өчен гимназия дипломы кирәк. Ямашев кичекмәстән имтиханнарга хәзерләнергә керешә.

Минһаҗ агайның кинәт үлеп китүе генә гаиләне авыр хәлгә куя. Өйдә олыгаеп килә торган ана, ике кыз бала бар. Учительская школаны тәмамлаган елны Ямашев

өйләнеп тә куйган иде. Хәзер ни эшләргә? Барлык туган-тумачалар, белеш-танышлар бер генә киңәшне бирәләр — сәүдә эшен дәвам иттерергә? Ләкин илдәге социаль үзгәрешләрне үтәдән-үтә күреп торган, политик аңы шактый җитлеккән Ямашев бу юл белән китә алмый. Гаиләләрен авыр хәлгә куеп булса да, ул үзе иманган һәм сайлаган юл белән китәргә тиеш. Ул яңадан зур көч һәм дәрт белән гимназия аттестаты алу өчен имтиханнарга хәзерләнергә керешә.

Тиздән Идел буена да революция дулкыны килеп җитте. Казан эшчеләре эш ташлады, крестьяннар алпавытлар изүенә каршы күтәрелде. Студентлар да югары уку йортларында демократик тәртипләр урнаштыру өчен көрәшкә кузгалдылар. Болар барысы да Казан социал-демократлары алдына революцион хәрәкәткә даими җитәкчелек итү бурычын куйды. Х. Ямашев та ул хәрәкәттән читтә кала алмады, революция дулкыны аны да үз эченә тартып алды. Ул изелгән һәм җәберләнгән халыкларны бәхетле итү өчен батырларча көрәшүчеләр сафына басты һәм Казан социал-демократлар оешмасына член булып керде.

Ул Казан эшчеләренең стачка һәм демонстрацияләрен хәзерләде, митингларда кайнар речьләр белән чыкты, буржуаз милләтчеләрнең усал ниятләрен фаш итте. Беренче рус революциясенең кайнар көрәш көннәрендә Х. Ямашев большевистик оешманың күренекле һәм тәҗрибәле кешеләреннән берсе булып өлгерде.

Казанда декабрь кораллы күтәрелешен хәзерләгәндә полиция эзәрлекләүләре тагын да көчәйде. Инде күтәрелеш өлгерде дигәндә полиция партия оешмасын тармар итте. Ямашевны да кулга алырга әмер бирделәр. Ямашев Яңа бистәдәге ышанычлы бер танышына барып сыена. Ләкин болай озак яшәргә мөмкин түгел, полициянең эзгә төшүе бар. Кулга эләгү куркынычы арткач, ул Казаннан китәргә була, Чистайга юнәлә.

Бирәдә аның хатынының туганнары тора. Ләкин кеше күзенә күренергә ярамый, танып, өяз полициясенә хәбәр итүләре бар. Һәрхәлдә, моннан тизрәк китү хәерле. Әлмәттә аның кыз туганы тора, бәлки аңа барып сыеныргадыр? Юлда төрле хәл булуы мөмкин. Туганнары аңа украин күлмәге һәм чикмәне табып бирәләр, битенә сакал да ябыштыра.

Ямашев Әлмәткә Якуб җизнәсенә икенче көнне кич, караңгы төшкәч кенә барып керә.

— Хөсәен туган,— диде Якуб җизнәсе,— бер дә хафаланма. Бакча якта бик чиста ак мунчабыз бар, көндез шунда торырсың, кичен — өйдә. Алдагысын тагын күз күрер.

Ялгыз калгач, ул еш кына үткәннәрне исенә төшерә: азатлык өчен барган бөек көрәштә катнашуына ул һич тә үкенми, горурлана гына. Бу үзе зур университет — көрәш университеты. Көрәш киң җәелеп барган көннәрдә аны, большевикларның Казан комитеты члены буларак, татар группасының җитәкчесе итеп билгеләделәр. Ул Свердлов, Саммер, Лихачев кебек күренекле һәм тәҗрибәле революционерлар белән кулга-кул тотынып эшләде. Аның татарлар арасындагы хезмәтләренә югары бәя биреп, В. И. Ленин җитәкчелегендә чыга торган «Пролетарий» газетасы Х. Ямашевны «зур ортодоксаль социаль-демократ» дип атады. Менә болар барысы да хәзер бербер артлы күз алдыннан үттеләр.

Атнадан артык вакыт үткәч, Хөсәен өйдәгеләргә болай эшсез утырырга ярамаганлыгын, кая да булса берәр шәһәргә китәргә кирәклеген әйтте. Ләкин аның янында бер нинди дә документы юк. Әгәр шул килеш чыгып китсә, бик тиз тотылуы бар. Аңа җизнәсе ярдәмгә килде. Ул Әлмәттә билгеле, хөлле кеше. Волость начальствосы белән дә элемтәсе зур. Бик еш аңа писарь кереп, сыйланып чыга. Менә шуның аркылы эшне җайлап җибәрергә мөмкин. Икенче көнне ук Якуб конторага керде дә, писарь белән сөйләште. Писарь исә аның үтенечен үтәргә вәгъдә бирде. Билгеле, бушка түгел...

Х. Ямашев Казанда туып үссә дә, яңа паспортта аны «Әлмәт авылы крестьяны» дип яздылар. Исем, фамилиясе элеккечә калды. Менә шушы паспорт белән ул ярым легаль хәлдә яши башлады.

Паспорт өлгерү белән, Ямашев Уфага китәргә булды. Уфа шактый зур шәһәр. Бирәдә партия оешмасы уңышлы гына эшләп килә, элемтәгә кереп, Уфа эшчеләре арасында революцион эш җәеп җибәрергә мөмкин.

Бирედә ул Казанда эшләп киткән социал-демократлар — Брюханов белән Накоряковны очратты, алар ышанычлы фатир табып бирделәр. Бераздан Ямашев, партиянең тәҗрибәле работнигы буларак, Уфа РСДРП комитетына член итеп тартылды, ул монда да татар, башкортлар арасында революцион эш алып барды, предприятиеләрдә марксистик түгәрәкләр оештырды, большевистик прокламацияләр таратты.

Бер вакыт Уфага Уралдан Үзәк Комитет члены И. А. Саммер килеп төшә. Х. Ямашевны яхшы белгәнгә, ул аның квартирына урнаша. Бераз ял иткәч, И. А. Саммер Уфа РСДРП Комитеты членнары белән очраша, аларны партиядәге хәл белән таныштыра, революция сүрелеп барган чорда нинди тактика үткәрергә кирәклеген аңлата. Шундый очрашуларның берсендә Ямашев үзенең татар телендә большевистик газета чыгарырга ниятьләнүен әйтә. Ләкин бу зур һәм әһәмиятле эш өчен каян акча табарга? Шул турыда сүз чыккач, Уфа большевиклары Комитет карамагында экспроприация юлы белән җыелган акча барлыгын хәбәр иттеләр. Иван Адамович, Үзәк Комитет вәкиле буларак, шул фондтан газета чыгару өчен 500 сум акча тотарга рөхсәт бирә. Әмма Уфаның үзендә газета чыгару өчен кирәкле шартлар юк, өстәвенә полиция күзәтүе дә көчле. Шуларны исәпкә алып, яңа газетаны Оренбургта чыгару уңай дип табылды.

1907 елның 4 январенда «Урал» исеме белән татар телендә яңа газета чыга башлады. «Урал»ның төп мәшәкатен Ямашев үз өстенә алды. Ул — редактор, әдәби сотрудник, корректор. Аның бөтен гомере типографиядә үтә. Тик Оренбургта сәргендә яшәүче Галимҗан Сәйфетдиновны газета эшенә тарткач кына Ямашевның авыр хезмәте бераз җиңеләйде.

«Урал» татар большевикларының сугышчан органына әйләнде. Ул партиянең дума тактикасын өзлексез яктыртып торды, милләтчеләрнең мәкерле максатларын фаш итте, демократик культураны үстерүгә зур игътибар бирде. «Урал» ул чак татар телендә марксизм-ленинизм идеяләрен таратучы бердәнбер орган булды. Аның битләрендә пролетар интернационализм һәм халыклар дуслыгы идеяләре киң урын алды.

Хезмәт халкы теләкләрен тырышып яклаучы газетаны патша властьлары туктаусыз эзәрлекләделәр. Редакциядә бик еш тентүләр булып торды. Газетага кушымта итеп чыгарылган политик брошюраларны җыеп алдылар. Ниһаять, патша хөкүмәтенә каршы мәкаләләр бастырганы өчен, «Урал»ны яптылар һәм аның сотрудникларын хөкемгә тарттылар.

Хөсәен җәен Уфага кайтты, Оренбургтагы борчулар бераз сүрелә төшкәч, әле һаман чиратын кичектереп килгән укуын дәвам иттерү турында уйланырга керешә. Ул яхшы белә: алда аны кискен бәрелешләр көтә. Катлаулы бурычларны уңышлы хәл итү өчен көчле, белемле булырга кирәк. Моның юлы бер — укуны дәвам иттерү. Ул Казан университеты ректорына үзен юридик факультетка ирекле тыңлаучы итеп алуны сорап гариза җибәрде. 19 сентябрьдә аңа үтенече канәгатьләндерелгәнне хәбәр иттеләр.

Университетта укулар башланыр алдыннан Х. Ямашев Казанга кайтты, иректә калган социал-демократлар, таныш эшчеләр белән очрашты. Якын дуслары Гафур Коләхметов, Галиәсгар Камал һәм Габдрахман Мостафин аны шатланып каршы алдылар. Шушы көннәрдә ул яңа гына Казанга килгән Габдулла Тукай белән очрашты. Замандашларының истәлекләренә караганда, алар Яңа бистәдә Алеевлар йортында күрешкәннәр. Менә шушы вакыттан алып большевик Ямашев белән атаклы шагыйрь Тукай арасында зур дуслык мөнәсәбәтләре башланып китә.

Кызганычка каршы, Хөсәен ашкынып көтеп алган укуын озак дәвам иттерә алмады. Революция елларында бернинди ялсыз, көне-төне эшләү, полиция эзәрлекләүләре аның сәламәтлеген бик нык какшаткан иде. Ул үзендә үпкә авыруы башлануын сизде. Көтмәгәндә килеп чыккан бу бәла аны университет лекцияләрен калдырып торырга мәҗбүр итте.

Врачлар кичекмәстән көньякка китеп дәваланырга киңәш бирделәр. Аңа якын иптәшләре ярдәм иттеләр: үзара акча җыеп, Х. Ямашевны Кавказга — Сухумига озаттылар.

Уңышлы гына дәваланып, шактый ныгып, язын Ямашев Казанга кайтты. Укуны дәвам иттерү мәсьәләсе аңа һаман тынычлык бирми иде. Хәзер ул ирекле тыңлаучы булып кына түгел, бәлки тулы хокуклы студент булып укырга ниятли. Билгеле, мо-

ның өчен беренче чиратта гимназия аттестаты кирәк. Ул җиңел эш түгел. Кимендә 9 лап фәнни имтихан тапшырасы бар. Теләккә ирешү өчен бертуктаусыз әзерләнергә, көне-төне укырга кирәк. Бу Ямашевны куркытмый. Ул җиң сызганып эшкә тотына — үзлегеннән гимназия курсын үзләштерергә хәзерләнә.

Барлык фәннәрдән сынауларны уңышлы узгач, педагогик совет Ямашевка өлгергәнлек аттестаты бирү турында карар чыгарды. Бу исә аңа университетка керү хокукын бирде. Баштарак Ямашев медицина факультетына керергә уйлаган иде. Ләкин ул бу фикереннән кире кайтты, юридик факультетны сайлады. Моның сәбәбен аңлау кыен түгел. Революцион көрәш утында кайнаган Ямашевка иҗтимагый-экономик фәннәр укыта торган юридик факультет якынрак иде.

Зур кыенлык белән булса да, беренче зур күпер үтелде — өлгергәнлек аттестаты кулда. Алда тагын бер хәтәр күперне үтәсе бар — ул губерна жандармы идарәсеннән политик ышанычлылык белешмәсе алу. Шул белешмәдән башка беркемне дә университетка кабул итмиләр. Х. Ямашев исә профессиональ революционер, өстәвенә Оренбургта суд хөкеменә тартылган кеше. Мондый хәтәр шәхескә ышанычлылык белешмәсе бирерләрме? Бу очракта аны Әлмәттә алган паспорты коткарды. Ул паспортта Хөсәен Казан кешесе итеп түгел, бәлки Әлмәт авылы крестьяны итеп күрсәтелгән. Шунлыктан жандарм идарәсе чиновниклары, артык төпченеп тормастан, Ямашевка, Әлмәт кешесе буларак, политик ышанычлылык белешмәсе бирделәр.

1911 елның августында Ямашев Казан университеты ректоры исеменә үзен юридик факультетка алуны сорап гариза бирде. 18 августта аны теләгән факультетына студент итеп кабул иттеләр. Шул көннән алып Ямашев лекцияләргә йөри башлады.

Университетның ак колонналарын үтеп, беренче лекциягә килгәндә, Хөсәен үзендә зур горурлык сизде. Идел буендагы бу фән сараенда бөек математик Лобачевский, мәшһүр Бутлеров, атаклы астроном Симонов, исеме киң таралган физиолог Ковалевский һәм күп кенә бүтән талантлы кешеләр укыганнар. Казан университетында укыганда даһи Ленин беренче тапкыр революцион көрәш юлына аяк баскан. Бөтен дөньяга билгеле шушы күренекле шәхесләр белем алган фән йортында хәзер Ямашев та укыячак. Татар егете өчен бу зур бәхет, зур шатлык.

Университетка кергәч тә Ямашев революцион эш алып баруын дәвам иттерде. Дөрес, бу зур хәвеф белән бәйләнгән иде. Әгәр жандарм шымчылары сизенсәләр, читенлек белән кергән университеттан аны бик тиз куачаклар. Ләкин ул, революционер буларак, көрәшсез, үз эченә генә бикләнеп яши алмый. Изелгән, җәберләнгән кешеләрне ирекkә, яктылыкка өндәү — аның изге бурычы.

Университетта укый башлавының беренче көннәреннән үк Ямашев татар яшьләре арасында киң эш җәеп җибәрде. Аның җитәкчелегендә 16 кешедән торган әдәби түгәрәк оешты. Университет студентлары Мөстәкыймов, Гобәйдуллин, Бикбов, укытучы Коләхметов, курсисткалар Габитова, Терегулова һәм Арсланова бу түгәрәкнең актив членнары иде. Бераз соңрак түгәрәк занятиеләренә Габдрахман Мостафин, Габдулла Кариев, Галимҗан Сәйфетдинов, Ибраһим Кулеев һ. б. йөри башлады. Түгәрәк членнары башта рус һәм дөнья әдәбияты классикларының әсәрләрен өйрәнделәр. Занятиеләрнең берсендә Арсланова «Шекспир әсәрләрендә хатыннар образы» дигән темага реферат укыды. Әмма тора-бара Ямашев түгәрәкнең эшенә политик юнәлеш бирергә тырышты.

Түгәрәк членнары арасында Фоат Туктаров һәм Нәҗиб Хәлфин кебек буржуаз милләтчеләр дә бар иде. Ямашев аларга каршы кискен идея көрәше ачты. Тиздән бу милләтчеләр түгәрәкне ташлап китәргә мәҗбүр булдылар. Шул рәвешчә Х. Ямашев түгәрәкнең демократик карашлы членнарын буржуаз милләтчеләрнең зарарлы йогынтысыннан саклап калды һәм аларны актив революцион эшкә тартты.

Университетта укыганда Ямашевка авыр хәлгә очраган көрәштәшләренә ярдәм итәргә туры килде. Аның якын дусты большевик Зариф Садыйков 1908 елда кулга алынды. Аның яшерен яшәү аркасында шактый нык какшаган сәламәтлеге төрмәдә утырганда тагын да начарланды. Салкын һәм юеш камерада ачлы-туклы яшәп, ул үпкә авыруы алды. Тик 1911 елда срогы тулгач кына азат иттеләр. Ул инде бөтен сәламәтлеген югалткан иде. Больницада ятып, бераз хәл алгач, 1911 елның ахырында көч-хәл белән Казанга кайтты. Озын юл аны тәмам ватты, эштән чыгарды, аяктан

екты. Кайтып җиту белән Хөсәен Ямашев аны Иске клиникага урнаштырды. Зариф Садыйков беркадәр вакыт дәваланды, ләкин тазара алмады. Врачлар аңа Кырымга китәргә киңәш бирделәр. Әмма Зарифның ерак җиргә дәваланырга барырлык бернинди материаль мөмкинлеге юк. Менә шундый гаять кыен моментта аңа Хөсәен Ямашев туганнарча ярдәм итте. Үзе студент булуга карамастан, ул Зарифка юлына һәм берникадәр вакыт дәвалануга җитәрлек акча табып бирде. 1912 елның февралендә Садыйков Мәскәү аша Симферопольгә юл тотты.

Әдәбият түгәрәгендәге идея көрәшендә җиңелгән милләтчеләр һәм аларны рухландыручылар тик ятмадылар, татар укучы яшьләре арасында исеме киң таралган Х. Ямашевка яла ягарга, аны хөкүмәткә ышанычсыз кеше итеп күрсәтергә ашыктылар. Түгәрәккә «Житель» кличкасы астына яшеренгән провокатор үтеп керде. Ул түгәрәк члennары кайчан, кайда җыелулары, нинди бәхәсләр алып барулары турында жандарм идарәсенә тәфтишле доносләр язып тордылар. Ямашевның Оренбургтагы эшен дә куерта башладылар, анда нинди эш буенча суд хөкеменә тартылуы белән кызыксындылар. Шушы уңай белән ике жандарм идарәсе арасында барган язышулар калын тышлы папкаларга теркәлде. Жандармнар, үзләренчә Ямашевның хөкүмәткә каршы эшләрен тәмам ачыклагач, аны кичекмәстән кулга алу өчен ордер хәзерләргә керештеләр. Ләкин патша ялчылары мәкерле планнарын гамәлгә ашырып өлгерә алмадылар. Революциягә, азатлык өчен көрәшкә, укуга бирелгән киеренке хезмәт Х. Ямашевның сәламәтлеген бик нык какшатты. 1912 елның 13 мартында ул «Гасыр» китапханәсенә эш белән кергәндә миенә кан савудан кинәт үлеп китте.

Хөсәен Ямашевның кинәт үлеме турындагы хәбәр яшен тизлеге белән бөтен шәһәргә таралды. Аның дуслары, көрәштәшләре бу югалтуны авыр кичерделәр. Хөсәен Ямашевның чиксез зур хезмәтләрен күреп торган Казан демократик җәмәгатьчелеге аны олылап, хөрмәтләп күмәргә хәзерләнде. Полиция ничек кенә тырышмасын, бу хәзерлеккә комачаулык итә алмады. Хөсәен Ямашевны күмү алдынгы татар яшьләренең куәтле демонстрациясенә әверелде.

Зур мәйдан. Анда кимендә ике меңнән артык кеше җыелган. Табутны мәйдан уртасына китереп куйдылар. Аның өстенә яшьләр һәм студентлар исеменнән язылган лентала салынган. Юридик түгәрәк идарәсе тарафыннан куелган лентада: «Ул үз халкының якты киләчәгенә тирәнтен ышану һәм өмет белән китте»,— дип язылган иде.

Саубуллашу сүзләре әйтеп, Хөсәен Ямашевның дуслары һәм көрәштәшләре аны социализм идеяләренә тирәнтен инанган, хезмәт халкы өчен армый-талмый эшләүче, кешеләрнең ышанычын казана белүче, тимер ихтыярлы, ялкынлы революционер итеп сурәтләделәр.

Хөсәен Ямашевның үлемен аның якын дусты Габдулла Тукай чиксез авыр кичерде. Бу зур югалту уңае белән «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» дигән атаклы шигырен язып, ул большевик көрәшченең югары гуманистик сыйфатларын түбәндәгечә тасвирлады:

**Ул көрәште һәм явыз эшкә җәза бирде көлеп,**
**Үткен акылы шул көрәшкә пакъ көмештән юл булып.**
**Ул көрәште, язда елмайган кояш төсле бәлант,**
**Карны, бозны ул ничек эретә көлеп һәм нур коеп.**

Хөсәен Ямашев чиксез авыр каршылыкларны үтеп, үзенең изге теләгенә — студент булу дәрәҗәсенә иреште. Кызганычка каршы, ул университетны тәмамлый алмады. Бүген Хөсәен Ямашевның гүзәл бюсты беренче рус марксисты Николай Федосеев белән беррәттән даһи Ленин мемориалында мактаулы урында тора. Аның онытылмас исеме кешеләрне яңа җиңүләргә, якты киләчәк өчен тиңдәшсез көрәшләргә рухландыра.

# ҺӘЙКӘЛ ЯНЫНДА УЙЛАНУЛАР

Сыскы авылы уртасында, өр-яңа культура йорты каршында, мәһабәт бер һәйкәл тора. Шул мәрмәр һәйкәлне уеп, алтын төсендәге хәрефләр белән түбәндәге сүзләр язылган: **«1918—1919 нчы елларда, халыкларыбызның азатлыгы өчен корбан булган баһадирлар —**

**Һадиуллин Фәйзүк**
**Һадиуллин Шәйдулла**
**Шаһиморатов Нәби**
**Мирзин Бәдамша**
**Мозаффаров Мөһдәсәр**
**Бакшанов Талыйп**
**Мөхәммәтшин Якуп —**

**шушы туганнар каберенә күмелгән».**

Бу изге урын чәчәкләр белән бизәлгән. Монда халык эзе бер дә суынмый. Замандашларыбыз халкыбызның бәхете, азатлыгы өчен кан түгеп, җан биреп сугышкан батырларны истә тоталар.

Красноуфимскидан Башкортстанга барган юл буенда ике авыл урнашкан — Сыскы һәм Табанлы Күл авыллары. Элекке заманда бу тирәдәге җирләрне башкортлар биләгән. Хәзерге Сыскы урынында әүвәл-әүвәлдән башкортларның Сыскы аймагының дачалары була килгән. Бу авылның салына башлавы XVI гасырның уртасына туры килә дияргә ярый. XVI гасырда һәм XVII гасырның башында Идел буенда яшәгән халыклар — татарлар, руслар һәм башка милләт халыклары ирекле тормыш эзләп, Урал ягына күчеп китеп, башкорт җирләренә килеп урнашалар. Шул елларны Сыскыга күп кенә типтәрләр, көнгерләр килеп утыра. Авылда өч урам хасил була. Берсендә күптәннән башкортлар яшәп килгән. Аларның җирләре, урман болыннары күп булган, алар авылның төп хуҗалары. Калган урамнарның берсендә — типтәрләр, икенчесендә — көнгерләр. Килмешәк типтәр-көнгерләрнең җир-сулары аз булгач, аларның күбесе байларга эшләп тамак туйдырган.

Шәйдулла Һадиуллин — типтәрләр нәселеннән. Аның ата-бабалары ярлы булган. Җирләре начар һәм аз, байларда эшләп тамак туйдырганнар. Үзе эшкә оста, күп һөнәргә ия булуга карамастан, фәкыйрьлектә яшәгән, сүзгә осталыгы белән зур ышаныч казанган. «Ярлылар арасында безгә каршы коткы тарата, падишаһ хәзрәтләренә сүз тидерә»,— дип, авыл байлары егетнең юк гаебен бар итеп яла ягып Себергә озатканнар.

Шәйдулланың тормышы сөргендә, ерак Себердә бик авыр башлана. Бер ялгызы, таныш кешеләре юк. Шулай да озакламый аңар ярдәм кулы сузучылар табыла. Алар — политик тоткыннар. Шәйдулланың хәленә кереп, файдалы киңәшләр бирәләр, аз-маз русча сөйләшергә, укырга-язарга өйрәтәләр. Аларның сөйләшү, бәхәсләшүен тыңлый-тыңлый, яшь тоткынның үзенә дә политик аң керә башлый. Ара-тирә ул үз фикерен дә әйткәли. Иптәшләре «дөрес уйлыйсың» дип мактыйлар. Тора-бара Шәйдулланың үзенә дә йомыш куша башлыйлар. Ул татар-башкортлар арасында патшаның явызлыгы турында сөйли, көрәшкә чакыра.

Февраль революциясе турындагы хәбәр сөргенгә байтак вакыт узгач кына ирешә. Шул ук төнне бу хәбәр бөтен баракларга җитә. Сакчыларның боерыгын тыңламыйлар, эшкә чыгарга уйларында да юк. Базардагы кебек, ишегалдында җыелышып гәпләшәләр генә. Шул арада сыңар куллы бер тоткын күтәрелеп боерык бирүгә бөтенесе дә сафка баса.

— Иптәшләр! — ди ул,— Петроград эшчеләре солдат-матрослар белән бергәләп Николай патшаны тәхетеннән бәреп төшергәннәр. Башка лагерьлардагы тоткыннар азатлыкка чыгып, туган якларына кайтып киткәннәр. Инде безне дә азат итәргә тиешләр!

Сафлар бозыла, кул чабулар, кочаклашу-үбешүләр башлана, күбесенең шатлыктан күз яшьләре тама...

Шәйдулла авылына кайтып төште. Ул авылда әллә ни үзгәрешләр күрмәде. Шул ук чиновниклар хөкем сөрә, байлар җырын җырлыйлар. Ярлы кешегә һаман игътибар юк. Авылдашлары тормышның киләчәге турында киңәш сорап килсәләр дә, ул ни әйтергә белми аптырап калды.

1918 ел, мартның беренче көннәре. Бөек Октябрь рев..юциясеннән соң өч-дүрт ай Красноуфимск өязенең авылларында байлар һәм ярлылар арасында каты көрәш барды. Төп максат — иске, патша хөкүмәтен..ән калган волостьларның җирле идарәләрен бетереп, волисполкомнар сайлап. Совет органнарын оештырып, бөтен властьны аларга тапшыру. Каты көрәш нәтиҗәсендә бу максатка ирешелде инде. Хәзер иң мөһиме — Совет органнарын ныгыту, Совет законнарын гамәлгә ашыру.

Юва авылында беренче волисполком утырышы үткәрелде. Анда авыллардан килгән ярлылар комитеты рәисләре дә катнашты. Һадиуллин Шәйдулла, Сыскы авылының ярлылар комитетының рәисе, утырыштан атын куалый-куалый кайтып төште. Атын тугарып баганага бәйләп куюга, иптәшләре «яңа хәбәр белергә» дип җыелдылар.

— Егетләр, безгә зур бурыч йөкләделәр — байларның артык ашлыкларын алып өязгә җибәрергә куштылар. Өяздән килгән продкомиссарның урынбасары иптәш Нәфиков завод-фабрик эшчеләренә, Кызыл Армиягә ашлыкның бик кирәклеген аңлатып бирде. Ә волисполкомның бүлек мөдире Михаил Судаков: «Тиздән җирләрне тигезләп бүлү чарасын күрә башларга кирәк булыр. Хәзергә шуның турында уйлаша торыгыз», дип, мине озатып калды,— диде Шәйдулла.

Нәби Шаһиморатов, Якуп Мөхәммәтшин кебек активистлар белән төн уртасына кадәр Минһаҗ һәм Гыймал байларның җирләрен, байлыкларын бүлеп алу турында сөйләшеп утырдылар. Тәрәзә артында, тышта нәрсәдер дөбердәп куйды. Хөснурия — Шәйдулланың хатыны — җиделе лампаның утын киметеп, тәрәзәдән караган иде, кемнеңдер карга бата-бата йөгергәнен күреп калды. Борчылып, бер-берсенә караштылар.

— Ярый егетләр, бүгенгә җитеп торыр,— диде Шәйдулла.— Иртәгә җыен алдыннан сөйләшербез әле.

Саубуллашып чыгып киттеләр. Шәйдулла аларны озатып калды. Авыл өйләренең утлары сүнеп беткән иде инде.

Иртәгесен төшкә кадәр комитет әгъзалары җыелып, киңәшеп алдылар. Шәйдулла үзәктән килгән карарларны, күрсәтмәләрне укыды, бүгенге җыенда каралачак мәсьәләләр турында киңәште.

Шул ук вакытта Минһаҗ бай өендә байлар иркенләп кенә баллап-майлап чәй, мәй эчеп, киңәшеп утырдылар. Хәл-әхвәл сорашкач, Минһаҗ бай:

— Җәмәгать, мин кичә үз кешемне Шәйдуллага йомышка йөгерткән идем. Ул, гакыл иясе, анда ярлы-ябагай серләшеп утырганын тыштан гына тыңлап торган. Бүген кич җыен булачак, чакырып йөрделәр инде. Бездән ашлык сорыйлар, имеш. Я, нишлибез? — диде.

— Нишләрбез дип ни... бирмәскә кирәк. Бердәм булырга, нык торырга! Артык ашлыгыбыз юк, өмет тә итмәсеннәр! — диде Гыймал бай.

— Әллә бераз бирәсе микән? — диде Бәдри бай.

— Бирәсе дә килми килүен, ә шулай да өстәл сугып каршылык күрсәтеп булмас, ахры,— диде йорт хуҗасы.

Җыен Ләбиб Ярмиев өендә бара. Байлар бер төркем булып утырган. Ярлылар, урта хәлleләр белән ике зур бүлмә тулы. Фронттан кайткан солдатлар да күренә. Алар хәбри киемдә. Берничә хатын-кыз да килгән. Президиумда Шәйдулла, Нәби, Исхак.

Берничә кеше чыгыш ясагач, Нәби комитет исеменнән карар укыды. Анда исемлеккә кертелгән бай хуҗалыклар ике көн эчендә егермешәр пот ашлык илтеп, мәгазигә[1] тапшырырга тиешлеге язылган иде. Ашлык хәзерләү шома гына үтмәде. Үз

---

[1] Мәгәзи — авылның чәчүлек орлык ашлыгын саклар өчен гомуми амбары.

ирәге белән тик бер-ике йөк кенә китерделәр. Бу эш өяздән продкомиссар урынбасары Габдрахман Нәфиков коралды дружина алып килеп, байларны чакыртып сөйләшеп, катгый рәвештә боерык биргәч кенә тәмамланды. Ашлык төягән олаулар белән Нәфиков үзе дә китеп барды. Кызыл армиячә гаиләләренә, гарипләнеп кайткан солдатларга ашарлык һәм чәчүгә җитәрлек ашлык таратылды. Гыймал һәм аның атасы икмәк хәзерләүгә зур каршылык күрсәттеләр. Коралды дружина килгәч кенә иң соңга калып тапшырган ашлыклары да чүпле булды.

Волисполком председателе урынбасары Фәттах Мифтахов коралды дружинниклар белән Сыскыга килде дә бер карар укыды. Ул байларга контрибуция салып, акча җыю турында иде. Байларны чакырып китереп, каравыл өенең төп бүлмәсендә һәрберсе белән аерым сөйләшеп карадылар, ә акча бирүче булмады. Тик кичкә таба, икенче-өченче мәртәбә кыстагач кына «риза» булып, шундук финотдел казначеена акчаларын бирделәр дә, квитанция алып кайтып киттеләр. Гыймал исә «акчам юк» дип кырт кисте.

Озак та үтми, Мәтәле, Устикин якларында алпавыт Голубцов фетнә оештыра. Башта аның отрядында үз атларына атланган байлар, элекке офицерлар һәм аларның ялчылары гына була. Алар үзләрен «Дутов казаклары» дип, ялган исем белән кузгалып чыккач, һәр авылда халыкны куркытып, ирләрне үзләренә буйсындырып алып китәләр. Бу отряд бик тиз үсә, тик кораллары сәнәк, сөңге я күсәктән гыйбарәт. Сажино, Манчаж, Юва волисполкомнарының кызыл дружиналары, нибары утыз-кырык кешедән генә торса да, берничә йөз «атлы казакны» куып җибәрә. Көчләп җыйналган «казаклар»ның күбесе үз авылларына кайтып китә.

Моннан соң элекке патша офицеры Кобяков та фетнә оештыра. Отрядның күбесе элекке офицерлар, байлар. Кораллары, пулеметлары да бар. Алар Юва волисполкомына кергән берничә авылны басып алалар. Волисполком җитәкчеләрен, Совет активистларын, бигрәк тә коммунистларны кулга алып, канлы үч алалар. Асу-кисүләр башлана.

Шушы шомлы көннәрдә Шәйдулла коралды дружинасын Ювага, хәрби комиссар карамагына җибәрә. Ә үзе көн буе, төн буе диярлек, ярдәмчеләре белән бергәләп, халыкны акларга каршы торырга, көч җитәрлек булмаса урманга качып, партизаннарча көрәшергә өндәп йөри. Богалыш ягындагы басу капкасына сак куеп, үзе төн уртасы авышкач кына өенә кереп ял итәргә ята.

Шул ук төнне Гыймал бай үзенең әшнәләре Хисам, Минхаҗ, Әхмәт белән яхшы атларга атланып, Богалыштагы Кобяков штабына Советлар ягында булган кешеләрнең исемлеген илтеп тапшыралар да, ак солдатлар ияртеп, Сыскыга әйләнеп кайталар. Мәкерле бай разведка башлыгына авылны урап, Табанлы Күл ягындагы басу капкасыннан керергә киңәш бирә. Шыпырт кына авылга керәләр. Ярлылар комитетының рәисен — Һадиуллин Шәйдулланы, комитет әгъзалары Хәсәнов Әсәдулла, Мирзин Бәдамша, Бакшанов Талыйп, Мөхәммәтшин Якупны кулга алып, канга батырганчы кыйнаганнан соң амбарга илтеп ябалар.

Фетнәчеләрнең һөҗүмнәре кинәт, астыртын булса да, күп кенә активистлар качып өлгерә. Алар Судаков оештырган партизаннар отрядына кушылып, акларга каршы сугышта катнаша. Шулар арасында Шәйдулланың энесе Һадиуллин Фәйзук тә бар.

Сыскы белән Табанлы Күлдә тынычлык бетә. Көн-төн тентү, талау, кулга алу, җәзалаулар башлана. Бөтен җәза бирүне Гыймал үзе башкарып, үч алып йөри. Аның кансыз башкисәр булуына өер башлыгы фатихасын бирү генә түгел, рәхмәтләр укый. Гыймалның кара айгырыннан төшкәне дә юк диярлек. Бүген иртүк Мәһдәсәр Мозафаров өенә килеп, капкасын ачып та тормады, айгырын койма аша сикертеп кенә керде дә тентү башлады. Иң элек өенә кереп: «Атагыз кая качты?» дип өстәлгә сугып, балаларны елатып чыкты. Аннан соң печән сараена кереп: «Кызыл эт! Чык үзең. Синең монда-качып ятканыңны беләм. Әгәр чыкмасаң, балаларыңны атып үтерәм дә, сараеңа ут төртәм!» — дип акырынды.

Бераз уйланып торгач, Гыймал печән йолкып алып, сарайга ут төртте. Башкисәр мавыкканда, Мәһдәсәр буш кисмәк ыргытып, аны аягыннан екты да, сикереп төшеп, буа башлады. Гыймал тыны буылгач бик каты гырылдап куйды. Шул тавышны ишетеп, бер солдат йөгереп керде һәм мылтык түтәсе белән Мәһдәсәрнең башына сугып җибәрде. Аның кул-аякларын бәйләп ыргыттылар. Гыймал аны тимер чыбык ка-

тыштырып үргән камчысы белән кыйнады. Аннары аны үз тарантасына пар атларын җигеп, амбарга илтеп яптылар. Тоткыннарның саны алтыга җитте.

Комитетчылардан тик Шәйдулланың ярдәмчесе Нәби Шаһиморатов кына иректә. Аны да Гыймал кулга алырга тырыша, тик таба алмый. Нәби яшеренеп кенә я Сыскыда, я Табанлы Күлдә йөри. Юва комендатурасында писарь булып эшләгән Гәбделхәй малае Фәхрази аша тоткындагы иптәшләренең хәлен белеп тора. Ул писарь, советлар яклы кешеләрнең исемлеген кулына төшергәч, моңа кадәр кулга алынган алты кешенең генә исемнәрен калдырып, башкаларныкын кисеп алып юк иткән.

Нәби, Фәхразинең хәбәре нигезендә, Красноуфимскига, Нәфиковка түбәндәге язуны җибәрә: «Шәйдулла һәм комитет әгъзалары — барысы алты кеше тоткында. Аларга суд булачак. Аларны коткарырга берничә егет җибәрүегезне үтенәм. Бу хатны тапшыручы безнең хәлләрне җентекләбрәк сөйләп бирер һәм егетләрегезгә килергә урман юлын күрсәтер».

Шушы көннәрдә Мәсгут-Ямаш тирәләрендәге партизан отрядлары, берләшеп, Борчаников җитәкчелегендә Красноуфимск кызылгвардиячеләренә ярдәмгә ашыга. Алар юл буендагы авылларда ак бандитларны куып, алар кулына эләккән большевикларны азат итәләр.

Бу хәлне ишетү белән, Кобяков Сыскы амбарларындагы комитетчыларны хәзер үк җәзалап үтерергә карар бирә.

Җәйнең иң матур көннәре иде. Корбан гаете көнне кешеләр мәчеткә җыелды. Бу яман хәбәрне ишетү белән Мофаккар мулла, чалма һәм чапан кигән килеш, сырлы яшел таягына таянып, мөнбәргә менде.

— Җәмәгать! Мөселминнәр! — диде ул.— Элекке елларда мин сезгә гает намазыннан соң, «Бәйрәм шәрифегез мөбәрәк булсын!» — дип озатып, сезнең инсафлы, итәгатьле булуыгызны теләп дога кыладыр идем, ә бүген шомлы вакыт. Әсир ителгән авылдашларыбызны чыгарып атачаклар дигән хәбәр ишетелде. Мәхәлләгездә имам буларак, изге бәйрәм көнендә булачак корбаннарга ясыйн уку — минем мөкатдәс бурычым. Гает намазын калдырып, без хәзер үк җәза мәйданына барырга тиешбез,— дип, хәзрәт сүзен тәмамлады. Бөтенесе дә кузгалып, этешә-төртешә мәчеттән чыктылар.

Халык, базарга җыелгандай, амбарны сырып алды. Хатын-кызларның, бала-чагаларның елашулары үзәкләрне өзә... Култык таягына таянган, хәрби кием кигән бер кеше алгарак чыгып:

— Гыймал башкисәргә ирек куйсагыз, ул бөтен авылны кырып бетерер. Аннан яхшылык өмет итмәгез. Я, нәрсә карап торасыз, коткарырга кирәк гонаһсыз бәндәләрне! — дип алга атлады. Картлар шаулаша башладылар. Алдагыраклары таякларын күтәреп айкый-айкый амбар ишегенә таба берничә адым атладылар. Бүген каравылда берәү генә түгел, өч-дүрт кеше тора. Шуларның берсе: «Стой, стрелять буду!», дип кычкырды да өскә ата башлады. Картлар тукталып калдылар. Шул арада айгырына атланып Гыймал бай килеп чыкты. Кулында камчысы, наганы, кылычы да бар. Аның артыннан ун-унбиш кораллы солдат килә. Ул, җыелган халыкны күргәч, бераз шүрләп, атын туктатмакчы иде дә, айгыры үрә басып алга сикергәч, наганыннан ата башлады. Халык янына җиткәч, камчысы белән уңга-сулга селтәнеп юл ярды да амбар ишеге янына җиткәч:

— Алып чыгыгыз!— дип боерды.

Ярлылар комитеты рәисе Шәйдулла Һадиуллин үлем җәзасын көткән вакытта да дәрәҗәсен югалтмады, дошман алдында нык һәм түземле булырга, сер чишмәскә киңәш биреп торды. Актык мәртәбә туган авылының урамыннан үткәндә, куллары бәйләнгән булса да, башын күтәреп, горур атлап барды. Җитәкче ни эшләсә, аның иптәшләре дә шуны кабатларга тырышты.

Урам үзәгеннән җәза мәйданына алты кеше атлый. Алда, уңда-сулда һәм артта кулларына штыклы мылтык тоткан солдатлар. Гыймал айгырын биетеп я алга, я артка чыга. Камчысын бертуктаусыз селтәп, боерыклар бирә.

Су буена, каенлык кырыена җиткәч тукталдылар. Ямь-яшел чирәм. Кошлар сайраша... Төрле чәчәкләр хуш ис тарата.

Куллары артка каерып бәйләнгән кешеләрне бер рәткә тезделәр. Каршыларында

солдатлар. Ике арада кулына наган тоткан Гыймал йөри. Бер якта әсирләрнең хатыннары, бала-чагалары, туганнары елаша.

Мофаккар мулла таягына таянып, акрын гына атлап, үтереләчәк кешеләрнең каршысына тезләнеп утырды да башкисәргә мөрәҗәгать итеп:

— Мөхтәрәм Гыймалетдин! Кичер син бу мөселман бәндәләрнең гөнаһларын. Аллаһы тәгаләгә тапшыр. Ул олуг, теге дөньяда үзе хөкүм итәр,— диде.

— Мофаккар хәзрәт! Болар мөселман түгелләр бит, мөртәтләр! Хосуси милеккә каршы торалар. Ислам динен дә, хәлле кешеләрнең байлыкка хуҗа булу хакын да инкарь итүчеләр. Ходай тәгалә теге дөньяда теләсә ни эшләсен, ә бу дөньяда мин үзем алла! Әйдә, хәзрәт, дыңгырдат ясыйныңны,— диде Гыймал. Ул солдатларга «Хәзерләнергә!» дип боерды. Мылтыкларын тезәгәч, «Пли!» дип кычкырды... Барысы бер Әсәдулла гына артка каерылып төште, ә биш кеше басып калды.

Гыймал:

— Нигә туры атмадыгыз? — дип җикеренгән иде, солдатлар ымлады: Шәйдулланың, Мәһдәсәрнең балалары әтиләренә барып ябышканнар икән.

Аларны аралап, Гыймал калганнарын үз кулы белән атып екты. Иң актыкта үзенең бажасы Якупны аткач, тиз генә айгырына атланып, солдатлар белән Сарана заводына таба китте. Алар әле ерак түгелләр иде — атылган Әсәдулла торып утырды...

— Солдатлар күздән югалгач торырсың! — дип, аны тагын яткырдылар. Берәүдән ул сикереп торды да йөгереп әрәмәгә кереп күздән югалды. Аңа пуля тимәгән икән, хәйлә белән үлемнән котылып калган.

Әсәдулла Хәсәнов урман эченнән кичкә таба Красноуфимск читенә барып җитеп, кемнеңдер ишегалдына кереп егылды. Шунда уйнап йөргән малайлар Әсәдулланы күреп, күпер янында сакта торган кызылгвардиячеләргә барып әйттеләр.

Су эчерткәч, ул күзен ачты. Штабка, Нәфиковка алып баруларын үтенде. Нәфиков Сыскыдагы кызганыч хәлне ишеткәч, Шәйдуллаларның һәлак булганлыгына бик көенде:

— Соңардык... Коткарырга соңардык,— диде ул.

Бу көннәрдә Красноуфимскиның үзендә дә тынычлык юк иде. Төрле яктан ак фетнәчеләр һөҗүм итә. Гыймал бандасының Сарана заводына таба киткәнен белгәч, Нәфиков та караңгы төшү белән үзенең кечкенә хәрәкәтчән отряды белән шул якка, Тарасов җитәкчелегендәге партизаннар отрядына ярдәмгә китте.

Нәби Шаһиморатов Совет яклыларны оештырып, Гыймалга каршы көрәш башларга дип йөри. Бүген караңгы төшкәч ул зират артыннан Табанлы Күлгә, Фәттах өенә килеп керде. Алар берничә ышанычлы кеше белән сөйләшеп, ризык һәм кораллар барлап, киләсе төнне урманга китеп урнашырга сүз беркетеп куйдылар.

— Нәби агай, безнең авылда әлегә тынычрак. Син сәндрәгә менеп ял ит,— диде Фәттах. Йоклап кына киткәннәр иде, ишекне мылтык түтәсе белән бәреп ачып, берничә кеше белән Гыймал бай атылып керде. Берәү шырпы сызып яндыра алмыйча маташканчы, Нәби ак келәткә кереп бикләнде. Ишекне ватмакчылар иде, Шаһиморатов аларга наганыннан атты. Солдатлар ишегалдына чыгып китте. Гыймал җикеренеп караса да тыңламадылар.

Гыймал: «Коралыңны ташлап бирелмәсәң, ут төртәм!» — дип, шырпы сыза башлады... Хуҗа хатынының коты алынып, балалары белән бергәләп елый-елый үтенгәч, Нәбине бирелергә мәҗбүр иттеләр.

Нәби белән Фәттахның кулларын артка каерып бәйләделәр, икесен рәттән тарантаска утыртып алып киттеләр. Нәби инде мәрхәмәт көтми. Гыймалның эт икәнен белә. Тик үзенең отряд оештырып, халыкны кансыз юлбасардан коткара алмавына үкенә... Олау Юва коменданты Гришка Пастуховның капка төбенә җитеп туктады. Юлбасарлар башлыгы песи кебек акрын гына кереп, кемнәрне тотып китергәнен сөйләп биргәч, комендант:

— Үзең ни теләсәң, шуны эшлә, йокымны бүлеп йөрмә,— дип, тәмле итеп иснәде дә, өенә кереп китте. Гыймал үзенә ирек куелгач, канәгатьләнеп, елмаеп килеп чыкты. Айгырына атланып:

— Әйдәгез Сыскыга! — дип боерды.

Амбар янына җиткәндә таң аткан иде инде. Нәбине өстерәп-төртләп алып кергәч, тибә-тибә кыйнадылар да, кулларын бәйләгән дилбегәсен чишеп алып, өрләккә асып куйдылар...

— Ишекне бикләп, сакчы куярбыз. Бераздан килеп ачарсың да, «үзе асылынган» дип, каравылчыны кайтарып җибәрерсең.

Кызыл Армиянең 28 нче, 30 нчы дивизияләре Уралны аклардан азат итәләр. Колчак гаскәре Себергә чигенә. Алардан да элек байлар кача.

1919 елның июль башында Василий Чуйков җитәкчелек иткән 43 нче полк, акларны тар-мар итеп, Сарана заводына омтыла. Кызылларның хәрәкәтчән төркемнәре якынайганын сизгәч, Колчак гаскәрләре поселокны утка тоталар да, Өфене кичеп, аръякка качалар.

Чуйков бөтен пулеметлардан һәм бомбометлардан елга аша ут ачарга куша. Үзе кызыл командирлар һәм кызылармиячеләр белән янгын сүндерергә тотына. Аларның артиллериясе әле килеп җитмәгән була.

Өфене кичеп, акларны чигенергә мәҗбүр иткәч, 43 нче полк Манчаж дигән зур авылга юнәлә. Фәйзүк белән Әсәдулла туган авыллары Сыскыга кереп чыгарга рөхсәт алалар. Командир алар белән Якупов дигән батыр разведчик һәм бер отделение укчы да җибәрә. Гыймал юлбасарны авылда таба алмыйлар. Ул инде Сулы Чикрәш урманында, качкынлыкта йөри икән.

Фәйзүк белән Әсәдулла аны эзләп йөри алмыйлар, үз частьларына кайтып, 6 нчы июльдә Манчажны, 7 нче июльдә Әртә заводын азат итәләр. Фәйзүк һәлак була. Аны үзенең туган авылында тантана белән җирлиләр.

Бик тырышып эзләсәләр дә, качкынның эзенә төшә алмыйлар. Тора-бара ул бөтенләй юкка чыга. Авыллардагы халык бераз тынычлана башлагач, Сыскыдан өч ат югала. Гыймал ат карагына әверелә. Атларны берәмләп кенә түгел, дистәләп урлап, ялган документ ясап, башка өязләргә илтеп саталар. Гыймалның юлдашлары да үзе кебек башкисәрләрдән, атаклы карақлардан. Милиция аларны озак вакыт тота алмый йөри.

Әсәдулла Хәсәнов Кызыл Армия сафында акларны Себергә куып тар-мар иткәч, туган авылына кайта. Гыймалның әле һаман качкынлыкта каракланып йөргәнен ишеткәч, ял да итеп тормый, «Юлбасарны эзләп тапмыйча, аны тотып җәзага тарттырмыйча, әйләнеп кайтачак түгелмен!» дип, юлга чыга.

Йөри торгач, урман эчендә яшәгән ике аучыга тап була. Бертуган ике аучы, аклар вакытында партизан отряды оештырып, фетнәчеләргә каршы сугышканнар. Өчәүләп күзәтеп йөри торгач, аның эзенә төшәләр. Көзге караңгы төндә, Гыймалның тау аша кырын юлдан үтәсен белеп, алдан ук хәзерләнеп торалар. Юл биек тау читеннән аска төшеп китә. Як-якта куе урман. Колач җитмәслек юан-юан чыршы-карагайлар бер-берсенә терәлеп үскән диярлек... Ат белән түгел, җәяүле кеше дә агач арасыннан үтә алмас.

Аучылар юан чыршыны егып, юлны буалар да агачның аргы ягында юлны казып куялар. Төн уртасы җитеп килгәндә, кара айгырына атланган Гыймал күренә. Гыймал тезгенен тартыбрак, эчке кесәсеннән коралын алмакчы иде, өлгермәде — айгыры кинәт сикереп тар, тирән чокырга килеп төште. Әсәдулла белән ике тәҗрибәле аучы каракка элмәкле аркан ыргытып, өскә тартып чыгардылар... Аның аяк-кулларын сыс бау белән тартып бәйләгәч, «инде нишләтергә?» дип торган арада, карак күкрәгеннән киереп, бауны шытырдатып өзде дә кесәсеннән наган тартып чыгарды. Тик атарга өлгерми калды. Аны аркан белән агач төбенә терәтеп куйган тегермән ташына бәйләп куйдылар. Ә Гыймал бар көчен җыеп селкенүе булды, түгәрәк таш урыныннан кузгалып тәгәри башлады... Тегермән ташы җинаятьчене үзе белән ияртеп, кыя астындагы күлгә чумды...

**МӨХӘММӘТ МУЛЛАНУРОВ.**

## ГАЛИМҖАН ЛАТЫЙПКА 70 ЯШЬ

# ЮЛЫҢ УҢ БУЛСЫН, ШАГЫЙРЬ!

Утызынчы еллар. Татар совет әдәбияты гөрләп үсә, алга бара. Әдәбият тирәсендә — күп санлы яшьләр. Тормыш тәҗрибәсе, белем ягыннан алар төрле-төрле. Ләкин уртаклыклары да зур: һәркайсы шигърияткә гашыйк, һәркайсы иҗат омтылышы белән яши.



Шагыйрь Галимҗан Латыйп иҗаты да утызынчы елларда башланып китә. Дөрес, беренче шигыре Татарстанда түгел, ә Башкортстандагы «Коммуна» (хәзер «Кызыл таң») газетасында 1935 елда басылып чыга аның. Бу аңлашыла да, чөнки Башкортстан — Г. Латыйпның туган ягы. Андагы бай табигать, Базы елгасы буендагы көяз балагачлар, бөдрә таллар, ерак горизонтка тоташкан тигез басулар булачак шагыйрьнең хисләрен уята, аларга азык бирә.

Г. Латыйпның беренче шигырьләр җыентыгы «Юл буйлап» исеме белән 1939 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күрә. Китапның аерата игътибарга лаек сыйфаты — авторның гражданлык позициясендә. Ул — актив көрәшче, ул — яңалык өчен, илдә барган социалистик төзелеш өчен тырыша һәм шуның өчен үзен җаваплы саный.

Китаптагы шигырьләрнең тематикасы киң. Арада автор игътибарын даими биләп торган темалар да бар: утызынчы елларда ил күләмендә җәелеп киткән социалистик төзелеш, сыйнфый дошман казынуларына каршы көрәшкә чакыру, уңышлар белән шатлану, горурлану.

Яшь шагыйрьнең бөтен шигырьләреннән диярлек оптимистик рух бәреп тора. Мәсәлән, менә мондый юлларны китаптан күп табарга мөмкин:

**Яу ап-ак кар,**
**Шатланып яу,**
**Яңа ел хөрмәтенә.**
**Яңа елның кочагында**
**Бәхетле тормыш килә.**

Ниһаять, тагын бер сыйфат: шигырьләр аңлаешлы, бик ачык тел белән язылганнар. Аларда катлаулы метафорага төренгән фикерләр юк.

Әлбәттә, «Юл буйлап»та урын алган шигырьләр кимчелекләрдән дә азат түгел иде. Нидән гыйбарәт соң ул кимчелекләр? Алар — беренче адымга, формалашу чо-

рына хас кимчелекләр. Конкрет алганда, яшь авторга тормыш материалын эшкәртүдә осталык җитеп бетмәде. Еш кына шулай килеп чыкты: автор бер нәрсә турында сөйләп килә-килә дә, кинәт аны ташлап икенчегә күчә. Нәтиҗәдә бер мәсьәлә дә сәнгатьчә ачылып, чишелеп җитми. «Юлбашчыга», «Сафлар килә» — шундый шигырьләргә мисал булып торалар. Шулай ук яшь шагыйрьдә сүзгә карата таләпчәнлек тә җитәрлек дәрәҗәдә тәрбияләнмәгән иде әле. Шигырь техникасына кагылышлы четаклыклар да үзләрен сиздерделәр. Коры риторикага бирелү, тормышның өске катыннан алынган информация белән чикләнү кебек кимчелекләр дә юк түгел иде. Менә соңгы фикергә бер мисал:

**Комсомол ул тирән шахталарда**
**Рекорд куйды күмер эшендә,**
**Орден алды көрәш кырларында,**
**Үрнәк булды барлык кешегә.**

1950 елда басылып чыккан «Хезмәт иртәсе» исемле икенче җыентык Г. Латыйпның иҗади формалашуында алга бер адым булды. Бирердә беренче җыентыкка хас кимчелекләр бермә-бер кими, уңай сыйфатлар тагын да үсә, ныгый төшә, авторның иҗат принцибы конкретлаша. Җыентыкта барлыгы 53 шигырь урын алган. Алар 40—50 нче елларда язылганнар һәм шул еллар күтәргән актуаль мәсьәләләргә багышланганнар. Гитлер басып алучыларына каршы көрәш, сугыштан соңгы социалистик төзелештә намуслы хезмәт — менә ул темаларның иң әһәмиятлеләре.

Г. Латыйп сурәтләгән хезмәт — ул кешенең яшәү нигезе, ул — дәрт һәм пафос, ул — матурлык, гүзәллек!

Тагын шунысы әһәмиятле: «Хезмәт иртәсе»ндәге шигырьләрдә, шагыйрь Зәки Нури сүзләре белән әйтсәк, «...хезмәтнең гүзәллеге аерым фактларны һәм тышкы билгеләрне санап чыгу юлы белән түгел, бәлки теге яки бу геройның уйлары, хисләре, кичерешләре белән тыгыз бәйләнештә күрсәтелә» («Татарстан яшьләре» газетасы, 1951 ел, 28 февраль). Алыйк «Ташчы» шигырен:

**Җиңнәрен куйган сызганып,**
**Кулында чүкеч аның.**
**Әйтерсең ул һәрбер ташка**
**Куша үзенең җанын.**

**Уңайлы булсын, ди,— һәр таш,**
**Кырларын ала китеп.**
**Тырышып эшли ул юлны,**
**Шома һәм тигез итеп.**

Бирердә хезмәт кешесе үз кабыгына бикләнмәгән. Ул тормышның гомуми агышы белән бергә атлый. Бу инде аерым кеше эшчәнлеген гомумхалык хезмәтенең өлеше, кисәге итеп сурәтләү дигән сүз. Хезмәт темасын сурәтләүдә Г. Латыйп үзенең алдагы иҗат эшчәнлегендә дә шушы юлдан — «Хезмәт иртәсе»ндә салынган юлдан атлый.

Ниһаять, «Хезмәт иртәсе»ндә авторның тагын бер иҗат үзенчәлеге формалаша. Күпчелек шигырьләр тормыштагы күренешне я сурәтләп, я хикәяләп бирәләр дә, соңыннан әлеге күренешнең асылын ача торган гомумиләштерү белән тәмамланалар. Менә «Цехта» исемле шигырь:

**Тышта йомшак, җылы һава,**
**Кичке утлар балкып яна,**
**җил исеп куя.**
**Мансур маңгай тирен сөртә,**
**Супертларын тигез йөртә,**
**детальләр уя.**

Шушы рәвешчә хикәяләү дәвам итә:

> ...Кулына ала детальне —
> Ялтырап торган металны,
> сокланып карый:
> Микрометр үлчәвенә,
> Машинаның көпчәгенә, —
> отлично!— ярый.

Ниһаять, менә шигырьне тәмамлаучы соңгы юллар. Алар күренешкә бәя бирәләр, гомумиләштерү ясыйлар:

> Бригадир әйтә Мансурга
> Һәм карап ала мастерга:
> — Алтын егетләр!
> Данygыз балкып торсын,— ди,
> Заводта артып торсын,— ди,
> сезнең кебекләр.

Әлбәттә, Г. Латыйпның тормыш материалын чагылдырудагы алымнары әйтелгәннәр белән генә чикләнми. Тормыш — бай һәм катлаулы. Димәк, аны сәнгатьчә чагылдыру да төрле формада, төрле алымнар белән башкарылырга тиеш. Шагыйрь моны яхшы аңлый. Шуңа күрә дә аның иҗади эзләнүләре тукталып тормый, һаман дәвам итә һәм менә 1958 елда дөнья күргән «Кыр чәчәге» исемле шигырьләр җыентыгында без тагын бер алым белән очрашабыз.

> Сүнәргә дә өлгермәгән
> Таң йолдызлары,
> Юнәлде басу ягына
> Колхоз кызлары.

«Кыр өстендә» исемле шигырьдә хикәяләү менә шулай башланып китә. Игътибар итик: әлеге юллар — битараф информация, коры хәбәр түгел, алар тормыштагы бер мизгелнең сурәте буларак кабул ителәләр. Аларда вакыт төсмере бар, аларда җанлы кешеләр бар. Икенчедән, әлеге сурәт — ул эчтәлекле сурәт һәм иң әһәмиятлесе — үз эчтәлеген үзе сөйләп тора торган сурәт: әнә бит безнең колхоз кызлары нинди уңган, нинди тырыш! Әле таң йолдызлары сүнәргә дә өлгермәгән, ә алар инде басуга юнәлделәр. Хикәяләү алга барган саен шигырьдәге тормыш сурәте тулыланa бара, идея-эстетик пафос бермә-бер көчәя. Укучы алдына заман образы, советча яшәү рәвеше килеп баса.

Әлеге алымнар Г. Латыйп иҗатында анда-санда калкып чыга торган эпизодик күренеш түгел. Алар тотрыклы, даими рәвештә шагыйрь иҗатының буеннан-буена сузылалар һәм шигырь тукымасындагы буяуларның реалистик төсен гәүдәләндерергә ярдәм итәләр. Әйе, Г. Латыйп — реалист шагыйрь. Аның шигырьләрендә тормыш сурәте күп очракларда иң гади көнкүреш детальләреннән тукыла. Менә шигырьләр: «Кәтү кайта», «Тимерче», «Тегермәндә», «Яңа күл», «Йортка яшь килен төшә», «Үзйөрешле комбайн» һ. б. Исемнәре үк әлеге шигырьләрнең тормыштан алынган булуларын әйтеп торалар. Алардагы буяулар — тормышчан һәм гади, аңлаешлы һәм ачык. Шигырьләрдә укучы үзен чолгап алган мохит турында бизәлгән отчет түгел, бәлки реаль тормышның үзен күрә.

Г. Латыйп иҗатының төп юнәлешен билгеләүче темалар бар, ул — Ленин, Туган ил, тынычлыкны саклау, хезмәт, интернационализм, халыклар дуслыгы.

Бөек юлбашчыбыз Ленинга багышланган шигырьләр авторның һәр җыентыгында диярлек урын алып килә: «Юл буйлап»та — «Юлбашчы», «Хезмәт иртәсе»ндә — «Ульяновскида», 1962 елда басылып чыккан шигырьләр җыентыгында — Ленин урамы», 1978 елдагы «Карлыгачларым»да — «Беренче тау» һ. б. Бу шигырьләр бер-бер-

ләрен кабатламыйлар, аларның һәркайсы темага үзенчә якын килә һәм юлбашчы образын сурәтләүгә өлеш кертә.

Партия язучыларны коммунистик төзелештә актив катнашырга чакыра. Бу төзелеш барышында яңа кеше тәрбияләнергә тиеш. Ә ул яңа кешене тәрбияләүдә әдәбият эшлеклеләренең бурычы нидән гыйбарәт соң? Партиянең XXVI съездында әдәбият, сәнгать эшлеклеләре алдында торган бурычларны билгеләп Л. И. Брежнев болай диде: «Әсәрләрнең геройлары вак эшләр даирәсендә бикләнеп калмасын, бәлки үз иленең мәшәкатьләре белән — киеренке хезмәт белән, гаделлек һәм яхшылык тантанасы өчен ныклы көрәш белән яшәсен». Әйтергә кирәк, Г. Латыйп бу ихтыяҗны аңлап иҗат итә. Аның геройлары барысы да коммунистик идеалларны раслыйлар, ил, халык интереслары белән яшиләр.

**Юл биргәнгә**
**юл бирәм,**
**Кул биргәнгә —**
**кул бирәм.**
**Тәкәбберга —**
**мин тәкәббер,**
**Кулда корыч дилбегәм.**

Бу — читтән күзәтеп торучы битараф кеше позициясе түгел. Мондый кеше җавапсызлык, тәлинкә тоту, җитешсезлекләрне күрмәү кебек, коммунистик әхлак нормаларына сыеша алмаган кимчелекләргә каршы баш күтәрә:

**Саклан дисең миңа,**
**Саклан дисең.**
**Борчылулар дисең файдасыз.**
**Тыныч кына яшәү кирәк, имеш,**
**Кайберәүләр кебек җайлашып.**

Бу — обыватель карашы. Аңа син затлы мебель бир, кыйммәтле палас тоттыр. Ул тыныч булсын, тәмле ашасын, корсак үстерсен. Башкасы аны кызыксындырмый: язучыларың да, культураң да, әхлак нормаларың да... Г. Латыйп геройлары мондый черек карашны кире кага.

**Мин үземнең тынычлыгым өчен**
**Мамык тыксам колак эченә.**
**Көпә-көндез күзем бәйләп йөрсәм,**
**Хыянәт итсәм йөрәк эшенә!**

**Нәрсә кала миннән**
**Ул чагында!!**
**Нигә кирәк минем яшәвем!!**
**Теләр идем хаклык хакы өчен**
**Мин һәр кемнең күкрәп яшьнәвен!**

Г. Латыйп геройлары — зур эшләр башкаручы кешеләр. Аларның хезмәт мәйданы киң. Ул тимерчелек алачыгыннан, колхоз басуларыннан башланып, завод-фабрика хезмәте аша галәм киңлекләренә очуга кадәр сузыла.

Г. Латыйп иҗаты — күп кырлы. Анда лирик шигырьләр белән беррәттән баллада, поэмалар да бар; дүрт, сигезьюллык афористик тезмәләр, җыр текстлары күп. Шагыйрь балалар өчен дә бик яратып иҗат итә. «Якты көннәр» (1952), «Яз башлана» (1953), «Кошлар килде» (1954), «Учак янында» (1955), «Аучы малае» (1959), «Җилферди лагерь байрагы» (1965), «Бәләкәй музыкант» (1970), «Крокодил елый» (1976) — болар барысы да балалар өчен язылган китаплар. Бу өлкәдә дә Г. Латыйпның үз алы-

мы, үз иҗат йөзе бар. Мәгълүм булганча, бала абстракт фикер йөртүне кабул итми. Аның белән аралашканда фикернең сурәтле, күргәзмәле булуы кирәк. Алай түгел икән — бала белән шагыйрь арасында аңлашу, якынлык барлыкка килмәячәк. Г. Латыйп шигырьләрендә без бала табигатенең менә шушы хосусиятен төгәл искә алып эш итүне күрәбез. Ул, бала табигатенә якын торган теге я бу күренешне, ситуацияне ала да, шуны ачык, җыйнак тел белән үзенең нәни укучысына сөйләп бирә. Фикер йөртү җанлы, сурәтле, димәк, бала кабул итәрлек килеп чыга. Мисалга «Кошлар кайткач» исемле шигырьне алыйк. Яз килүен сурәтләү белән башлана ул әсәр, аннары хикәяләүгә бала килеп керә.

**Кайткан кошларны күрергә**
**Урамга чыкты Гаяз:**
**— Кай ара килеп җиткән соң,**
**Кошларны алып бу яз!**

Соклану, ис китү хисе белән тулы Гаяз кошка: «Яратам җырыңны!» дип эндәшә.

**— Ышанмыйм,— диде сыерчык,—**
**Җанымны кыйнамачы.**
**Белгәнсең минем килерне,**
**Оя да куймагансың!**

Һәм менә — шигырьнең финалы:

**Очты кошчык бу тирәдән,**
**Яңадан күренмәде.**
**Хәзер кем назлар икән соң**
**Җыр белән күңелләрне!**

Әлбәттә, мондый фикер кечкенә укучыга барып җитми калмаячак.

Г. Латыйп иҗатының игътибарга лаеклы әле тагын бер юнәлеше бар. Ул җыр текстлары да яза. Шагыйрь бу юнәлештә дә күптәннән бирле уңышлы гына эшләп килә. Аның тарафыннан иҗат ителгән шигырьләргә А. Вәлиуллин, А. Ключарев, С. Садыйкова, И. Шәмсетдинов кебек танылган композиторлар музыка язды. Бүгенге көндә ул җырларны теләп башкаралар, яратып тыңлыйлар.

Г. Латыйповның иҗат эшчәнлеге дәвам итә. Алда — яңа үрләр, киеренке хезмәт. Алда — тынгысызлык һәм яну. Юлың уң булсын, шагыйрь!

**ШӘРӘФ ӘХМӘДУЛЛИН**

## Әмирхан Еники

# ОЧРАШУ ҺӘМ АЕРЫЛЫШУ

Бу әле истәлек түгел. Бу, ничек дим, яңа кичергәнне, онытылмас борын, теркәп калырга омтылу гына... Әш шунда ки, миңа июньнең беренче яртысында шактый гына юл йөрергә туры килде. Ә юлымның башы һәм дәвамы ничектер үзеннән-үзе ике олы шагыйрьнең исеме белән бәйләнгән булып чыкты. Һич тә уйламаган, көтелмәгән вакыйга! Менә ни өчен мин, ашыгып язуны яратмасам да, бу юлы тизрәк кулыма каләм алдым.

... Дүртенче июньдә мин үз эшләрем белән Уфага китәргә тиеш идем. Икенче июньдә, сәгать бишләр тирәсендә, Хәсән абзый Туфанның хәлен белер өчен клиникага бардым. Бер үк вакытта Хәсән абзыйга Уфага китүемне дә белдерәсем килде — Уфа аңа бик якын бит, якын иткән кешеләре дә күп, моны барыбыз да беләбез... Икенче каттагы 7 палатага ишек кагып кердем. Уң кулда, ишеккә якынрак караватта, Хәсән абзый ята. Янында Мөнҗия ханым, үзләре генә — палатада башка авырулар юк. Хәсән абзыйның өстенә ак җәймә генә ябылган, йөзе дә апак, иреннәре дә ак, яртылаш йомык күзләре дә ак... Үтә ябык, юка гәүдәсе ак җәймә астыннан беленми дә диярлек. Ак мендәр өстендә кue чал чәчләре тузгый төшкән башы гына калкып тора. Урындык алып карават янына утырдым, хәлен сораштым. Хәсән абзый җавап урынына «ярый» дигән төсле бер-ике тапкыр башын какты. Мөнҗия ханым: «Хәле әзрәк җиңеләйде, температурасы 37 гә төште» диде. Ләкин күрәм, сизәм: шагыйрьнең хәле шулай да җиңелгә охшамаган. Әйтергә онытканмын, мин кергәндә аның муенында урап салынган ак марля дә бар иде, күрәсең, тамагы да авырта торгандыр. Һәрхәлдә сөйләшүе аңа җиңел түгел, сүзне күбрәк Мөнҗия ханым алып бара... Бераздан мин: «Иртәдән соңга Уфага китәм, Хәсән абзый, йомышың, тапшырасы сүзең юкмы?» — дип сорадым. Ул аз гына көттереп, әкрен тавыш белән: «Сәйфинең хәлен... хәл-әхвәлен белеп кайт!» диде. Шуннан башкасын әйтмәде, ләкин Мөнҗия ханым өстәп: «Барлык дусларына сәлам әйтегез, сез аларны үзегез дә беләсез», — диде. Хәсән абзый аның сүзләрен куәтләгәндәй башын гына селкеп торды... Шушы кыска гына сөйләшү дәвамында ул хәлсезлектән кысыла төшкән күзләре белән ни өчендер һаман миңа карап ятты. Аның бу карашында хәлен белергә килгән кешегә игътибар күрсәтү генә түгел, нидер уйлап, нәрсәләрнедер исенә төшереп, хәтта сынап карау да сизелә иде. Мин эчемнән генә борчылып та куйдым: ни уйлый икән, күңелендә ни икән, һич югы сиздерсә иде!.. Без бит бер-беребезне бик борыннан беләбез — ярты гасырдан да артыграк. Мин әле аның өр-яңа сәер исем белән, өр-яңа шагыйрь булып кинәт күтәрелеп чыккан һәм мәһабәт куе-озын чәчләрен артка тарап, иске күн тужуркадан йөргән чакларын яхшы хәтерлим. Дөрес, мин аңа элек яки

соңыннан бик якын тордым, якын дусларының берсе булдым, дип мактана алмыйм. Аралашкан, бергә йөргән, бер табында утырдаш булган чаклар күп булды, яшерәсе юк — ара-тирә бәхәсләшеп алулар да булгалады, әмма ул минем өчен һәрвакытта олы иде, өстен иде. Мин аның нинди шагыйрь икәнен бер вакытта да исемнән чыгармадым. Шулай ук безнең бу озын, катлаулы дәвер эчендә минем аңа, ни сүзем, ни гамәлем белән дигәндәй, бер кайчан да зарарым тимәде — бу җәһәттән, шөкер, җаным тыныч. Әгәр шушы минутта ул мина карап, нидер уйланып ята икән, берәр төрле шәхси наразилыгы бардыр дип борчылырга һич тә сәбәп күрмим, булмаска да тиеш. Ә гомумән алганда, кешеләргә карата һәрвакытта бик таләпчән шагыйрь башына нинди генә фикерләр килмәскә мөмкин?! Шул исәптән, миңа карата да!

Үз вакытында Хәсән абзый минем ике хикәямне — «Туган туфрак» белән «Әйтелмәгән васыять»не яраткан иде. Бу хакта минем үземә дә әйткәне бар, ә соңгысын кайбер җирдә яклаган да булса кирәк... Ә менә хәзер, сөйләшә торгач, кызык кына бер нәрсәне белдем. Мөнҗия ханым миннән «Рәшә»дә тасвир ителгән йортның кайда икәнлеген сорады. Һәм кызыксынып соравын болай аңлатты: Хәсән абзый белән икәүләп йөрергә чыкканда алар һаман шул йортны эзлиләр, имеш!.. Ник дисәң, Хәсән абзыйга әнә шул «Рәшә»дәге шикелле аулак урамдагы бакчалы ялгыз йортлар бик ошый икән... Һәм Хәсән абзый үзе дә Мөнҗиянең сүзләренә кушылгандай көлемсерәп кенә тыңлап ятты... Әлбәттә, бу кечкенә деталь, әмма аңлаган кеше өчен мәгънәсе бар, минемчә...

Авыруны артык ялыктырмас өчен мин бер ун минуттан кузгала да башладым. Хәсән абзыйның ак җәймә өстендә яткан тар гына озынча кулын ике учыма алдым. Беләм, учымда — тимер дә тоткан, чәчәк тә үстергән кодрәтле кул — бармаклары арасыннан яшел каләмен тиз генә төшермәс әле ул! Шигъри мәрҗәннәрне ак кәгазьгә вак-вак кына батырып тезәр әле, боерган булса!.. Шуны да әйтергә кирәк, моннан 50—55 еллар элек Хәсән абзый яшенә караганда шактый олы сыман картрак чырайлы бер кеше иде. Ә житмеш-сиксәннәргә житкәндә инде ул, киресенчә, гаҗәп яшь чырайлы картка әверелде. Һичнигә бирешмичә, сыгылмыйча үзен саклый белде шагыйрь!

— Хуш, Хәсән абзый, Уфадан әйләнеп кайтуыма терелеп тор! — дидем мин аңа.

— Хуш! — диде ул да, башын кагып, әкрен генә.

Әйе, шагыйрьнең хәле җиңел түгел иде, ирексездән күңелне шомлы уй да чәнчеп узды, әмма мин шик-шөбһәләрне басып, янадан әле күрешүебезгә ышанган хәлдә аның яныннан чыгып киттем.

Әйткәнемчә, бу икенче июньдә булды, ә дүртендә инде мин Уфага очтым. Бу — атна кич иде. Шимбә көн алтысында Ибраһим Нуруллин белән без икәү Юматауга Сәйфи агай янына киттек. (Ибраһим Уфага миннән алдарак барган иде)... Таныш дача, бакча түрендә агач йорт — Сәйфи агай җәен-көзен күбрәк шунда ялгыз уздыра. 87 яшьлек дәртле шагыйрь безне куанып каршы алды. Башта беседкада бераз сөйләшеп утырдык, аннары өйгә кердек. Өйнең алгы ягы һәм иркен генә эчке ягы бар — анда өстәл тулы язган-сызган кәгазьләр, шүрлек тулы иске һәм яңа китаплар. Сәйфи агайның азык-төлеге дә үз янында, самоварны да үзе куеп җибәрә. (Элегрәк бер килүемдә ул миңа балык та кыздырып ашаткан иде әле)... Алгы якта гына юка балы белән тәмләп чәй эчә-эчә танасык әңгәмәне дәвам иттердек. Билгеле, сүзнең башында ук мин Сәйфи агайга Хәсән абзыйның сәламен тапшырдым. Алар бер дәвер кешеләре, бер мәдрәсә шәкертләре, бик күп еллар бер-берсенә туганнарча нык бәйләнгән һәм бер-берсенең язмышы өчен даими борчылып яшәүче шәхесләр. Шуңа күрә мин карт шагыйрьне артык хәвефләндермәс өчен авыруның хәле турында саклыныбрак, ләкин шуның белән бергә чын

дөресен бик үк яшермәскә дә тырышып сөйләдем. Әмма бу минутларда авыру шагыйрьнең үлү ихтималын беребез дә уйламаганбыздыр дип беләм, чөнки Хәсән Туфан кебек кешенең алай тиз генә үлеп китүен акыл да сыйдырмый, күңелләр дә кабул итәрлек түгел иде... Сүз дә, билгеле, күбрәк дөньяви эшләр турында барды. Сәйфи агайны тыңлавы бик күңелле, Гафурилар, Бабичлар замандашы бик күпне белә, хәтере бер дә картаймый, фикере өзлексез эшли, зур максатлар белән яши — өч якта өч эшем көтеп ята ди... Тарихыбызга, әдәби хәрәкәтебезгә кагылышлы күп кенә мәсьәләләр турында аның җанын борчыган әйтер сүзләре бар. Үлем түшәгендә яткан Хәсән абзыйның миңа барсыннан элек «Сәйфи хәлен белеп» кайтырга кушуы да очраклы түгелдер, әлбәттә. Мондый кайгырту аларның уйлары, теләкләре, максатлары уртаклыктан, ниһаять, бер-берсенең бик кадерлегә калган гомерләре өчен борчылудан туган да булырга тиеш.

Шушы очрашудан соң берничә көн узды, Ибраһим да китеп барды, ә минем Уфада эшләрем күп иде әле. Ләкин уйламаганда тагын бер юлсәфәр килеп чыкты. Башкортстан Язучылар союзы бик матур бер чараны гадәткә керткән: һәр елны җәй башында Фатих Кәримнең туган авылы — Аетка барып, шагыйрь хөрмәтенә шигъри бәйрәм уздырып кайталар икән. Моны рустан күчеребрәк «Фатих Кәрим укулары» дип атарга да өлгергәннәр. Менә шул шигъри бәйрәмгә мине дә чакырдылар— мин, эшләрем калса да, бик теләп риза булдым. Фатих белән бит без Дим буенда үскән кешеләр, ләкин аның авылы Дим үрендә, ә минем ул тарафларда бер дә булганым юк иде. (Һәм күптән инде буласым да килә иде). Аннары шушы бәйрәмгә бару өчен Рафаэль Сафин «Янган тау»дан Илдар Юзеевны да алып кайткан —димәк, юл йөрү өчен компания дә күңелле булачак.

Шулай итеп, 10 июньдә, сәгать 11ләр тирәсендә (Казан вакыты белән тугызларда) без ике машинага утырышып, Уфадан Бишбүләк районына чыгып киттек. Беренче машинада Рафаэль, Илдар, мин; икенчесендә — Фатих Кәримнең кызы һәм башка якын туганнары... Вакытны болай төгәл әйтүем өчен гаҗәпләнмәгез, чөнки 10 нчы июнь соңыннан безнең күңелләргә бик нык керәчәк, әмма Уфадан чыгып киткәндә, Казаннан бер нинди хәбәр дә юк иде әле.

Юлыбыз — Кандыра күл, Бәләбәй аша. Башкортстанда асфальт юллар шәп, тизлек монда 90 километрдан да ким түгел, каршы очраган машиналар «выжт» та «выжт» үтеп кенә торалар. Тик бу тизлек турында уйламаска гына кирәк... Җәйнең башы гына бит әле, бөтен әйләнәдә зөбәрҗәттәй ямь-яшел кырлар, якында-еракта кара-кучкыл урманнар күренеп кала, ләкин шулай да машина тәрәзәсеннән табигатьне яхшылап күреп тә, күзәтеп тә булмый — күбрәк алга гына карап барырга туры килә. «Жигули» табигатькә сокланыр өчен түгел, тизрәк барып җитәр өчен ул!

Ә менә машина эчендә сүз күбрәк шигърият турында барды. Хәер, сүзнең төрлесе булгандыр инде, әмма берсе аеруча нык истә калды: Рафаэль Сафин безгә Хәсән Туфанның «Ант» поэмасыннан өзекләр укып күрсәтте. Хикмәтле әсәр икән, бик көчле язылган урыннары бар — минем әле беренче тапкыр гына ишетүем. Поэма кайчандыр журнал битләрендә басылган булган, ләкин соңыннан шагыйрьнең бер генә җыентыгына да кермәгән. Кулында да сакланып калмаган. Рафаэль менә шуны каяндыр табып, тулысынча күчереп алган һәм Хәсән абзыйның үзенә тапшырырга вәгъдә дә биргән булган.

Поэманы тыңлау бездә, билгеле инде, төрле уй-фикерләр уятты. Шул ук вакытта без Фатих Кәрим авылына китеп барабыз — менә шуңа

күрә дә бу ике чын олы шагыйрьнең язмышлары безнең аңыбызда үзеннән-үзе бергә кушылды. Икесе дә зур рухи батырлыкка ия булган шәхесләр!..

... Онытмыйк, унынчы июнь!.. Көн әйбәт, артык эссе дә түгел, баруы рәхәт, җиңел. Фатих Кәримгә гүя Хәсән Туфанны да яныбызда алып барабыз. Менә Гази Кашшафның туган авылы Кандыра Күлне дә уздык. Юлыбыз көньякка, Бәләбәй урләренә таба борылды, бара торгач Бәләбәйнең үзен дә үтеп киттек. Уйласаң, заманында бу яклардан күпме татар шагыйрьләре чыккан: Зыя Ярмәки, Әхмәт Ерикәй, Фатих Кәрим, Ярлы Кәрим (Фатихның бертуган агасы) — болар әле искә төшкәннәре генә... Шагыйрь һәм әдип кайдан чыга? «Туган тел»не сабыйга күңелдән ятлаткан мәктәптән, билгеле, мин моны үземнән дә бик яхшы беләм... Орлыксыз бер генә чәчәк тә үсеп чыкмый, әлбәттә.

Ахырда, 260 километр җирне 4 сәгать эчендә үтеп, без Бишбүләккә дә килеп җиттек. Бу күңелле генә бер «районзәк», урта бер җирендә иркен генә мәйданы бар, мәйдан уртасында — Ленин һәйкәле... Иң элек без гадәт буенча райкомның беренче секретаре иптәш Әхмәтов янына кереп, бераз утырып чыктык. Сабан туе көрәшчесенә охшаганрак кара тутлы, чем кара чәчле бу таза кеше купшы сүзләрсез, елмая бирел кенә безне районның бүгенге хәле белән таныштырды. Иң-та калганы шул — районда халыкның күпчелеге татарлар белән чувашлар икән. Монда безгә хуҗа сыйфатында райкомның икенче секретаре иптәш Хәйретдинов кушылды. Башта ук әйтәсем килә, бу гаять житез, өлгер кеше искиткеч сүз остасы (оратор) булып чыкты. Татарча әйтсә — саф татарча, русчасы — руслыкыннан аергысыз, чувашча сөйләсә — сатып җибәрер. Телгә ниндидер махсус талант үзендә! Мин аңа көлебрәк, «сип, туган, бу сәләтең белән бик ерак китәрсең», дигән идем дә, ул килешмичә, «юк, тел генә җитми, тагын бер нәрсә кирәк әле» диде, ләкин нәрсә кирәген әйтмәде.

Бишбүләктә без шулай ук туган якларына кунакка кайткан чуваш шагыйре Ухсайны да очраттык. Ухсай ул безнең әдәбиятка якын кеше, өлкән язучыларның барысын да диярлек яхшы белә. Хәсән абзый турында да, билгеле, сорашмыйча калмады. Без Хәсән абзыйның каты гына авырып ятуын әйттек, ләкин, иншалла терелсә кирәк, дидек — без әле бу сәгатьләрдә бернәрсә дә белми идек. Аннары район ашханәсенең аулак бер бүлмәсендә әйбәт кенә ашап-эчеп (кымызны да беренче мәртәбә шунда авыз итеп) чыкканнан соң, төп «ноктабыз» — Фатих Кәрим авылына китеп бардык. Инде күп калмаган иде, бер 30 гына километр...

... Менә Аст авылы үзе дә! Шактый ук зур авыл икән, тигез үзәнлектә артык сибелмичә оешып кына утырган заманча төзек, таза авыл... Мин инде аның Дим буенда утырганын күптән белә идем. Минем үскән җирем Дәүләкән дә нәкъ Дим өстендә, ләкин ул Димнең урта агымында, ә Аст — бер 70—80 чакрым югарыда. Фатих Кәрим белән туган елларыбыз да бер, димәк, без — кайчандыр бер үк елга буенда, бер үк суны эчеп үскән малайлар. Менә ни өчен минем «Фатих Димен» бик күптән күрәсем килә иде.

Ләкин ашыкмыйк, чираты җитәр — күрербез... Шулай, килеп төштек, әйбәт каршы алдылар, колхоз җитәкчеләре белән таныштык. Колхозның исеме дә «Дим» икән. Председателе иптәш Фәттахов буйга-сынга мәһабәт-таза, салмак-сабыр, аз сүзле кеше, ләкин әле шактый ук яшь булса кирәк. Йола кушканча, башта аның бүлмәсендә (дөресрәге, кабинетында) азрак сөйләшеп утырдык, аннары инде «Кәрим урыннары» белән таныша башладык. Иң элек, билгеле, музеена киттек. Бу — идарәдән ерак түгел, урамга буй салынган, шифер белән япкан чибәр генә яшел йорт. Стенасына цементтан гына булса да мемориаль такта да беркетелгән. Йортны колхоз идарәсе Фатихның атасыннан калган урынга музей өчен махсус китертеп куйган. (Аны финский йорт, диделәр безгә.)

Фатих туып-үскән бүрәнә йорт та сакланган икән, ләкин аны күптән инде колхоз кирәгенә каядыр икенче урынга күчергән булганнар. (Күрәсең, ул вакытта әле музей ачу истә тотылмаган.) Ничек кенә булмасын, Ает җитәкчеләре шушы җирнең баласы, шушы илнең җырчысы шагыйрь Фатих Кәрим музеен оештырып бик күркәм, бик кирәкле эш эшләгәннәр.

Без менә шул музейның ихатасына рәшәткә ишекне ачып керәбез. Бу инде кайчандыр Фатих таптаган, Фатих аунаган ишегалды. Дөресрәге, ул үскән чактагы зур ишегалдының кечкенә бер өлеше — аны музейга кирәк кадәр генә рәшәткә койма белән әйләндереп алганнар. Шушы кечкенә мәйданны да куе биек үлән каплаган, тик музей ишегенә илтә торган сукмак кына тап-такыр. Димәк, сукмактан йөрүчеләр өзелеп тормый!..

Без дә шул сукмактан узып, ишек төбендә үк аякларыбызга чүпрәк «чабаталарны» бәйләп, музей бусагасыннан атлап кердек. Иркен генә ике бүлмә, алгысында Фатих Кәрим замандашларының, шулай ук татар һәм башкорт әдәбияты вәкилләренең фоторәсемнәре — карт буыннан алып, яшь буынга чаклы барсы да диярлек бар. Шулай итеп башта гүя ике тугандаш әдәбият дөньясына керәбез, шуннан соң гына Фатихның үз янына — икенче бүлмәгә үтәбез. Бүлмә түрендә аның буяу белән язылган зур портреты тора — без кулыбыздагы хуш исле кыр чәчәкләрен шуның алдына илтеп салабыз. Фатих безгә: «Хуш килдегез, дуслар!» дигән төсле көлемсерәп кенә карап тора. Әйе, портреты үзенә бик охшаган, тере Фатих диярсең — мин бит аның бөтен кыяфәтен бик яхшы белә идем.

Монда инде турыдан-туры Фатих Кәримгә кагылышлы күп кенә материал тупланган. Экспонатлар барсы да бик пөхтә итеп, кадерләп куелган — күренеп тора, яраткан, бәясен белгән кулларның эше бу... Музейның мөдире Саимә исемле бер ханым икән. Болай карап торуга гаптгади авыл хатыны, әмма шушы музейга бөтен җаны белән бирелгән кеше. Безгә дә ул экспонатларын күрсәтә-күрсәтә, Фатих Кәрим турында белгәннәрен бик тәфсилләп, рухланып дигәндәй, сөйләп бирде.

Музейдан чыккач, без Дим буена киттек. Күпердән чыгып, тугаенда да йөрдек. Бу инде Димнең югары агымы, ләкин монда да ул ярданярга тулып ага — киң дә, тирән дә. Кечкенә Фатих өчен ул куркыныч та булгандыр әле, хәер, малай кеше аны уйлап торамыни — бөтерелеп кызу гына аккан суда ул күпме йөзмәгәндер дә яшел ярлары буйлап күпме генә йөгермәгәндер?!. Аннары малай кеше агым суга карап хыялланырга да ярата бит әле. Менә безнең Фатих та — киндер букчасында Тукайны йөрткән авыл шәкерте — хыялы белән якты Димгә ияреп һәм Дим белән бергә Агыйдел-Камаларга кушылып, бик ерактагы «нурлы һәм моңлы» Казанга да барып җиткәндер. Бәлки шушы хыялы аны күп тә үтми (уналты яшендә үк) белем һәм мәдәният учагы Казанга тартып та китергәндер... Әйе, Казан Фатих Кәримнең шигъри ватаны, шунда таба ул үзенең газаплы һәм данлы язмышын, шуннан башлана аның үлемсезлеккә соңгы юлы!.. Ул елларда бер кулына мылтык, икенчесенә каләм тотып, илен сакларга ант итүче шагыйрьләр аз булмады. Фатих Кәримнең һәрбер очып килгән пуля үлем китергән чакта язган менә мондый сүзләре бар:

> **Үлем турында уйлама, илең турында уйла,**
> **Илең турында уйласаң, гомерең озын була!**

Шагыйрь гомерен фашист пулясы ахыр чиктә өзде өзүен, ләкин аның әнә шул сүзләре гади солдат өчен сугыш кырында бердәнбер юаныч булып калды.

Кичен халык эштән бушагач, авылның ак кирпечтән салынган яңа клубында Аст кешеләре белән очрашу булды. Онытмас борын әйтим, монда безгә тагын бер шагыйрь — Стәрлебаш районыннан килгән Фәйзи Гомәров та кушылды... Кунаклар сыйфатында без барыбыз да сәхнәгә менеп утырыштык. Зал халык белән тулы иде. Очрашуларның тәртибе кайда да бер диярлек: башта тамашачыларны килгән кунаклар белән таныштыру, аннары инде аларның үзләренә сүз бирү — монда да әнә шулай башланып китте. Әйтергә кирәк, халык безне шылт та итмичә тыңлады. Мин сәхнә түреннән залдагы кешеләрнең йөзләренә сихерләнгәндәй карап утырдым. Һәр сүзне алар тыңлау гына түгел, гүя йотып баралар — йөзләрендә тирән уй, сагыш, ә күзләрендә вакыт-вакыт яшь тә чагыла. Безнең бит Илдар да, Рафаэль дә бик шәп гармунчылар. Ирексездән яшьләрең бәреп чыгар...

**Саратский яшел гармун**
**Көмеш кыңгыраулары.**
**Бу көмеш кыңгырауларның**
**Кичке яңгыраулары.**
**Әллә нишләтә күңелне,**
**Үксеп елыйсы килә...**
**Елау егет эшемени,**
**Эх, бер җырлыйсы килә!..**
. . . . . . . . . . . . .

Әнә шулай Фатих шигыре белән башлады Рафаэль сүзен һәм, гармунын тартып, уйнап та җибәрде.

Илдар да үзенең «Таныш моңнар» дигән поэмасын гармун моңына кушып сөйләде. Билгеле инде, бу ике шагыйрьнең сүзләре һәм уеннары халыкны гәмам әсир итте, шагыйрь кем дә шигырь нәрсә икәнен алар күңеленә бик нык сеңдерде, минемчә... Шуның өстенә Фатих Кәрим кызы Ләйләнең һәм башка якыннарының чыгышлары да Аст кешеләрендә авылдаш шагыйрьләре өчен горурлык хисе уятмыйча калмагандыр, әлбәттә... Әйе, җанлы сүз, җыр һәм шигырьнең кодрәте зур, дуслар!.. Халык шуңа сусап тора, шуны көтә — кая гына барсаң да моны бик ачык тоеп була. Шуңа күрә дә әйтәсем килә: менә безнең шагыйрьләр бу җирне, бу халыкны онытмасыннар иде, якын итсеннәр иде, ел да «Кәрим укулары»на ерак араны якын итеп килсеннәр иде... Кәрим сүзләренә язылган бик матур көйләребез бар, бер-ике җырчы да килеп, «укуларны» бизәсәләр, халыктан бары рәхмәт кенә ишетеп китәрләр иде. Шулай ук скульпторларыбыз шагыйрьнең бюстын эшләп, музей алдына китереп куйсалар, Аст авылына бу бик зур бер бүләк булыр иде. Кыскасы, Башкортстан язучылары башлаган шушы гүзәл традиция Татарстан язучыларының якын катнашы белән елдан-ел дәвам итсен иде. Хәер, итәр, итүенә бик нык ышанасы килә.

Әнә шулай узды бу тиз генә истән чыкмас матур, күңелле очрашу. Вакыт соң иде инде, шулай да халык авыл яшьләренең концертын тыңлый калды, ә безне хуҗалар иркен таза бер өйгә кунак итәргә алып кердeләр. Монда, авылча гади, әмма бик мул әзерләнгән табын әйләнәсендә дә, ихлас сүзләр, яхшы теләкләр, җыр-музыка җитәрлек булды. Безнең әйбәт җырлар Астка да күптән килеп җиткән, барысын да беләләр, «Җидегән чишмә»не дә җырладылар, «Киек казлар»ны да.

**Киек казлар кыйгылдаша,**
**Җырлашалар микәнни?**
**—Туган илләр кала бит, — дип**
**Елашалар микәнни?..**
. . . . . . . . . . . . .

Башларны иеп. без Хәсән абзыйның әнә шул моң-зарын тыңлап утырабыз... Әмма ләкин без берни дә, берни дә белми идек әле. Унынчы июнь үтте инде, унберенче июньнең таңы туып килә... Һәм шушы таңда Хәсән Туфанның баш очында ике карчыкның төн утырып чыкканын мин бары соңыннан гына ишетеп белдем.

*
* *

Аеттан Бишбүләккә без таң алдыннан гына кайтып яттык. Унберенче июньдә сәгать 9 ларда торып, иртәнге чәйне эчкәннән соң, кайтыр юлга чыктык. Юлыбыз Дим юнәлеше буйлап, Шафран, Әлшәй аша иде, чөнки иптәшләр мине Дәүләкәндә калдырып китәргә тиешләр. Райком секретаре, элеге телгә оста Җәлил Хәйретдинов һәм тагын бер иптәш безне район чигенә кадәр озата бардылар. Ләкин чиккә җиткәнче әле алар безне бер биек калкулык өстендә туктаттылар. Машиналардан төшкәч тә безнең алдыбызда искиткеч манзара ачылды: шактый ук түбәндә, инеш буйлап утырган татар авылы (исеме дә «Чишмә» икән), аның әйләнәсендә сузылып киткән, урман каплаган таулар, тау итәкләрендә ямь-яшел аланлыклар. Гүя кеше кулы тимичә сакланып килгән шигъри бер табигать! Билгеле, мондый шигъри табигать алдында сүзсез-җансыз калу мөмкин түгел иде. Менә Рафаэль Сафин гармунын яңадан кулына алды һәм түбә өстеннән әнә шул күксел тауларга, яшел аланлыкларга карап, «Уел»ны сузып җырлап җибәрде... Мин бер читкәрәк китеп тыңладым... Яңадан күрергә һәм ишетергә әллә туры килер, әллә килмәс?! Әйе, күңел нечкәрүен басу җиңел булмады.

Аннары аяк өсте генә капкалап алдык та кузгалдык. Бишбүләк — Әлшәй чигенә җиткәч, ачык йөзле, юмарт күңелле хуҗаларыбыз белән куллар кысышып, ниһаять, аерылыштык... Хәзер инде юлыбыз — минем Дәүләкәнгә... Уйланып барам, бу ике музыкант шагыйрьне Дәүләкән кешеләренә дә күрсәтергә иде бит... Ләкин егетләрем бик арыганнар иде инде... Кайткан саен башкорт шагыйрьләрен үзем белән Дәүләкәнгә китерәсем килде, әмма ни сәбәптер, шушы гади генә теләкне дә гамәлгә ашырып булмады. Казага калган хыял — күпме алар?

*
* *

Уфага мин уникесендә бик соң гына кайттым. Номерга килеп керүемә бер биш минут та үтмәгәндер, телефон шалтырады. Трубканы алсам, Флера ханым тавышы. Хәл-әхвәл сорашканнан соң, ул миңа Хәсән Туфанның үлүен хәбәр итте. Мин бер мәлгә тынып калдым, аннары сорадым: кайчан?.. Унысында иртә белән, диде Флера ханым, без үзебез дә монда килгәч кенә ишеттек. (Бакый абзый белән алар Казаннан пароходта җидесендә үк чыгып киткәннәр икән.) Тагын өстәп, Флера ханым Нажар Нәҗминең кичә ашыгыч рәвештә Казанга очуын да әйтте.

Димәк, унында иртән, без Бишбүләккә чыгып киткән сәгатьләрдә, бәлки әле чыгып китәргә дә өлгермәгәнбездер, хәер, моның хәзер ни әһәмияте бар?! Хакыйкать бит бер генә: Туфан юк, Туфан киткән!..

Флера ханым белән сөйләшеп беткәч, мин күпмедер вакыт тынып, тик кенә утырдым. Нишләргә? Фатих Әмирхан Тукайның үлгәнен ишеткәч, кулын күтәреп:

— Инна лиллаһи вә инна иләйһи раҗигун! — дип дога кылган. Без исә алай җанга юаныч таба белмибез, без бик күп уйлый гына беләбез.

**Уйлар,**
**китегез, кит!**

Калыпларга аккан чуен кебек
тыгызлыйсыз күңелне!..

Бу Туфанның үз сүзләре. Кайсыдыр шигыреннән хәтердә сакланып калган. (Бер илле ел бардыр инде.) Дөресен генә әйткәндә, зур югалтуның бөтен тирәнлеген, үкенечен без сәгате-минуты белән генә аңлап та бетермибез. Соңрак килә ул безгә... Аннары Хәсән абзыйның авыр хәлдә ятуын күреп киткәнгәдер, ахрысы, бу үлем хәбәре миңа, ничек дим, кинәт китереп суккан шикелле тәэсир дә итмәде, күрәсең, күңел ничектер әзер булып торган моңа. Соңгы мәртәбә күрүем күз алдыма килде: өстендә ак җәймә, ак чәчләр, ак йөз, ак иреннәр... Әйе, ак кеше! Соңыннан миңа әйттеләр, табутта ятканда ул тынычланып йокыга талган сабый кебек иде, диделәр. Ышанам, бигрәк тә тынычлануына ышанам... Әйе, күпме генә яшәмә, ахыры бер: кеше китә... Шагыйрьдән нәрсә калганын без беләбез — анысы кулыбызда. Ә менә үзе белән алып киткәнен белү — юк, мөмкин түгел. Хәлбуки, киткәне дә аз булмаска тиеш — бөек шагыйрьләр, минемчә, бер вакытта да үзләрен актыгына кадәр сыгып, чыгарып бетермиләр. Ә Туфан бөек шагыйрь иде. Уйланудан, борчылудан, өметләнүдән туктамаган шагыйрь иде.

... Икенче көнне бик соң гына миңа Рафаэль Сафин килеп керде. Кайгылы, борчулы, кулында Туфанның «Лирика»сы. «Бер дә тынычлана алмыйм, — ди Рафаэль, — ачам да шушы лириканы укыйм, ачам да укыйм!..» Шагыйрьнең үлү хәбәрен соңга калып ишетүенә, җирләшергә бара алмыйча калуына бик үкенә.

Әйе, үкенүләр дә, ачынулар да, кайгырулар да булыр әле, булыр. Гадәттә бездә бу хисләр кеше арабыздан киткәч туа. Әнә шул куллардан төшмәячәк шигърияте безгә тынгылык бирмәячәк. Тукай белән шулай булган иде, Такташ белән дә шулай булды, Туфан белән дә һичшиксез шулай булачак.

*Июль, 1981 ел.*

Кечкенә искәрмә. Бу язма әле Уфада чакта ук бик ашыгыч рәвештә генә язылган иде. Казанга кайтып, яңадан төзәтеп, күчереп яза башлагач, мин аны башка язуларым белән бергә югалттым. (Таксида онытып калдырганмын.) Көне-сәгате белән эзләргә керешсәм дә таба алмадым һәм табылуына өметемне дә өзгән идем инде... Әмма, бәхеткә каршы, бер-ике атнадан язуларымны табып миңа кайтардылар. Шуны эзләүдә, табуда катнашы булган барлык иптәшләргә дә чын күңелдән тирән рәхмәтемне белдерәсем килә.

Ә. Е.

**Фатыйма Ильская,**
РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы

# ИСТӘЛЕКЛӘРЕМ

## КЕРЕШ СҮЗ

Миңа балачагымны искә алу авыр. Чөнки шат, якты балалык мизгелләры миңа таныш түгел. Балачагымны гел караңгылык эчендә күрәм. Мәсәлән, менә болайрак итеп: ... Оренбург. Вокзал янындагы кечкенә генә йорт. Ул йортны землянка дип атасаң дөресрәк булыр. Йортыбыз янында — чиндидер төзелеш, тирә-юньдә йомычкалар. Мин йомычкалар җыям. 12 яшькә кадәр гел йомычка җыйдым мин. Йортыбыз эчендә исә гел бик күп капчык була иде. Бабам Галимҗан, әбием Гөбәйдә үз гомерләрен капчык арасында уздырганнар. Бабам — тегермәндә йөк ташучы иде, әбием исә — капчыклар ямаучы. Әти, әниемне хәтерләмим. Сукыр лампа яктысында әбием, бабам алар турында җай гына, матур гына итеп сөйлиләр иде. Әнием Һиҗәстә Оренбургта туган. 15 яшендә аны кияүгә биргәннәр. Төскә бик чибәр булган минем әнием, зифа гәүдәле. Әтием Салих та матурлыгы белән кешеләрнең игътибарын үзенә тарткан. Ул кара эшче булган. 25—26 яшьләрендә, ничектер, эш эзләп киткәнме, Кара диңгез буенда үлгән. Мин әтиемнән 9 айлык чагымда калганмын. Әнием — күкрәк бакасыннан (йөрәк авыруыннан) үлгән. Ул үлгәндә миңа яшь ярым була.

8 яшьтә, мәктәпкә керәсе урында, мин җиңгәм белән бергә эшкә йөри башлыйм, йон ташыйм. Оренбург байлары Мәхмүд, Әхмәт һәм Гани Хөсәеновлар сарык, кәҗә тиресе, йон җыеп, аларны эшкәртеп, зур сәүдә алып баралар. Аларның йон юу өчен зур корылмалары — Оренбург янындагы елганың икенче ягында, фабрика сыман бина иде. Анда йөзләгән хатын-кыз, бала-чага мәш килә. Гади халык аны мойка дип йөртә. Менә шунда — мойкада, йон юам, йон ташыйм. Иртәнге 6 дан кичке 6 га кадәр.

Тагын шуны хәтерлим: бабам мине җәйләрен үзе белән далага, казакъ авылларына алып китә иде. Ул эшли. Ә мин иксез-чиксез казакъ сәхрәсе буйлап чабып йөрим... Кычкырып көләм. Далада тавышым матур булып яңгырый. Аның яңгыравы мине тагын да куандыра, ярсыта. Тавышымның үзенчәлеге, бәлкем, әнә шул далада чарлангандыр, чыныкkандыр.

12 яшь. Зурлар мәктәбенә, ул заманда оренбурглылар әйткәнчә, «Воскресенская школа»га рус мәктәбенә йөрим. Русча укырга, язарга өйрәнәм.

Миңа 15 яшь. Көннәрнең берендә, әлеге мойкадан кайтканда, афиша күрәм: татарча спектакль «Мәкер һәм мәхәббәт», Ф. Шиллер әсәре. Бе-

ренче тапкыр спектакль карыйм, таң калам. Үзем аңлый алмыйм әле. Күңелдә сәхнәгә омтылу туа. Сәхнәдә буласы, әнә шулай уйныйсы килә. Спектакль йөрәгемә ялкын салып китә. Театр турында хыяллана башлыйм.

Мине сәхнәгә беренче башлап алып чыгучы артист Локман Аитов булды. Язгы кояшлы көн иде. Урамда мине Локман Аитов туктатты:

— Бәләкәй кыз, «Народный Дом»-га кил. Без сине артистка итәбез.

Мин куркам. Икеләнәм. Аптырап торам. Ничек инде артистка?

— Безнең труппа русчадан тәрҗемә итеп «Өрәкләр» дигән спектакль куя. Мәрьям ролен уйнарга бер кыз кирәк. Кил. Без сиңа сүзләрне әйтеп торырбыз. Өйрәтербез. Артистка булырсың.

Каушавымнан ничек уйнаганымны да хәтерләмим. Уйнавым ошаган булса кирәк, мине тагын чакырдылар...

Озак та үтмәде, Габдулла Кариевтан хат килә. Мине «Сәйяр» труппасы чакыра. Казанга чакыралар!

Миңа Казан якын, кадерле. Мин «Сәйяр»да тудым. Минем иҗади яшәвем дә 1916 нчы елның көзеннән «Сәйяр» труппасында башланды.



• *Фатыйма Ильская — Глафира Фирсовна ролендә (А. Островский. «Соңгы корбан». 1968 ел).*

Хәзер В. И. Качалов исемендәге рус драма театры ул елларда «Большой театр» дип йөртелә иде. Менә шул театр бинасында «Шәфкать туташы» спектаклендәге Юлечка булып мин беренче тапкыр Казан тамашачыларына күрендем. Мәңге онытылмаслык спектакль! Беренче чыгыш! Театр тәнкыйтьчесе Габдрахман Кәрам бер төркем язучылар белән сәхнә артына кереп мине котлый. Габдулла Кариевка үзләренең сокланууларын белдерәләр.

Фатих Әмирханның «Тигезсезләр» драмасында уйнавым — бусы инде икенче чыгышым. Мин — Рокыя ролендә. Спектакль тәмамлангач залны алкышлар күмеп китә.

Берәздән минем каршыма коляскада сөйкемле генә яшь кеше килә. Кулында чәчәкләр. Ул елмая. Кемнеңдер тавышын ишетәм:

— Фатыйма, таныш, бу — мөхәррир Фатих Әмирхан!

— Мин бүген чын спектакль карадым. Мин үзем язган Рокыямны күрдем! Минем Рокыям Оренбургтан килгән икән! — Шулай ди Фатих Әмирхан һәм миңа чәчәкләр суза. (Ул чәчәкләр минем өчен бик кыйммәтлеләр. Алар минем күңелемдә бүген дә саклананалар)...

«Мөхәррир!» Бу сүз мине аптырашка сала. Адым саен мине ниндидер яңалык көтә. Яңа сүзләр. Аларның һәрберсе минем өчен серле. «Мөхәррир» диләр. Күрәм: «Мөхәррирга» хөрмәт бик зур. Кем соң ул мөхәррир? Аны да мин соңрак кына аңлыйм. Татарча укый да белмим әле. Рус мәктәбенә нибары 3—4 ел гына йөрдем. Аннары тегүчелек мәктәбе! Сизәм, бу мохитта мондый белем белән генә яшәү читен. Аз белемле икәнлегемне әйтергә оялам. Мең рәхмәт, Габдулла Кариев моны тиз сизә. Аның тырышлыгы белән университет студентларының берсе миңа дәресләр бирә башлый...

Казанга килүемә озак та үтми, көннәрнең берендә Габдулла Кариев сүз башлый:

— Бу кызыбыз ятим. Ул ил өчен туган кыз. Ил кызы булсын. Ильская дип атыйк. Аның фамилиясе бүгеннән башлап Ильская. Фатыйма Ильская! Хуҗасаетова, фамилиясе онытыла...

Хәзер инде миңа 80 яшь. 62 елга якын мин өзлексез сәхнәдә. Озын гомер кичердем. Күп күрдем. Шатлык та, кайгы да аз булмады. Күз яшьләрем дә коелды. Күп уйландым. Гомерем буена бер фикер миңа юлдаш булды: «Бары үзең өчен генә яшәү, тыныч кына яшәү — ул яшәү түгел. Ул — тормыш түгел!.. Хезмәтең кешеләргә кирәк булсын! Син кешеләргә кирәк бул!»

Менә шул хакта, яшәү мәгънәсе турында сөйлисем килә минем. Язмыш миңа күп нәрсә бирде. Язмыш миңа бик күп бәхетле очрашулар бүләк итте. Тормыш юлымда берсеннән-берсе игелекле кешеләр очрап, алар мина ярдәм кулларын суздылар. Барысына да үземнең рәхмәтемне белдерәсем килә. Алар хакында бигрәк тә яшьләргә сөйлисем килә.

Беренче сүзем Габдулла Кариев турында.

## Һәр яктан гүзәл...

Халкыбызның кыю фикерле, кайнар йөрәкле улы Габдулла Кариев тормышын театрга багышлаган күркәм кеше иде. Һәр артистның иҗат мөмкинлекләрен күрә белгән режиссер, сабыр педагог та, оештыру сәләте зур булган җитәкче — театр хуҗасы, элеккечә әйткәндә, антрепренер да ул.

Артист Габдулла Кариев сәхнәдә бервакытта да үзен кабатламады. Ул бер-берсенә һич охшамаган образлар иҗат итте. Шуларның бер-икесенә генә тукталам. Мин аның «Соңгы сәлам» (Кәрим Тинчурин) спектаклендә балыкчы, Г. Камалның «Безнең шәһәрнең серләре»ндә шкафчы Әхмәтҗан рольләрендә уйнавын һичбер кемнең уйнавы белән чагыштыра, тиңли алмыйм. Алар бик төгәл, дөрес эшләнгән портретлар.

Менә Кариев — балыкчы. Бик гади, урта яшьләрдәге татар. Өстендә көрән кыска кием, башында иске татар бүреге. Йөреше салмаграк. Ул Идел яры буенда, кармакларын суга салган. Үзе сөйләшә, ә игътибары суда, балык чирткәннә көтә. Аның сөйләшүләрендә, хәрәкәтләрендә халыкның әчкерсез, аз сүзле, гади, акыллы кешесен күрәсең... Печән базары каһарманы, кара фикерле Әхмәтҗан сөйләшүендә бөтенләй икенче. ямьсез ят тавыш, явызлык, тупаслык ишетелә. Әхмәтҗан күңелдә чиркану тудыра. Бу рольдә Кариевның мәһабәт гәүдәсе ничектер кечерәеп кала.

Икенче бер рольдә Кариев — чын Европа кешесе, чын аристократ. Соклангыч матур, мәһабәт гәүдә. Өстендә гаҗәп пөхтә фрак, йөрешләрендә затлылык, тәрбиялелек күзгә бәрелә. Кариевны бу рольдә күргәч, аның кичә генә шкафчы Әхмәтҗанны уйнавын күз алдына китерү дә мөмкин түгел төсле. Свингали зәңгәр күзләре белән миңа тутырып карый. Ул күз карашында ихтыяр көче шул кадәр куәтле, мин ирексез тулысынча аңа буйсынам. Буйсынмыйча булдыра алмыйм. Ул минс гипнозлаган. Пәрдә төшкәч, тәнәфестә үз бүлмәмә кергәч тә мин әле озак вакытлар айный алмыйм. Һаман үземне образда, Свингали гипнозында итеп сизәм. Габдулла Кариев сәхнәдә әнә шундый тирән ышандыру көченә ия иде. Спектакльдән соң, репетицияләр үткәргәндә байтак вакыт мин аның режиссер Кариев булуына җайлаша алмый тора идем. Чөнки күңелдә әле һаман ул тудырган образлар хакимлек итә. Габдулла Кариев — реалистик юнәлеш артисты, аның образлары тормыштан алынган җанлы, реаль кешеләр. Ул һәр образның төп характерын оста билгели. Мин аның катнашы белән барган спектакльләрне сәхнә артыннан онытылып карый идем.

Габдулла Кариев зур рухи көчкә ия булган, талантлы һәм бик таләпчән режиссер иде. Ул биргән дәресләр, аның көндәлек репетицияләрдә әйткән сүзләре, өйрәтүләре, спектакльдән тыш очрашулар — барысы да минем өчен зур мәктәп булдылар.

— Сәхнәдә үзеңне тормыштагыча табигый тот.

— Сүзеңне ихлас күңелдән сөйлә. Һәр сүзең, һәр хәрәкәтең, һәр күз карашың тамашачыны ышандырсын. Аларда гадилек тә, нәфислек тә булсын.

— Фикерең тамашачыга анык булсын, сүзең югалмасын. Ул тамашачының аңына барып җитсен, йөрәгенә үтеп керсен.

— Гәүдә хәрәкәтләре билгеле ритмга буйсынсын. Хәрәкәтләр җиңел, матур булсыннар. Моның өчен музыканы белергә, музыканы тыңларга, тыңларга кирәк.

— Сәхнәдә бертөрлелек, кабатлану булмасын. Һәр образ өчен үзенчәлекләрне билгели бел, моңарчы күрелмәгән төсмерләүләр эзлә. Һәр образга үзенә генә хас йөрү, сөйләшү, кулларны оста файдалану алымнарын тап. Шулай булганда гына иҗатка ирешербез. Иҗатсыз сәхнә юк! — дип өйрәтә иде артистларны режиссер Кариев. Чын сәхнә иҗатчысы булу өчен безнең алга зур тәрбияви таләпләр куйды: «Артист көр күңелле, бик тәрбияле булырга тиеш. Эчке рухи күркәмлек тышкы матурлык белән бергә үрелгән булсын. Артист — чын мәгънәсендә рухы белән дә, тышкы кыяфәте белән дә күркәм кеше булсын». Үзеңне пөхтә йөртүне ул, хәрби кешеләрнең Устав үтәве мәҗбүри булган кебек, катгый таләп итә иде. Бу таләпләрне үтәүдә ул үзе бик зур үрнәк булды.

Режиссер Кариев спектакльләрнең сәнгатьчә кыйммәтен күтәрүгә күп көч куйды. Рус театры казанышларын яңа аякка басып килүче татар театрына күчерергә теләге зур иде. Моның хакына ул теләсә нинди чыгымнардан да курыкмый иде. Спектакльләрдән килгән акчаның зуррак өлеше, кагыйдә буенча, антрепренерга тиеш булса да, ул акчаны үзенә түгел, ә постановка чыгымнарына файдалана. Рус режиссерларын, рус художникларын чакыра. Кариевның бөтен омтылышы — иҗади үсү, камилләшү, театрның җәмгыять тормышында әһәмиятен югары күтәрү. Моның өчен ул күп кенә оештыру эшләре башкара, һәр спектакльнең ничек үтүенә, һәр артистның ничек уйнавына җентекләп анализ ясый. Булган кимчелекләребезне ачып сала. Уңышларыбыз булса — сөенә. Аны бигрәк тә труппага яңа кергән яшьләрнең уңышлы адымнары куандыра. Кариев бик еш якын дусты Габдулла Тукайны искә ала, аның сөйләгәннәреннән, әсәрләреннән безгә мисаллар китерә. Мондый сөйләшүләр, репетицияләр, әлбәттә, безнең өчен онытылмас сабак иделәр. Минем кебек махсус театр мәктәбен үтмәгән, сәнгать теорияләрен өйрәнмәгән, Казанга килгәнче «Сәйяр» артисткасы булганга кадәр, Оренбург байларында йон юып тамак туйдырган кызга Кариев дәресләре чын сәнгать университеты иде. Мин генә түгел, минем кебек халык арасыннан чыккан эшче кызы Нәфига Арапова, Нәгыймә Таҗдарова, Гөлсем Болгарская һәм башка бик күп сәхнәдәшләрем мең рәхмәтләр укып, Габдулла Кариевка бурычлы булуларын гомер буе әйтә килделәр. Чөнки Кариев мәктәбе — ул кешегә тирән ихтирам тәрбияләүче, иҗади хезмәткә өндәүче, артистны илһамландыручы, рухландыручы сәнгать мәктәбе иде.

Режиссер Кариев бездә иҗат оптимизмы, үзендә булган сәнгать очкыннарын дөрләтә белүне тәрбияләде. «Сәйяр» артистларын театрга булган чиксез мәхәббәт, бергә эшләү, бергә иҗат итү теләге берләштерде. Тормыш вак-төякләрен, көнкүреш мәшәкатьләрен репетиция башлану белән бөтенләй онытабыз. Фәкать иҗат итү генә кала. Үпкәләүләрне, көнләшүләрне белми идек без. Андый хисләр театрны, сәнгатьне кимсетәләр кебек тоела иде. Репетициягә кичегеп килү — акылга сыймас-

лык хәл. Спектакль уйныйсы көнне без театрга өч-дүрт сәгать алдан килеп әзерләнә башлый идек. Спектакль — ул безнең өчен зур тантана, бәйрәм иде. Спектакль уйнауны — эшкә килү, хезмәт бурычын үтәү дип карау — ул театрны кимсетү булып тоела иде. «Рухланып, илһамланып яшә, тормышта тыйнак бул!» — шулай өйрәтә иде безне режиссер Габдулла Кариев.

«Һәр спектакльгә рецензия булсын!» — Габдулла Кариев әнә шундый бурыч куя, аны гамәлгә ашыру өчен язучылар, тәнкыйтьчеләр белән алдан сөйләшә, аларны спектакльләргә анализ ясаган җыелышларыбызга чакыра. Шул заманның театр тәнкыйтьчесе Габдрахман Кәрам, язучы Фатих Әмирхан, драматург Галиәсгар Камал безнең труппада бик еш булалар. Кариев тәнкыйтьтән, рецензияләрдә кимчелекләрне күрсәтүләреннән һич курыкмый. Ул акыллы киңәш, яңа фикерләр, кыйммәтле тәкъдимнәр ишетергә ашкына, театрга ярдәм итәргә теләүчеләргә нәндидер бер ялкынлы омтылыш белән яши иде. Кариев киңәшеп эшләргә ярата. Аның иң якын киңәшчесе, дусты Кәрим Тинчурин иде. Хәтеремдә, Кәрим Тинчурин бервакыт «Сәйяр»дән аерылып торды, берничә ай Мәскәүдә булды. Шул чакта режиссерыбыз канаты каерылган кош кебек йөрде, Кәрим Тинчуринның юклыгын авыр кичерде.



*Кара кыз ролендә — Ф. Ильская (Ф. Бурнаш. «Лачыннар». 1936 ел).*

Антрепренер Габдулла Кариев үзен дәрәҗәле итеп тота. Кешеләр белән оста сөйләшә. Аның матур, тулы, төз буй-сыны, кешеләргә ихтирам белән мөрәҗәгать итә белүе һәр эшне уңай чишәргә ярдәм итә. Аңа беркем дә кире җавап кайтарырга батырчылык итми иде төсле. Әгәр шулай үтемле сөйләшә, кешеләр каршында үзен куя белмәсә, 1917 елда әле рус җәмәгатьчелегенә бөтенләй диярлек таныш булмаган татар труппасы Мәскәүдә гастроль спектакльләре куя алыр идеме? Ә ул спектакльләр Мәскәүнең танылган театрларыннан берсе — Корш театры бинасында бардылар. Шул гастроль вакытында Габдулла Кариев безне Мәскәүнең художество театрына алып барды, К. С. Станиславский белән таныштырды. Кариевның соңыннан да К. С. Станиславский белән очрашып сөйләшкәне хәтеремдә. Станиславскийның йогынтысы Кариевка, аның аркылы безгә зур булуын мин еллар узгач кына аңлый алдым.

Кариевта рус культурасын үзләштерергә омтылыш көчле. Ул шул заманның танылган артистлар иҗатын якыннанрак белергә тиеш. Казандагы рус театрлары спектакльләрен карап бара. Безне дә рус спектакльләренә йөртә... Мин аның белән бергә «Кармен», «Фауст», «Евгений Онегин» опраларын тыңладым.

Кариевның карашы киләчәккә төбәлгән иде. Ул татар театрының киләчәген бик матур итеп күзаллый иде. Минемчә, монда дусты Фатих Әмирханның да йогынтысы булгандыр. Олы әдипнең «Фәтхулла хәзрәт» яки «Гарәфә кич төшемдә» дигән әсәрләрен искә алыйк. Татар мәдәниятенең киләчәген сурәтләгән язучы белән тынгысыз сәнгатькәр киләчәк

турында күп сөйләшкәннәр, күп хыялланганнардыр. Чөнки Кариев безгә кабат-кабат искәртеп тора:

— Эх, безнең театр шәп булачак! Безнең дә Вера Федоровна Комиссаржевская кебек ялкынлы артисткаларыбыз тамашачыларны гүзәллекне сөяргә, аңларга өндәячәкләр.

Сәхнәдә 18 генә ел уйнаса да, мәңге онытылмас иҗатчы булып калган Вера Федоровна: «Сәхнәдә уйнарга кирәкми, сәхнәдә тик дөреслек белән генә яшәргә кирәк. Сәхнәдә бер генә дә уйланмаган, акланмаган, урынсыз хәрәкәт эшләнмәсен»,— дигән фикер белән иҗат иткән. Образларын ул заман рухын тирән аңлап тудырган. Аның сәхнәдә үзүзен тотуында хатын-кызларга гына хас гүзәллек, нәфислек, нәзакәтлелек, ирекка ашкыну көче нык чагылган.

Кариев татарның да әнә шундый артистлары булуы турында хыяллана. Татар театрында В. Ф. Комиссаржевская кебек артисткаларның тууына ышану — халкыбызның талантына ышану дигән сүз.

Габдулла Кариев тормышта гүзәллекне яратучан кеше иде. Кием пөхтәлеге, торак чисталыгы — бу инде үзеннән-үзе мәгълүм булган иң гади таләп. Аш-су тәмле булсын, ул мөмкинлек булганда көндезге ашны иң яхшы рестораннарда ашый. Дуслар белән бергә булырга тырыша. Аның визит карточкасы һәрвакыт үзе белән бергә. Театр эшләрен хөкүмәт оешмаларында хәл иткәндә ул пролетка ала. Татар артисты, татар театры вәкиле мескен булып күренмәсен. Ул артистның кешелек дәрәҗәсен югары тоту өчен борчыла. Музыка тыңларга, поэзия әсәрләрен укырга, бигрәк тә Тукайны укырга ярата. Художникларның рәсемнәрен сокланып карый.

Чеховның «Кеше һәр яктан гүзәл булырга тиеш...» дигән фикерен Кариев тормышта гамәлгә ашыручыларның берсе иде дисәм килә.

Узганнарга борылып карыйсың, озын юл үтелгән. Театрыбызның уңышы зур. Шулай да күрсенеп куясың. Яшьләребез театрның матур традицияләрен белеп бетермиләр яки онытып куялар. Еш кына сәхнәдә яшь партнерларның салкын уйнавын, шаблоннарга бирелүен күрәсең. Кайчак үз театрын икенче, өченче планга куеп, «төшемле» хезмәткә алга куючылар белән дә очрашасың. Менә аларга Кариевны ишеттерәсе, аның тормыш юлын исләренә төшерәсе килә. Күпме генә сәхнәдә уйнасам да, күпме генә тырышсам да, мин Кариевка рәхмәт тойгымны, аңар булган чиксез ихтирамымны әйтеп бетерә алмадым шикелле.

## Камал III

Казан. Островский урамындагы 10 нчы йорт. Хәзер бу йортта Ленин комсомолы исемендәге Яшь тамашачылар театры урнашкан. Ә 1922 нче елда Татар Дәүләт драма театры үзенең иҗади эшчәнлеген менә шунда башлап җибәрде. Эче шәрыкъ стилендә эшләнгән җыйнак бина үзендә әле дә кыйммәтле истәлекләрне саклый сыман. Бик күп сәхнә осталарының яшьлек хатирәләре: иҗат дөньясына беренче аяк басулары, беренче дулкынланулары нәкъ менә шушы бина белән бәйле бит.

1926 нчы елны бу йортта татар театрының 20 еллыгына багышланган тантана узды. Бу йорттан без артист Нури Сакаевны озаттык. Салих Сәйдәшевнең мәшһүр Матәм маршы шушы йортта туды. Һади Такташ белән казанлылар аның табуты янына басып шушы йортта саубуллаштылар. Салих Сәйдәшевнең беренче әсәрләре монда язылдылар. Ул йорт яныннан узганда минем күңелдә сүз белән әйтеп бетерә алмый торган хисләр, уйлар туа... Бик күп вакыйгалар күз алдында яңадан пәйда булалар.

1924 ел. Әстерханнан Казанга Камал III килә. Без аның белән беренче тапкыр шушы йортта очрашабыз. Яшь, ифрат инсафлы егет. Әле аның сәхнә тәҗрибәсе бик аз. Әле ул артист булып җитлекмәгән. Шу-

лай да, беренче очрашулардан соң минем күңелемдә: «бу егет — чын артист, зур артист булачак. Аның исеме халык телендә озак яшәр» дигән фикер туа. Яшь чакта туган фикеремнең раслануына хәзер мин бик шат. Камал III — татар совет театры тарихында зур мирас калдырган олы җанлы артист булып өлгерде.

Труппага яңа гына килеп кергән Камал башта сәхнәгә кечкенә генә рольләрдә чыга иде. Талантларны тиз танып алып үтәли күрә белүче режиссер Кәрим ага Тинчурин аны тиз арада алгы сафка бастырды. Монда, әлбәттә, Әстерханнан килгән Зәйни Солтанов, Габдулла Уральскийның да тырышлыклары аз булмады. Әстерханда бергә эшли башлаган бу өлкән артистларның яшь егеткә ышанычлары нык булган, күрәсең.

Яшь артистыбыз Камал бик тиз арада Гадел Кутуй, Һади Такташ белән дуслашып китте. Ул елларны без дә шагыйрьләр, язучылар белән бик аралаша идек. Бергә ял итәбез, кичләрен бергә киногa барабыз, яки берәребезнең бүлмәсендә җыелып, гөр килеп чәй эчәбез. Менә шунда инде театр, әдәбият турында кайнар бәхәсләр туа!

Безнең шау-шулы төркемебездә Камал бик тиз арада үз кеше булып китте. Без, гомумән, бер-беребезгә ярдәмле, мәрхәмәтле идек. Беребез берәр күңелсезлеккә очраса — шунда ук ярдәм итәргә хәзер идек. Шул уңай белән бер кечкенә вакыйга истә калган. Ул болай булды. Камал III нең өсте-башы чиста, пөхтә йөрсә дә, ярлылыгы күзгә нык бәрелә иде. Көннәрдән бер көнне аның хөрмәтенә бенефис оештырылды. Гадәт буенча бенефиста артистка бүләкләр бирелә. Ә мин аңар чалбар бүләк иттем. Дуслар шуны көлкегә алдылар. Камалның хәтерен калдыргансыңдыр, диделәр. Мин борчылып, ихлас күңелдән ярдәм итәргә теләгәнлекне Камалның үзенә әйттем. «Үпкәләмәдеңме?» дип сорадым.

— Юк, киресенчә, рәхмәтем зур. Бик урынлы булды бит ул бүләк,— диде Камал.

Камал — кешеләргә бик ышанучан, тиз тәэсирләнүчән иде. Үзенә карата эшләнгән яхшылык, игътибар күрсәтү аны бик дулкынландыра, ул аңар балаларча самимилек белән сөенә иде. Ачулана белми, үпкәли белми торган кеше иде ул. Хәтеремдә, «Хан кызы» спектаклен уйнаганда мин кылыч белән ялгыш аның кулын җәрәхәтләдем. Күрәм — Камалның кулыннан кан тама. Әллә нишләп киттем. Ә тәнәфестә янына йөгереп барып, гафу үтендем. Ә ул елмаеп кына миңа җавап кайтара: «Бу — җәрәхәт? Юк, җәрәхәт түгел — рәхәт ул!» Ачуланмады, үпкәләмәде. Ә мин нык борчылган идем.

Кешеләрне борчырга яратмый, һичкемнән әйбер яки бурычка акча сорамас иде ул. Иптәшләргә һичвакыт авыр сүз әйтмәс, рәнҗетмәс иде.

Камал III белән мин 50 елга якын бергә иҗат иттем. Без аерылмас партнерлар идек. Мондый озын гомерле, бер-берсен аңлап иҗат итүче партнерлар театр сәнгатендә сирәктер.

Камал — сизгер, йомшак күңелле зат. Иҗатта соң дәрәҗәдә бирелеп эшли. Ул — сине дә рухландыра торган партнер. Ул һәр хәрәкәтеңә җайлы, матур хәрәкәт белән җавап кайтарырга тырыша.

Камал музыка ярата, халык көйләрен яхшы белә, мандолинада матур гына уйный иде. Бу сыйфатлар исә аңар образларны тагы да тулырак, төгәлрәк ачарга ярдәм итәләр. Әйтик, Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясе куела. Камал әлеге спектакльдә мандолинада уйный. Менә шул уйнау — нәни генә деталь — XX гасыр башланганда яшәгән демократик татар яшьләрен, якты тормышка омтылучы егетләрне күз алдына гаять тормышчан итеп китереп бастыра. Аларның бик күбесенә мандолинада уйнау, татар, рус поэзиясенең иң гүзәл юлларын яттан сөйләү хас иде бит.

Элеккеге зыялылар һәм Камал III үзе дә минем хәтеремдә әнә шулай сакланалар.

## Сердәшем иде

Спектакль бара. Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасы. Галиябануның әнисе Садридан әтисе белән әнисе авыл яшьләренең су буенда күңел ачулары турында сорашалар. Садри — үсмер малай, тизрәк бу «сорау алудан» котылырга тели.

... Тамашачы йотлыгып яңа спектакль карый. Сәхнәдә «Ил», Кәрим Тинчуринның мелодрамасы. Сәхнәдә янадан яшүсмер малай. «Кем уйный соң?» — «Нәфига!» Һич танырлык түгел бит! Бу малай «Галиябану»дагы Садрины да хәтерләтми. Бөтенләй башка малай... Әйе, чыннан да, Нәфига бит!

Нәфига Арапова нәфис, ыспай гәүдәле, кечкенә буйлы, матур, төз аяклы. Аның хәрәкәтләре житез, жиңел. Ул бик тиз арада тамашачының игътибарын үзенә яулап ала. Ул, кечкенә Нәфига, ниндидер илаһи бер көч белән уйный, үзенә тарта, ышандыра. Сәхнәгә чыгу белән көчле, кодрәтле бер кешегә әверелә Нәфига. Аның уйнавын бер генә тапкыр күрсәң дә, аны мәңге онытa алмыйсың. Рухи көчле артистка иде ул.

Без Нәфига белән яшьтәшләр. Быел, февраль аенда аңа да 80 яшь тулар иде. Театрда бергә 1916 нчы елда эшли башладык. «Сәйяр» труппасында иң яшьләр без идек. Безгә еш кына балалар рольләрен бирәләр иде. Күрәсең, балалыктан чыгып өлгермәгән булганбыздыр ахры. Еллар узган саен гади эшче кызы, яшь артистка Нәфига Арапованың иҗади үзенчәлеге һаман ачыклана барды. Сәхнәдә ул минем я энем, я апам, я әнием, ә тормышта исә иң якын дустым — сердәшем иде.

Нәфига турында: «ул талантлы, ул эшчән», — дип кенә әйтү аз. Нәфига Арапова сәхнә өчен туган. Аның бөтен тормышы, яшәеше тулысынча театрга буйсынган. Бары сәхнә, театр өчен яши. Әдипләр, художниклар, музыкантлар белән якыннан аралаша. Аларга ярдәм итәргә, нәрсә белән булса да кирәкле, файдалы булырга ул һәрвакыт әзер. Бер мисални искә алам. Өлкән художнигыбыз Бакый Урманченың мәгълүм рәсемен барыбыз да яхшы беләбез. Сепаратор янында яшь кенә авыл хатыны басып тора. Чын авылча милли киемнән. Мөлаем йөзле хатынның торышында гадилек, тыйнаклык күзгә чагыла. Рәсем тамашачының игътибарын бик тормышчан булуы белән тиз җәлеп итә. Бу рәсемдә без Нәфига Арапованы күрәбез. Рәссамның үтенүе буенча Нәфига Арапова авылча киенеп, сәгатьләр буе басып тора, аңар авыл хатыны образын гәүдәләндерергә булыша.

Иҗат кешеләре мәҗлесләрендә Нәфига бәхәсләшергә ярата. Үзен борчыган проблемаларга җавап эзли. Шундый бәхәсләр бүгенгедәй хәтердә. Хәзерге Ленин урамында, элеккечә әйткәндә, «Дом Советов»та яшим. Шул ук урамда, «Франция» кунакханәсендә Һади Такташ тора. Без спектакль уйнамаган кичләрне бик житез генә Нәфига килеп керә дә, минем: «Ай, бара алмыйм, юк!» — диюемә карамастан, җилтерәтеп өемнән алып чыга да, күз ачып йомганчы без инде Һади Такташка барып та житәбез. Аның бүлмәсендә һәрвакыт әдипләрдән кемдер була. Яңа шигырьләрне без беренче башлап тыңлыйбыз. Бәхәсләрнең чиге юк. Барысы да әдәбият турында. Уен-көлке, тапкыр сүзләр күп әйтелә.

Нәфига күп укый. Ул газеталарны барыбыздан да элегрәк укырга өлгерә. Театр, спектакль турындагы рецензияләрне дә, әлбәттә, иң элек укып өлгергән кеше дә — Нәфига. Театр сәнгатенең, сәхнәнең зур таләпләренә җавап бирү, чын артистка исемен йөртергә хаклы булу өчен ул режиссер үткәргән репетицияләр белән генә чикләнми. Репетиция беткәч тә әле ул сәхнәдә кала, роль өчен ниндидер детальләр, алымнар эзли.

Минә Кәрим Тинчуринның «Ил» мелодрамасы. Айтуган — Арапова — спектакль буенча минем энем — сөйкемле, тырыш авыл малае. Айтуган — табигать баласы, табигатьне ярата. Ул гел җырлап йөри. «Ак-

каенның яфраклары...» жырын ахырынача жырлап бетерә алмый — бүленә: ниндидер яңалык сөйләргә ашыга. Эш сөючән малай. Аның кулында пәке, әле бабасына таяк сырлый, тагын нәрсәдер юна, бал кортларын да карап килә. Ә алпавыт утарындагы бәрелештә үткен, кыю Айтуган һәлак була. Айтуганның үлемен Арапова трагедия дәрәҗәсенә күтәрә. Читән өстеннән ул канатлары сынган коштай егылып төшә. Ирекккә, бәхеткә омтылган сәләтле, сәламәт рухлы ир бала — табигать баласы халык көрәшендә корбан була. Арапованың уйнавы әнә шул фикерне тирән ача. «Ил» спектаклендә тамашачы Айтуганның чыгышын түземсезлек белән көтә һәм Айтуган-Арапованың һәр күренеше кайнар алкышлар белән бара. Татар театры тарихында Нәфига Арапова иҗат иткән Айтуган образы онытылмас урын алып тора.

Инде Х. Ибраһимовның «Башмагым» комедиясендәге Җиһанны искә алыйк. Тупас, надан, азгын нәфесле Казан байларын асламчы хатын Җиһан яхшы белә. Алар алдында ул хәйләкәр. Алардан үз файдасына каера да белә. Менә ул Кәрим бай өенә килгән. Рәхәтләнеп мунча кергән. Мунчадан чыккан Җиһан сәхнәгә килеп керүгә, тамашачы гөр килеп көлә, кул чаба. Җиһан муенына чигүле озын Казан сөлгесен салган, кулындагы себеркесеннән пар күтәрелә. Нәфиганы танып булмый: сәхнәдә бик тапкыр, житез, тик мунчадан соң гына бераз хәлдән тайган Җиһан абыстай.

Арапова бик яхшы партнерша. Без аның белән Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр» комедиясендә уйныйбыз. Бай кызлары без. Бөкре Рокыя — минем апам. Мин — гимназистка Дилбәр. Бу образлар драматург тарафыннан безгә исәпләнеп язылган. Никадәр усаллык ул Рокыяда! Ул тормышны, әйләнә-тирәсендәге кешеләрнең чын йөзләрен үтәли күрә. Шуңа да ачулы ул. Сеңелесе Дилбәрдән дә көлә, аны мыскыл итә. Тавышы ямьсез, әллә ничек тамак төбеннән чыга. Әтисенең: «Чәй хәзерләргә иде», — дигән сүзләренә каршы Рокыя-Арапова: «Күмер юк, күмер»,— дип җавап кайтара. Бу җавап җанны тетрәтерлек көч, ачу белән әйтелә, без, сәхнәдәшләре, тынып калабыз. Шул чак аның кечкенә күзләре зурая, үзе бөкре булса да, тулы гәүдәле, көчле рухлы кешегә әверелә сыман. «Җилкәнсезләр» репетициясеннән соң урамга чыккач та Арапова минем белән Рокыя булып сөйләшә. Мине үзенә буйсындыра. Репетициядән соң да аның шулай булуы миңа үзем уйный торган рольне — Дилбәрнең кемлеген аңларга ярдәм итә. Мин аны тыңлыйм, ә үземне һаман бер сорау мавыктыра: «Каян кила Нәфигага бу рухи көч?»

1936 нчы ел. А. Афиногеновның «Салют, Испания» әсәрен куябыз. Спектакльне фашистларга каршы баш күтәргән испан халкының батырлыгына багышлыйбыз. Испанлыларның авыр көрәш алып барган чорында уйныйбыз. Революцион романтика белән сугарылган ялкынлы спектакль. Мин Долорес Ибарурри ролендә. Нәфига Арапова яшь революционер — яшүсмер малай образын иҗат итә. Кайнар темперамент, үзенә генә хас дәрт, көч белән уйный. Артистка! Ул гүзәл! Ул бәр кешене сокландыра. Күпләр артистка турында шулай фикер йөртәләр. Арапова исә тышкы матурлык белән мавыкмый. Комплиментлар аны кызыктырмый. Сәхнәдә тормыштан алынган җанлы образ, җанлы кешеләр булсын. Ул кешеләр тамашачыны борчысын, уйландырсын. Нәфига Арапова әнә шул уй-максат белән иҗат итте.

Нәфига Арапова гомумән, гүзәллекне, пөхтәлекне ярата иде. Зәвыклы киенә, аягында биек үкчәле лодочка, чәч һәрвакыт матур бөдрәләнгән. Аңарда сентиментальлек юк. Иптәшләренә карата ул принципиаль, таләпчән позициядән чыгып фикер йөртә, алдашуны яратмый. Фикерен туры, ачык әйтә. Музыка ярата. Оста җырлый, оста бии. Матур танцевать итә. Бу осталыкларын ул образлар иҗат иткәндә бик урынлы, уңышлы файдалана.

Нәфига Араповаының, кызганычка каршы, шәхси тормышта бәхете булмады. Ул бик яхшы күңелле бер татар матросын яратты. Аңар кияүгә чыкты. Әмма ире бик иртә вафат булды.

Без, дуслары, Араповаы яратып, сагынып искә алганда, «чәй» дибез дә елмаябыз. Арапова кебек чәй яраткан, аның тәмен, кадерен белгән һәм аның кебек чәй хәзерли алган кеше тагын бар микән?! Аңар килсәң, ул сине чәй белән сыйламыйча җибәрми. Ул чәй хәзерләгәндә кунак тыныч кына, тыйнак кына, хуҗаны артык сөйләштерми генә утырырга тиеш. Нәфига үзенең матур кечкенә самоварын тиз генә куеп җибәрә. Самовар утлы күмерләре белән җырлап, шаулап торырга тиеш. Чәй чәйнеге кайнар су белән кат-кат нык юыла. Чәй салына, чәй дәмләү соклангыч бер осталык, пөхтәлек белән башкарыла. Ниһаять, кунак өстәл янына чакырыла. Ак ашъяулык җәелә, тәмле ризыклар куела, чынаяклар янә бер кат кайнар су белән чайкап алына. Кайнар чынаякларга тәмле итеп дәмләнгән чәй агыла. Бүлмәгә хуш ис тарала. Чәй янында күңелле сөйләшүләр озакка сузыла.



*Ф. Ильская — Гөлбану (Н. Исәнбәт. «Хуҗа Насретдин». 1974 ел).*

Нәфига Арапова радиодан балалар өчен тапшыруларда хикәяләр укый иде. Радиочыгышлар 1930 елларда безнең өчен яңалык, иҗатыбызда яңа өлкә иде. Микрофон күпләрне эле каушата иде. Арапова бу каушауны җиңүчеләрнең берсе булды. Шунысы кызык, радиостудиягә ул үзе белән чәй алып бара иде. Тапшыру башланганчы кайнар чәй эчеп, көч җыеп ала иде...

Татарстанның атказанган артисткасы Нәфига Араповадан без бик иртә, вакытсыз аерылдык. Татар театры тарихында Нәфига Арапова ялкынлы иҗади хезмәте белән онытылмаслык эз калдырды.

## Максим Горький мәктәбе

Татар театры тарихында бөек пролетар язучысы Максим Горький пьесалары хөрмәтле урын алып тора. Алар тормышны тирәнтен аңларга, чын кеше булырга өндиләр, дусны дошманнан аера белергә өйрәтәләр.

Максим Горький иҗаты белән мин беренче тапкыр 1917 елда очраштым. Шул елны Мәскәүдә мөселманнар съезды җыелды һәм әлеге съезд көннәренә турылап «Сәйяр» труппасы башкалага юл тотты. Бер кичне Габдулла Кариев безне Мәскәү художество академия театрына алып барды. Максим Горькийның «Тормыш төбендә» спектакле уйнала икән. Спектакль күңелләребезгә тирән эз салды. Артистларның һәр сүзгә зур мәгънә биреп сөйләүләренә таң калдык. Аларның сәхнәдә үзләрен тормыштагыча гади, иркен тотуы безне бик сокландырды. Яшь кыз Настя ролен спектакльдә А. П. Чеховның хатыны Ольга Книппер-Чехова уйнады. Янымда утырган дусларым — Нәфига Арапова, тәнкыйтьче Габдрахман Кәрам, артист-режиссер Кәрим Тинчурин: «Менә бу Настя роле сиңа бик килешер, Фатыйма. Сиңа уйнарга туры килер. Игътибар ит ул образга»,— диделәр. Мин спектакльне дөньямны онытып

карадым. Артистларның уйнаулары мине бик рухландырды, канатландырды, иҗади этәргеч булды.

Озак та үтмәде, безнең труппа Горькийның «Мещаннар» пьесасын куйды. Спектакль уңышлы булды. 1921 елда «Тормыш төбендә» пьесасын уйнадык. Миңа ул спектакльдә, дусларым алдан ук әйткәнчә, Настя роле тапшырылды. Башта, рольне алгач та, Настя мине артык кызыксындырмады, мавыктырмады. Ләкин һәр репетициядән соң аңар игътибарым көчәя барды. Ул бәхетсез кызның йөрәк кичерешләрен һаман ача бардым, аны күз алдыма бик ачык китерә башладым. Аны яраттым. Настяның саф күңелен, катлаулы язмышын халыкка аңлатасым килде. Нәтиҗәдә ул рольне бик яратып, бөтен күңелемне биреп уйнадым. Тамашачы да Настяны җылы кабул итте.

1936 елда талантлы режиссер Гомәр Исмәгыйлев Максим Горькийның «Дошманнар» пьесасын бик тирән уйлап, ифрат уңышлы куйды. Бу спектакльдә миңа Татьяна роле бирелде. Татьяна образын беренче көннән үк бик бирелеп эшли башладым. Ул миңа һәр яктан бик якын иде. Бердән, Татьяна — артистка. Икенчедән, ул хаклык, турылык яклаучы, якты, гадел, бәхетле тормыш турында хыялланучы. Ул нык рухлы хатын. Ул гади кешеләр белән аралаша, революцион рухлы эшчеләр белән элемтәдә тора. Миңа, гади эшче гаиләсендә туган кешегә, болар барысы да бик якын һәм аңлаешлы. Шуңар күрә дә Татьянаның нәз шул якларын тулырак, көчлерәк ачарга тырыштым. Күпләгән рецензияләр бу образның уңышлы, көчле булуын бердәм билгеләп үттеләр, аны театр тарихындагы матур сәхифәләрнең берсе дип таныдылар.

1946 елда куелган «Варварлар» спектаклендә мин Яков Коломийцев хатыны Софьяны уйнадым. Бу спектакль дә зур уңыш казанды.

1952 ел. Театр Горькийның «Соңгылар» пьесасын сәхнәгә куя. Мин — Надежда Поликарповна Монахова. Бу — бик көчле образ. Монахова ике йөзле, мәкерле җан. Аны иҗат итүгә мин бөтен көчемне, барлык сәхнә осталыгымны, күпьеллык тәҗрибәмне туплады. Күп эшләдем. Үземнең уйнавым белән кешеләрдәге мәкерлелекне, астыртынлыкны фаш итәргә тырыштым, кешеләрне уяу булырга өндәдем.

Максим Горький әсәрләрен татар сәхнәсендә уйнау — катлаулы бурыч. Ул пьесалар гаҗәп тирән эчтәлеклеләр. Алардагы зур фикер байлыгы бик оста тел белән кыска һәм ачык әйтелә. Алар тормышның катлаулы проблемаларын дөрес аңлый белергә ярдәм итәләр. Горький әсәрләрен халыкка җиткерү ифрат күп көч, художество осталыгын таләп итә. Шул җаваплы бурычны үтәүдә катнашуым белән үземне бәхетле саныйм.

**Редакциядән:**

**Быел күренекле артисткабызга 80 яшь тулды. Без, күп санлы журнал укучылар һәм сәнгать сөючеләр исеменнән, Фатыйма Ильскаяны олы юбилее белән кайнар котлыйбыз, озын гомер, ныклы сәламәтлек телибез!**

# САБАН ТУЙЛАРДАН — ДӨНЬЯ СӘХНӘСЕНӘ

## ПРОФЕССИОНАЛЬ БАЛЕТЫБЫЗ ТАРИХЫННАН

Халкыбызның бию сәнгате үзенең тамырлары белән бик борынгы дәверләргә барып тоташа. Болгар хәрабәләренең берсеннән табылган укалы чигеш калдыгында, мәсәлән, биеп торучы ике сурәт төшерелгән. Тарихның бу шаһиты инде шактый таушалган булса да, андагы сурәтләрнең килеш-килбәтен аерып була әле. Егет, тезләрен бергә кушып чүккән дә, кулларын артка куйган. Мондый хәрәкәт татар халык биюләренә хас, һәм аны сәнгать галиме һәм тикшеренүче Ф. Вәлиев XIV—XV гасырларның билгесез остасы шулай «төшереп куйган» дип исәпли.

Сабан туйларын гына искә төшереп үтик. Андагы күңел ачуны, җыр-биюне бернинди дин-шәригать кануннары да тыя алмаган. Кубызы-курае бер-берсе белән ярышкан, ә XIX йөзләрдә аларга инде кулдан ясалган скрипка, тальян кушылган. Алар «әйттергән»гә биеп җибәрмичә ничек түзеп тормак кирәк?! Яшь-җилкенчәкне «тәмуг кисәве булу»лар гына куркытып тора алмаган, яшь йөрәкләр җитез аякларны биергә җилкендергән.

Ә менә татар профессиональ сәхнәсендә халык биюе беренче тапкыр 1916—1917 елгы театр сезонында башкарыла. Ул Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасында була. Хәзер бу биюнең куелышы һәм башкарылу осталыгы турында профессиональ фикер йөртүе кыен эш, әмма шунысы хак: тамашачы алдында, профессиональ сәхнәдә халык биюенең пәйда булуы, һичшиксез, уңай күренеш булган.

XIX гасырның буеннан-буена диярлек һәм XX гасыр башында Казанда рус Опера театры яшәп килгән. Аның сәнгате татар милли мәдәниятына йогынты ясамый калмаган, әлбәттә. Хәлбуки, театрга татар публикасы барып XIX йөзнең икенче яртысында гына, һәр көн тамашачы булдыру белән кызыксынган антрепренер П. Медведев тырышлыгы аркасында йөри башлый. Ул чорда театрда М. Глинка, Ш. Гуно, А. Даргомыжский, бераз соңрак П. Чайковский опералары куела. Татарлар театрга аеруча 1905 ел вакыйгаларыннан соң күп йөри башлыйлар. Инде сәүдәгәр-капиталистлар гына түгел, ә эшче халык, төрле һөнәр ияләре дөнья һәм рус театр культурасы белән таныша башлый. Ул чакта «Кармен», «Князь Игорь», «Руслан» кебек әсәрләрдән популяр көйләрне татар халык музыкантлары башкаруында да ишетергә мөмкин булган.

Шул ук Опера театрында, аз санлы булса да, махсус балет труппасы яшәп килә. Унбиш-егерме кешедән генә торган бу труппа операда ярдәмче рольне генә башкара, ягъни операдагы бию күренешләрендә генә чыгышлар ясый.

Октябрь революциясеннән соң да Казан Опера театры үзенең эшен туктатмый. Ә 1919 елгы янгын вакытында декорацияләр, костюмнар харап булып, театр бинасы да нык зыян күргәч, балет артистлары, нигездә, концертларда гына катнаша башлыйлар. Аларның кайберләре, мәсәлән, Н. Леонтьева белән С. Глинская, Татар дәүләт опера һәм балет театры (1938 елда) яңабаштан оештырылгач, элекке эшләренә кайталар.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң республикада бию сәнгате өр-яңа күтәрелеш кичерә. Халык сәхнә биюе Татар дәүләт академия театрында туган музыкаль драма жанры белән тыгыз бәйләнештә үсә. Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Мирхәйдәр Фәйзи, Фәтхи Бурнаш кебек күренекле драматурглар белән бергә музыкаль-драматик спектакльләр тудыруда атаклы композитор, татар профессиональ музыкасына нигез салучыларның берсе Салих Сәйдәшев күп хезмәт куя. (Салих Сәйдәшев ТДАТта 1922 елдан башлап дирижер һәм музыка бүлеге мөдире булып эшли.)

Музыкаль-драматик спектакльләргә С. Сәйдәшев язган көйләр халык характерын пластикада күрсәтү өчен аеруча кулай килә. Беренче татар балетмейстеры Гай Таһировның Татар Дәүләт академия театры сәхнәсендә күбесенчә Салих Сәйдәшев музыкасына халык биюләрен куюы гына да күп нәрсә турында сөйли. Гай Таһиров ТДАТта актер, биюче һәм балетмейстер булып 1928 елдан эшли башлый.

Казанда чыгып килгән көндәлек матбугатта республиканың егерменче-утызынчы еллар культура тормышы турындагы хәбәрләрне укыганда, еш кына Ковальский, Минский һәм, аеруча, Муко кебек балетмейстерлар исемнәрен очратасың. Аларның беренчесе янган Опера театрының балетмейстеры, ә егерменче елларда Казандагы дәүләт хореография студиясендә характерлы биюләр буенча педагог була. Элеккеге Опера театрының солисты булган Муко да шул ук студиядә классик бию педагогы булып эшли.

Ул вакытта Казанда даими эшләүче хореография коллективлары булмый. Бию куючылар артистларны берничә спектакльгә хезмәт биржасы аркылы яллыйлар. Бу хәл, 1930 елны Г. Таһировка җиде кешелек бию группасы җыярга рөхсәт бирелгәнгә кадәр, Академия театрында да шулай дәвам итә. Беренче биюче артистлар арасында соңра Татарстанның атказанган артистлары исемен алган Бари Әхтәмов белән Анна Гацулина да була.

1933 елда республика хөкүмәте балетмейстер Гай Таһиров белән биюче Бари Әхтәмовны Мәскәүгә СССРның Зур театры каршындагы хореография училищесына укырга җибәрә. Берсе балетмейстер сәнгатенең серләренә тагын да тирәнрәк төшенергә, икенчесе бию осталыгын арттырырга бара.

Шушы ук елны Мәскәү консерваториясе каршында татар опера студиясе ачыла. Анда Мәрьям Рахманкулова, Галия Кайбицкая, Мөнирә Булатова, Асия Измайлова, Усман Әлмиев, Фәхри Насретдинов, Җәүдәт Фәйзи кабул ителә. Консерваториядә шулай ук Фәрит Яруллин, Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, Җәләл Садриҗиһанов кебек музыкантлар да укый. Шушы уку йортларын тәмамлаучылар 1939 елның җәендә үзенең беренче сезонын башлап җибәргән Татар дәүләт опера һәм балет театрының төп иҗат көчләрен тәшкил итәләр.

ТАССР Халык Комиссарлары Советы 1938 елның көзендә Татар дәүләт опера театры оештыру турында карар кабул итә. Бу көнгә инде Мәскәүдән укуын тәмамлап кайткан Гай Таһировка театрның баш балетмейстеры урыны тәкъдим ителә.

Беренче спектакль итеп П. Гертельның «Кирәксез саклык» балеты әзерләнә (хореограф — Ж. Доберваль). Репетицияләр һәм спектакльләр Зур драма театры бинасында бара. Сәхнә балет өчен бик үк җайлы булмаса да, уңайсызлыклар турында беркем дә уйлап тормый, һәркем эшкә бар күңелен һәм көчен сала.

Һәм менә ул көн! 1939 елның 9 сентябрендә татар профессиональ балет сәхнәсендә беренче спектакль куела. Төп рольдә В. Алеева чыгыш ясый. Ул Мәскәү хореография училищесын тәмамлаган, һәм, Казанга чакырып китерелгәнче, берничә ел Минск опера һәм балет театры сәхнәсендә эшләгән. Лиза партиясе бик катлаулы булса да, Алеева аны «җиңеп» чыга. Табигый чибәрлек һәм сөйкемлелек, зур профессиональ мөмкинлекләр, тәҗрибә балеринага образ тудыруда бик булыша, биюенә җиңеллек һәм нәфислек бирә. Ә бу, үз чиратында, спектакльнең гомуми уңышына тәэсир итми калмый.

Колен ролендәге А. Ярославцев да әйбәт партнер була аңа. Ленинград мәктәбе шәкерте булган бу биюче Алеева янында бию техникасы ягыннан кайтышрак булса да, мимика һәм ишарәләрдән оста файдалана белүе белән рольне уңышлы башкарып чыга.

Спектакльдә үткен комик ситуацияләр тудыруда Марцелина — Г. Таһиров һәм Никез — И. Карый күп көч куялар. Беренче образ тамашачы каршында иске җил тегермәне канатларыдай кулларын бутый-бутый бер җәнҗалчы булып килеп чыкса, икенчесе исә шулкадәр оялчан, хәтта гомере буе Лиза белән кавышырга дип хыялланып йөрсә дә, мәгъшукасы янына бармас өчен аякларын терәп баса, теше-тырнагы белән бөтен нәрсәгә тотынып калырга әзер. Бай, ләкин зәвыксыз костюм аның җилкәсендә карачкыга кидерелгән кебек күренә.

Беравыктан балет труппасын 90 кешегә җиткерергә дигән карар чыга. Шул кадәр актерны каян алырга дип баш ватып торганда, бер очраклылык ярдәм итә: 1939—40 елларның җәй көннәрендә Мәскәүдә Үзәк культура һәм ял паркының хореография театры зур популярлык казана. Илледән артык кешене берләштергән, югары профессиональ осталыкка ия бу коллективта заманның атаклы балеринасы Е. В. Гельцер классик бию дәресләре алып бара. 1940 елның көзендә театр ниндидер сәбәпләр аркасында эшсез кала. Нәкъ шушы вакытта Мәскәүгә килгән Г. Таһиров труппага

Казанда эшләргә тәкъдим итә. 1941 елның гыйнварында труппа Казанга килә һәм шунда ук Мәскәүдә булачак татар әдәбияты һәм сәнгате көннәренә әзерләнә башлый. Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетын куярга карар кылына. Әдәби нигезен Әхмәт Фәйзи эшләргә алына, балет үзенчәлекләрен нечкәләп тоярга аңа Леонид Якобсон ярдәм итә.

Декадага әзерләнү һәм үткәрү чорына Мәскәүдән һәм Ленинградтан хореография буенча күренекле белгечләр чакырыла. Алардан П. Гусев балетның художество җитәкчесе, Л. Якобсон «Шүрәле»не куючы, ә А. Лопухов актерлар белән характерлы биюләр өстендә эшләүче итеп беркетелә.

Чакырылып китерелгән бөтен кеше ул чакта «Совет» кунакханәсендә яши. Фәрит Яруллинга да шунда аерым номер алып, пианино куялар. Монда ул үзенең атаклы балетын яза. Аның бүлмәсенә бик еш Якобсон керә, киңәшләрен бирә, берничә номер әзер булу белән мехчылар клубына чаба. Репетицияләр клубның спорт залында бара. Балет менә шулай туа һәм куела тора.

Шүрәле партиясен гаять дәрәҗәдә эшчән, үз-үзенә таләпчән биюче Бари Әхтәмов әзерли. Ул балет залыннан тәүлекләр буе чыкмыйча, бию детальләренең тәгәллегенә ирешергә омтыла. Соңыннан Якобсон андый уңышлы Шүрәле образын беркайда да — Мәскәүдә дә, Ленинградта да очратканым булмады дип искә ала.

Былтыр партиясен Ленинградтан чакыртылган Габдрахман Кумысников, ә Сөембикәне аның тормыш иптәше Наимә Балтачеева башкарырга тиеш була.

1941 елның июненда балет труппасы «Шүрәле»не оркестр белән репетицияләүгә әзерләнә. Ләкин Бөек Ватан сугышы башланып китү бөтен хыялларны юкка чыгара. Театр тормышы сүнеп кала. Аның күп артистлары һәм эшлеклеләре фронтка китә. Театрның әдәби бүлек мөдире Муса Җәлилнең исеме соңыннан татар халкының батырлык символы, совет кешесенең җиңелмәс рухы билгесе булып бөтен дөньяга яңгырар...

1943 елның көзендә Ватаныбыз өчен каты сугышларда «Шүрәле» балетының авторы лейтенант Фәрит Яруллин һәлак булыр... Театрның күп кешеләре сугыштан кире әйләнеп кайтмас... Сугыш халык җилкәсенә күтәрә алмастай йөк булып ята. Пушкалар сүз ала!.. Әмма музалар да авыз йомып тора алмыйлар. Хәрби частьлар өчен фронт концерт бригадалары оештырыла, сәнгать осталары алгы сызыкта көрәшүче сугышчылар белән очрашуларга баралар. Зур театраль коллективлар тормышы да озак тынып тормый.

1942 елның язында татар опера театры да стационарда үзенең эшен яңадан башлап җибәрә. Бу юлы инде — Г. Камал исемендәге театр бинасында.

Дөрес, «Шүрәле»не торгызу турында авыз ачарга да мөмкин булмый: балет труппасында бик аз кеше калган һәм ул опера яки музыкаль драмалардагы биюле күренешләрдә генә катнаша ала.

Бары 1944 елда гына балет труппасы үзенең яңа эшен күрсәтә ала. Ул А. Ключарев музыкасына Г. Таһиров либреттосы буенча куелган «Яшьләр ялда» дигән бер күренешле балет сюитасы була. Премьера, театрның бишьеллык юбилеена багышлап, 1944 елның 22 июненә билгеләнә. Спектакльнең хореографик нигезенә халык биюләре салына.

Аз гына элегрәк, 1943 елның язында, Казанга тормыш иптәше биюче Марина Михно белән РСФСРның атказанган артисты Леонид Алексеевич Жуков килә. Заманында атаклы балерина Екатерина Гельцерның партнеры буларак, ул хореографиядә зур тәҗрибә һәм сәнгать культурасы туплаган оста була. Жуков шунда ук балетмейстерлык эшенә чума: классик бию дәресләре бирә, репетицияләр үткәрә.

Ниһаять, 1944 ел сезоны башыннан Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетына әзерлек эшләренә керешәләр. Аның премьерасы 1945 елның 12 мартында була. Балетның беренче һәм өченче пәрдәләрен Л. Жуков, икенчесен Г. Таһиров куя.

Труппа ул вакытта аз санлы һәм профессиональ яктан бик көчле булмаганлыктан, Л. Жуков артык «мөгез чыгарып» маташмый, гади куелышка бара, әмма биюләрнең тәгәллегенә, кордебалетның ансамбльлегенә зур таләпләр куя. «Авыл» пәрдәсен куюда Г. Таһиров халык биюләреннән, жанрлы һәм юмористик күренешләрдән күп файдалана.

[1]Шул көннәр матбугатында Бари Әхтәмовның Былтыр партиясен, Марина Михно һәм Анна Гацулинаның Сөембикәне, В. Романюкның Шүрәлене зур сәнгать осталыгы белән башкарганлыклары билгеләп үтелә. (Мәсәлән, В. Юрьев мәкаләсендә: «Красная Татария», 1945 ел, 31 март.)

Аерым-аерым алганда, һәр пәрдә үзенчә кызыклы булса да, спектакль итеп бергә укмаштыргач, бердәм стиль булмаганлыгы күзгә нык ташлана, милли һәм классик биюләрнең уңышлы синтезын эзләү һәм табу зарурлыгы ачыклана.

«Шүрәле»дән соң театр 1945 елның 23 августында А. Аданның «Жизель» балеты премьерасын күрсәтә. Балетмейстер Л. Жуков труппаның иҗади көчен аңлаган хәлдә (солистлар рольләрен башкарып чыга алсалар да, кордебалетның хәле шәптән булмый), хореографияне гадиләштерә. Шулай да, тулаем алганда, Л. Жуков классик вариантка йөз тота. Татар балетын чын-чынлап профессиональ юлга бастыру, актерларның башкару осталыгын күтәрү максатын күздә тотып, ул классик номерлардан концерт программасы әзерли һәм инде П. И. Чайковскийның «Аккош күле» балеты турында уйлана башлый.

«Аккош күле»нең премьерасы бары ике елдан соң гына күрсәтелә. Профессиональ күзлектән караганда, труппа бу вакытта шактый югары баскычка күтәрелгән була инде. «Жизель» премьерасыннан соң узган вакыт эчендә кордебалет нык үсә, артисткалар инде җитез һәм чиста бииләр.

Одетта-Одиллия партиясен Нинель Юлтыева башкара. (Хәзер ул — РСФСРның халык артисткасы, доцент, Казан дәүләт культура институтының хореография кафедрасы мөдире.) Н. Юлтыеваның театрга килүе труппаны бик нык көчәйтеп җибәрә. Табигать яшь балеринадан берсен дә кызганмаган: тышкы чибәрлек һәм сыгылмалылык, осталык һәм гаҗәеп эшчәнлек — аңарда бөтенесе дә була.

Юлтыеваның партнеры булып Свердловскида балет студиясен тәмамлаган яшь биюче Игорь Круглов чыгыш ясый. Артык зур бию сәләтенә ия булмаса да, ул үзенең Зигфридына ниндидер романтик серлелек бирә ала.

Спектакльдә шамакай партиясен Рөстәм Сафин бик уңышлы башкара. Театр каршындагы хореография студиясен тәмамлаган бу егет характерлы биюләрне ярату башкаруы белән аерылып тора. Ул комбинацияләрне биек сикерештә башкара ала һәм партерда соклангыч бөтерелә.

Җыеп әйткәндә, 1947 елгы «Аккош күле» татар балетына яңа профессиональ дәрәҗәгә ирешергә ярдәм иткән спектакльләрнең берсе булды. Б. Асафьевның аннан бер ел элек кенә куелган «Бакчасарай фонтаны» да шундый ук әһәмияткә ия иде. Бу спектакльдә актерлар уен белән мавыгырга, геройларның психологиясенә керергә өйрәнделәр һәм кайбер уңышларга да ирештеләр. Ә уңыш, хәтта кечкенә генә булганда да, канатландырмый калмый.

Театр үзенең алга таба үсешен Р. Глиэрның «Кызыл мәк» дигән балетын куеп дәвам итте. Аны сәхнәләштерү турында инде 1947 елда ук сүз булса да, бу эшкә балет студиясен тәмамлаучылар труппага килеп кушылгач кына керешергә мөмкинлек туа.

Хәлбуки, спектакльдә әйбәт кенә урыннар булса да, тулаем ул әллә ни зур уңыш казана алмый. Моны, күрәсең, күмәк күренешләрнең йомшак яңгыравы белән аңлатырга кирәктер. Ә бу, ахыр чиктә, спектакльнең төп идеясен — халыкның революцион бердәмлеге идеясен күләгәдә калдыра.

«Кызыл мәк» гыйбрәтле сабак була. Шул хакыйкать ачык аңлашыла: төп партияләрне башкаручылар никадәр генә көчле булмасын, үз рольләрен алар ничек кенә оста башкармасыннар, хореографик постановканы заманча куйыйм дисәң, кордебалетка да игътибарны кызганма.

Бу проблеманы театр 1953 елда А. Крейнның «Лауренсия» балетын сәхнәләштереп хәл итә (дирижер Хәсби Фазлуллин, рәссам Петр Сперанский). Спектакльне куйган Константин Боярский «Лауренсия»нең Вахтанг Чабукиани редакциясендә Ленинградның С. М. Киров исемендәге опера һәм балет театрында сәхнәләштерелгән вариантына таяна.

Лауренсия ролендә Нинель Юлтыеваның чыгышы чын-чыннан вакыйгага әверелә. Моңарчы моңсу-хыялый принцессалар ролен башкарып килгән балеринаның яңа — героик рольдә тамашачыны шаккатыра алуына күпләр башта ышанып бетми. Баш

күтәргән халыкны әйдәүче Лауренсия — Юлтыева позаларының төгәллеге, холкының ныклыгы һәм максатчанлыгы һәм бигрәк тә сикерешләре белән игътибарны җәлеп итә. Нәкъ менә аның сикерешләрендә Лауренсиянең тормышка мәхәббәте һәм зур ихтыяр көче күренә.

«Лауренсия» тамашачының зур игътибарына лаек була һәм театр яңа бинага күчкәнче репертуарда ныклы урын алып тора. Татар балеты бу спектакле белән героик эчтәлек үзләштерү юлында һәм, димәк, үзенең табигый үсешендә дә яңа адым ясый.

1952 елның 31 декабрендә театр Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты премьерасын күрсәтә. Бу юлы спектакльне ГИТИСның дипломант-балетмейстеры Я. Брунак куя.

Постановкада, әйтик, кызларның кошлар булып биюе кебек уңышлы күренешләр белән бергә, балетмейстерга бик үк бирешмәгән кисәкләр дә була. Дүртенче пәрдәдә көрәшнең кискенлеге һәм киеренкелеге ачык итеп күрсәтелә алмый, авыл күренешләрендә сихри гүзәллек һәм күтәренкелек биреп җиткерелми. Кайбер кимчелекләре булуга да карамастан, балет театр репертуарында өч ел тора. Монда труппаның иҗат энтузиазмы һәм солистларның профессиональ әзерлеге зур роль уйный.

Шүрәле партиясен Рөстәм Садыйков башкара. Бу биюче хореография теленең бөтен нечкәлекләрен яхшы белә. Былтыр — Әдһәм Нарыйков уенында да героик-эпик башлангыч калку күренә. Ә инде спектакльдә Бибкәй (Сөембикә) партиясен башкарган Нинель Юлтыева аеруча йөзек кашы булып балкый. Лирик талант һәм профессиональ осталык Н. Юлтыевага тамашачы алдында нәфис, гүзәл образ тудырырга ярдәм итә.

Шулай итеп, 1952—53 елларда Татар опера һәм балет театры катлаулы гына хореографик бурычларны хәл итәрлек көч туплый. Әмма ныклап аякка басу өчен тагын берничә ел кирәк була әле. Хикмәт югары әзерлекле балетмейстер һәм оештыручы юклыкта гына түгел. Балетта заман һәм иҗат таләпләренә җавап бирерлек репетиция роль уйный.

Һәм менә, ниһаять, 1956 елның 28 сентябрендә Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсы белән яңа опера һәм балет театры бинасында яңа сезон ачыла. Ә бер айдан П. И. Чайковскийның «Аккош күле» балетының премьерасы күрсәтелә. Н. Юлтыева аның Станиславский һәм Немирович-Данченко исемендәге Мәскәү музыкаль театрында В. Бурмейстер редакциясендә барган вариантын куя.

Бу вакытка балет труппасы Мәскәү, Ленинград һәм Пермь хореография училищеларын тәмамлаган күп кенә яшь артистлар белән тулылана. Алар арасында К. Динисов, Р. Шакулов, М. Домарев, Л. Мойжес, К. Җаббарова һ. б. бар иде. Соңрак алар арасыннан Татарстанның халык артисткасы Галина Калашникова, Татарстанның атказанган артисткасы Роза Новицкая, РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Ревдар Садыйков һ. б. лар үсеп чыкты.

Балетка Х. Фазлуллин дирижерлык итә. Ул балетның моңарчы төшереп калдырылган музыкаль кисәкләрен яңадан торгыза. Мәсәлән, дүртенче акттагы аккошларның кайгылы маршын яңадан кертү сәхнәдә иң драматик эпизодларны тудырырга ярдәм итә: сихерләнеп мәңгелек коллыкка дучар ителгән кызларның сагышы онытылмаслык тәэсир калдыра.

Одетта-Одиллияне В. Потемкина белән Н. Юлтыева алмашып бииләр. Аларның беренчесе Одетта булуга караганда Одиллияне алгарак чыгара. Табигый дәрт Одеттаның лирик башлангычын басып калдыра. Юлтыева исә ике рольне дә менә дигән итеп башкара. Н. Юлтыева Одиллиясе дәртле дә, күз буярлык мәкерле дә. Зигфрид ролендә Салих Хәйруллин — кайнар һәм тиз кабынучан. Бию техникасында аңа тиңнәр булмый.

1956—57 елларда театрның балет труппасы Мәскәүдә булачак Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына әзерләнә башлый. Шул уңайдан Ф. Яруллинның «Шүрәле»сен яңадан куярга булалар. Театрның баш балетмейстеры Людмила Бордзиловская һәм Шәймөхәммәт Байдәүләтов яшь хореографлар өчен авыр булган бу эшне җиңел чыгалар — классик хореографиягә нигезләнгән милли балет тудыруга ирешәләр.

1957 елның 27 мартындагы премьера Шүрәле оясындагы шашыну дәрәҗәсендәге күренеш белән ачылып китә. Кечкенә шүрәле малайлары өермәдәй бөтерелә, алар уртасында — Шүрәле үзе. Монда Салих Хәйруллинның пластикасына теләсә кайсы балерина кызыга алыр иде.

Спектакльнең икенче пәрдәсен авторлар мөмкин кадәр халык иҗатына якынайтырга тырышалар. Балетмейстерлар спектакльгә шигъри әкият дип карыйлар, шуңа күрә Былтыр ролен Рөстәм Садыйков та, Әдһәм Нарыйков та лирик-романтик рухта башкаралар. Сөембикәне шулай ук ике балерина — К. Янбулатова һәм Н. Юлтыева башкара. Н. Юлтыева инде тәҗрибә җыеп өлгергән, шуңа күрә аның техникасы югары, биюе төгәл һәм образлы.

Өченче пәрдәдә финал кызык эшләнә. Ярсуыннан нишләргә белмәгән Шүрәле урманга ут төртә һәм шул ялкында үз якыннары белән бергә янып көлгә оча. Элек минорда яңгыраган финал маршы бу юлы мажор интонацияләрдә яңгырый. Былтыр мәңгелек яшьлек һәм бәхет символы итеп Сөембикәне кулына күтәрә. Ә аның артыннан халык килә.

«Шүрәле» балеты Мәскәүдә 1957 елның 24 маеннан 4 июненә кадәр барган татар әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә күрсәтелә. Матбугат һәм тамашачы театрның яңа эшенә югары бәя бирә.

1950 елдан 1954 елга кадәр Ф. Яруллин балеты Ленинград, Одесса, Львов, Киев, Рига, Саратов, Таллин опера һәм балет театрларында куела. 1955 елны аны СССРның Зур театры куя. Ә илленче елларның икенче яртысыннан башлап «Шүрәле» балеты Болгария, Румыния, Албания һ. б. илләрнең балет сәхнәләренә менә.

Асыл милли үзенчәлекләрне барлык милләтләр һәм халыкларның уртак хәзинәсенә әверелдергән ил генә интернациональ ил була ала. Бу уңайдан 1917 елга кадәр бары өч кенә классик балет — француз, итальян, рус балетлары гына булганны искә төшереп үтү дә урынсыз булмас. Ә хәзер безнең илдә 18 милли классик балет мәктәбе бар. Арада татар милли балеты да лаеклы урын билэп тора.

**ВЛАДИМИР ГОРШКОВ.**

## Укучының күңел дәфтәренә

**Бенгаль мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Бамбук саргая чәчәк атса, кеше хур була — хата эшләсә.*
*Ярага сөртергә дә май юк, ә аңа пирог кыздыр.*
*Туган туганның хәленә керсен: уң кулың сузгач, сулын да бирсен.*
*Җиргә чәчкән бер бөртектән ике үренте шытмый.*
*Тимерче каракны күрми, ә ачкыч ясап бирә.*
*Җәннәттә көл булганчы, җәһәннәмдә гөл бул.*
*Ана сөтен имеп туймаган, ата җилкәсен кимерә.*
*Чыбыркы турында уйла — ат сатып алгач кына.*
*Эштән качып эшкә ашыга.*
*Су үзе килмәсә дә сусыны килер.*
*Алтын куначага кунган карга кебек кылана.*
*Биек агачны давыл ныграк чайкалдыра.*
*Балыкны да кыздыралар балык маена салып.*
*Энә эзләп учак яндыра.*

# КАРТАЙМАС ИҖАТ

Габдулла ага Шамуковны без хаклы рәвештә Һади Такташ, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Гыйлем Камай, Нәкый Исәнбәт, Сибгат Хәким чордашы дибез. Алар белән бер заманда яшәгәнгә генә түгел, үзенең хезмәте, иҗаты, гомер юлы белән дә якын булганга.

Габдулла Шамуков — артист кеше. Бу аның профессиясе генә түгел. Ул — сәхнә шагыйре, иҗат ялкыны белән янып яшәүче, тынгысыз шәхес. Ул табигате, дөньяны тоюы, кабул итүе белән шагыйрь кеше...

Габдулла Шамуковның иҗаты утызынчы елларда башкорт сәхнәсендә башланып китә. Бу еллар — илебездә актив социалистик төзелеш, күпмилләтле совет сәнгатенең үзен раслау, киң юлга чыгу дәвере. Ул елларда башкорт театрының яшәү рәвешен билгеләгән, аның данын, шөһрәтен булдырган артистлар — Арслан Мөбәрәков, Вәли Галимов, Зәйтүнә Бикбулатова, Газим Тукаев, Рим Сыртланов, Булат Имашевлар сәхнәгә аяк атлый. Яшь артистларның иҗатлары кабынып, ялкынланып, үсеп китә. Аларга Г. Шамуковның таланты да килеп кушыла. Ул үзен бик тиз арада лирик хисләргә бай һәм тирән фикерләү сәләтенә ия артист итеп таныта.

Утызынчы еллар өчен аеруча хас булган ялкынлы тормыш ритмы Г. Шамуков тарафыннан гәүдәләндерелгән образларда да ачык чагыла. Алар — Шолоховның «Күтәрелгән чирәм»ендәге Найденов, Таһировның «Соңгылар»ындагы Тавиль, Бурнашның «Яшь йөрәкләр»ендәге Сәйфулла, Мифтаховның «Зимагурлар»ындагы Шаһгали, Горькийның «Егор Булычев һәм башкалар»ындагы Алексей Достигаев, «Тормыш төбендә»ге Барон, Шиллерның «Юлбасарлар»ындагы Герман, Гогольнең «Өйләнү»ендәге Подколесин, Островскийның «Корыч ничек чыныкты»сындагы Сережа, Гафуриның «Кара йөзләр»ендәге Сәгыйть, Ивановның «Бронепоезд 14-69»ындагы Вася Окорок һәм башка бик күп образлар. Бу исемлек үзе генә дә актерның никадәр капма-каршы характердагы рольләр өстендә эшләве турында сөйли. Алар кем генә булмасын — иске гадәтләрдән арынып кына килүче һәм кешелек горурлыгының ямен-тәмен әле тоя гына башлаган авыл малаемы, яки яңа тормышның беренче кирпечләрен салырга өлгергән эшче егетме — барысы өчен дә уртак бер сыйфат ярылып ята — аларның күбесе җирдәге ямьсызлыкны, явызлыкны күрә алмый, ирекле тормыш төзергә омтыла, кыю рәвештә көрәшчеләр сафына килеп баса.

Образның эчке халәтен нечкә тою һәм аларның характер асылын үтемле итеп сурәтли алу Г. Шамуковны тиз арада сәләтле артистлар рәтенә күтәрә. Ә башкорт театры Әхмәт Фәйзинең «Тукай» әсәрен сәхнәгә куярга ниятләгәч, аңа, һич икеләнмичә, шагыйрь ролен ышанып тапшыралар. Меңнәрнең йөрәгендә моң һәм җыр булып яңгыраган Тукай образы Шамуков өчен дә якын һәм кадерле була. Чөнки шагыйрь образы аның йөрәгенә әнисенең мөнәҗәт көйләренә көйләгән бишек җыры аша ук сеңгән. Яшүсмер чакта, бабасының китаплар белән тулы кәрҗиненә хуҗа булып алгач, Тукай шигырьләрен ул үзе укып, ятлап әсәрләнгән һәм балигъ булгач та, шагыйрьнең иҗатына соклану, аны ярату хисе күңелендә арта барган.

Тукайны шулай ихлас якын итмәсә, шулай чын күңелдән аңламаса, мөгаен, Габдулла Шамуков шагыйрь образын бөтен катлаулылыгы һәм тирәнлеге белән сурәтли дә алмас иде. Сәхнәдә ул үзенең кыюлыгы һәм гадилеге, сафлыгы һәм илһамлы табигате белән тамашачының мәхәббәтен казанды. Башкорт шагыйре Кадыйр Даян ул елларда Шамуковның артистлык талантын табигый чишмәләргә тиңләде. Шамуков тарафыннан гәүдәләндерелгән Тукай образында бөек шәхеснең фаҗигале язмышы һәм киләчәкне раслаучы оптимизмы бергә кушылган иде.

Тукай образы яшь артистка үзенең алдагы иҗатында тагын да катлаулырак һәм зуррак темага — Ленин темасына якынлашу өчен мөһим бер адым булды.

Драматург Николай Погодинның «Мылтыклы кеше» пьесасы Башкорт Дәүләт академия театрында 1941 нче елны, ә Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театрында 1946 нчы елда куелды. Икесендә дә Владимир Ильич Ленин образын Г. Шамуков башкарды. Бу еллар артист өчен шатлыклы һәм киеренке иҗади эзләнү еллары булдылар. Аңа Ленинның эчке дөньясын үзләштерергә, башкарыла-

чак образның психологиясен, хисләр һәм фикерләр табигатен аңларга, юлбашчының тормыш ритмы белән сәхнәдә яши белергә кирәк иде. Куелган бурычның олы масштабы актерның хыялын һәм фикерләрен үстереп, үрләтеп җибәрде.

Актер Ленин шәхесенең бөтен катлаулылыгын — даһиның мәхәббәтлеген һәм кешелек гадилеген, ирләрчә ныклыгын һәм тыйнаклыгын, кырыслыгын һәм миһербанлылыгын, куелган максатка ирешүдә тайпылышсызлыгын, үзе сайлаган юлның дөреслегенә тирән инануын, рухи сизгерлеген һәм сәламәт юморын ача алды. Менә шушы күпьяклы чалымнар Ильич образының төгәл бөтенлелеген тәшкил иттеләр. Шамуков Ленин фикеренең һәм фантазиясенең талпынышын тоярга, аны дулкынландырган мәсьәләләр даирәсен аңларга тырышты һәм, шул сәбәпле, тамашачы алдында халык юлбашчысы образын оста гәүдәләндерә алды.

Ленин образы Г. Шамуковның күңеленә тирән үтеп кергән образларның берсе булды. Ул гомере буена — Ленинны уйнаган чорда да, аннан соң да — бертуктаусыз юлбашчы образы турында уйланып, илһамланып яшәде. Шагыйрь Сибгат Хәким сүзләре белән әйтсәк, Шамуковның да «күңеле Ленинга тора-тора кайтты», «ул аннан ераклашмады». Артистның Ленин роле өстендә ничек эшләве, аны ничек иҗат итүе, үзен дулкынландырган сорауларга ничек итеп җавап эзләве турында вакытлы матбугат битләрендә әледән-әле чыгыш ясавы да шул хакта сөйли. Шулай булмый мөмкин дә түгел, Ленин образын тудыру, сәхнәдә Ленин булып яшәү бәхете һәр артистка да эләкми.

1946 елны Г. Шамуков Г. Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театрына чакырыла һәм, әйткәнебезчә, аңа Ленин образын иҗат итү тапшырыла. Бу вакытта инде ул үзен тапкан, иҗади яктан ныгыган сәхнә художнигы иде. Башкорт театры артистларына хас романтик күтәренкелек, киңлек, хисләр биеклегенә омтылу Шамуковның да уен алымын характерлый торган төп сыйфатлар иде. Шул ук вакытта ул үз иҗатында образларның социаль йөзен ачык итеп сурәтләргә омтылды, тирән анализлар ясарга тырышты.



*Габдулла Шамуков (уртада) — Хуҗа Насретдин ролендә (Н. Исәнбәт. «Хуҗа Насретдин» комедиясе).*

Кырык еллык тарихы булган татар театрына күчү Г. Шамуковның талантын тагын да үстерү, тагын да камилләштерү өчен бик уңайлы җирлек булды. Бер туфрактан икенче туфракка күчүне гадәттә күпләр авыр кичерә, ләкин Шамуков мондый авырлыкны сизмәде, диярлек. Татар һәм башкорт театрындагы иҗат юнәлешләренең максатларының уртаклыгы нәтиҗәсе иде бу.

Татар театрында бу чорда режиссер Ширияздан Сарымсаков һәм Габдулла Юсупов белән берлектә өлкән буын артистларыбыз Зәйни Солтанов, Гөлсем Болгарская, Фатыйма Ильская, Касыйм Шамиль, Хөсәен Уразиков, Галия Булатова, Хәлил Әбҗәлилов, Хәким Сәлимҗановлар иҗат итәләр иде. Аларның һәркайсының иҗаты белән турыдан-туры бәйләнешкә керү, сәхнәдәш булу Шамуковка үзенең иҗат палитрасын яңа төсмерләр табарга да ярдәм итте. Театр артистларына хас тормышчанлык, психологик нечкәлек, ихлас күңеллек һәм искиткеч сизгерлек Шамуковның алдагы иҗатында нык чагылыш тапты, аның табигый сыйфатларына әверелде. Артистның театрда 33 ел буенча иҗат иткән образлар галереясына күз салсак, моның шулай икәнлегенә төшенү авыр булмас.

Ул иҗат иткән образларга нинди сыйфатлар хас соң? Иң беренче чиратта — эчке бер активлык. Ул бервакытта да үзе иҗат иткән образга, аның эчке дөньясына битараф кала алмый. Аның һәр образга карата аерым-ачык мөнәсәбәте бар. Сурәтли торган образы тискәреме, уңаймы, аның белән фикердәшме, түгелме,— Г. Шамуков образның характер асылын, социаль мәгънәсен анык, конкрет төстә чагылдыра. Г. Шамуков, гомумән, жанр сафлыгын ярата. Үзенең Нәкый Исәнбәт иҗатына багышланган хезмәтендә дә ул жанр ачыклыгы турында болай дип яза: «драматургның һәрбер әсәре дип әйтерлек билгеле бер жанрга буйсына: я ул саф комедия, я саф драма, яки саф трагедия була. Аның әсәрләре арасында соңгы елларда гражданлык алып киткән, тулысынча бер жанрга да керә алмый торган пьесалар юк дәрәҗәсендә. Андый әсәрләр уңыш казана алмыйлар. Жанр ягыннан ачык булмагач, аларны гәүдәләндерүе дә читен. Тиз арада сәхнәдән төшә торган тонык спектакльләр, гадәттә, әнә шундый бер жанрга да кермәгән пьесаларга нигезләнгән була».

Г. Шамуков иҗат иткән образларга күз төшерсәк, жанр ачыклыгына ирешү нәтиҗәсендә аның нинди уңышлар яулавын күреп була. Мәсәлән, 1958 елны «Советская культура» газетасында татар театры артистлары һәм Габдулла Шамуковның уены хакында болай дип язылды:

«Театрның актерлар составы гаҗәеп әйбәт. Спектакльләрдә теге яки бу актерны сез яңадан очратырсыз һәм аның төрле кыяфәткә керә, үзгәрә алуына сокланмыйча булдыра алмыйсыз. Артистларның сәхнәдә үз-үзләрен тотышларына, кыланышларына гаҗәеп җиңеллек, иркенлек хас. Алар иҗатында күзгә бәрелеп торган тагын бер сыйфат — ул да булса тәэсирлелек, онытылып, бар көченңне биреп иҗат итү... Менә сез спектакль вакытында театрның күренекле артисты Габдулла Шамуков белән очрашасыз. Ул үзенең рухы, социаль эчтәлеге, темпераменты ягыннан капма-каршы характердагы өч образ иҗат иткән һәм, күрүегезчә, аның тарафыннан табылган тышкы буяулар образның эчке хәрәкәтен ничек дөрес чагылдыра».

Әлеге мәкаләдә өч образ телгә алына — Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр» сатирик комедиясендәге Нуретдин бай, Нәкый Исәнбәтнең «Муса Җәлил» трагедиясендәге язучы Илстан һәм «Зифа» комедиясендәге Балтаев образлары. Өчесе өч төрле жанрда хәл ителгән образлар. Артист аларның һәркайсына билгеле бер жанр таләбе аша карап, эчке халәтләрен, социаль-фәлсәфи асылларын аермачык чагылдыра. Г. Шамуков иҗатында, гомумән, тискәре образлар галереясы гаять бай. Монда кем генә юк! Хәтта Шамуковның комиклык талантын аның интеллектуаль сәләтенең аерым бер мавыктыргыч үзенчәлеге итеп тә карарга мөмкин. Алар үзләренең фаш итү көче һәм сатирик юнәлешләре белән гаять дәрәҗәдә үткерләр һәм анықлар. Аларга сәнгатьчә нәфислек, художество бөтенлеге, тәгәллек хас. «Ревизор»да Хлестаков һәм Добчинский, «Өйләнү»дә Подколесин, «Котырган акчалар»да Телятев, «Ташкыннар»да писарь Басарый, «Җилкәнсезләр»дә Нуретдин, «Җырланмаган җыр»да Арыкбаев, «Хуҗа Насретдин»да Ахун, «Зифа»да Балтаев, «Һиҗрәт»тә шагыйрь, «Ата хакы — тәңре хакы»нда Гордей Павлович, «Кол»да Ксанф, «Колгали»дә Актай, «Намус хөкеме»ндә Рөстәм Ахметович һәм башка бик күп рольләрне менә шундый образлар рәтенә кертеп була. Бу рольләрнең һәркайсы, зур яки кечкенә булуларына карамастан, Г. Шамуков башкаруында спектакльнең үзәк образлары рәтенә күтәрелә алдылар.

Ә инде шул ук образларга вакыт күзлеге аша карасак, аларның ни дәрәҗәдә һәм кайсы якка үзгәргәнлекләре дә шактый ачык сизелә. Тормыш белән бергә тамашачының зәвыгы, аның теге яки бу образны кабул итүе, үзләштерүе дә үзгәрә

Димәк, артистның уены, образны сурәтләү чаралары да үзгәрә. Шул җәһәттән, мисал өчен, «Зифа»дагы Балтаев образын соңгы елларда иҗат ителгән «Намус хөкеме» спектаклендәге Рөстәм Ахметович образы белән чагыштырып карыйк. Бу ике рольне иҗат итү арасында егерме ел вакыт узган. Драматургик материал үзгә булуга карамастан, аларны бер үк яссылыкта карарга мөмкинлек бар: алар икесе дә кире типлар, икесенең дә кешелек сыйфатлары хезмәттә ачыла, икесе дә үз карьералары өчен калтырап торган «әшем кешеләре». Ләкин артист тудырган бу ике образ арасында хәзер шактый зур аерма да бар. Балтаев образы гаять ачык буяулар белән тасвирланган. Ул — бөтенләе белән, гөрләп торган комедия образы. Рөстәм Ахметович исә бүгенге көн сәхнәсе таләпләре буенчарак иҗат ителгән, катлаулырак һәм нәфисрәк итеп сурәтләнгән. Жанры буенча да ул бер комедия жанрына гына сыя алмый. Бу образ күбрәк трагикомедия күзлеге аша карала һәм аның аша кеше характерына психологик нечкәлек белән анализ ясала. Герой гротеск чигенә китереп җиткерелә, безнең алда гаять куркыныч һәм чиркангыч, астыртын эш итүче кеше фигурасы калкып чыга. Г. Шамуков бу кешенең рухи гариплеген заманча тасвирлау чаралары аша оста итеп сурәтли. Артист Рөстәм Ахметовичның намус югалтуын рольнең төп темасы итеп ала һәм әнә шул теманы төрле яклап актырта.

Әйе, без Шамуковның комик осталыгына сокланабыз. Ләкин әле башка төрле Шамуков та бар бит! Моннан берничә ел элек аңа Г. Боровикның «Канлы күләгәләр» спектаклендәге клоун Бом роле өстендә эшләргә туры килде. Клоун Бом гомере буена кеше көлдергән, тормышының мәгънәсе, асылы турында ул уйлап та карамаган. Ә менә властька Пиночет хунтасы килү белән, аның бердәнбер кызын, асфальтка кояш рәсеме төшергән өчен генә, фашистлар төрмәгә утыртканнар. Үз кызын яраткан һәр ата кебек, ул да нинди генә юллар белән булса да кызын коткарырга тели, ләкин өлгерә алмый — аның кызын газаплап үтерәләр.

Г. Шамуков клоун кыяфәтендә сәхнәгә килеп чыгу белән тамаша залында күңелле җанлану сизелә, артист хәзер кызык күрсәтәчәк, янәсе. Тик безнең күз алдыбызда клоун кәмитләре түгел, ә бәлки ата кешенең йөрәк әрнүләре, күңел җәрәхәте ачыла. Артистның уенына ияреп, без дә аның рухи халәте белән яши башлыйбыз, аның кайгысы, күз яшьләрен уртаклашабыз. Ә инде пәрдә ябылганнан соң, бу аерым бер кешенең генә фаҗигасе түгел, ә бәлки фашистлар түрәлек иткән илдә яшәүче меңләгән ата-аналарның фаҗигасе икәнлеген аңлыйбыз. Бүгенге көндә җирдә гаделсезлек, хаксызлык, фашизм хөкем сөргәндә берәүнең дә битараф яшәргә хакы юклыгына төшенәбез.

...Җиденче дистәнең аргы ягына чыккан артист Габдулла ага Шамуков үзенең ялкынлы иҗаты, бетмәс-төкәнмәс егәрлеге белән безне бүген дә сокландыра. Аның турында сөйләгәндә күз алдына тарих битләре чагылып китә сыман: Зәйни ага Солтановның баһадирдай сыны һәм халыкчан характеры, Хәлил ага Әбҗәлиловның зирәк һәм юмарт елмаюы, Хөсәен ага Уразиковның тыйнак, сабыр холкы һәм башка бик күпләрнең иҗат характерлары чалымлана. Әмма СССРның халык артисты, Ленин ордены кавалеры Габдулла Шамуковның шагыйрьләргә тиң иҗаты татар театры тарихы битләрендә аерым урын били. Картая белмәс бу иҗади шәхеснең театр сәнгатебез тарихында кабатланмас олы урыны бар.

**ДАНИЯ ГЫЙМРАНОВА.**

# ТАУЛАРДАГЫ КАЙТАВАЗ

ДАГСТАН ХАЛЫКЛАРЫ ИҖАТЫННАН

## Кем эше булыр?

— Җәләлетдин, кичә минем каравыл өен кереп актарганнар? Кем эше булыр икән?

— Әллә мылтыгыңны урлаганнармы?

— Юк.

— Алайса минем улым түгел.

## Дөрес сүз

— Гомереңдә ичмаса бер генә мәртәбә булса да дөрес сүз әйткәнең бармы синең? — дип сорыйлар Захардан.

— Әгәр «бар» дисәм, бу сүзем ялган булыр иде, — ди ул тыныч кына.

## Яңа кием

— Синең оныгың атна саен күлмәк алмаштыра, — диләр Абдуллага.

— Күрәсең, ул яңа киемне чиста тоталмый торгандыр,— дип аклана карт.

## Телләр турында

Комык Абдул-Вәһаб берчакны Лак аулы кешесе Абдуллага сорау бирә:

— Синең хатының комыкча беләме?

— Әгәр лак телен дә белмәсә тагын да яхшырак булыр иде...

## Иң кыска юл

— Җәләлетдин, зиратка иң кыска юл каян уза монда?

— Әнә тегеннәнрәк, Әхмәт эчемлекләр сата торган кибет яныннан.

## Хәлләре шәптән түгел

Сайдун җәй көне аулга кунакка кайта һәм шунда йөзьяшәр карт белән күрешә.

— Хәлләр ничек, Супи-Мөхәммәт бабай?

— Шәптән түгел, улым.

— Ник алай?

— Бер тешем селкенә башлады.

## Тишек туфли

Сайдун аулга иң модалы, иң матур босоножки киеп кайткан. Супи-Мөхәммәт карт шуның каешларына җентекләп карап тора-тора да әйтә:

— Үзең болай бик әйбәт егет күренәсең, әтиең дә рәтле кешеләрдән иде, ә син ничек соң болай аулга яхшырак бер туфли дә киеп кайталмадың? Кертеп калдыр булмаса миңа бу чарыкларыңны, бәлки, тишек җирләрен ямаштыра алырмын.

## Гайбәттән курку

Йөзьяшәр Супи-Мөхәммәт кинәттән сырхаулый башлагач, әле туксан гына яшьтәге күршесе Зубайриҗәт ханым аның хәлен белергә керә. Чирләгән кеше аңа үпкә белдерә икән:

— Оятыңа көч килмәдеме соң? Бер атна буе инде түшәктә ятам, ә син юк та юк. Шул да булдымы күршелек?

— Күптән кергән булыр идем дә, Супиҗан, курыктым шул, аул буйлап хәбәр таралыр, хатын башы белән ялгызак ир янына йөри дип гайбәт сатулары бар дип курыктым.

## Хәбәрне аңламаган

Күршесе Шахмарданны Заһиди туйга чакыра. Гаҗәпкә каршы, тегесе мәҗлескә килми.

Чакыру кәгазе аңа машинкада сугып җибәрелгән булган икән.

— Уйлап тапканнар ничек хәбәр итәргә... Өй түбәсенә менеп бер кычкырган булсалар, җитмәс идеме?!.

## Үкенече бер генә

Кәеф-сафа корып утырганда бик каты төчкергәч, Габделлатыйп бабайның протез тешләре җиргә төшеп китә. Шуны бер көчек эләктереп ала да чаба икән.

— Протез өчен кайгырган юк! — ди бабай, — аның яңасын да эшләтеп була, тик менә бүген Рамазанның хинкалын ашап булмавы үкенечкә калачак — ул бит мине кичке ашка чакырган иде.

## Менә дигән оста

— Гамзат, сездә оста ташчы юкмы?

— Безнең Газилов менә дигән оста. Аулда ул салган алты өйнең өчәве генә ишелде әле.

## Кәкре канау

— Минкаил, бакчаңа канауны ник туры итеп казымадың?
— Беләсеңме, дус кеше, канау казыганда биредә күршем Гасанның арбасы тора иде. Аның шул арбаны урыныннан һич кузгатмасын яхшы белгәнгә, канауны бераз борыбрак казырга туры килде.

## Бер сүз

— Дибир, ник син минем туйда булмадың?
— Бер сүзеңне ишеттермәдең ич?..
— Нинди сүз ул?
— «Кил» дию булмады.

## Кияү кебек

Усманның күршесе бер көнне аңардан сорый икән:
— Синең үгезең чирләгән иде бит, хәзер хәле ничек соң?
— Минем үгеземнең хәле, бик беләсең килсә, синең тол кызыңа йортка кергән кияү хәленнән һич тә начар түгел.

## Өмә күрдем

Мохтар Махачкаладан кайта.
— Я, сөйләп җибәр әле, калада нинди яңалыклар бар?
— Якшәмбе өмәсе булды. Шунда мин бер оешма хезмәткәрләренең агач төпләрен, шулар белән беррәттән телеграмм баганалары төбен дә өйгәнен күрдем.

## Ай яктысы кимеми

Карт Осман улына сорау бирә:
— Менә айга арбалар, ракеталар җибәрә башладылар. Бу куркыныч түгелме соң? Айның яктысы кимемәсме?
— Юк, әлбәттә, кимемәс.
— Алайса бик яхшы. Юкса, үзара гына әйткәндә, мин кай төннәрне, председательдән яшереп, ай яктысында үз ындырыбызны сукалыйм бит.

## Тәҗрибәле тегермәнче

— Җәләлетдин, сезнең аулда тәҗрибәле тегермәнче юкмы? Без дә үзебезгә тегермән салмакчы идек.
— Әнә безнең председателебез иң тәҗрибәле тегермәнче инде: аның әтисе авылда беренче тегермәнне салган иде, ә ул үзе аулның соңгы тегермәнен җимертте.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ИҖАТ КОЛЛЕКТИВЛАРЫ ПАРТОЕШМАЛАРЫНДА

Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды. Отчет доклады белән партия оешмасы секретаре Ринат Мөхәммәдиев чыкты. Ул язучыларыбызның КПССның XXVI съезды карарларын тормышка ашыруга кертkән өлешләре, әдәбиятыбызның бүгенгесе һәм алдагы бурычлары турындагы мәсьәләләргә киң тукталды. Доклад буенча фикер алышуларда Р. Мостафин, Д. Вәлиев, Т. Миңнуллин, Ф. Миңнуллин, Р. Миңнуллин, М. Садри, Ә. Гаффар, Б. Камалов, С. Садыйкова, Г. Латыйп, Р. Хафизова, М. Хәбибуллин, М. Маликова, Г. Ахунов, партиянең Бауман район комитетының икенче секретаре Ф. Габидуллин катнаштылар.

Яңа партбюрога С. Хәким, Г. Ахунов, Г. Паушкин, И. Юзеев, В. Ихсанова, Р. Мөхәммәдиев, Р. Низамиев иптәшләр сайланды.

Язучылар союзы партия оешмасы секретаре итеп яңадан Р. Мөхәммәдиев сайланды.

* * *

Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды. Анда отчет доклады белән партоешма секретаре Н. Дунаев чыкты. Ул иҗат коллективының совет кешеләренә идея-эстетик тәрбия бирү юнәлешендәге эшчәнлегенә һәм бу уңайдан әдәбият-сәнгать эшлеклеләре алдына КПССның XXVI съезды куйган бурычларга киң тукталды.

Доклад буенча фикер алышуда СССРның халык артисты Ш. Биктимеров, РСФСРның халык артистлары Р. Җиһаншина, М. Сәлимҗанов, ТАССРның халык артисты Һ. Солтанов, артист Ш. Барыев һ. б. катнашты. Алар театр репертуарын идея-тематик яктан баету, артистларның осталыгын күтәрү, театр белән тамашачы арасындагы элемтәне тагын да ныгыту һ. б. мәсьәләләр уңаеннан үзләренең фикер һәм теләкләре белән уртаклаштылар.

Отчет-сайлау җыелышында КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин чыгыш ясады.

## «КАЗАН УТЛАРЫ»Н ТИКШЕРҮ

Татарстан Язучылар союзы идарәсе үз органы булган «Казан утлары» журналын һәрвакыт игътибар үзәгендә тота. Менә октябрь аенда союз идарәсенең «Казан утлары»нда басылган әсәрләрне тикшерүгә багышланган зур җыелышы булып узды. Анда сүз 1981 елгы 1—6 саннар турында барды.

Тәнкыйтьче Э. Нигъмәтуллин быелгы ярты елда басылган проза әсәрләре, яшь тәнкыйтьче Ф. Зөлкарнәев поэзия, филология фәннәре кандидаты А. Яхин әдәби тәнкыйть, Р. Максудов публицистика турында сөйләделәр.

Фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, язучылар Т. Миңнуллин, М. Хәбибуллин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Мостафин, Ф. Хөсни, М. Вәлиев, А. Расих, Г. Иделле һ. б. иптәшләр катнашты.

## БӨТЕНСОЮЗ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Казанда Бөтенсоюз фәнни конференциясе булды. Ул СССР халыклары культураларының үзара йогынтысы һәм үзара баетышуы мәсьәләләренә багышланды.

Конференцияне «СССРда социалистик һәм коммунистик төзелеш тарихы» гыйльми советы, СССР фәннәр академиясенең СССР тарихы институты, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты, Казан дәүләт педагогия институты оештырды. Конференциянең пленар утырышларында, секцияләрдә Мәскәү, Казан, Уфа, Фрунзе, Саранск, Ижевск, Чабаксар, Алабуга галимнәренең йөздән артык доклады һәм чыгышы тыңланды.

Бөтенсоюз фәнни конференциясендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин чыгыш ясады.

Бөтенсоюз конференциясендә катнашучылар В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының Ленин мемориалында булдылар.

## РӨСТӘМ ЯХИНГА 60 ЯШЬ

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында РСФСРның халык артисты, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты композитор Рөстәм Яхинга 60 яшь тулуга багышланган юбилей кичәсе булды. Юбилей кичәсе президиумында — ТАССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов, КПСС өлкә комитеты секретарьлары В. С. Дергунов, М. Ф. Вәлиев, КПССның Казан шәһәр ко-

митеты беренче секретаре М. К. Рәмиев, партия, совет, комсомол һәм профсоюз оешмалары җитәкче работниклары, республика иҗат оешмалары һәм производство коллективлары вәкилләре.
Кичәне ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе М. З. Яруллин ачты. Р. М. Яхин иҗаты турында сәнгать фәннәре кандидаты И. Н. Исәнбәт сөйләде.
Юбилярны ТАССР культура министры И. Н. Алиев, халык депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитеты секретаре Л. Г. Космылина, ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе урынбасары Б. Мулюков, Азербайҗан Композиторлар союзы идарәсе вәкиле М. А. Мирзоев, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Әхунов, Татарстан мех производство берләшмәсе генераль директоры Н. С. Рәхимов, Казан культура институты ректоры Р. А. Шәмсетдинова, Ташкент консерваториясе доценты Г. Г. Сабитов, халык депутатларының Түбән Кама шәһәр Советы башкарма комитеты председателе урынбасары Н. Ф. Буханова һәм башкалар кайнар котладылар.
Соңыннан сәнгать осталарының композитор Р. М. Яхин әсәрләреннән төзелгән концерты булды.

## ТӘНКЫЙТЬЧЕНЕҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

21 октябрьда Актерлар йортында язучы һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафинның иҗат кичәсе булды. Ул Татарстан Язучылар союзы һәм республика китап сөючеләр җәмгыяте тарафыннан оештырылды.
Кичәне язучы Роберт Батулла ачып җибәрде. Аннары Рафаэль Мостафин белән залда утыручылар арасында әңгәмә башланды. Кичә сорау-җавап формасында алып барылды.
Р. Мостафин Советлар Союзы Герое, патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең һәм аның иптәшләренең фашистларга каршы көрәшен өйрәнүдәге тәҗрибәсе, бу өлкәдәге яңа ачышлары турында сөйләде, иҗат планнары белән уртаклашты.

## ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Чаллы Язучылар оешмасының чираттагы җыелышы булып узды. Оешманың җаваплы секретаре Разил Вәлиев язучының җәмгыятьтә тоткан урыны, гражданлык бурычлары һәм иҗади активлыгы, язучы шәхесе, әдәби әсәр геройлары белән тормыш геройлары арасындагы бәйләнешләр турында сөйләде, ике җыелыш арасында эшләнгән эшләр белән таныштырып үтте.
Җыелышның икенче өлешендә шагыйрь Ямаш Игәнәйнең иҗат отчеты тыңланды. Докладчы Нәҗип Мадъяров шагыйрь иҗатының үзенчәлекле якларына тукталды, кимчелекле якларын әйтеп узды. Фикер алышуда язучылар Разил Вәлиев, Эдуард Касыймов, Кадыйр Сибгатуллин, Тәлгат Галиуллин, Рахмай Хисмәтуллин, филология фәннәре кандидаты Әнвәр Шәрипов катнаштылар.
Ямаш Игәнәй СССР Язучылар союзы членлыгына тәкъдим ителде.

*
* *

РСФСР Язучылар союзы идарәсенең карары белән Чаллы Язучылар оешмасы каршында әдәбиятны пропагандалау бюросы ачылды. Аның җитәкчесе итеп язучы Газиз Кашапов билгеләнде. Яңа бюро Чаллы, Түбән Кама, Минзәлә, Зәй, Әлмәт шәһәрләре, Алабуга, Сарман, Азнакай һәм Кама буеның башка районнарында хезмәт күрсәтәчәк.

*
* *

Чаллы Язучылар оешмасы Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрендә Г. Тукай премиясе лауреатлары шагыйрь Шәүкәт Галиев белән шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеев иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичәләр уздырды.
Шыгрым тулы залларда үткән бу кичәләрдә «Энергетик» һәм «КамАЗ» культура сарайларының үзешчән сәнгать осталары, үзешчән композиторлар, вокаль ансамбльләр, Чаллы шагыйрьләре катнашты.
Шәүкәт Галиев һәм Илдар Юзеев үзләренең шигырьләрен укыдылар, тамашачыларның күп санлы сорауларына җавап бирделәр.
Мондый кичәләр «Чаллыда очрашулар» исеме астында киләчәктә дә оештырылачак.

*
* *

«Энергетик» культура сараенда «Ләйсән» әдәби берләшмәсенең отчет-сайлау җыелышы булды. «Иҗтимагый тормыш активлыгыннан — иҗади активлылыкка!» — дигән отчет доклады белән берләшмә бюросы җитәкчесе Газиз Кашапов чыкты.
Фикер алышуларда катнашкан Кадыйр Сибгатуллин, Мансур Сафин, Хәниф Хөснуллин, Равил Лотфуллин, Әнвәр Шәрипов, Рафис Сәлимҗанов, Әгния Сабирова, Рәйсә Фәхразыева, Венера Хәбибрахманова, Чаллы Язучылар оешмасының җаваплы секретаре Разил Вәлиев берләшмә членнарының иҗат активлыгын үстерү, КамАЗ темасына тагын да игътибарлырак булу турында сөйләделәр.
Җыелышта берләшмәнең җитәкчесе итеп Газиз Кашапов сайланды.

*
* *

«КамАЗ» культура йортында «Орфей» әдәби берләшмәсенең отчет-сайлау җыелышы булды. Еллык эшкә отчет белән берләшмә җитәкчесе Николай Алешков чыкты. Фикер алышуда А. Чурбанов һәм М. Сафин СССР Язучыларының VII съезды карарларын үтәү буенча берләшмә алдында торган бурычларга тукталдылар. Чаллы Язучылар оешмасының җаваплы секретаре Разил Вәлиев, Казаннан килгән кунаклар — шагыйрь-тәрҗемәче Николай Беляев һәм прозаик Роберт Батулла берләшмә эшен яхшырту буенча файдалы киңәшләр бирделәр.

Җыелыш «Орфей» әдәби берләшмәсенең яңа бюросы составын сайлады.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

Октябрь аенда Чаллы шәһәрендә Минзәлә театрының гастрольләре булды. Театрның КамАЗ эшчеләре, Чаллы төзүчеләре алдындагы иҗади отчеты уңышлы үтте. Театр коллективы белән иҗади дуслыкны тагын да ныгыту һәм аның эшенә бәя бирү, алдагы планнары белән танышу өчен Чаллыга драматург Аяз Гыйләҗев, Рөстәм Мингалимов һәм бер төркем театр белгечләре килгән иде. Шәһәрнең «Энергетик» культура сараенда театр коллективы эшенә җентекле анализ ясалды.

* * *

Октябрь аенда шагыйрьләр секциясенең чираттагы утырышы булды. Анда секциянең соңгы өч ел эчендәге эше турында отчет белән шагыйрь Рәдиф Гатауллин чыкты. Чыгыш ясаучылардан Татарстан Язучылар союзы председателе Г. Ахунов, тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин, шагыйрьләр И. Юзеев, М. Садри секциянең эшен яхшы яктан билгеләп үттеләр, алда торган бурычлар, мәсьәләләр турында сөйләп, кызыклы тәкъдимнәр керттеләр.

1981 елда басылып чыккан шигъри китаплар — Ш. Маннапов, Ф. Гыйззәтуллина, Я. Игәнәй, Р. Рәкыйпов китаплары — аларга хас үзенчәлекләр турында кызыклы күзәтүләр белән яшь шагыйрьләр Рашат Низамиев, Хәйдәр Гайнетдинов, тәнкыйтьчеләр Салих Маннапов, Фәиз Зөлкарнәев чыкты.

Утырышта секциянең С. Хәким, И. Юзеев, Ә. Баянов, Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин (председатель), Р. Мингалимов (урынбасар), Зөлфәт, Ф. Сафин, Р. Низамиев, Ф. Гыйззәтуллина составындагы яңа бюросы сайланды.

* * *

Казан дәүләт университетында эшләп килгән «Әллүки» әдәбият берләшмәсендә шагыйрьләр Р. Гатауллин һәм Р. Миңнуллин кунакта булдылар. Алар үзләре эшләгән «Казан утлары» журналында басылачак яңа әсәрләр турында сөйләделәр, үз шигырьләрен укыдылар, студентларның күп санлы сорауларына җавап бирделәр.

Очрашуда язучы М. Мәһдиев һәм әдәбият белгече Х. Миннегулов катнашты.

* * *

Октябрь аенда Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе Буа районында язучы Фаил Шәфигуллинның иҗат кичәләрен үткәрде.

Колхозларның, заводларның культура сарайларында, мәктәп-училищеларда зур уңыш белән узган бу кичәләрдә нәфис сүз остасы Рәшит Сабиров авторның юмористик хикәяләрен укыды, җырчы Алчәчәк Исламова һәм баянчы Фәнис Гыйльметдинов Ф. Шәфигуллин сүзләренә язылган җырларны башкардылар.

Очрашуларда автор үзе дә катнашты.

* * *

Язучылар союзының Г. Тукай исемендәге клубында шагыйрә Флера Гыйззәтуллина иҗатына багышланган кичә булды. Шагыйрәнең иҗаты турында кереш сүз белән язучы Кояш Тимбикова чыкты. Аннан соң сүз авторның үзенә бирелде, ул яңа шигырьләрен укыды.

Кичәнең музыкаль өлешендә шагыйрә сүзләренә композиторлар С. Садыйкова, А. Имаев, Ә. Шәрәфиев иҗат иткән җырлар яңгырады.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен «Советская Татария» газетасы фотокорреспонденты Әсрар Шакирҗанович Шакирҗановка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1981 ел, 2 ноябрь Указы нигезендә, «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен түбәндәге иптәшләргә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1981 ел, 2 ноябрь Указы нигезендә, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде:

Әскәрова Фирдәвес Каюмовна — Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры артисткасы.

Нуруллина Фидания Нургаязовна — Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры артисткасы.

Сәлахов Расимҗан Салихҗанович — Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры артисты.

## АВТОРЛАР ИГЪТИБАРЫНА

Редакциягә бары тик машинкада басылган кулъязмаларның беренче нөсхәләре генә кабул ителә. Әсәрләр 210×297 мм лы форматтагы ак кәгазьгә кара төстәге тасма аша ике интервал калдырып басылырга тиеш.

Бер биттә иң күбе — 30 юл, һәр юлда — бары тик 60 (сүз араларын да исәпләп) тамга була.

Кәгазь битендә сулдан — 25 мм, өстән — 20 мм, уң яктан — 10 мм, астан 25 мм чиста ара калдырыла.

Әсәрнең исеме һәм бүлек исемнәре төп тексттан астан да, өстән дә өчәр интервал белән аерыла.

Кызыл юл өч хәреф урыны кадәр бушлык белән ясала.

Күләме ун биттән арткан кулъязмалар ике экземпляр җибәрелергә тиеш.

Редколлегия таләпләренә җавап бирә алмаган һәм шунлыктан журналда басылмаячак кулъязмалар анализланмый, рецензияләнми, авторга кире кайтарылмый.

Редакция

## КИЛӘСЕ САНДА:

Проза.

**АТИЛЛА РАСИХ. Ямашев.** Роман.

Поэзия.

**НУРИ АРСЛАНОВ. Уналты гына икән.**
**НӘБИ ДӘҮЛИ. Ветеран йоклый алмый.**

Очерк һәм публицистика.

Әдәби тәнкыйть.

**ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН. Заман һәм повесть.**
**САЛИХ МАННАПОВ. Дөньяның кыл уртасында.**

Рубрикалар: «Безнең календарь», «Китап күзәтү», «Халык иҗаты», «Культурабыз тарихына», «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары».

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)** ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал, орган Союза писателей Татарии

Индекс 73210